www.kazanutlary.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

*ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*

Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Илдус ГЫЙЛӘҖЕВ. Чын исемен тарих саклаган. *Шигырьләр*. ....3
Ркаил ЗӘЙДУЛЛА. *Хикәяләр*. ....7
Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА. Тарих борылмаган еллар юк. *Шигырьләр*. ....51
Җәүдәт ДӘРЗАМАН. Төшләремә кереп сагындыра. *Шигырьләр*. ....108
Георгий ИБУШЕВ. Читтә өзгәләнгәч аңлыйсың. *Шигырьләр*. ....113

ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ

Юныс САФИУЛЛИН. Йосыф һәм Зөләйха. *Мюзикл*. .... 55

*«Иң шәп хикәя» конкурсына:* Ралия КӘРИМОВА. Майра. *Фантастик хикәя.* ....111

*100нче бит:* Нажар НӘҖМИ. Татар теле. ....100

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Кайсын КУЛИЕВ. Мин җырладым яшәү турында. *Шигырьләр*. *(Рафис Корбанның кереш сүзе белән)*. ....116

«ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ»

Хак тарихны кайтару юлында. *(Д.Исхаков, Ф.Хуҗин, И.Заһидуллин, Җ.Мөхәммәтшин, И.Ибраһимов, Р.Ханнанов, К.Кәримов, В.Имамов катнашында)*. .... 120

ГАМЬЛЕ ӘҢГӘМӘ

Халкыбыз яшәгәндә, сәнгать яшәр! *Сәнгать фәннәре докторы, язучы Мөхәммәтгали АРСЛАНОВ белән Илфак ИБРАҺИМОВ әңгәмәсе*. ....136

ТАРИХ

Лирон ХӘМИДУЛЛИН. Беренче мөфтиләрне биргән төбәк. ....143

*Истәлекләр*: Мәгъсум ХАРИСОВ. Укытучы иртә чалара. ....160

*Әдәби хәзинәләребез*: Зәки ВӘЛИДИ ТУГАН. *Хатирәләр*. ....168

СӘНГАТЬ

Мөхәммәтгали АРСЛАНОВ. Зыялы режиссёр иҗаты. *(Празат Исәнбәтнең тууына 90 ел)*. ....178
Гөлзадә БӘЙРӘМОВА. Тормыш чынбарлыгы. *(Юныс Сафиуллинга 70 яшь)*. ....182
Гөлзадә БӘЙРӘМОВА. Тугрылык. *(Рәшидә Җиһаншинаның тууына 100 ел)*. ....185

Бөтендөнья татар конгрессының VI съезды резолюциясе. ....186

Халык бердәмлегендә – милләтнең көче! Татар халкына Бөтендөнья татар конгрессының VI корылтаеннан мөрәҗәгать. ....189

«Казан утлары» архивыннан. ....134
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

Гамәлгә куючы –
«Татмедиа»
акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Илфак Мирза улы**
**ИБРАҺИМОВ**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Рәдиф Җамалетдинов**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Зиннур Мансуров**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Вакыйф Нуриев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Данил Салихов**
**Айрат Сибагатуллин**
**Энгель Фәттахов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Рәфикъ Юныс**

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлзадә Бәйрәмова, Фәнил Гыйләҗев, Камил Кәримов, Ләйсән Солтанова, Рәфикъ Юныс.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Наил Кадыйров.**
*Сайт мөхәррире:* **Рәзилә Хәйретдинова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Люция Сөләйманова** (баш бухгалтер).

✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир – 222-05-50 (өст. 1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1266).*
: **Факс** – (843) *222-09-83 (өст.1612).*

: **E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 29.09.2017, график буенча 29.09.2017.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ А-2339. Тираж 4050.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекслар: 73210 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен), П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), 16262 (Татарстаннан читтәге юридик затлар өчен), П2368 (Татарстандагы юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2017 ел



Илдус
Гыйләҗев

# ЧЫН ИСЕМЕН ТАРИХ САКЛАГАН

## Беркем дә онытылмый!

Брест крепостенең тарихында
Сокланырлык мисал күрәсең:
Һушын югалтканчы  бирелмәгән
Гаврилов-майор керәшен.
Вәхшиләргә Ходай Тәгаләнең
Бәддогасы төшсен, каргышы.
Бозга катырып та, сатылмаган
Татар генералы Карбышев.
Чара беткәч, дошман ут ноктасын
Үз гәүдәсе белән каплаган
Матросов – безнең Мөхәммәтҗан!
Чын исемен тарих саклаган.
Шәхси атаманы бозып кына
Батырлыкның төшми кыймммәте.
Зур хәрефләр белән язу тиеш
Шундый уллар биргән милләтне!

## Өзелмәс бәйлелек

Җырчы җырчы булаламы,
Тыңлаучысы булмаса?
Язучылар кемгә кирәк,
Укучысы калмаса?
Театр, кино юкка чыгар,
Тамашачы килмәсә.
Рәсем ясау нигә хаҗәт,
Кеше кереп күрмәсә?
Иҗатчыны олылаучы,
Үстерүче – халкыбыз!
Без дә аны кадерләргә,
Яшәтергә хаклыбыз!

---

Илдус ГЫЙЛӘҖЕВ (1946) – *шагыйрь; «Җир китабы», «Мәгарә», «Кадерле китап» һ.б. китаплар авторы. Һ.Такташ исемендәге әдәби премия лауреаты. Азнакай районында яши.*

## Бәлки, аңларлар иде

*Дай свободу другим,*
*и ты обретёшь её сам.*
Борынгы әйтем

Камчаткадан Кырымгача
Озын тукыма сузып,
Язып карыйк шул сүзләрне,
Калын хәрефләр сызып!

## Безгә сугылган тамга

Даталарның төрлесе бар,
Иң каһәрлесе – минеке.
Язмышыма уелган сан:
Бер мең биш йөз илле ике.
Идел-йортым таркалган ел,
Илем хәзер читләрнеке.
...Бүтәннәргә сабак булсын
Бер мең биш йөз илле ике!

## Илаһи өчлек

Өч сүз беләм мине җирдә
Дөрес яшәтә торган.
Мин аларны дога итеп
Көн дә кабатлап торам:
Кешеләргә – мәрхәмәт!
Гашыйкларга – мәхәббәт!!
Диндарларга – Мөхәммәд!!!

## Нигә аңламыйлар?

*В России всегда было*
*стыдно быть богатым.*
Олигархлар сүзе

Безнең телгә күчергәндә
Аңлашыладыр күбрәк:
Байлыкны бит, талап түгел,
Эшләп тупларга кирәк!

## Бетү тамашасы

Пәрдәнең алгы ягында
Чибәр кызлар такмак сүтә.
Куллар чабып куанабыз:
Татар яши, сәнгать үсә.

Пәрдәнең арткы ягында,
Туксан төрле сәбәп табып,
Чиста татар авылыннан
Түрә кайта мәктәп ябып...

## Шишаралар эзлим

*Клиндерләр эзлим, клиндерләр.*
С.Хәким

Калды микән әле авылларда
Бәрәкәтле бәйрәм ясаучылар:
Утын ягып, мич төбенә салып,
Өйдә пешкән ипи ашаучылар?
Сагындыра бик еш әле генә
Мичтән алган күмәч-шишараның
Пешә-пешә әни өзеп биргән
Кыерчыгын тәмләп ашаганым.
Кибет ипиенең тәме башка,
Колмак исе ташлап киткәндерме?!
Әллә кайнар «кибән башы» ашап,
Авыз суым кибеп беткәндерме...

## Телнең ачылу яше

Тәнкыйтьләргә кушмадылар,
Баса, тыя килделәр.
«Эш бирмәсләр, күтәрмәсләр,
Тел күрсәтмә», – диделәр.
Кимчелекне фаш итмәгәч,
Яхшырмады дөньясы.
Ризасызлык бит югыйсә
Алгарышның догасы.
Үсәсем юк, эш кирәкми,
Ярсуларым басылды.
Ни уйласам, шуны сөйлим,
Җитмештә тел ачылды...

## Гомер бакчасында

Соң арада аякларым
Авырайды әллә нидән.
Өч төп бәрәңге казырга
Килми хәзер хәлләреннән.
Кая китте чүгә-калка
Биеп йөргән вакытларым.
Тыпыр-тыпыр сыный идек
Сәхнәләрнең сайгакларын.

Тәпи-тәпи күпме уздык
Басу, авыл юлларыннан,
Көч-гайрәтем туксангача
Җитәр дипме уйланылган?
Юк икән шул...Чутлап кына
Салынган ул йөрәгеңә.
...Зур бакчага карап торам,
Таяндым да көрәгемә...

## Сатылып кына...

Сизмәдем дә үзем, кай арада
Юешләнеп беткән күз төбем.
Бер сәбәпсез генә агып чыккан,
Сөртеп алдым «хәсрәт бөртеген».
Елар чакта тыеп калынгандыр...
Олыгайдым шул, тапкан барыр юл.
...Чыгасы яшь озак елдан соң да
Чыга икән, чыга барыбер...

## Күркәм гадәтләр


Сине бик тә кырыс, диләр,
Зәһәр диләр, усал.
Шулай кирәк, таптыйлар ич
«Мәми авыз» булсаң.
Сине бик тә гарьчел, диләр.
Рәхәтләнеп гарьлән.
Андый холык саклап калыр
Бинахактан, әрдән.
Сине бик тә көнчел, диләр.
Сәбәп булса, көнләш.
Тик тәртәне сындырганчы
Акыл белән киңәш.
Сине бик тә саран, диләр.
Хуплыйм, бигрәк әйбәт.
Сараннарга беркайчан да
Йокмый начар гайбәт.
Ул гадәтләр читтә кирәк,
Өйдә артып китә.
Минем янда күндәм булсаң,
Миңа бик тә җитә...

## Коры куаныч

Кайберәүләр, бәлки, белмиләрдер,
Эчмичә дә була исереп.
Гашыйк булсаң, күңел исәрләнә,
Тәэсире зур сөю хисенең.
Уйларыңны тарта югарыга,
Канат куеп, җанны җилкетә.
...Ә мин күптән җирдән аерылмыйм,
Айнык йөрүләргә ни җитә...

## Өмет

Кышкы ботинкаларымны
Юып, сөртеп, корытып,
Тартмаларга урнаштырдым,
Бар дөньямны онытып.
Күңелемдә сорау калка,
Белмим нәрсә дияргә:
Насыйп итәр микән Ходай
Тагын бер кыш кияргә?!



Ркаил
Зәйдулла

# ХИКӘЯЛӘР

## Кырымга китү

Ишек шакыдылар. Дөресрәге, кемдер сак кына тибеп карады. Мин җитди урында эшләмим, гәҗит идарәсе генә – кергәндә артык тәкәллефләнеп тормыйлар бирдә, шакучы юк та юк инде, ишекне каерып ачалар йә тибеп керәләр; йөзләрендә кырыс таләпчәнлек: син кем әле монда, янәсе, син монда бер кәгазь көясе генә, көя! Син һәркемне елмаеп каршы алырга тиеш, йомышын тыңларга, юатырга, нидер юнәтергә... Мин ул заманда авыл хуҗалыгы бүлегендә эшли идем. Миңа гадәттә кем килә? – авылдагы влач белән риза булмаган гыйсьян җанлы адәмнәр. Алар инде итагать саклап тормый. Ә бу кемсә ишеккә сак кына тибеп карый, типми дә әле, аягы белән кыюсыз гына орына.

– Керегез!

Ишек акрын гына ачылды, бүлмәгә иң башта төсе уңып карарлыгы калмаган, әмма шактый зур букча шуып керде. Мин аңладым: аяк түгел, шул кагылган икән ишеккә кыяр-кыймас. Ләкин ул ялгыз түгел иде. Озак тоткарланмыйча бераздан букчаның иясе күренде. Инәсенең башмагы! Эт тиресеннән тегелгән йонлач бүреген сул кулы белән калкытып куюыннан ук таныдым мин аны. Сепер татары – күптәнге дустым Пулат бит бу!

Авызны ачтым да катып калдым. Аны бит үлгән дигәннәр иде! Биш ел элек үк... Үлеп ике ай үткәч кенә Төмәндәге фатирыннан табып алганнар, дип сөйләделәр. Ялгыз яши иде ул, инде сөяркәсе дә берәү генә калган – илледән узгач соң... Югалып торуы да гайре табигый түгел, юлда йөрергә ярата иде мәрхүм (мәрхүм дә дип әйтеп булмый бит әле!) – бүген Төмәндә, иртәгә Мәскәүдә, бер атнадан инде әллә кайдагы Төньяк котыпта... Гомерлек биләмче, төзәлмәс сәях! Ике ай бернинди хәбәре булмагач, сөяркәсе дә борчыла башлаган, мөгаен; фатир ишеген җимереп керсәләр, ул кухня идәнендә ята икән. Ул – ул түгел, Мәңгелек сәфәргә киткән мумия!

Бөтен Төмәнне ду китереп җирләгәннәр мумияне. Себер татар әдәбиятының Тукае дип игълан иткәннәр үзен. Барлык язганнарын бергә җыйгач, Себердә табылган фольклор әсәрләрен дә шунда кушып, Пулат хакындагы истәлекләр

---

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА (1962) – *шагыйрь, прозаик, драматург; «Мәгарә», «Ташка ордым башны», «Саташкан сандугач» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

белән сипләгәч, саллы гына китап та килеп чыккан. Сепер татарлары бүтән татарлардан аерым халык, аларның үз әдәбияты бар, дип берәү әлеге китап нигезендә диссертация яклап доктор да булган, имеш. Мәскәүгә чакырып, ниндидер мидал да такканнар түшенә.

Шулай шаулап, өр-яңа милләт туу шатлыгыннан туйлар уздырып, җирләгәннәр теге фатирда табылган җәсәдне... Пулат яши! Пулат безнең белән киләчәккә бара! – дип фейерверк чөйгәннәр. Түмән губернаторы хәтта өч-дүрт туптан залп та бирергә риза булган. Канәгать булып таралганнар шуннан соң Сепер татарлары. Тынычланганнар. Безнең гомум татар гадәте буенча биш ел буена Пулат кабере өстенә таш утыртырга да вакытлары булмаган. Шуңа үпкәләп кабердән чыкмагандыр бит Пулат? Мөмкин хәл түгел безнең заманда. «Могҗизаларны үткән чорларда калдырдык. Пулат яши!» – дип кычкыруларны җитдигә алып булмый ич инде.

Мин үз-үземә ышанмыйча күземне угаладым. Тик ышанмыйча булмый иде, Пулат теп-тере кыяфәттә ашыкмый гына каршыма килеп утырды, каңсасын[1] тимер чыбык белән чистартты да кайдандыр куен кесәсеннән чигелгән янчык тартып чыгарды, учында сикертеп авырлыгын үлчәп карагандай итте. Минем аңгырайган карашымны тотып:

– Сәйнәп пүләге, – диде. – Син пит Тукыз авылында танышкан идең аның пелән. Исеңдәме, пескә пер тырыс торнакүз[2] алып килгән иде. Икенце көнне урманда сиңа арнап озан[3] та атты.

Ул янчыктан вакланган тәмәкене бармак очы белән сак кына алып, каңсасына тутыра башлады. Дәшми-тынмый беравык утыргач, чакматашын чыгарды.

– Монда тартырга ярамый, – дидем мин, кабаланып. Гаҗәпләнүдән Пулатның ике кашы өскә күтәрелде.

– Тәмәке тартмыйца үләң цыгарып пуламы? – дип мыгырданды ул. – Аннары, казанча шивәгә күчәргә кирәк табып: – Шигырь язып буламыни төтен җибәрмичә? – дип кабатлады.

– Шигырь язучы юк хәзер, – дидем мин, кистереп. – Яудагы кебек кырылып бетте барысы. Сине дә бит биш ел элек үк...

– Юк сүз ул, – диде Пулат, мине бүлдереп. – Үлгән кеше Себердән үк килеп синең каршыңда утыра аламы? Каңсамны кабызсам, мин әле бөтенләй дә үлмәгән кебек!

Дөрес әйтә, каршымда нәкъ элекке Пулат иде. Себернең зәһәр җилләрендә кайрыланган кара-кучкыл бите, соры каймалы яшькелт-кара бадәм күзләре, почык борыны шул ук – берни үзгәрмәгән. Чыраенда борынгы татар сагышы. Күчем хан, безнең көннәргә кадәр яшәсә, шундыйрак кыяфәттә булыр иде, мөгаен.

– Мине үлгән тип уйладылар, ә мин Касаннықка кайтып киттем, – диде ул, бөтенләй диярлек әдәби телдә сөйләшә башлады. – Тышчаны калдырдым, нигә ул миңа? Искергән иде инде. – Ул йонлач бүреген салып өстәлгә куйды, торып басты. – Менә хәзергесе ничек? Гырнадир кебек бит, ә? Нәкъ элеккечә.

Мин берни дә аңламыйча аңа текәлдем. Аракы эчкәнгә дә охшамаган. Аек дип тә булмый, әллә ниләр сөйләгәч. Дөрес, ул элек тә сәер иде. Ләкин болай ук түгел. Тышчаны калдырдым, диме? Түмәндәге фатирының кухнясында ике ай ятып мумиягә әверелгән җәсәденме әйтә ул? Аннары телевизордан

[1] Каңса – тәмәке трубкасы.
[2] Торнакүз – мүк җиләге.
[3] Озан – көртлек.

күрсәттеләр – Мәскәүдән! – быел язын Казанлык авылын тоташтан су баскан, беркем котыла алмаган! Ә Мәскәү ул андый хәлләрне хәбәр иткәндә алдамый, гадәттә. Әйе, фаҗига... Һуманитар катастрофа! Тик бер нишләп тә булмый, табигать шундый финтларны күрсәткәләп тора. Борынгылар тикмәгә авылны Казанлык дип атамаган, димәк, андый җирне иртәме-соңмы су басмый калмый.

– Ничек алыштырып була соң тышчаны? – дип сорадым мин, башны тилегә салып. – Искесен ташладың да ди, ә яңасын кайсы кибеттә саталар?

Бүлмәдә эссе иде, Пулат таушалган мутон тунын чиште, тун астындагы свитеры да миңа таныш шикелле булып күренде. Узган гасырның җитмешенче елларында ук, Хемингуэйга охшарга тырышып, икебезгә икене Мәскәүдә сатып алган идек. Шул шатлыктан калган тиеннәргә сыра да эчтек. Ансыз буламыни инде без яшь чакларда. Бераз башына киткәч, Мәскәүнең йөрәгенә басып, Пулат урысча язган бердәнбер шигырен кычкырды:

Я потомок Куцума,<br>
Стою у ЦУМа.<br>
И русским на диво,<br>
Пью ихнее пиво!

Әйе, гаярь егет иде Пулат. Хәзер әнә йончыган шәүлә кебек утыра каршымда. Хемингуэй свитеры гына безнең бәхетле елларны искә төшереп тора сыман. Мин көлеп җибәрдем. Шатлык иде миңа бу свитерны күрү! Вакыт пәрәвезен аралап, Пулатның да йөзеннән мескен елмаю саркып чыккандай булды. Тышчасын алыштырса алыштыргандыр – мондый елмаюны мин хәтерләмим – тик киеме элекке иде Пулатның, иске иде. Анысы күңелгә ошады – яңа кием алырга ул яшь чакта да атлыгып тормады. Андый вак-төяккә акча тоту аның өчен җинаятькә тиң иде.

– Тышча ул вакыты чыккач үзе төшеп кала, ә киемнән арыну кыен, – диде ул, янә фәлсәфә томанына уранып.

– Кая урнашырга булдың? – дип сорадым мин. Әйе, бу чыннан да Пулат! Һәм аны болытлардан гөнаһлы җиргә төшерергә кирәк иде. Әлбәттә, кунакханәләр, кыйммәтле һотелләр аңа төс булмавы, алар тирәсенә якын киләчәктә бармаячагы ерактан күренә. Ә кая куначак? Элегрәк ул буйдак Мингалим дустыбыз фатирында туктала, шунда «Пулат, Пулат кайткан!» – дип ду килеп бәйрәм итә идек. Тик инде Мингалим дә икенче ел Казанда юк, Мәңгелек сәфәрдә вакыты.

Пулат букчасына ымлады: «Палык», – диде. Мин сәгатькә карадым, эш вакыты төкәнеп маташа, һәм, дөресен әйткәндә, эшлисе дә килми, чөнки Пулатны таныгач ук җирдәге һәр эшнең акыл өшерлек мәгънәсезлеккә ия булуын аңлаган кеше аңларлык иде. Бераздан инде без, буранлы Казан урамнарын кичеп, мин яши торган өйгә якынлаштык.

– Шәкә юкка чыкты бит! – диде Пулат, өйгә керер алдыннан. Шәкә Казанлык авылында клуб мөдире иде. Нишләп юкка чыкты икән соң ул? Ләкин өйгә кергәнче Шәкәнең язмышын мин күңелемә бик якын алмадым. Иң әүвәл хатынны күрәсе бар әле. Билгеле, ул бернинди кунак та көтми иде. Тик кунак килмәсенә дә иманы камил булмагандыр. Ара-тирә кунаклар гел килеп тора безгә. Дөресрәге, алар миңа ияреп кайта иде.

Дустымның Себердән үк килүен аңлаткач, кайчандыр бергә нужа күрүебезне дә искә төшергәч, хатын алай-болай сүз әйтмәде тагын, елмайган атлы булып

табын әзерләде, чәй кайнатты. Пулат үзе, алъяпкыч бәйләп, балык чистарта башлады, үз кулы белән тоткан чөгәләрне кыздырырга иде исәбе.

– Шәкә юкка чыкты, дисеңме?

– Әйе, күз алдымда гаип булды. Җир йотты ахрысы.

– Син бүген гел юк сүз сөйлисең!

Пулат, пычагын өстәлгә куеп, урындыкка утырды, җансыз күзләрен почмакка төбәп, шомлы тавыш белән әйтте:

– Шәкә Кырымга китәргә ниятләде.

– Моның нәрсәсе гаҗәп? Кырымда быел алты миллион кеше ял итәчәк, диде әнә телевизор. Бу бит Рәсәйдәге бөтен татар халкы кадәр!

Пулатның күзенә җан иңгәндәй булды. Рәсәйне, дөресрәге, Советлар илен ярата иде ул. Хәтта патриот дисәң дә, бик ялгыш булмас.

– Кырым! Дөрес тартып алдык хахулдан! Ул безнең җир. Шәкәнең дә анда барып урнашасы килде. Урнашыр да иде... тик менә күз алдында юкка чыкты. Юкса, Кырым ул элек-электән ханнар кулында булган.

Пулат үзен Күчем хан нәселеннән саный иде, Шәкә белән алар чыбык очы туганнар, димәк, ул да хан ыруыннан... Әһә, менә бит! Кырымга Себердән дә тарихи дәгъва, кабул ит, мөртәт Украина! Тик Пулат белмидер: Киев кенәзе Владимир, киләчәктә урыслар Кырымны яуласын өчен, ханнарга кадәр үк Херсонеста чукынып куйган! Ә Киев әле ул чакта Украина башкаласы булмаганмы... Фу-у... безнең баш кына җитәрлек түгел монда.

– Әкият ул, – диде Пулат, шаккатмалы – ул минем уемны укый иде. – Әллә ничә гасырдан соң монахлар уйлап тапкан әкият. Елъязмалардагы Владимир – чынлыкта норман конунгы Вальдемар, һәм ул беркайчан да христиан булмаган. Башкисәр, илбасар, әйе, әмма...

Мин аны бүлдердем. Авыл хуҗалыгы буенча белгеч булганга, тарихта сай йөзәм мин, Путинның диңгез култыгында, су астына төшеп, борынгы амфора табып йөргүен дә аңламадым – янәсе бабалары шуннан шәраб эчкән, диюе идеме; аның инде кирәге дә юк – Кырымны кемгә дә барыбер кире бирмәячәк; мине Шәкәнең язмышы ныграк кызыксындыра иде. Ничек ул Пулатның күз алдында юкка чыккан?

– Башкисәрлек христиан булырга да, мөселман булырга да мишәйт итми, – дидем мин, – борынгы заманда әле ул хупланган да.

– Шәкә Кырымга китеп хан булмакчы иде, – диде Пулат, бераз тын торгач.

Мин шаркылдап көлеп җибәрдем. Кыска буйлы, тар җилкәле, кысык күзен калын пыялалы күзлек белән каплаган Шәкәне һич тә хан кыяфәтендә күз алдына китереп булмый иде. Киноларда ханнарны бик куркыныч, әшәке итеп күрсәтәләр бит, ә Шәкәдән табигый итагатьлелек бөркелә, аңа карап нигәдер елмаясы гына килеп тора. Хәер, борынгы ханнарның нинди кыяфәттә булганын хәзер кем белә, бәлки нәкъ Шәкә кебек булганнардыр... Без дә бөтенләй төшеп калганнардан түгел, дигәндәй битараф кына әйтеп куйдым, янәсе, без сез белгәнне күптән киптереп элгән.

– Сез бит Шәйбан нәселеннән, биләмәгез – Күк Урда, Иделнең уң ягына хокукыгыз юк. Анда ханлык итү өчен Гәрәйләр нәселеннән булырга кирәк.

– Гәрәйләр нәселеннән тәхеткә утырырлык кеше калмады, – диде Пулат. – Тарихи миссияне безгә – Күчем хан токымына – үтәргә кала. Шәкә шул юлда гаип булды. Ул Кырым тәхетенә лаеклы кандидат иде. Хәтерлисең бит аны?

Хәтерләмичә!

Егерменче гасырның туксанынчы елы иде булса кирәк. Әлбәттә, милади.

Һижринең әле ни икәнен дә белмибез. Пулат белән «Кысла» сыраханәсендә күрештек. Кремль астындагы әлеге пыяла бинада шагыйрьләр һәм бандитлар, рәссамнар һәм теләнчеләр, көйчеләр һәм йөкчеләр – Казанның бөтен түбән катлавы! – тулып ята, биредә кемне генә очратмыйсың! Иң түрдә, әлбәттә, Ленин портреты янында, кәттәдән дә кәттә булып бармен кукраеп баскан. Ул болай әллә кем дә түгел сыман – тирле кружкаларга күбекле сыра коя, керле тастымал белән кран төбен сөрткәләп ала; ә өстендә крахмалланган ап-ак күлмәк, муенында чем-кара күбәләк, дирижёр таякчыгы тоттырып бүгеннән сәхнәгә чыгарырлык. Бик якын килмә инде син аңа, агайне, мәгарә төбендәге үтә күренмәле су эчендә яткан таш салкынлыгы бөркелә сөмсере коелган битеннән. Һәркем белә – ул совет миллионеры һәм бандитлар арасында абруе зур. Исеме әле дә хәтердә. Мәхмүд! Мин аның белән кул бирешеп күрешә идем көнчел карашлар астында – ай нинди нәфрәтләнеп карый иде миңа шул чакта дус-иш, таныш-белеш. Көнләшү, безнең профессия кешеләренең яшәү рәвеше ул. Әлбәттә, бераздан Мәхмүдне атып үтерделәр. Һәм монда безнең профессия кешеләренең бернинди катнашы да юк иде, билгеле.

Пулат Мәскәүгә китешли Казаныбызга туктыйсы иткән. Кулында ул заманда бик модный нәни чемодан – «дипломат». Килешмәсә дә килешми икән – аю тәпиенә чәнечке кыстырган сыманрак... «Кысла»да сыраны биек түгәрәк өстәл кырында баскан килеш эчешле иде, шуңа Пулат дипломатын, идәнгә куеп, ике аяк арасына кыскан. Аерата мөһим йомыш белән йөрүе икән – Ленинга ходоклар барган төсле, Пулат, Себер татарлары аерым халык булырга тиеш, дигән йөз дә унике имзалы хат-петицияне Кремльгә үз кулы белән тапшырырга дип юлга чыккан. «Төньяк халыкларына вак булган өчен өстәмә льготалар каралган, ә безгә шымытыр!» – диде ул, гарьләнеп.

– Шул хәер-сәдака хакына бездән аерылмакчы буласызмы?

– Надан син, – диде Пулат, үпкәләп. Дулкынлана башласа, ул Себер шивәсенә күчengәләп ала иде: – Тукайны оныттыңмы? Шагыйрь ул общественный деятель дә, политик та пулырга тиеш. Пес пит Мәскәү өчен генә аерылган пулып кыланабыз. Тиздән үләчәк халык, дип, хантыларга, мансиларга биргән кебек, өстәмә акча гына тамызсыннар, без аңа нәшрият, милли университет, зур китапханә!

– Вокзал, – дидем мин, аны бүлдереп.

– Нәстә?

– Аэропорт!

Пулат миңа кулын селтәп сүзен төгәлләде:

– Тагын әллә нәрсәләр ачып бетерәчәкбез! – Ул инде бөтенләй тугарылып, кулын киләчәккә селти иде. – Республика! Сепер Татар Республикасы! Пу пит, пеләсеңме, нинди мөмкинлекләр! И син, надан... – Кинәт ул шып туктады. Аптырап аяк астына карады, аннары миңа рәнҗүле караш ташлады. Мәгълүм ки, кул болгаганда, тел чишелгәндә, җиргә нык басарга теләп аяк та бераз як-якка аерыла, һәм дипломат шул арада бераз үз иркендә калган икән. Әйтәм бит, «Кысла»да бур өстенә бур, алар янында карак, кем генә мондый форсатны кулдан ычкындырсын?! Милләткүләм визит ясарга сәбәп булган хат-петициядән шулай итеп җилләр исте. Пулат елап җибәрде:

– Ницек мин Сепергә катеп күреним?

– Борчылма, – дидем мин, аны юатып. – Монда намуслы бурлар...

Чыннан да, ярты сәгать тә үтмәде, Мәхмүд биш-алты кәгазь бите селкеп кычкырды:

– Кемнең макулатурасы бу?

Пулат ерактан таныды петицияне. Модный дипломатны, әлбәттә, кире кайтармадылар. Әйтәм бит, төс түгел иде ул Пулатка. Килешми иде. Аның өчен иң мөһиме – хат-петициянең югалмавы, ул шуңа кош тоткандай шатланды, бичара. Хәзер инде анык кына хәтерләмим, Пулаттан да соравы уңайсыз – иске ярасына кагылу дип кабул итәргә мөмкин, – Мәскәүдән урадымы ул, юкмы? Урагандыр. Кысыр өмет – татарның ышанычлы юлдашы соңгы гасырларда. Аннары юкны бушка аударып йөрү Пулатның яраткан шөгыле дә иде. Себер Татар Республикасы... Хе!

Шунысы гына истә: бераздан мин аңа ияреп Себергә киттем. Ничә еллар дәвамында Пулат туган иле турында шулкадәр җәелеп сөйләде, мин инде җәннәт бакчаларын нәкъ менә Себердә дип күз алдына китерә башлаган идем. Анда мүк җиләген дә тырмалап кына җыялар, эрбет чикләвеге башка коела, көртлекләр ау мылтыгын үзләре эзләп йөри, суларында балык искиткеч күп – сәнәк белән генә чәнчеп аласы икән. Белмим, нигә элек анда каторгага җибәргәннәрдер дә, нигә татар: «Себер җире – сөрген җире», – дип моңайгандыр. Хәер, «Себер үзебезнеке!» – дип тә җырлаган ул.

Пулат мине әллә кая саз ягындагы Казанлык авылына алып китте. «Цын Сепер татарын күрәсең килсә, алар парысы та ошынта», – диде Пулат. Казанлык җәһәннәм тишегендә, димәсәң инде... тик аңардан якын да түгел, олы җирдән коры юл юк, туңдыргач, чана белән барып була да, җәен су юлы. Боргалак, әлбәттә, теләсә кайчан оча ала, тик бит аңа күпме генә кеше сыя? Шуңа күрә аңа утыру өчен кесәң калын булу кирәк. Ул да көн саен түгел, атнага бер тапкыр гына оча, ерак гасырларда яшәп яткан авылга гәҗит-журналлар, хатлар, посылкалар алып килә. Әле җәй иде, без Пулат белән авылга көймәдә барырга булдык. «Гомер онытмаслык тәэссорат булачак!» – диде ул, күтәренке тавыш белән.

Чыннан да, Агыт суы сурәтләп туймаслык иде! Кыйгачлап төшкән кояш нурларында ул көмеш тәңкәләрен җемелдәтеп гүя чалкан ята, ике як ярдан аңа елак тирәкләр иелгән, офыкка табарак карагачлар төмсәләнеп күренә, дөньяның киңлеген, дәһшәтен бөтен күзәнәкләрең белән тоясың, биредә син бик бәләкәй икән! Шул ук вакытта җиһанның барлык кодрәте, могҗизасы сиңа гына туплангандай тойгы да каядыр ми төпкелләрендә пәйда булып, ялган ләззәт кан тамырларыннан талгын гына ага башлый. Һә-әй! Кичкә таба Агыт суы Олы күлгә кушылды, монда аккошлар, чумга үрдәкләр, су тавыклары йөзеп йөри – көймәгә юл бирергә исләрендә дә юк! – аларны ишкәк белән куа-куа акрын гына каршы якка шуыштык. Ниһаять, аждаһа борынлы юаш көймә, төнбоекларны ерып, ярга килеп туктады. Ярда кипкән балык әрдәнәләре кеше буе – биредә балыкчыларның ун-унбиш йортлы авылы урнашкан икән. Уат идеме соң исеме? Пулатны Себердә һәр татар белә, асыл мәгънәдә кочак җәеп каршы алдылар. Бигрәк тә кызлары. Башына сәүкәлә кигән, озын толымына чулпылар аскан карагат күзле бер кыз, бала итәкле яшел күлмәген чеметеп генә тотып, безгә якынайды. И-их, егетләр! Сез сорамагыз, мин сөйләмим. Казанга назлы килен булып төшкәндә, Сөембикә шундый кыяфәттә булгандыр, валлаһи. Кулны кулга кушырып, без аның белән урманга кереп киттек. «Кайчә! – дидем, – мин монда калам. Балыкчы булам, сунарчы булам». Кайчә көлде, «Калымың күпме? – дип сорады. – Язлык канча палык тотасың?» Чыпчык тезеннән булган балачак инешендә күлмәк белән маймыч сөзгән малай мин... тик монда белмим шул... нинди калым?

Күл буенда җикән камыш,
Күзләрендә сары сагыш.
Калды ярда, кул болгады,
Томанга кереп югалды.

Иртән тагын юлга чыктык. Нәкъ җырдагыча, Кайчә ярда калды, тик кул болгамады. Бер урында баскан килеш каккан казык кебек тора бирде. Нинди уйлар биләде икән аның башын? Әллә табигатьнең садә баласына тирән кичерешләр хас түгелме? Уйласаң, бик гади бит бу дөньяда барысы да – кавышулар, аерылышулар... туу... үлем... Без дә бер сүз эндәшмичә ишкәкләргә ябыштык. Олы күл Җылы күлгә тар гына арык аша кушыла. Арыкны йөз еллар элгәреме, әллә аннан да элегрәк, мондагы бер шәех казыткан, аннан көймә – өч йөз метрлар булыр – ике ярга ышкылып диярлек бара, шуңа бер генә кеше җайлап ишәргә тиеш – мин яр өстеннән атларга булдым. Ә монда сазлык, аякны куярга өлгермисең, ул сасы сулар чыгарып бата да башлый. Анда-монда кәрлә каеннар үсә, мин бер корыган ботакны таяк итеп, түмгәктән түмгәккә сикерә-сикерә, көймә белән янәшә алга омтылдым. Сак атламасаң, батып китүең дә бар, Ходай сакласын...

– Шәкә дә ярдан барасы иде, мин көймәдә калдым... Сазлык йотты бугай үзен – юкка чыкты! – диде Пулат, минем хатирәләрне бүлдереп. Инде мин тәмам ышандым: ул минем уйларны укый белә, күңелемне, иңләп-буйлап, гүя үз көтүлеге иткән иде.

Җылы күлне кичеп, сазлык аша кеше тотарлык түмгәкләргә баса-баса биш-алты чакрым интектергеч юл үткәч, ниһаять, түбәнлектә Казанлык авылы күренде. Монда килеп җиткәнче үк мин Себерне нигә курорт итмәгәннәренә төшендем. Җәннәттә черки булмый! Бөтен башны иңгә кадәр салындырган махсус челтәр белән каплыйсың – әле аңарчы тәнеңне черкигә каршы крем белән сөртеп! – бер генә керер тишек тә юк сыман; әллә кайдан үтеп безелди, авыртуы бер хәл, кычытуына һич чыдар әмәл юк. Бездәге черкинең борыныннан үбеп, соңра һәйкәл куярлык!

Казанлык авылы, эссе кояш астында да өшегән кебек, бөрешеп яткан зур җанварны хәтерләтә иде түбәнлектә. Ул өстән шулай, ә аста, үзендә, авыл тек авыл. Клубының кашагасына «Дворец культуры» дип зур итеп язып куелган. Казанлык та урысча Казанлык түгел, Подберезье булып чыкты. Бик оста тәрҗемә ителгән. Клуб каршындагы озын баганага борынгы кара тәлинкә – радио беркетелеп, аннан Габдулла Рәхимкуловның «Шәйморза» җыры бөтен авыл өстенә яңгырый иде.

Шәкә кысан гына бүлмәдә гәҗит караштырып утыра иде без кергәндә. Исәнләштек. Минем Казаннан ук килүемә аның исе китмәде.

– Казан өчен күңелем тыныч, – диде ул. – Шәйми яхшы идарә итә. Ул... – Бер пыяласы чатнаган күзлеген борын өстенә турылап урнаштыргач, нәтиҗә ясады: – Ни әйтим? Хәйләкәр-р... Чын сәясәтче. Әйе, Казан өчен күңелем тыныч, – дип үз-үзен җөпләде ул. Аннары уйчан кыяфәттә: – Соңгы арада Анголадагы хәлләр борчый әле мине, – диде. – Аугустино Нетто ялгышрак юлдан китте.

– Акыл өйрәтеп кайтыр идең, – дип, Пулат сүзгә кушылды.

– Бармыйча да булмас шул. – Шәкә мышнап җилкә чокырын кашыды. – Менә син Казанның нигә җиңелгәнен беләсеңме? – дип Африкадан тиз генә безгә кайтты ул.

– Аны мең төрле кеше мең дә бер төрле аңлата, – дидем мин, теләмичә генә.

Бәхәскә урын калдырмаслык итеп Шәкә кул чирты белән өстәлгә сугып алды:

– Аның сәбәбе бер генә: башбаштак казаннар безнең Мамук ханны куып җибәргән!

– Әйе, сур ялгыш пулган ул, – дип җөпләде аны Пулат.

Озак утырдык без Шәкә бүлмәсендә.

– Менә ни өчен безнең авыл Казанлык дип атала? – Шәкә имән бармагын өскә чөйде. – Син уйлама уйсу ергә урнашканга дип... Иң әүвәл монда казаннар килеп төпләнгән. Казан җимерелгәч... Казанныклар барысы да авылның үзәгендә яшәде, сәүдәгә хирыслар иде. Аларның инде бүген барысы да Төмәндә... Югары очта – бохарлыклар, анда элек мәчет булган. Бабалары Күчем хан заманында Бохара ханлыгыннан килгән, безне дингә дүндерергә. Хәзер һәммәсе укытучы. Ә без – чын сеперләр – түбән очта, безнең һөнәр – аучылык, балыкчылык. Күчем хан җиңелеп, казаклар кыса башлагач, дала ягыннан сазлык арасына, казаннык кардәшләр янына килеп сыенганбыз.

– Чын сепер булгач, син нигә мондый囗 эштә соң – клубта?

– Каны сыекланган, – диде Пулат, кулын селтәп.

– Ауга чыгам мин кайчакта. – Шәкә, аклангандай, күзлеген рәтләде.

– Әйе, – дип көлде Пулат, – кайсыдыр елны Шәкә аю аулый язды. Кереп киткән бу урманга, мылтык тотып. Биш чакрымнар ары анда ташландык техника мазарлыгы. Шунда Шәкә К-700 тракторы тәгәрмәченең шинын чылатып ята икән. Артында мыш-мыш килгән тавышка борылса-а... Аю бабай үзе! Куркуыннан Шәкә артка чигенә башлаган һәм теге шинның уртасына егылып та төшкән. Бер әйләнгән аю шин тирәли, ике әйләнгән... Ята икән Шәкә калтырап, ау мылтыгын кочаклаган килеш. Кинәт аю танавын җыерган да, Шәкә өстенә төкереп, урманга кереп киткән.

– Бер дә көлке түгел, – диде Шәкә, карасына катып. – Бабай ул шаяртмый. Йөзгә йөз килеп кара әле менә үзе белән, ничегрәк сайрарсың икән?

– Йөзгә йөз дә килгән булды... – дип Пулат урыныннан торды. Мин аңа ышандым – аучылык аның канында иде.

Шәкәнең кәефе кырылды.

– Менә шушы хәлне егерме ел инде мәзәк итеп сөйлиләр, – диде ул, миңа зарлангандай. – Зур тарихи вакыйга инде ул безнең авыл өчен. Монда бит, гадәттә, авыз тутырып сөйләрлек бернәрсә дә булмый. Туалар, яшәп маташалар да үләләр. Тормышмыни бу? Китәргә иде каядыр. Чын-чынлап яшәп алырга иде бер. Юкса тирес корты кебек бит без монда!

Мин, уңайсызланып, тамак кырдым. Себергә романтика эзләп килгән адәм бит үзем дә. Аучылар, балыкчылар турында берәр чын әсәр язып булмасмы дип...

– Сугыш башланмадымы? – дип сорады ул, ялварган тавыш белән.

– Юк әле, ләкин өмет бар, – дидем мин.

Балык чистартудан бүленеп, Пулат тагын хатирәләремә катышты:

– Кырымны тартып алгач, Шәкә яңадан тугандай булды. Салып алгач, гел ура кычкырды, янәсе, Кырым үзебезнеке...

– Эшсезлектән интегә иде ул.

– Юк, ул Казанлыкны тарсынды – масштаб кечкенә, аңа зур эшләр лаек иде. Шуңа да Кырымга җыенды.

– Ул гына җитмәгән ди анда!

– Татарсыз Кырымны терелтеп булмый, – диде Пулат, үз сүзенә нык ышанып. – Татарларны кугач, тәмәке үстерүче дә калмаган бит анда, беләсеңме? Затлы йөзем сортлары юкка чыккан. Ханлык власте урнаштырсак, без Кырымны янә гөлбакча ясыйбыз, Алла теләсә. Әнә Израильдән өч йөз мең яһүд кайтырга тели. Кайтсыннар! Җир эшен яраталар – кибуцалар төзербез далада.

– Урыслар кул чабып торыр, әйеме?

– Алар бит инде без! Телләре генә аерым иде элек. Хәзер инде рәхәтләнеп уртак тел табабыз. Нүгәр[4] булыр кайсысы... Э-эх, Шәкә генә сазлыкта калды менә.

– Ничек батты соң ул?

– Кырымга китәм, дип теңкәне корыткач, көймә белән озатырга булдым аны Олы күлгә кадәр. Арыктан йөзгәндә, икенең берәве сазлыктан атлый бит, үзең дә беләсең. Менә ул да китте йөз тапкыр үткән юлдан. Кем уйлаган аны...

Кыздырылган чөгә исе, авыз суларын китереп, бүлмәгә таралды. Аш астына берәр касә авызга капладык.

– Бәлки, ул батмагандыр? – дидем мин, Пулатның кәефен күтәрергә теләп. – Саубуллашып тормагандыр, бәлки?

– Чыннан да, – дип, Пулат көлеп җибәрде. – Кырымда ятадыр әле, субакы!

Сүзгә сүз ияреп, ут алдырырга да онытып торабыз икән, ярым караңгыда тере Пулат түгел, яшьлектән калган свитер эчендә мумия утыра кебек тоелды бер мизгелдә... Эчке калтыравымны басарга тырышып, сорау бирдем:

– Казанда озак торасыңмы? Аннары кая җыенасың?

Пулатның уч-уч караңгылык оялаган ике күз чокырының төбендә диңгез суы чайпалгандай булды:

– Кая җыенам? Кырымга, әлбәттә! – диде ул, катгый итеп.

## Капка

Әтисе шоп-шома капка баганасын кытыршы учы белән сыйпап торды. Аннан читкә китте. Улына да ымлады: мондарак кил, янәсе.

Самат әтисе янына килеп басты. Читтән яхшырак күренә икән шул... булган бу! Күзен янә ырыс капканы кыйгачлап япкан түбәгә төбәде. Ул аңа капканы каядыр очырып китәргә җыенган җилкән булып күренде. Кара инде – капка үзе еракларга, күк томаннарга уралган серле илләргә алгысынган корабка охшаган түгелме соң?

Әтисе канәгатьләнү кичерә иде, и-их дип, яңагын ышкып алды. Ул гел шулай – күңеле булса, яңагын ышкып тора. Ә бүген ул бик озак кырынды, яңагы шоп-шома, капка баганасы кебек димәсәң инде, менәтерәк...

– Мату-ур... – дип сузды Самат. – Җилкәнле корабка охшаган бит, әти, име...

Әтисе, яратып, улын аркасыннан сөйде.

– Капка тек капка... – Аннары кинәнеп көлеп җибәрде: – Капка капкага охшарга тиеш, улым.

Ишегалдына уздылар. Таш плитә җәелгән бер сукмак зур йортка, икенчесе бакча түренә – алар куна торган җәйге өйгә таба сузылган иде. Тирә-юньдә яшел хәтфә үлән шыпырт искән җилдә акрын гына кайнап ята. Аларны күзәтеп кенә торганмы, зур йортның болдырына бикә чыгып басты. Сары чәчле, яшел күзле, борыны бераз почыграк булса да, килешеп тора үзенә. Һавалы итеп күрсәтә. Шорты кигән, күлмәк изүе ачык...

[4] Нүгәр – дус-иш.

– Кабул итеп алыгыз... Капка әзер, – дип, әтисе болай да киң авызын җәеп елмайды. Самат аңа аптырап карап алды – ничектер бүтәнчә сөйли иде әтисе, бикәгә ярарга тырышамы соң...

– Кабул итүче мин түгел... – Бикә, башын читкә борып, ирен арасына нечкә сигарет төртте. – Ренат Әсхәтович шулай мөгез чыгарырга ярата. Капка, имеш. Нәкъ авылдагыча булсын, имеш. Барысы да таш койма коеп, тимер капка утырта, ә бу...

Тәмәке төтене, бөдрәләнеп, һавага таралды. Саматның борынына ниндидер әчкелтем хуш ис килеп бәрелгәндәй булды. Һе... Бу шул... сасы тәмәке тартмас шул инде. Сорты бүтән.

Әтисе иренеп кенә күктәге ак болытларга күз салды.

– Ренат Әсхәтович – акыллы кеше. Тимер тимер инде ул. Агач бүтән. Агачның җаны бар.

Бикә чыркылдап көлеп җибәрде.

– Философ икәнсең бит, Мостафа. Агачның җаны... Кайда күрәсең инде ул җанны?

– Агач җылы...

Хатын, юкны сөйләмә, дигән кебек, кулын селтәп куйды.

Әтисе ирен чите белән елмайды. Самат исә бикәнең наданлыгына шаккатты. Агачның җанлы булуын алар авылында һәркем белә.

– Без бүген кайтып китәсе идек, – диде әтисе.

– Тагын бер кич кунарга туры килер. Ренат Әсхәтовичтан узып мин сезне җибәрә алмыйм. Кая ашыгасыз? Ял итегез бераз. Әнә күлгә су коенырга төшегез. Гел эш тә эш димәгән. – Һәм бикә борылып өенә кереп китте.

– Һы... – Әтисе уң кулы белән сул кул аркасына сугып алды. Бераз пошынса, аның шундый гадәте бар. – Без бит... без ял итәргә килмәгән. Уттай эш өстендә... – Ул җәйге өйгә таба атлады.

Эссе иде. Су коенып менсәң, начар булмас иде анысы.

– Коенасың килсә, бар... – диде әтисе, аның уен сизгәндәй. – Мин шәһәргә чыгып керәм әле. Бераз күчтәнәч-мазар алырмын.

Самат уенчак тай кебек сикереп алды. Капка «их» итәргә дә өлгермәде, малай инде зур йортларны урап алган таш коймалар буйлап күлгә йөгерә иде.

– Артык эчкә кермә! – дип кычкырган әтисенең дә тавышын ишетмәде.

Саматның әтисе Мостафа – тирә-юньгә данлыклы капка ясау остасы. Аңа тиң булырлык күрше Урмай авылыннан Минап әбзәй генә бар, дип сөйлиләр иде. Мостафа ясаган урыс капкаларны – ә бу якта аларны нигәдер кабак дип атыйлар – халык, чыннан да, бәхет китерә, дип ышана, «бигрәкләр дә җиңел куллы шул Мостафа», – дип, әби-чәби чыш-пыш килә иде. Түбән очтагы имче Минҗиһан карчыкның: «Мостафа ясаган кабактан атлап чыксаң, юлың уңа да уңа инде», – дип сөйләп торганын Самат үз колагы белән ишеткәне бар. Җәй башларында алар үзләре дә яңа капка ясаттылар... Ясаттылар...

– Инде ярты авылны урыс кабаклы иттең, ә үзебезнең һаман җил капка... адәм көлкесе, – дип, ике көннең берендә әнисе кабатлый торгач, әтисе Урмайга барып Минап әбзәйне алып килде.

– Син соң үзең оста бит... – дип аптырады Минап. – Нигә мине яллыйсың?

– Үземә шәп итеп ясамам дип куркам... – Мостафа маңгаен ышкып алды. – Кыюлык җитми, малай...

Минап аны аңлады. Ун көн дигәндә һөнәрдәшенә менә дигән шәп капканы җиткереп тә бирде.

Шуннан соң бер ай үттеме-юкмы, Саматның әнисе үлде. Баш мие кайнарлык эссе иде. Авыл хатыннары урманга печән чабарга китте. Әнисе шунда чалгысы янәшәсендә егылып үлде, диделәр. Башына кан сауган.

Үлемнең чын асылын белми иде әле Самат. Әнисе каядыр вакытлыча гына киткән сыман тоелды аңа. Гәүдәсен гүргә төшергәндә дә, малай үзләренә нинди фаҗига килүен чынлап аңламады. Юк, бу әнисе түгелдер, бу бөтенләй бүтән кешедер булып тоелды. Ничек аның әнисен анда – җир астында калдырсыннар? Әнә бит ул, әле кичә генә түгелме соң, иңбашына чалгысын салып, яңа капкадан чыгып китте. «Самат, Гөлфияне яхшы кара, ашны мичкә куеп калдырдым, вакытында ашарсыз», – диде. Ә биш яшьлек Гөлфия, өстендәге япманы тибеп очырып, таралып йоклый иде әле.

Китте...

Әмма ул тиздән кайтып керәчәк, и-и Саматкаем, үсеп тәмам егет булдың бит, ишегалдын әнә ничек пөхтә себереп чыгаргансың, дип аны мактаячак.

Иртән, әтисенең эчтән каралып киткән йөзенә карагач кына, ул имәнеп, әнисенең беркайчан да, мәңгегә-мәңгегә, кире кайтмасын аңлагандай булды.

Тагын берничә көннән аларга Минап килеп керде.

– Аңлыйм хәлеңне, кардәшем, – дип, Мостафаның иңеннән кочты. – Моңардан да авыр кайгы була алмый.

Өстәл янына утырыштылар.

– Үлгән артыннан үлеп булмый, – дип сүзен дәвам итте Минап. – Миңа әле генә бер Казан баеның йомышын тапшырдылар. Алар бит хәзер, үзең беләсең, шәһәр читендә үз йортларында, ни соң әле, аты коргыры, катиҗларда яши. Шул – миңа хәбәр салучы – авылча урыс капка торгызмакчы була икән. Байларның үз кытыклары... – дип, Минап кыска гына көлгәндәй итеп куйды: ы-хы-ых...

Мостафа аны тыңламый да иде шикелле. Аның ни катнашы бар монда? Маена чыдаша алмаган бер лыкыр баеның кайгысымы?..

– Җилләнеп кайтасыңмы әллә? Кайгыңны бераз таратып, дим. Малаеңны да ал ярдәмгә. – Минап, үрелеп, дәү кулы белән Саматның башыннан сыйпагандай итте. – Үсеп егет булган бит инде бу. Тьфү-тьфү, күз тимәсен...

– Шулай дисеңме... – Мостафаның тавышы бик-бик сүрән иде. Үз-үзенә сөйләнгәндәй әйтеп куйды: – Бармыйча да булмас шул. Гөлфияне әбиләрендә калдырырбыз. Җан биргәнгә җүн бирер Ходай.

Минап аңа керләнеп беткән кәгазь кисәге сузды.

– Менә адресы. Казанга җитәрәк ул... Иртәгә үк кузгалыгыз. Бай шулай дигән. Бә-әк кырку кеше, диләр. Төгәллекне ярата, димәк... – Минап тагын кыска гына көлгәндәй итеп куйды: ы-хы-ых... Күмгүк иреннәре ерылып, тешсез авызыннан Саматка караңгы аңкавы күренгәндәй булды.

Минап, керпе чәчен сыпырып, урыныннан күтәрелде. Чәче дә яңадан торып басты.

– Ярар, юлыгыз уң булсын, – диде ул. – Бигайбә.

– Син соң үзең нигә бармаска булдың? – дип сорады Мостафа, аны озата чыкканда.

– Мин шул Бүре Рәшитенә капка ясый башлаган идем. Ничек бүленәсең...

Иртәгесен, ата белән ул, Казанга җитәрәк, кашагасына зур итеп «Нарат» дип язылган зур йорт янына төшеп калдылар. Җир астыннан юл аркылы чыгып, урман аша Казан баеның биләмәсенә юл тоттылар.

Бай өйдә иде. Тәбәнәк буйлы, бүксәсе килешле генә алга чыккан. Икесен дә сыек зәңгәр күзе белән бораулап алды.

– Капканы шушында ясарсыз, – диде ул, Мостафаның сузылган кулын күрмәгәндәй. – Шәп булсын. Шәп булса, түләүне кызганмам. – Һәм сүзенә нокта куйды: – Әйттем!

Тик әйтәсе сүзе калган икән:

– Мин ун көнгә чит илгә китәм. – Ул янында басып торган хатынына ымлады: – Сорауларыгыз булса, нидер кирәк булса, менә Роза Фатыйховнага мөрәҗәгать итәрсез.

Өйдән яше Самат чамасындагы бер кыз йөгереп чыкты. Юк, бу аңардан өлкәнрәктер: юка күлмәген төртеп имиләре ташып тора, йөзе дә балалыктан инде күптән азган сыман...

– Папочка! Кайчан кайтасың? – дип, ул әтисенең муенын юантык беләкләре белән урап та алды.

– Позвоню... – Бай, кызын үзеннән аерып алып, машинасына таба китте. Шофёр егет, машина ишеген ачып, янәшәдә басып тора иде.

Кыз кузгалып киткән машинага кул болгап торды да, Самат белән Мостафага күз дә ташламыйча, өйгә кереп китте.

Самат, киләп-килешкә үк киемнәрен комлыкка ташлап, күлгә чумды. Шылт иткән аваз юк, бу вакытта әле монда кеше булмый. «Эх, трусикны да саласы булган», дип уйлады малай, үкенеп. Теге ярда биек чыршылар гүяки итәкләрен суга манчып тын калган. Бераз йөзеп баргач, ул чалкан ятты. Күк йөзе зәп-зәңгәр иде. Малайның күңелен аңлатып булмастай шатлык биләп алды. Менә шулай бер кайгысыз су өстендә яту... рәхәт бит... рәхәт бит... Шунда бәгырен кисеп утлы хәнҗәр үткәндәй булды. Әнкәй, әнкәй... Ул бит шулай каерылып беркайчан да шушы зәңгәр күккә карый алмаячак! Өстә әнисенең йөзе чалынып киткәндәй булды. Үлгәч, кешенең җаны күкләргә аша, дип сөйли иде түгелме соң әбисе... Димәк, аңа каерылып күккә карыйсы юк. Ул үзе күктә! Ул әле Саматны да күзәтеп торадыр. Аның өчен сөенәдер дә әле... Сөенер дә шул – Самат хәзер бала-чага түгел бит инде, әтисенең кул арасына керә башлады. Хәзер алар бер-берсенә терәк, әбисе әйтмешли. Сеңлесе Гөлфия дә исенә төште. Ул сагынадыр инде... әнисен дә, әтисе белән абыйсын да.

Эссе. Быел җәй эссе килде шул. Самат, ашыгып, җәйге өйгә килеп керде. Һай, рәхәт! Салкынча... Өй быел гына салынган әле, нарат исе куерып борынына килеп бәрелде. Түрдә әтисенең караваты, ишек кырындарак, сул як стенага терәлгән сәкедә малай үзе йоклый иде. Кояш күзеннән кинәт кергәнгә өй эче тагын да караңгырак тоелды. Сәкегә якынайгач, ул үзе дә сизмәстән күзен угалап алды. Чү... анда кемдер ята түгелме соң? Тезләрен өскә калкытып кемдер ята шул. Кем дип... бай кызы бит бу! – шул, үзе, мәтәлеп китәрсең... Елмаямы соң – күзләре симез битендә эреп беткән сыман. Ярым караңгыда кып-кызыл бүртенгән ирене кыймылдап алды:

– Чё туктадың? Кил, яныма утыр.

Нишлисең, Самат күндәм генә кыз янына килеп утырды. Кыздан килгән кайнарлык тәнен өтеп алгандай булды. Малай аның өскә калыккан шәп-шәрә якты ботларына карамаска тырышты, «капка баганаларымыни!» – дигән уй гына башыннан үтеп китте дә, баш эшләүдән туктады, тонды, бушап калды.

– Исемең ничек әле?

– Самат.

– Самат... Саматлор... – Кыз кинәт кенә малайның иңеннән кочты да үзенә аударды.

Самат, йомшарган гәүдәсен җыеп, кирегә тартылды.

Кыз көлеп җибәрде.

– Ничә яшь сиңа?

– Унөч... Ундүрт тула инде ун айдан.

– Без яшьтәш икән бит. Ә син... салага әле... – кыз аңа йомшак кулы белән төртте.

Самат эндәшмәде. Кыз терсәгенә таянып калкынды да аңа йотардай булып карады.

– Син... әле малай гына?

Кинәт кыз аны кочаклап алды, ирене белән авызын эзли башлады. Самат тартылды, имчәгенә ике кулын батырып, кызны үзеннән алып ташлады.

Кыз кычкырып көлде. Сәкедән сикереп төште дә итәген рәтләде.

– Их син, дерёвня! – Ишек янына килгәч, борылды: – Борыныңны төшермә, мин сине өйрәтермен. – Пышылдады: – Төнлә йоклама, килермен. – Аннан тагын көлде. – Ишекне бикләмә только... – Һәм чыгып та йөгерде.

Аңгыраеп бик озак утырды Самат сәкедә. Мендәрдән килгән ис ничектер күңелне уйната, тынгысызлый – ул аны өстен аска әйләндереп куйды. Өйрәтермен, имеш. Син белгәнне без инде... Һи... Һи... Оят иде аңа, йөрәкне әллә нинди кымырҗытып торган оятсызлык...

Әтисе кайтып кергәнне сизмичә дә калган икән. Биштәрен идәнгә куйгач, әтисе аңа борылды:

– Нигә болай караңгыга терәлеп утырасың? – Ул тәрәзә пәрдәсен кырыйга тартып куйды. – Күл буенда кызынып ятасы урынга...

Янына килде. Кәефе әйбәт күренә. Әллә бераз кәккән инде...

– Йә, нигә боектың? Борынны төшермә...

– Ә?!

Әтисенең кинәт кәефе алмашынды. Чүмәште дә аны кочаклап елап җибәрде.

– У-улым... Ятим калдык би-ит.

Олылар ямьсез елый. Самат, дерелдәп, әтисенең тынчу кочагына сеңде. Кайнар күз яше муенына тамды. Аның да күкрәгеннән өзгәләнгән авазлар бүселеп чыкты. Икәү еладылар.

Әтисе, кинәт торды да, алып кайткан нигъмәтләрне өстәлгә чыгарып тезде.

– Эш бетте, бәйрәм итәбез, – диде ул. Елау галәмәтеме, тавышы бераз карлыккан иде. Соңгы күз яшен озын, итләч борыныннан учы белән селтәп төшерде. – Әйдә, улым, кил, җаның теләгәнне аша, без дә кешеләр бит... – Һәм башланган шешәдән касәгә аракы койды.

– Әти, эчмә...

– Аз гына, улым. Эш бетү шатлыгыннан.

Алар өстәл янында икәүләшеп озак утырды. Күзенә йокы эленә башлагач, Самат сәкесенә барып ятты. Күптән караңгы төшкән иде инде.

...Ул капылт уянып китте. Өй эченә шыплап ай яктысы тулган. Түрдә ниндидер кыштырдаган тавышка колагын торгызды. Әтисе йоклый алмыйча борсаланып ятамы соң? Бастырылган мәллә? «Аһ» та «уһ» килә түгелме... Малай, башын күтәреп, әтисе караватына таба карады. Әтисе өстендә чәчен тузгытып шәрә хатын-кыз утыра иде. Албасты! Кайдан килгән ул? Бай кызының: «Килермен, ишекне бикләмә», – дигән сүзләре исенә төште. Самат бит бераз йоклап алгач, тышка чыгып кергән иде. Төн уртасы булгандыр. Алай да бай йортында ут яна иде әле. Күктә йодрык-йодрык йолдызлар. Карлыган куаклары арасында малай шактый озак басып торды. Ишекне бикләп кергәнен дә ачык хәтерли.

– Аһа-һа-һа... – дип аһылдады хатын. Ул чалкан әйләнеп төшкән иде. Бу бит бикә! Бай абзый хатыны.

Әтисе шуның белән ята. Ята!

– Аһ, Мустафа, Мустафа!

Самат юеш битен сыпырды. Юк, ул еламый, эчендә кемдер елый иде.

Китәргә иде... Авылга кайтырга. Ул бит инде монда әтисенә кирәкми.

Самат шыпырт кына сәкедән төште дә, ишекне акрын гына ачып, тышка чыкты. Салкынча бармаклары белән йөзенә төн ябышты. Самат туктап тормады, яңа капкадан йөгереп чыкты да урманга ташланды. Битен гөлҗимеш куаклары тырнады, юлына имән аркылы ятты, ә ул йөгерде дә йөгерде. Уңга каерырга кирәк – урман юлы шул якта булырга тиеш. Аннан инде ул трассага килеп чыгачак, анда инде алар ягына берәр машина очрамый калмас. Булмаса, иртәнге автобусны көтәр.

Агач башларына эләгеп калган күк йөзе бишек кебек айкала, чайкала, аннан – күк тирәнлегеннән – әнисенең тавышы ишетелә сыман: «Йөгер, тизрәк йөгер, улым. Калма аның янында-а...» Менә хәзер шушы чаукалыкны гына әйләнеп уза да, анда инде урман юлы...

Вак таш җәелгән урман юлына аягы тигәч, ул үзенә таба тавышсыз-тынсыз якынлашкан ике фара яктысыннан сукыраеп кинәт туктап калды.

Агач башларына эленгән бәллүр бишек, чәлпәрәмә килеп, җиргә коелды.

...Затлы машина шофёры рульне кочаклап катып калды. Бераз аңга килгәч, туңган иреннәре языла, ул елап җибәрде:

– Ренат Әсхәтович... Кичерегез, мин... өлгерә алмадым...

– Борчылма, монда синең гаебең юк, – диде хуҗа.

## Кабахәт

Бер олау кер үтүклисе бар иде Гөлиянең. Ярата ул бу эшне. Башны җигәсе юк – кулы үз хуты белән йөри, ә күңеле исә әллә кайларга китеп бара, әйтерсең, сафлык һәм яктылык бөркеп торган күлмәк-ыштаннарга, яулык-тастымалларга, чүпрәк-чапрак, чурт-чураманга һич катышы юк. Башка дөньяда! Урманда озак адашып йөргәннән соң, иркен, якты аланда ябалдашын җәеп утырган карт тирәк төбенә оеп ял итәргә сузылган мөсафир сыман әйтеп аңлатмаслык рәхәтлек кичерә шул сәгатьләрдә. Ләкин әчкелтем хатирәләр монда да сискәндереп куя, кеше аяк басмаган әрәмәлекләрдәге шыпырт сукмакларга әйди. Менә хәзер дә... алсу лифчигын кулга алуга... Күңелгә якын, тәнгә килешле кием-салым була, искерсә дә ташлыйсы килми шуны. Бер-ике ел элек тәненә сыланып тора иде шушы лифчик, үлчәп теккәндәй иде ул кибеттән алганда да. Инде кечерәйде... Гөлия елмаеп куйды – кечерәйде дип инде... ул ике кулын догага әзерләгәндәй күтәреп, тәкәббер генә борын чөеп торган имчәкләрен сыйпап алды. Ие, яратып кия торган алсу лифчигы кыса хәзер. Тик ташлыйсы да килми. Илнур салдырган лифчик бит ул. Аңарчы ул тирәгә беркемнең кулы тигәне булмады. Юк-юк, түбән тәгәрәмәде Илнурның кулы, ул бит юләр түгел, Гөлиянең ирек куймасын белә. Колагын өткән кайнар сулышы менә бүген йөрәгенә төшеп бөтен җанын әрнеткәндәй булды. «Өйләнешкәч тә өлгерербез, – дип тынына буылып пышылдады ул. – Шулай бит, җаныем?» Җиде генә түгел, сигез тапкыр үлчи торган кеше иде Илнур. Ул үлчәде, тәкъдире үчләнде – чит илләрдә гомерен кистеләр. Соңгы хәбәре Донбасстан килде. Хәрби хезмәте төкәнгәч

тә армиядә калган иде ул, имеш, туй үткәрергә уч тутырып акча эшләп кайта. Кайтты... Алып кайттылар. Тутыя табутын ачарга да рөхсәт булмады. Шулай беркем белән киңәш-табыш итмичә генә Гөлияне ташлап китеп барды Илнур. Шулай ярыймы инде, ә? Илнурны искә алган саен күзенә дыңгычланып нур тулуын сизде кыз. Әнә ул – озын буйлы, киң җилкәле; чем-кара күзен кысып, авызын исә ерып каршыга килә: кочагын җәйгән. Юк шул, булмый, булмый; насыйп түгел икән инде ул кочакта эрергә. Ташлап китте бит, китте... Кабахәт! Гөлия күз яшен сөртеп алды. Өйләнешкәч өлгерә, янәсе... Калган эшкә кар ява торган була шул.

Урыны-урыны белән аязучан болыт, дип хәбәр иткән иде телевизордан кызыл авызлы, кыска итәкле, әмма озын тырнаклы кыз – дөрес әйткән, иртәдән бирле кар ява, Илнурның кабере тәмам кар астында калды инде, калды.

Гөлиянең әтиләре, иртә торып коймак белән чәй эчкәннән соң, киенеп-ясанып, тиздән буласы кодаларына туй мәрәкәсен юллап киткәннәр иде. Ерак тормый алар, өстәге урамда гына. Ләкин әтисе барыбер машинасын кабызды, җәяү йөрергә ул инде янәсе саяк-сандырак түгел. Кодасына тиңләшә алмаса да – анысының машинасы oho-ho! – ул да арбадан төшеп калмаган, күт астында мимеч машинасы кешнәп тора, Аллага шөкер.

Гөлияне кияүгә бирәләр.

Әрлән Хисмәтенең малае Радик тәмам каныкты аңа. Илнур армиягә китүгә бәйләнә башлаган иде, инде аны тутыя табутта кайтаргач, тышавы бөтенләй бушады. Оятсыз тәре! Өч аймы соң, элек, тансыдан кайтканда, килде дә кысып кочаклап алды. «Син минеке!» – дип кычкырды, шакшы аракы исе килеп торган авызын аңа таба сузып. Ахирәте Венера белән култыклашып бара иде Гөлия, өстенә бер чиләк юынтык су койдылармыни! Венера бер читкә каерылып көлеп тора җитмәсә. Юка баш! Ә Гөлия нишли ала? Ике нәни йодрыгы белән азгын Радикның калкан кебек калын, киң күкрәген төйде инде үзенчә... Шул чакта... Гадәттәгечә, күршеләре Айрат иярә иде аларга. Бер адым арткарак калып, ике кызның үзара сүзенә кушылмыйча тын гына атлый иде ул бүген дә. «Сагынма Илнурны! – дип кычкырды тагын Радик. – Юк ул! Бандералар дөңкегән аны. Оныт!» Селәгәй тулган авызы Гөлиянең иреннәрен эзли, бәбәкләре оядан атылып чыгарга тора. Шул чакта... Гөлиядән кинәт аерылды да көзге пычракка килеп төште Радик. Айратның селтәнгән кулын гына күреп калды Гөлия. Кемнән-кемнән, күрше малайдан ул мондый тәвәккәллекне көтмәгән иде. Авыл егетләре Радик белән каршылыкка кермәскә тырыша, ул бик гарьчел, усал хәтерле, мәкерле, бәйләнешмәвең яхшы. Анысы бер хәер, атасы Хисмәт тирә-якта бер авторитет. Көйсез улының юлына аркылы төшсәң, бөтенләй юкка чыгуың да бар. Хисмәт бай үз сүзен генә сүз итә торган коры кеше, улының нинди җимеш икәнен белә, корт төшкәнен дә күреп тора – тик бит үз баласы! Аны кыерсытырга юл куйса, ул кем була? Әйе, беркем дә булмый. Тешен кысып ул аның кыланмышына түзә, түзмәгәндә каеш белән арт сабагын да укытып ала; тик җиткән егет ләбаса! Димәк, бер генә юл кала – өйләндерергә! Аягына сыер басса, тиз аңга килер, эттән туган... дисәң инде, дөрес үк булмас, Хисмәт үзен эткә түгел, бүрегә тиңли иде.

Шул ук көнне Айратны полиция тотып китте. Радикны үтергәнче кыйнавы гына җитмәгән икән, кесәсеннән әфьюн чыккан, ә өендә ваһһабитка өйрәтә торган китап тапканнар, имеш! Булыр да, Айрат авыл егетләре белән артык аралашмый торган сәеррәк җан иясе иде бераз. Шизакатьлерәк иде ул, үзара әйткәндә. Бервакытта хәтта аның авыл клубындагы китапханәгә кереп

киткәнен дә кемдер күреп калган. Китапханәгә! Егет кешегә төсме шул? Тәмәке дә тартмый иде ул... Эчү мәҗлесләрендә дә катнашмый иде мәхлук. Менә бит! Нинди елан асрап ятканнар куенда. Ярый әле, җаен китереп, авылны шартлатмаган.

Шулай дип сөйләнүчеләр булды, тик кем генә ышанды икән бу сафсатага? Намазга баскан берничә карт-коры эчтән генә зөбаный Хисмәтне каргады, Айратны утыртуда шуның кулы уйнаганы һәркемгә ачык иде. Кибет тирәсендә хатын-кыз чәпчеп алды – шул гына! Оныттылар берничә көннән Айратны. Әтисенең дә кем икәне билгеле булмаган ятим-йотама кемгә кирәк? Акылга җиңелрәк әнисе генә – Дивана Эльвира дип йөртәләр иде аны авылда – кинәт гаип булган улын берничә тапкыр урамга чыгып эзләп керде дә тынды. Аннары аны да каядыр алып киттеләр. Картлар йортынамы соң, әллә җүләрләр йортынамы, диделәр... Гөлиянең әтисе буш калган йортның тәрәзләренә аркылы-торкылы такталар сугып чыкты. Бетте шуның белән! Аллаһы әкбәр!

Тик Гөлия белмиме инде Айратның кем икәнен? Бер урамда уйнап үстеләр, бер сыйныфта укыдылар. Кыюсыз, сүзен беркайчан да өздереп әйтә алмаган Айрат та булдымы ваһһабит? Адәм көлкесе, дияр идең, нинди көлке монда, ун елга ук утыртачаклар диме соң... Җебегән Айрат исән каламы инде андагы бандитлар арасында. Гөлиянең бәгырен әрнетеп торган нәрсә – Айрат бит аның аркасында эләкте бу бәлагә! Аны яклап кул күтәрде бит ул йөзе кара Радикка. Ябык кулын селтәгән килеш әле дә күз алдында тора әнә – сөяк тә тире! Өрсәң очып китәр, ачуым да бер килмәгәе. Озын чәче иңенә ишелеп төшкән, иягендә өч-дүрт бөртек сакал, күзе кылыймы соң – берсе чәршәмбегә, икенчесе бөтенләй якшәмбегә карый. Шул да булдымы террорист?! Нишләп кенә ята икән инде ул төрмәдә, мескенем.

Бәла бит ул үзе генә килми, ишен дә ияртә. Әрләнә Хисмәте ишек шакуга ук йөрәге кысылып куйган иде Гөлиянең – юк, алдамый шул йөрәк! Үз бүлмәсендә аягөсте килеш залдагы һәр хәрәкәтне тоеп, һәр ым-ишарәне кан тамырлары аша кичереп, тын да алмый торды ул. Чакырылмаган кунак белән әтисе өстәл тирәсенә кара-каршы урынлашты. «Йә, – диде хуҗа, – дога кылыйк, – йола шулай куша». Ул соңгы вакытта җомга көннәрендә мәчеткә йөри башлаган иде. Хисмәт битараф кына битен сыпырды да гадәте белән үгезне мөгезеннән алды:

– Без ят кешеләр түгел, – диде ул, кистереп. – Бер төптән чыккан ырулар. Йөз кызартырлык эшебез юк.

«Ә Айрат? Айрат! Айрат...» – дип йөрәге сулкылдады Гөлиянең. Йөз кызарырлык кынамы... Җәһәннәм утында янарлык! Тик аның йөрәген беркем ишетмәде, чал ирләр салмак кына сүзне дәвам итте.

– Әйе, бер төптән, – дип җөпләде хуҗа.

– Дүртенче буынга киткәч, авылда әммәбез кардәш. Зыян юк, кыз ярәшергә ярый. – Хисмәт кыска гына көлеп куйды.

Ишекне шакыганда сизенгән иде Гөлия, хәзер инде Әрләннең нигә бусагадан атлавын тәмам аңлады: улына – азгын Радикка (!) – аны – алма кебек Гөлияне, хатынлыкка сорарга килгән.

«Әтием! Әтием! – дип сулкылдады бичара йөрәк, – зинһар, ризалашма, бирмә шул сасы авызга газиз кызыңны, бәхетсез итмә».

– Минем Радик синең кызга кызыгып йөри икән. – Хисмәт авыр сулады. Бераз тынып торгач, сүзен дәвам итте. – Яшерен-батырын түгел, малай бераз тулыксыз. Киртәдән сикергән чаклары була. Хатыны, балалары булгач, көйгә килер. Мин шулай уйлыйм.

– Һе... – дип куйды әтисе. – Буласының, беләсеңме, кайдан ук билгеле?

– Беләм. Балачактан ук, бу... ук билгеле кем буласы. Минем малай ул – минем малай! – Хисмәт нәни йодрыгын өстәлгә куйды. Тәрәзәдән яктылыкныңмы кыңгыр төшүе – өстәлдә яткан йодрык шактый олы булып күзгә ташланды. Шулай булмыйни, элекке биш калхуз, бөтен кыр-басулары, техникасы, ихаталары-биналары белән, Хисмәтнең шушы йодрыгы эченә керде дә бетте бит, ходавәндә. Калхузлар дигәнемез, бер дә булмаган кебек, эт сигәнче вәйран булды да куйды. Вәссәлам!

– Әйбәт яшәрләр. Малайны мин үзем авызлыкlармын. Киленгә кырын карасамы?!

Хисмәт инде Гөлияне килен дип саный! Сүзенә каршы килерләр, ишектән кире борырлар, дип ул башына да китерми иде. Каршы килеп кара! Авылда яшәрлегеңне калдырмас, ник туганыңа үкенерсең. Алай да әтисе тиз генә бирешәсе итмәде.

– Хәзер бит, үзең беләсең, кордаш... Яшьләр үзләре сайлый. Аннары минем кыз әле сабыйлыктан да чыкмаган. Эһе. Калага укырга китмәк кели.

– Бабайлар ни әйткән? Бүрек бәреп егылмаса, кызны кияүгә бирергә була, дигәннәр. – Хисмәт тагын кыска гына көлеп куйды. – Алар юләр булмаган.

– Акыллырак булганнар, дисеңме? Ай-һай! Акыллы халык дәүләтсез калмый.

Хисмәт, хуҗаның сүзен игътибарсыз калдырып, үзалдына сөйләнгәндәй:

– Укымак кели... Ни пычагыма... Әнә минем дурак укып йөргән булды. Экономист итәм, янәсе. Финансист! Имтихан саен акча түләдем. Дипломын сатып алдым. Хәзер кем инде ул? Бишне алтыга тапкырлый белми! Телефонына карап әйтә! Хәсрәт... Апкайттым шәһәрдән. Тракторга утыртам хайванны. Басу сөрсен, бүтән эшкә ярамагач.

– Син шул дуракка кызымны димлисеңме?

– Әйе! Үзеге таза анық. Минем орлык! Әйтәм бит, өйләнгәч, бала-чагасы булгач, ипкә килә ул.

– Ай-һай. Белмим ни әйтергә дә...

– Син кирле-морлы сөйләнеп утырма! Ни әйтергә белмәсәң, хатыныңны чакыр. Мин тешләгән җирдән өзмичә калмыйм.

– Син, кордаш, ордым-бәрдем сөйләшмә әле. Кыз бирү ул уен-муен түгел. Хатынны да чакырырбыз. Киңәш-табышсыз булмас.

– Кызың өлгергән. Вакытында озатмасаң, бозылып та китә ул кыз бала. Заманаы кара син. Кяфер өстенә кяфер.

Гөлиянең әнисе каядыр биләмгә киткән иде, озын гомерле булыр – нәкъ үзен искә алганда кайтып та керде.

– И-и, Хисмәт әбзәй килгән наса, сиңайтәм, чылтыратып та әйтмисең, – дип, аш бүлмәсенә ашыкты. Аңа өмет юк иде. Әрләннәр белән туганлашырга улмы каршы булсын?! Бай тормышка кызыкмаган көне юк. Инде әтисенең тәмам колак итен ашап бетерде. Хәйран күп кредит алганнар иде банктан, хәзер шуны түлисе бар. Әнә ничек балкыды, түрендә Әрләнне күргәч.

Калым-фәлән, бирнә-төгәннәр турында тыңларлык рәте калмаган иде Гөлиянең, күңеле тулудан әлсерәп ятагына ауды да – акты да китте.

Үтүген яраткан лифчигы өстенә куйган килеш тәмам онытылган бит, әй, көйгән ис борынына төрткәч кенә аңына килде. Лифчикның йомрысына таба омтылып, алсу тукыма өстендә өчпочмаклы кара эз калган иде. Күзенә тагын мөлдерәмә яшь тулды – ташларга инде моны... Илнурның соңгы истәлеген.

Лифчикны йомарлап ишек төбендәге чүп чиләгенә таба борылган иде, артына авып китә язды: бусагада чәче төптән кыркылган Айрат басып тора! Тар чыраена әллә нинди сәер киң елмаю ябыштырган, үзе тач бер малай-шалай инде, әйтәсе дә юк.

– Айрат?! – Үз күзенә үзе ышанмыйча, Гөлия Айратка таба омтылды, аның арык иңбашына каккалады. – Чыгардыларммы? Нигә торасың инде каккан казык кебек, әйт тизрәк!

– Качып кайттым, – диде егет-малай гади генә.

– Качтың? – Гөлия гаҗәпләнүдән кычкырып җибәрде. – Качтың? Соң сине бит хәзер атып үтерәләр. Син шуны беләсеңме? Инде сине дөнья бетереп эзлиләрдер.

– Син кияүгә чыгасыңмы? – дип сорады Айрат һәм, балачактагы гадәтенчә, йодрыгы белән авызын сөртеп куйды. – Радикка...

– Анысы сиңа нигә инде? – дип ачыргаланды кыз. – Син соң аңлыйсыңмы...

– Бик яхшы аңлыйм, – диде Айрат. – Шуңа качып кайттым да.

– Нәрсә? – Гөлия, беренче тапкыр күргәндәй, Айратка батырып карады. Әйе, ул бу егетне беренче тапкыр күрә иде. Теге ул белгән җебек Айрат түгел бит бу! Бөтенләй бүтән Айрат! Әле генә миен кисеп үткәндәй булды: аңа сыланып маташкан исерек Радикны төртеп егуы да, хәзер полиция кулыннан качып кайтуы да тикмәгә түгел, ул бит... ул бит... И-и мескен! Гөлиягә гашыйк булып йөргән ләбаса. Хәзер дә гашыйк. Ә Гөлия аны уйлап та бирмәде. Ничек инде ул, ярты авылның егетләрен саташтырган Гөлия, Дивана Эльвираның өтек малаена карасын?! Айратның шулай өметләнеп йөрүе аны рәнҗетә түгелме соң... бар ягы килгән кызны! Гарьлек, гарьлек, билләһи.

Тик... тик... кем аны шулай хөсетсез, самими ярата алыр соң бүтән? Кем аның хакына төрмәгә керергә дә риза булыр? Карышмыйча гомерен корбан итәр?

– Син бит... бөтенләй... – дип бытылдады ул, каушап, – сиздермәдең...

– Көн саен клубтан сезгә кем ияреп кайтты алайса?

– Мин сине Венера артыннан йөри дип уйлый идем.

Күзен почмакка төртеп ялганлады Гөлия, моңарчы Айратка кагылышлы бер уй да килгәне юк иде башына. Әйе, искәрә иде алар Венера белән: Дивана Эльвираның тилемсә малае ияреп кайта аларның эзенә басып... кайтса соң?! Вакыты җиткәч, кем кайтмас үз өенә. Ашаган җиренә сыер да кайта. Ә-ә, исендә, Венера колагына пышылдаган иде бугай: «Бу малай сиңа бик мәхәббәтле карый, авыз суын корытып...» Гөлия көлгән генә иде. Кинәнеп көлгән иде ахрысы. Сәләмә генә малай булса да, тугрылыклы әнчек кебек арттан ияреп килүен күрү барыбер кыз күңеленә рәхәтлек биргән иде. Ул бит тулысынча синең ихтыярыңда! Боерык бирсәң, ул бит синең өчен коега да баштүбән сикерәчәк, чәчрәп китим, шушы урында ялгышсам. Тик кызга кирәкми иде ул тилемсәнең коега сикерүе. Әйе, кинәнеп көлде дә, шунда ук онытты күрше малае турында Гөлия.

– Радикка чыгуыңны ишеткәч, миңа шок булды, – диде Айрат, тынлыкны бозып. – Аңа түгел, син миңа чыгарга тиеш!

– Әниеңне картлар йортына алып киттеләр.

– Юк, юләрләр йортына... – Айратның йөзендә берни үзгәрмәде. – Күптән кирәк иде. Анда аңа әйбәтрәк булыр. Юкса монда...

Гөлия иңбашын сикертеп куйды. Аңлады ул Айратның ни әйтергә теләгәнен. Әбисеннән ишеткән мәкаль исенә төште:

– Илдә чыпчык үлми.

– Чыпчык үлми, кеше үлә, – диде егет, иренен кыегайтып. – Гөлия! Әйдә, киттек минем белән! Россия зур, табарбыз ышык урын.

– Айрат! Сине барыбер эзләп табачаклар. Алардан качып булмый.

– Качарбыз, беркем табалмас.

Гөлия аңа ияреп каядыр китүне башына да китерә алмый иде, сорады:

– Бер тиенсез кая гына барып җитәрбез?

Айрат, иренен турсайтып, ятакка утырды.

– Сезнең шул булыр инде... Акча! Акча! Шул гына сезгә дөнья тоткасы. Радикка да шуның өчен чыгасыңдыр әле?

– Мыскыл итмә, – диде Гөлия, малай янына чүмәшеп.

– Мин төрмәдән качтым синең өчен, ә син... син...

Гөлия егетне тынычландырырга маташты: иңеннән сыпырды, чигәсеннән үбеп алды. Бик тә, бик тә кызганыч иде Айрат.

– Мин бит синең өчен үләргә риза!

– Беләм, беләм...

– Ташла ул Әрлән малаен. Бәхетсез булырсың гомер буе!

– Соң инде, Айрат. Берсекөнгә туй. Хәзер качып китсәм, әтиләр нишләр? Андый хурлыкны ничек күтәрер?

Айрат илереп елый башлады.

– Нигә качтым мин төрмәдән? Сиңа ышандым! Тотсалар, кыйнап үтерәләр бит мине! – Ул инде бәләкәй гәүдәсе белән Гөлиянең куенына кереп беткән, кырыкмыш башын имиләр өстенә урнаштырган – шунда күз яшен түгә иде. Ниһаять, ул юеш йөзен күтәрде. Аһ, кызганыч, кызганыч бала... Юеш иде ирене. Корсак төбендәрәк пәйда булган нindидер авыртыну аяк бармакларына, муен тамырларына кадәр таралып, аркасына яткырды Гөлияне. Бичара малай, көтелмәгән бәхетенә сыеша алмыйча, ыңгыраша иде. «Чү! Чү!» – дип пышылдады кыз; нигә алай әйтте, үзе дә аңламады.

– Гөлия!

Ишек тоткасына кулын салган егеткә Гөлия аркан борылды, итәген рәтләде.

– Китик бергә. Без бит хәзер... – дип нидер әйтергә маташкан егетне бүлдерде:

– Юк!

– Ярар! Радик – сарык! Ә мин – беренче! Онытма: veni, vidi, vici.

– Нәстә?

– Цезарь әйткән: килдем, күрдем, җиңдем.

– Кабахәт! – Кыз өстәлдәге кул астына эләккән алсу лифчикны кукраеп торган малай өстенә ыргытты. – Кабахәт! – Бая гына шундый якын, газиз, ә хәзер, берничә минут эчендә, шулкадәр ят, күңел кайтаргыч кемсәгә әверелгән иде ул. Лифчик, пионер галстугын хәтерләтеп, Айратның муенына уралды. – Кабахәт! – дип янә кычкырды Гөлия, нигә ярсыганын үзе дә аңламыйча. Ярсыйсы, аяк тибеп кычкырасы, бөтен дөньяны җимерәсе килә иде.

Начар артистларча пафос белән көлеп, Айрат кар явып торган урамга йөгерде. Анда дөнья түгәрәк һәм ап-ак иде шикелле.

Чи-чи чинаган полиция машинасының тавышын ишетеп, Гөлия тәрәзәгә капланды. Тавышсыз гына иңрәде ул: кая барып бәрелергә белмәгәндәй, Айрат ике машина арасында бәргәләнә иде. Бераздан битлек кигән, башаяк коралланган дәү-дәү ирләр кечкенә автобустан коелышты, икәве, төркемнән аерылып, түм-түгәрәк күк астында берүзе калган малайны күз ачып йомганчы

бөтереп алды; кулын боргычлап, җиңел машинаның арткы утыргычына ыргыттылар. Машинага керер алдыннан бер мизгелдә Айратның күз карашын тотты сыман Гөлия. Бәхетле иде кебек Айратның күз карашы шул мизгелдә. Ачы тавышларын урамга таратып, машиналар китеп югалды. Гөлияләр турында, ак кар өстендә, алсу тап калды.

## Калдык

Көн кичкә авышкан иде. Яхшы! Ул көн буе киләп сарды, анда барды, монда әшнәләре белән ләчтит сатып утырды. Таныш-белешләре күп аның Канашта. Ул бераз чайкалып бишенче катка күтәрелде, фатирының ишек кыңгыравын чылтыратты. Фатирының дип... хатынының фатиры инде, ярты ел элек бер марҗага йортка кергән иде. Яхшы! Йортка кергәнче утка кер, диләр тагын. Элек шулай булгандыр да, бәлки... Ә хәзер аның бер ояты да юк...

Ишекнең теге ягында кыштырдау ишетелгәндәй булды.

Вагыйз тагын кыңгырау төймәсенә басты, аптырагач, ишекне йодрык белән төеп алды.

– Галя!

Ишек кинәт ачылып китте, аннан хатынының кызгылт тимгелләр тибеп торган киңчә чырае атылып чыкты. Кемдер кызган таба белән кизәндемени, Вагыйз артка чигенеп куйды.

– Кертмим! – дип чәрелдәде хатын. – Туйдым мин синнән. Булдыксыз, эшлексез татар! Тагын күпме ашатып ятарга була сине... – Ишек шапылдап ябылды.

Йорт төбендә беравык аңгыраеп басып торгач, Вагыйз әкрен генә тимер юл вокзалына таба юнәлде. Сыендырырлар әле, бәлки, берәр әшнәсе очрар. Ашыйсы килү дә үзен сиздерә кебек.

Яхшы түгел иде.

Ә бит әйбәт кенә яшәп киттеләр. Галяны авылга да алып кайткан иде Вагыйз. Култыклашып урам буйлап та уздылар. Авылда марҗага өйләнеп беркемне дә шаккатыра алмыйсың да... барыбер тел шартлатып калдылар агай-эне, әби-чәби. Бала-чагалар байтак кына арттан йөгереп барды. Шаккатмаслыкмы – марҗа Вагыйздан бер башка озын, үзе юан, аяклары гына да гөбе кадәр.

«Өйләнә алмассың, сиңа кем чыксын», – дигән әнисе дә телсез калды.

Вокзалда, гадәттәгечә, кеше мыж килә иде. Ул буфет тирәсенәрәк килеп басты. Янәшәдәге өстәл янында ике кеше кыздырылган тавык ашый. Уртада шешә кукраеп утыра. Чем-кара чәче шешенке маңгаена төшкән кысык күзлесе, ишарәләп, Вагыйзны үз яннарына чакырды.

– Нигә балтаң суга төшкән кеше кебек торасың, браток?

Икенчесе Вагыйзга аракы тулы стакан сузды. Ул, киресенчә, сап-сары чәчле, сипкелле иде. Сипкелләре, сикереп чыгып, менә-менә идәнгә коелыр сыман. Вагыйз дөресен әйтте:

– Хатын куып чыгарды, – диде.

Шуннан соң аны типкәләп уяттылар. Вагыйз эренле күзләре белән як-ягына каранды. Сыер абзарында йоклап ята түгелме соң ул? Әле генә вокзалда иде, ә хәзер абзарда салам өстендә...

– Мин кайда? – диде ул, аптырап.

– Оҗмахка эләктең, браток, – дип көлде Сипкелле. – Хәзер ашау – байдан, үлем – Ходайдан сиңа.

– Тор, имгәк, – дип җикерде Кысык күз. – Өченче тәүлек йоклыйсың инде. Менә сиңа эш фронты. – Ул кулын җәеп абзарга ишарәләде. – Савучы да булырсың, көтүче дә... кыскасы, терлекче.

Вагыйз иренеп кенә торып басты. Башы чатнап авырта иде. Сыерлар, ризасызлык белдереп, мөгрәшеп куйды. Вагыйз, күзен угалап, бу ике кешегә кызыксынып карады.

– Шаяртасызмы? – диде ул, нигәдер өметләнеп.

Кысык күз көтмәгәндә аның эченә китереп сукты. Вагыйз бөгелеп төште.

– Син хәзер безнең кол! – диде Сипкелле. – Аңлыйсыңмы шул сүзне?

Кысык күз кизәнми генә Вагыйзның яңагына кундырды. Авыз эче җылынып китте, ирен читеннән кан сузылып чыкты.

– Аңладыңмы?

– Аңладым.

Алар абзардан чыктылар. Тышта офыккача дала җәйрәп ята иде.

Берәү чүгәләп учак кабызып маташа. Учак өстенә казан аскан.

– Сашка! – дип кычкырды Кысык күз. – Сиңа ярдәмче алып килдек.

Сашка дигәне чал чәчле, сакалы берничә көн кырылмаган, чепи күзле бер карт булып чыкты. Чандыр, аркасында калак сөякләре тырпаеп тора. Өстәвенә чукрак та иде ахрысы, кулын колагына китереп:

– Ә? – дип торып басты. Озын буйлы иде бу карт, бик ябык иде – сәләмә пинжәген гүя скелетка кидереп куйганнар.

– Менә иптәш булды сиңа. Эш рәтенә төшендер.

– Шурба хәзер кайнап чыга, – диде Сашка. Учак инде кабынган, ялкыны әрсезләнеп казан төбен ялый.

Кысык күз белән Сипкелле машинага утырып китеп барды.

«Качарга кирәк!» – дип уйлады Вагыйз.

– Без кайда? – дип сорады Сашкадан. Кычкырып сорады.

– Акырма... – Карт учакка таягы белән төрткәләде. – Җир өстендә әле пока.

– Якын-тирәдә берәр авыл бармы? – Вагыйз Канашның бик еракта калуын аңлап алган иде инде.

– Белмим, – диде Сашка. – Сиңа авыл нигә кирәк? Безгә моннан беркая да китәргә ярамый. Ничава, күнегерсең. Бераздан каядыр китәсең дә килмәс. Кем көтеп тора безне анда. Ә монда яхшы: ашау – байдан, үлем – Ходайдан.

«Качарга кирәк!» – дип уйлады Вагыйз.

Тик кая качасың?

– Монда егерме сыер, икебезгә унышар, саварга иртәнге дүртенче яртыда торырга туры килер, – дип, «эш рәтен» өйрәтә башлады Сашка. – Алтыда инде көтүгә куабыз. Кич белән тагын шул мәрәкә. Иртә-кичен сөтне машина белән килеп алалар.

– Мин ничек монда эләктем соң? – дип, уйлаганын үзе дә сизмәстән кычкырып әйтте Вагыйз.

– Баш катырма юк белән... Ашау-эчү яхшы. Әнә тегендә йоклыйбыз. – Сашка абзар кырындагы бер алачыкка төртеп күрсәтте. – Яхшы. Алай-болай сугыш башланмадымы анда?

– Кайда?

– Дөнҗада...

– Ишетелмәде.

«Аракыга йокы даруы салганнар!» – дип уйлады Вагыйз. Иртә-кич сөтне алып китә торган булгач, димәк, кешеләр алай ук ерак яшәми.

– Исемең ничек соң?

– Васька.

Тамак ялгап алгач, Вагыйз дала буйлап китте. «Васька! Акылыңа кил», – дип кычкырып калган Сашкага ул кул гына селтәде. Барды да барды. Кояш лепкәсен пешерде, йөзеннән шаулап тир акты. Күз алдында яшелле-зәңгәрле түгәрәкләр биеште. Аяк буыннары тотмый башлагач, ул йөзтүбән җиргә капланды. Бераздан аның янына машина килеп туктады.

– Кая җыендың, падла! – дип, Сипкелле аның эченә китереп типте.

Аны, кулларын бәйләп, машинага тактылар. Машина акрын гына сыерлар калган якка кузгалып китте.

Вагыйз бүтән качмады. Күнекте. Чыннан да, бу дөньяда кемгә кирәк ул? Ә монда ашау – байдан, үлем – Ходайдан. Кешене шул ашау кайгысы йөртә түгелме соң дөнья йөзләрендә? Ә үлем инде ул кайда да үлем. Ходайдан...

...«Вагыйз югалган!» – дигән хәбәр авыл өстендә яшен тизлегендә таралмады. Аның югалганын күп кеше сизмәде дә. Әнисе генә сирәк-мирәк сагынгалады бугай. «Күз көеге булып йөргәнче, югалуы артык», – диде бер энесе. Аңардан барысы да туйган иде. Әнисе турында әйтмим, аналар үз балаларыннан туймый.

– Күптән үтереп ташлаганнардыр инде, – диде Таракан Зиннәт.

– Күңелем сизә, исән ул, – диде Нәби. Алар Вагыйз белән бер мәктәп коридорында укыганнар иде.

– Бәлки, аны бүтән планетага алып киткәннәрдер? Хәзер гадәти маршрут ул, – дидем мин.

– Күңелем сизә, исән ул, – дип кабатлады Нәби.

Бу хәлләргә инде унбиш еллап вакыт үтте. Вагыйз онытылды. Кешеләр җирдә гел югалып тора, әллә кемнәр югала – беркемнең дә исе китми.

Менә беркөнне авылга затлы машина килеп керде. «Мерседес»мы соң шунда... Кем утырып кайтты, дисезме? Әйе, әйе, Вагыйз! Үзе генә түгел, янында ике кеше бар иде. Берсе – Кысык күз, икенчесе – Сипкелле. Вагыйз алардан бер адым да читкә тайпылмады. Бер-берсенә тагылып өйгә дә кереп киттеләр. Анда Вагыйзның әнисе ялгызы яши иде.

Шулкадәр озак еллар аерылып торганнан соң, әнисе белән ничек күрешкәндер Вагыйз, миңа мәгълүм түгел. Күз яшен күрсәтмәгәндер, элек андый гадәте юк иде.

– Әби! Улың алтын куллы синең! – дигән, имеш, Кысык күз Вагыйзның әнисенә. Авылда шулай сөйләделәр. Апа кеше ул минутларда үзен бәхетле хис иткәндер, шаять. Юлдан язган улына карата андый бәяләмәне кайчан ишетә алыр иде әле ул?!

«Мерседес» авылда озак тормады. Шул ук көнне китеп тә барды бугай. Вагыйзның озак еллардан соң ике ят кеше белән кайтып китүе сәбәбен эзләп Нәби генә бер көн баш ватып йөрде.

Икенче көнне билгеле булды: Кысык күз белән Сипкеллегә Вагыйзның кеше булуын ачыклый торган белешмә кирәк булган икән. Муниципалитетта шулай диделәр.

## Кыска ялганыш

Авылда кичләрен капка төбенә чыгып утыру гадәте бар инде ул. Чыгасың, ике-өч күршең сиңа кушыла. Офыкта кып-кызыл кояш эреп ята. Моңсулык япанчасын бөркәнеп, сабырлык кушагын билгә буып, авыл төнгә керергә җыена. Әйе. Күз бәйләнгәнче утырабыз берничә карт-коры. Телевизор карап кына ятмассың бит. Дөрес, дөнья хәлләре монда да арттан калмый. Эквадор президенты өчен ничек борчылмыйсың?! Көн буе Аурупа өстендә очып йөргән, имеш, бахыр. Чөнки дә җиргә кунарга рөхсәт булмаган. Ниһаять, бер аулак кумырыкка төшеп утыргач, полисия кереп тентегән үзен. Рәҗе шулай кешене мыскыл итәргә ярый? Әмерикә котыртып ята икән Аурупаны шундый шуклыкларга. Аларга нәрсә, шаярырга булсын.

Сүз иярә сүз чыга шулай. Авылда да сөйләрлек гыйбрәтләр күп. Гыйбрәттән генә тора да инде хәзер авыл. Безнең урамда гел карт-коры гына калды. Кайчан гына монда уптым яшьләр иде, урам иңләп, көнне төнгә кушып, бала-чага чатыр-чабадыр иде. Урамның исеме генә дә үзе гыйбрәт – Котылдык дип атала. Аерылып, ниһаять, усал каенаналарыннан котылган киленчәкләр кушкан исем. Каенаналар да төшеп калган түгел, аларның үз атамасы – безнең очны Комгансызлар дип йөртәләр иде заманында. Шулай да тора-бара киленчәкләр кушкан исем өскә чыкты. Әнә шул кайчандыр чибәр, чая киленчәкләрнең берсе камыт аякларын сак кына күчергәләп, таяк белән ярдәм итештереп монда таба килеп ята. Каш өстенә кулымны куеп караган идем, аптырап киттем: минем кәмпер бит бу! Үзгәрсә дә үзгәрә икән кеше. Ә бит теге чакта... Һи-и...идриттити. Теге вакытта, аулак өйдә нинди иде?! Борынгылар әйтмешли, мисле кура җиләге иде инде, һич арттырмыйм. Авыл егетләре сыланырга җай гына эзли иде. Мине сайлады. Һы, ник сайламасын, һөнәрем дәрәҗәле – электрик; бераз саксыз йөткерсәң дә, ильич лампалары сүнә торган заман – бөтен авылның күзе миндә! Кыяфәт тә шәп, кылык та – камчы кебек уйнак, чыбыркы сымак шартларга гына тора идем яшь чакта! «Али карендәш!» – дип кылкынып торалар иде. Ә хәзер нәрсә? Хәзер шул, юкәдән ишкән бау кебек сөйрәләм шунда.

– Маузер өзелде, – диде минем карчык битараф кына.

Мин тиз генә битне сыпырып куйдым. Рәҗигун!

Туфрактан яралган, янә туфракка кайта кеше. Хәтта ки Маузер булса да... Атна-ун көн ятты бугай ул үлем түшәгендә. Сызлануга түзә алмыйча, аты-юлы белән сүгенеп. Каршыдагы чапыраш күрше булгач, хәлен белергә кергәләп чыга идем. Юкса нигә миңа аның хәле?

– Карчыкларны чакырып карыйм әле, мәетне төнлә ялгыз калдыру ярамас.

Хатынга каршы төшмәсәм дә, күзне ризасызлык элпәсе каплап алды. Исән чакта Маузер кеше яратмады, җүнләп исәнләшә дә белми иде. Үзен дә беркем өнәмәде. Янәшәсендә хәзер берничә карчыкның мыдыр-мыдыр укынып утыруын теләр иде микән... Алладан да, мулладан да җәяү качкан кеше иде бит ул.

– Син, димен, муллага барып әйт. – Кортка ерак китмәгән икән әле. Дөресе, бөтенләй китмәгән, бөкрәеп һәмишә каршыда басып тора!

Әйе, муллага хәбәр итәргә кирәк. Үлем-төшем аның төп эше. Авыз тутырып әйткәндә, үлеме мәрхүмнеке, төшеме исә муллага. Хәер, Маузердан нинди төшем... Исән чагында да өч тиен сәдака бирмәгәндер.

Мулла ерак яшәми, түбән очта гына. Караңгы төшкәнче барып җитәрмен

шәт. Китеп тә барам түгелме соң инде менәтерәк. Мин шундый! Яшьтән үк тоткан җирдән сындыра идем. Әле дә озак сөйләшеп тормадым, атладым мулла өе тарафына – түбән очка.

Маузер кайчан авылга кайтып төште соң әле ул?

Көтмәгәндә, уйламаганда, ашка төшкән чебен кебек. Авылда аның беркеме юк, аны да беркем көтми иде. Дөресе, дөньяда барлыгын да оныткан идек. Йә, бер тамырың өзелгәч, нигә, кайтып, кеше күзен борчып йөрергә? Маузер турында әйтүем. Әйе, чәчәсен чәчеп, тынычланып калган вакыт иде. Бәрәңге инде борынлаган, теге кабахәт комсыз коңгызларны котыртып, кара җир өстендә яшел яфраклары күренә. Менә шул чакта кайтып төште ул. Йортлары инде егерме елдан артык ташландык тора иде. Шунда яши башлады зимагур.

Кулыннан эш килә икән, юкса элек бер саяк-сандырак иде, берничә көндә йортның эчен чистартып, юып чыгарды, тәрәзәләрен алмаштырды, ишегалдындагы үләнне чапты, капканы рәтләде. Әлмира карчык хәтта бакчада казынганын да күреп калган. Менә бит кеше ничек үзгәрә... Егет чагында ничек кыланганын күрсәгез иде сез аның... И аның күкрәк киереп урамнан узулары! Әйтерсең, Чулак Әләү малае түгел, әлләкем... Үз-үзен артык яраткангамы, кырыкка җитәрәк тә өйләнмәгән иде. Килергә атлыгып торучылар да күренмәде. Хатын-кыз эт шикелле ул – кемнең кем икәнен бик тиз сизеп ала. Хәзер нәрсә... Җилкәләр төшкән, күкрәк инде киерелми, үзе бөкрәйгән, йөзгә тоҗым кунган. Юкса бит әле ул алтмышны да тутырмаган кеше! Тормышы татлы булмагандыр читтә. Йөзенә караганда гел ачыны ашаганга охшап тора.

Кайда йөргәндер шул гомер... Алла белә. Маузер безнең белән аралашмый, без дә күрешергә атлыгып тормыйбыз, кайткан икән кайткан, яхшымы, начармы, ата нигезе. Бәлки, туфрагы тарткандыр олыгайган көннәрендә. Югыйсә монда кемгә кирәк ул? Затсыз бәндә иде Маузер, затсызның яхшы якка үзгәргәнен күргән юк әле. Күңел турында әйтәм инде, башкасы үзгәрер аның...

Шулай да беркөнне килде ул безнең янга. Өен рәтләп бетергән иде инде. Без әлеге дә баягы капка төбендә утырабыз. Без дигәнем шул берничә бөртек карт-коры. Әлмира карчык инде иң беренче булып чыгып утыра, тамагын кырып. Аз гына ютәлләп, кибарьлек өчен, мин чыгам. Капка төбендәге утыргыч шомарып беткән. Нигә тагын да шомартмаска? Бераздан юл тузанына галушларын ышкып Әлбирт күренә.

– Бисмилла, – ди, арык артын утыргычка төртеп.

Соңгы атнада ни сөйлисең, ни сөйләсәң дә, тәртә очы һаман шул Маузерга килеп төртелә.

– Аның югалганына бер утыз ел бардыр, адәм тәганәсе?

Әлмира карчыкны җөпләп, Әлбирт сүзгә кушыла:

– Мәскәүдә сугыш чыга язган иде бит, шул елны... Шәймине дә читлеккә утыртып алып китәселәре иде.

– Туксанынчы ел! – дим мин, катгый итеп. Үзем шунда ук икеләнеп тә алам: әллә туксан берме?

– Һи, гумерләр, – дип уфтана Әлмира карчык. – Суга баткандай юкка чыккан иде шул. Әнисен җирләргә дә кайтмады.

– Табалмадылар.

– Хәернисаттәй үлгәнгә дә инде, и-һи, – дидем мин дә. – Әләү абзыйдан соң озак тормады ул да.

– Ә? Кайда йөргән дисең? – дип, учын колагына китерә Әлмира.

– Әнә үзе килә, сорарсың. – Әлбирт капкадан чыгып килүче Маузерга ымлады. Чыннан да, Маузер безгә таба атлый иде.

– Саумысс, – диде ул, каршыга туктап. – Шәп кенә торас-смы?

Күзе элеккечә янып тормый, сүнгән, төсе уңган. Кәкре борыны исә бер якка янтайган.

– Аллага шөкер! – диде Әлбирт. Аңа шулай әйтү тиеш, чөнки дә ул күптән инде авыл мулласы булырга хыяллана. «Колһуалла» белән «Фатиха» сүрәләрен ятлап куйганына да бишбылтыр. Нишлисең, берәү үлми, икенчең көн күрми. Тик түбән очтагы Сәет хәзрәт урынны бушатырга ашыкмый иде әле. Тиз генә җыенмый иде авыл читендәге каеннар арасына китәргә. Авырый дип күптән сөйлиләр дә... Хәзер кем авырмый? Табигать хәлләре шундый чөнки. Типсә тимер өзәрлек егетләр дә бүген дөнья җимертеп эшләп йөри, иртәгә сорыйсың, күренмәгәч... Китте ул, диләр. Көтмәгәндә китеп барган шулай хушлашмыйча да. Теге дөньяга... Без йөрибез әле менә иске сәпит кебек чалыш-мылыш. Яшәсен Сәет абзый да. Бик әйбәт хәзрәт. Искечә белеме әллә ни юктыр да, тик безнең авылга ярап тора әле пука. Бетеп барган авылга «Мөхәммәдия» шәкерте килмәс.

Әлбирт электән шундый – югары урынга кызыга торган гадәте бар. Кызыгуын кызыга, ә белеме чыпчык тезеннән дә юк. Яшь чакта бик озак партком секретаре булырга хыялланып йөргән иде. Армиядән үк коммунист булып кайткан, хәсис. Җыелышларда сәхнәгә чыгып тузга язмаганны сөйләргә аңа куш. Тик партком итеп барыбер куймадылар, тикшереп алалар икән анда да. Әлбиртнең шунда барлык хәрефләрне дә танымавы ачыкланган. «А»ны таный икән, «Б»ны – хет үтер, танымый. Элек күргәне булмаган... Шулай да гомерен эшләмичә уздырды Әлбирт. Әле ревизия комиссиясенә, әле партийный контрольгә билгеләп кенә тордылар үзен. Менә хәзер Сәет хәзрәт урынына борынын сузып маташа. Әлбирт хәсрәт! – исеме үк килешми бит мулла булырга. Әлбирт исемле мулла була димени? Шуны аңларлык та акылы юк.

Маузер, миңа карап:

– Кичә кишер-суган чәчкән идем, – диде. – Бүген карыйм: орлык өскә бәреп чыккан, чыпчыклар чүпләп ята. Нигә алай?

– Чәчү вакыты үтте бит инде, – дип кул селтәде Әлбирт.

Ә Маузер һаман миңа карап тора. Мин нәрсә беләм? Без үскәндә авылда бөтенләй яшелчә белән маташмыйлар иде. Күңеле уйнаган хатыннарга тозлы кәбестә кирәксә дә, күрше авыл чирмешләреннән чыгып алдылар.

– Тупрак не принимает, – диде Маузер, урысчалап.

Ни әйтим, җилкәне генә сикертеп куйдым. Күпме яшәп, андый хәлне күргән юк иде әле. Тупрак ул кеше түгел, тупрак – киң күңелле, һәр нәрсәне кабул итә. Җаныбыз гарешкә очуга, үзебезне дә кабул итәр. Ленин гына ята ул әнә җир өстендә фиргавен сыман. Күмеп куйсалар, аны да кире төкермәс иде җир...

– Али әбзәй, әйдә, бернәрсә күрсәтәм, – дип, Маузер иңемә кулын салды. Комы коелып бетмәгән иде әле: кулы авыр, гайрәте, ташмаса да, сизелерлек.

Киттем инде ияреп. Әлмира белән Әлбирт утырып калды. Әлмираның нидер сорарга ачылган авызы шул килеш ябылмыйча тора иде әле мин әйләнеп килгәндә дә.

– Әйдә, әйдә, курыкма, – дип, Маузер мине бакча башына ук алып китте. Аптырадым – нигә куркырга әле миңа? Үз җиремдә басып торам, Аллага шөкер. Куркыр тунибыз күптән тузган. Шул үлемнән курыксаң гына инде.

Анысы да гадәт буенча гына. Курык-курыкма, иртәме-соңмы ул барыбер киләчәк. Һәм алып китәчәк үзе белән – һич югы моңа шикләнмәскә була.

Маузер өшегән кеше кебек калтырана иде.

Ул төртеп күрсәткән төшкә карагач, минем дә күз маңгайга таба шуышты: каен үсентесе, менәтерәк... утыртылган чокырыннан суырылып чыккан да берике метр читкә китеп ауган. Актарылган туфракта тамыр эзе тырналып күренә.

Бала-чага эше дияр идең, бездә аларның исе дә юк. Миннән шикләнмидер бит бу зимагур...

– Үзе чыккан ул, – диде Маузер, уемны сизгәндәй. Аннары тагын кабатлады: – Тупрак не принимает.

– Нич-чек?

– Менә мин дә аптырадым шул. Нич-чек?

– Ни әйтергә дә белмим.

– Нигез... Нигез танымый мине... – Маузер бүтән бер сүз дә әйтмичә, бөкрәеп, өенә таба атлады. Мин сәерсенеп чыгып киттем. Әллә нинди хикмәтләре бар бу дөньяның.

Шуннан соң Маузер нидер чәчеп, утыртып маташмады, ахрысы. Вакыты да калмаган иде инде, бераздан ул авырый башлады. Әҗәл чире йоккан, дип сөйләделәр.

Якын кешеләре, чыбык очы гына туганнары да булмагач, минем карчык кереп караштырып йөрде инде. Эт баласын да андый чакта ялгызын калдырмыйлар. Маузер кебек бәндәләрнең авызына су салудан берәр төрле савап буламы, белмим, әмма да ләкин дәптәргә гөнаһ язылмас, дидек алай да.

Менә бүген китеп барган Маузер. Ата нигезендә. Туфрак тигезли һәркемне. Анысы шулай, беребез дә мәңгелеккә килмәгән. Тик мәетне башта җирләргә кирәк бит әле, туфрак тигезләсен өчен. Шактый мәшәкатьле эш ул... Кәфенлегение кирәк, ләхет тактасы дигәндәй. Мулла белән киңәшми ярамый. Мәчетнең мая акчасы да бардыр әле.

– Менә шундый хәлләр, хәзрәт.

Мулла – Сәет абзыйны әйтүем – сакалын сыпырып шактый уйланып утырды. Ул төз гәүдәле, җитмештән узса да, мускуллары кабарып тора, кирәксә, йөгереп китәргә дә, куып җитәргә дә күп сорамас. Әүхәтле, кабилиятле. Яшерен-батырын түгел, полкауник ул безнең! Әтисез үсеп, шундый дәрәҗәгә ireш әле! Элегрәк, без үскәндә, аны җилдән туган, дип тә ирештерәләр иде. Шуңа күрәдер дә мәктәпне бетерер-бетермәс чыкты да китте авылдан. Тәвәккәл егет иде ул. Тәвәккәл таш яра шул. Полкауник булып кайтты да озак еллар үткәч, кул кушырып утырмады – менә безгә мулла булды. Моңа җитәргә әле Әлбирткә... Әйтәм бит, буш хыял белән юанып йөри ул, хәсрәт.

– Мин аңа ясин чыкмыйм, – диде мулла, авыр сулап. – Шулай да зират кырыена күмми булмас.

– Алай ярыймы соң, хәзрәт? Догасыз-нисез... Мордар түгел бит ул.

– Син аның авылдан нигә качканын беләсеңме соң?

– Әтисенә кул күтәргән, дип ишеткән идем.

Чулак Әләүне яхшы хәтерлим мин. Алма агачыннан ерак төшми – Маузер төмсә чырае, кешесөймәслеге белән атасына охшаган... Чулак Әләүнең дә күзе тездән түбән иде, сүзе билдән аста. Үзе белән дә күрешергә, исәнләшергә теләүчеләр бик юк иде. Бигрәк тә хатын-кыз... урамда ул күренүгә, берәр ихатага кереп китү җаен карый иде. Сугышның беренче көннәрендә уңышлы яраланып, чулакланып авылга кайткан Әләү бригадир булып алган, балда-

майда йөзгән, тол калган байтак киленчәк аның кулы аша узган, дип сөйләнәләр иде. Сәет хәзрәт тә аның улы дигәнне ишеткәнем бар да, тик әйтәләр бит: кеше ышанмастайны чын булса да сөйләмә! Сугыш вакытында тууы хак, әлбәттә, тик бит Чулак Әләүгә тамчы да охшамаган. Аңардан Сәет хәзрәт кебек дастуйный кеше ничек тусын?!

– Кыйнап үтерде! Әләү... – Мулла, тамагына нидер тыгылгандай, озак кына йөткеренде. – Аны бит үзем җыештырдым, беләм. Кайтып урнашкан гына идем әле мулла булып. Әле дә күз алдымда... Каралмаган җире калмаган иде. Ничектер эшне йомдылар. Хатыны йөрде бугай, күтәрмәдән егылды дип таныклап. Бу мөртәтне эзләүче дә булмады.

– Хәзер инде нәрсә... Анда җавап бирер.

– Бирер. Һәр гамәл өчен җавап бирәсе. Тик менә туфрак пычрана.

Мин гадәтемчә җилкә сикерттем. Ни әйтәсең? Туфракның эше пычрак йоту инде аның...

– Әләү... башын күтәрмәсен дә, җүнле кеше түгел иде үзе дә.

Сәет хәзрәтнең йөзе кара-кучкыл булып янып чыкты.

– Булсын! – диде ул, ярсып.

Мин аптырадым – нигә ярсый ул шулкадәр? Ата кешегә кул күтәрергә ярамый. Кем булса да, аны кичерергә тиеш. Ул синең атаң! Аллаһы Тәгаләнең кодрәте белән синең дөньяга тууыңа ул сәбәпче!

Мин, уңайсызланып, үз уемнан үзем оялып, башымны аска идем.

– Иртән килермен, – диде Сәет хәзрәт, сүзне озакка сузмастан. – Кәфенлек бар, тактаны сәвит бирер. Әлбирт белән кереп җитегез, бергә җыештырырбыз.

Карчыгым инде кайтып җиткән иде. Мәет кырында төн чыгарга берәү дә риза булмаган. Хәзерге карчыклар да инде... Йокы калдырамы инде алар йола дип. Сәдака булмасын белә торып әле. «Бараммы соң, – дигән Әлмира. – Йөзе аркылы килсен мөртәтнең». Алай ук кыланмаса да ярый иде дә... Кешене гаепләр алдыннан – бигрәк тә үлгән кешене! – башта бераз үзең турында да уйлап куюы артык булмас. Әлмираны да беләбез. Аңа китсә, аның йөзе дә, бөтенләй үк аркылы килмәсә дә, тулаем үз фурмасын саклар идеме икән, ай-һай. Әлбирт тә башым авырта, кан басымы артты, дип, ах та ух килеп, өендә калды. Сәдака исен сизсә, башын култык астына кыстырып булса да килер иде әле, хәсрәт! Ярый, хәерле булсын. Берүзем утырдым мәет кырында «бисмилла, амин, бисмилла, амин», – дип кабатлап. Төн куерганчы. Шуннан башка ни әйтим? Ә Маузер ята тын гына шул ике сүзгә дә риза булып... Нигә электр чыбыкларын алмаштырмады икән аякта йөргәндә? Бигрәк искеләр. Пужар чыгарга да күп сорамас...

Кайтып киттем бераздан өйгә. Утны сүндермәдем. Караңгыда ятарга өлгерер әле.

Таң атканчы керермен, дигәнием. Йоланы бозу булса булыр, ятсын бер үзе. Гомер буе аерым яшәгән Маузер инде үлеп киткәч кенә безне сагынмас. Кабердә дә ялгыз ятасы, күнегә торсын.

Төн уртасында карчык янтыгыма төртеп уятты. Өй эче яп-якты! Йокыдан кинәт айнып тәрәзәгә капландым. Маузер йорты дөрләп яна иде.

Аяк астында буталган карчыкны читкә этеп, чалбарны да кимичә урамга йөгердем. Кан басымының артуын оныткан Әлбирт тә килеп җитте. «Ярый әле җил юк!» – дип кычкырды ул. Җил чыннан да юк, кичә радио да җил булмасын әйткән иде. Ә радиога без ышанабыз.

Йорт инде кипкән шырпы хәлендә булган, мөгаен, бик тиз янып көлгә

әйләнде. Шактый борчылдык чаткысы безгә сикермәсен дип. Алла сакласын. Юкса янгын сүндерүчеләр белән полиция таң белән генә килеп җитте. Беравыздан искергән электр чыбыгын гаепләделәр. Кыска ялганыш, диме шунда... Чыннан да, шул гомердән бирле ялганыш ничек кыскармасын?

Көле суынгач, актарынып, берничә күмерләнгән сөяк табып алды полиция. Тикшерер өчен пакетка салып каядыр алып киттеләр. Шуның белән шул. Аллаһы әкбәр.

## Абага чәчәге

Авыз күтәреп авыл диярлеге булса, аның бер диванасы булырга тиеш!

Бездә дә бар берәү. Аны бөтенләй үк юләр дип тә булмый. Ләкин кеше тек кеше диягә дә тел бармый. Әллә нинди генә иде ул, сәер иде, кыскасы. Дөньяда гаме юк, үз көенә тик йөри киләп сарып, сулаган һавасын ыслап. Безнең дә аңарга эшебез төшми, ул үз юлында, безнең үз мәшәкатебез.

Мәшәкать...

Яшәп маташу мәшәкате... Һәркем үзенә бер шөгыль таба инде андый чакта. Әнә подпалкауник Сәет, түбән очтагысын әйтүем, мулла булып йөри, үзе белмәгәнне өйрәтә; Али күрше бөтенләй ычкынды: авыл карт-корысын җыеп, җыр ансамбле оештырмакчы... Әле мине дә чакырып маташты. Бармыйча да булмас, минем тавышсыз көрчеккә терәлә ул, үзе шулай әйтте: син җырлаганда, дир, тавышың түбән очка кадәр ишетелә иде элегрәк. Хәзер дә әле, Аллага шөкер – азан әйтергә хутлаган кебек. Анысын инде бөтен халык белә. Белмәгәне шул – Әлмира карчык бәет чыгара башлаган! Читтән кайткан бер зимагур үз йортында янып үлгән иде, пупирусын сүндерми генә йоклап киткән, диделәр – салган булгандыр, мәләвен; бер атна үттеме-юкмы, авылда бәет таралды: «Көтеп алдык авыл белән изге корбан гаетен; мин сөйләрмен, сез тыңларсыз мескен Маузер бәетен». Мескен Маузер дигәне шул зимагур була инде, үлеп шулай ат казанды, йолкыш. Алладан җәяү качкан нәстә – юкса аңа нинди бәет? Бездә шулай... Авылның киләчәге дип көн-төн йокламый янып-көеп йөргән кеше гел читтә кала. Күрмәмешкә салышалар. Анысына инде без күнеккән, тик шаккатмалысы шул: үз гомерендә китап тотып карамаган Әлмира кортканың шундый сәлияте. «Тарих ике мең унынчы сәнә иде дөнҗада...» – дип башлап җибәрә, малай, тавышы көрәеп китә хәтта. Күрше авыл мәктәбенә укучылар белән очрашуга чакырганнар беркөн үзен. Чакырмый ни! Бәетен Казанның кайсыдыр журналында бастырганнар, имеш. «Азат хатын»дамы соң... Халыкның авызы һаман исән, дип язганнар диме соң... Үзем күрмәдем, Али күрше сөйләде, ул Казаннан ишетеп кайткан. Менә бит ул дөнҗа нинди...

Мин исә... белерсез минем турында да... Ишетерсез әле, боерган булса... Бу авыл төс түгел дә бит миңа, нишлисең – тәкъдир. Белемле, әүкатле кешене бездә өнәмиләр шул. Борынгы заманда ук, Аллага якынрак булсын, дип, зирәк кешеләрне безнең бабайлар агачка аскан икән. Шулай дип язалар иске китапларда. Хәзер дә авызыңны үлчәп ачмасаң, һы-ы... Нечкә җиреңнән асып куярлар, Алла сакласын.

Дивана – Атый дибез инде без аны, Атаулла булды микән асыл исеме? – кәҗә асрый. Җәй көннәрендә кәҗәсенә дип ул болында печән чаба, киптерә, аннары уфалла арбасына төяп шул печәнне өенә алып кайтып, ындырларында

кибән куя. Нигә кәҗәгә шулкадәр печән? Ашарына үзе таба бит ул мәлгунь. Рәт-рәт булып тезелгән әллә ничә еллык кибәннәрдә гаме юк аның.

Ә безнең исә ачуны китереп тора ул кибәннәр. Вәт, дивана дими ни дисең ул Атыйга? Яше инде утызларда, ә акылы сабыйныкы. Мин үткәндә, ул, уң кулын өскә чөеп, «һайль» дип кычкырып кала. Ахмак! Сабыен сабый акылы, тик бит сабыйның да тел төбендә нидер була. Күршебез Али пужарник кына котыртып ята бугай аны.

Әнә әле дә турына чыгып баскан дивана, мине көтеп тора. Йөзендә күңел кайтаргыч елмаю... Ә мин Түбән оч Сәет кордашның хәлен белергә барып ятам. Бик каты авырый, дигәннәрие. Үлем түшәгенә үк яткан диме соң... Әйе, биреште ул соңгы вакытта. Армиядә хезмәт иткәндә, Чиләбе ягында бер завуд шартлаган булган, шуның җиле Сәеткә дә тиеп киткән, диделәр. Гади җил түгел, радиация! Хәлен белергә кирәк, ясин чыгарга да вакыт җиткәндер, һәрберебезгә килә торган мәрәкә.

Таяк очын миңа төбәп, Атый кычкыра:

– Һальт!

Ирексездән тып итеп туктап калдым. Ни димәкче була дивана?

– Борыл! Сәет мулла кәнсәләргә китте.

Кая барырга белми аптырап калдым. Ышаныргамы диванага? Диванага да ышанмагач, кемгә генә ышанасың бүгенге заманда. Башны бутады бу Сәете дә. Үләргә тотынгансың икән, үл инде син кеше төсле! Бер ятып, бер торып, күңелне адаштырма.

– Никутат килгән!

Кем, ди дивана? Депутат, диме? Сәет, үләргә яткан җирдән торып, кәнсәләр тирәсендә юкка гына йөрмәс. Мин дә шул якка борылдым. Арттан Атый кычкырып калды:

– Һайль!

Кәнсәләрдә авыл башлыгыбыз Рәйсә киң җилкәле, табак битле берәүгә нидер сөйләп тора иде. Авыл хәлләрен җиткерәдер инде шомартып-ялтыратып. Табак битле кеше ара-тирә башын селеккәли акыллы чырай белән. Атыйның депутат дигәне шушыдыр, мөгаен. Соңыннан ачыкланды, алай ук түгел икән, депутат булырга хыяллана гына икән әле. Тиздән сайлаулар буласы диме соң. Сыек каш астында чак кына беленеп торган елтыр кысык күзенә караганда, депутат булып та куюы бар моның. Бармакларын гел бергә җыеп торуыннан ифрат та ертлач адәм икәнен хәтта мин дә чамаладым. Юкса кешеләргә ышана торган гадәтем бар. Ихлас күңелле булганым өчен. Кәчтүменнән ташып чыккан мул корсагын әледән-әле сыйпаштырып ала сасык. Канәгатьлекнең аргы ягына чыгып, кинәт кенә кикереп куяр төсле. Менә шулар йөри бит әлләкем булып. Мин шуңардан кимме? Кәеф кырылды. Тик бернишләп тә булмый, елмаерга тырышып, мысыр мәкаме белән борын эченнән генә сәлам бирдем.

Сәет исә түргә үк менеп утырган. Сәламемне дә ул алды. «Вәгаләйкүм әссәлам!» – дип битен дә сыпырып куйды.

– Үт, Альберт абзый! – диде Рәйсә, миңа күз ташламыйча гына. Бигрәк төксе хатын!

Утырдым, озак кына дога кылдым. Аннары, Рәйсәгә карап:

– Мин инде биш ел Альберт түгел, мин хәзер Әлбир агаң булам, – дидем. Мондый исем белән хәзрәт булырга да чамам бар. Ничек яңгырап тора: Әл! Бир!

– Әйе, хәзер Әлбир ул, – дип мине җөпләде Сәет. Хәйләкәр дә соң, кирәк чакта куеныңа елан булып керә торган бәндә.

Табак битле кунак исә, кулымны кысып, озак кына селеккәләп торды. «Хәлләр ару гынамы, Әлбир агай?» – дип, сәламәтлегемне сорашты. Җилкәмнән дә кагып куйды әле. Элек первый секретарь шулай кага иде әүкатле кешеләр җилкәсен. Үз итеп. Рәхәт булып китте перәме. Чын хуҗаларча какты. Депутат булырлыгы бар моның.

– Яңгыр юк менә, игеннәр көеп утыра, – дидем мин, янәсе, сәламәтлек кайгысымы монда, ил-көн турында уйланып, йөрәк яндырып йөргәндә.

– Мәчет янына бер приструй кирәгие, – дип, Сәет безнең сүзгә кушылды. – Кичәгенәк Әлбир кордаш белән дә шул турыда киңәшкән идек әле.

Мин акаеп Сәет төлкегә карадым. Киңәштек, диме? Күзгә карап ялганлап тора! Тик ничек каршы төшәсең? Киңәш-табыш итү борынгыдан калган.

– Әйе, – дип тамак кырдым вәкарь белән генә. – Кирәк. Инвинтар куярга урын юк безнең.

– Булыр! – диде табак битле.

– Башта авылга юл кертәсе иде әле, – дип, безнең сүзне бүлде Рәйсә, башын күтәрми генә. – Ату язын-көзен сазга батып ятабыз. Балаларны мәктәпкә илтеп булмый.

Авылның биш баласын көн дә район үзәгенә укырга йөртәләр иде. Беркем ышанмас – егерме ел элек кенә биш йөз укучысы булган урта мәктәп гөрләп тора иде! Мәркәз инвестор керткәч, авылның комы коелды тәмам.

– Юл кирәк, әйе... – дип, Рәйсәне дә җөпләдем мин.

– Булыр! – диде табак битле.

– Клубта бүген Марат Артурович белән очрашу була, – диде Рәйсә, миңа карап. – Килегез, Әлбир абый. Күршеләреңә дә әйт. Концерт та була. Менә Марат Артурович Казаннан артистлар алып килгән.

Тәк-тәк-тәк... Кәнсирт диген... Бусы ярап торыр пажалый. Депутат буласы кеше алып килгәч, бушка инде ул. Клубның бишбылтыр ачылганы юк, аның ачкычы да Рәйсә кесәсендә тутыгып беткәндер әллә кайчан. Килербез, Алла боерса... Үтеп киткәндә, эченнән ниндидер музыка яңгырагандай булды шул. Казан әртисләре рипитиси куеп ята, димәк.

– Марат Артурович, без чарага тиклем тамак ялгап алыйк, – диде Рәйсә, миңа төксе генә күз сирпеп. – Хәзрәт, әйдәгез...

Ачуымнан эчемә кату чыгып, ишеккә таба кузгалдым. Мин аларның сыңар икмәгенә калганмы? Аллага шөкер, пинсәм килеп тора, өстәлемнән әфлисун өзелми. Кеше аерган була Рәйсә тәре! Салдафун Сәеттән кайсы ягым белән ким мин? Әрсезлек юк миндә, шул гына. Нәселебездә булмады. Хәрәм ризык эчкә ярамый. Ярар, безнең урамга да бәйрәм килер әле, ибдәш Сталин әйтмешли...

Шулай үзалдыма сөйләнеп, өйгә дә кайтып җиткәнмен. Капка төбендә Али басып тора.

– Мәчеттә идең мәллә, Әлбир хәсрәт?

– Нәрсә?

– Кайда йөрисең, димен.

– Казаннан әртисләр килгән! Ишеттеңме?

– Барабыз, әбәзәтелне. Карчык җыена калды.

– Анда депутат берәү килгән. Безнең очка яңа мәчет җиткермәкче. Җиткерер дә. Миллионер! Аңа мәчет салу төкерү белән бер. Миңа карап әйтә: сезгә яңа мәчет кирәк, дир, яңа мәхәллә, итагдали... Яхшы булыр иде, мәйтәм.

Авыз эчендәге буп-буш абзарын күрсәтеп ыржайды Али пужарник, ну, хәсрәт, ди, бүрең улый икән, ниһаять.

Улар да шул, мин кемнән ким? Алига сүз әрәм итмичә, өйгә ашыктым. Әйе, безнең очта мәчет салып куйсалар, ул бит бөтенләй бүтән нәрсә бит! Шыгырданда әнә сигезенче мәчет салып яталар икән. Без алардан кимме? Ике мәчетле авыл инде ул уен-муен түгел. Ике яктан азан яңгыраса, һы... Алига аңа нәрсә, үгез үлсә – ит, арба ватылса – утын. Мажик бит ул, укымаган.

Киенеп-ясанып, мин капка төбенә чыгып басканда, кояш, алагаем зураеп, офык читенә кунган иде. Эссе җил ишарәсе тыгызланып килде дә яңа гына төзәтелгән мыегымны сыйпап үтте. Башны каерып күккә карадым. Ник бер болыт әсәре булсын. Өй каршындагы карлыган куагының яфраклары куырылып килгән. Эчтәрәк ел да кытай алмасы белән кинәндерүче карт алмагач, кая барырга белмәгәндәй, аптырап басып тора. Яңгыр юк. Кояшның, бөтен офыкка таралып баеп баруы күңелгә бераз өмет өсти дә соң... Җил чалымы да тамак төбен кытыклап алды. Шыбырдап бер коеп китсәнә! Сафланып китәр идек бераз мир белән.

– Исәнмесез! – Яңгыравык тавышка сискәнеп борылсам... Әлхәмделиллаһи раббел галәмин! Коры кашыкка салып йотарлык бер кыз бала үтеп бара. Ак күлмәге тезен каплар-капламас, аягында биек үкчәле кызыл түфли, башына өрфия яулык бөркәнгән. Кәс-кәс атлауларын күрсәгез сез! Урам тузанына үкчәсенең эзен калдырып үтеп тә китте. Ай-һай-һай, кем кызы икән бу? Бер дә мондый чибәр нәмәрсәкәй моңарчы күзгә-башка чалынмый иде безнең очта. Берәрсенә кунакка кайткандыр ахрысы.

Исән мин! Мондый кызлар шулай сирәк-мирәк булса да турыңнан узгалап торганда, үләсе килми шул тиктомалдан. Чурту-матыр! Шул чакта безгә чапыраш тыкрыктан Атый дивана килеп чыкты да теге кыз артыннан титаклады. Мине күрмәде дә. Югыйсә, «һайль» кычкырмый калмас иде. Тукта, мине үчекләү кайгысы моңарда юк бугай ла, ак күлмәкле кызны күзләп бара бит бу. Эзенә басып килә. Менә сиңа дивана! Алай ук дивана да түгелме әллә... мал аера белгәч... Кыз да, бераз баргач, үзе артыннан калмый ияреп килгән дивананы абайлап, кинәт туктады, кибарәнә борылып, диванага йодрыгын селекте. Атый да туктады, төпсез ыштанын өскәрәк күтәрде, шаулатып борынын тартты. Кыз исә кәс-кәс атлап юлын дәвам итте.

Мин инде клубка таба дип аягымның берсен атлаган да идем, тик Атый дивананың кыланмышын күреп, баскан җирдә катып калдым. Ул кызның үкчә эзе төшкән тузанны иелеп куш учына алды, иснәде – шул мизгелдә сез аның йөзен күрсәгез! Кашы-күзе, авызы-борыны бер ноктага җыелды – тоташ бәхет инде, мәтәлепләр генә китим. Аннары шул тузанны ул башына сипте...

Алпан-тилпән киткән Атыйны күз уңыннан югалтмыйча, мин дә клуб ягына атладым.

Клуб каршында теге кызны бик тә фырт киенгән егет көтеп тора иде. Ул да ак күлмәктән, ак чалбардан, аягында исә кара түфли. Чәче бераз бөдрәләнеп тора. Борыны төз, йөзе озынча – әртис тә әртис, бу да әртис! Таш астыннан чыккан хәзерге яшьләр, кызның биленнән эләктереп тә алды. «А-аһ...» дигән сулкылдык авазга борылып карасам, безнең дивана икән: авызы ачылган, челт-мелтләп торган кылый күзеннән тузан сарган битендә ике эз калдырып яше ага... Ул да җан иясе шул, нишлисең... Бернишләп тә булмый, Ходай шулай яраткач.

Шактый кеше җыелган – зал яртылаш тулган иде. Казан әртисләре килә, дигәч, безнең күрше Әлмира кортка да килеп утырган. Беренче рәттә утыра учын колагына куеп. Тик әртисләр алар табак битлегә ияреп йөрүчеләр генә. Алар тәк... тагылма. Башта ялыкканчы табак битлене тыңлыйсы бар әле. Менә

комач япкан өстәл янына чыгып та утырдылар. Табак битленең уң ягына Рәйсә урнашты, сул ягына Сәет чүмәште. Күкрәген киереп утыра, адәм тәганәсе генә димәсәң. Яра-ар, утырсын. Мин менә ишек төбендәге урындыкка рәхәтләнеп җәелдем. Үз иркемдә чөнки. Теләсәм – утырам, теләсәм – чыгып китәм. Ә Сәет әнә дога укып җәмәәтне амин тоттыргач, табак битлене мактый башлады. Башка чарасы юк чөнки. Бә-әк булдыклы адәм икән табак битле, депутат булса, тагын да булдыклырак буласы икән...

Халыкка ни, ул кансирт башланганын көтә. Әнә иң арттагы рәттә... Теге бая дивана Атыйның авыз суларын китергән кызый бөдрә чәчле егетнең кочагына ук кереп беткән. Белмим, аларга монда ни калгандыр. Аулаграк урыннар да җитәрлек авылда. Болар да кансиртка алданып килмәгәндер бит инде... Бәлки, кызык өчен генә кереп утырганнардыр. Юк, оят калмады яшьләрдә – үбешәләр түгелме соң чукынчыклар?! Менә шундый заманнар килгәч кенә картаеп кит инде, шайтан алгыры! Без яшь чакта кызның кулыннан тоту гына да зур мәртәбә иде, мәтәлеп кенә китим.

Рәйсә табак битлегә сүз бирде. «Иптәшләр, – ди бу, – без катлаулы заманда яшибез. Күршеләр сугыш белән яный. НАТО безнең чикләргә ракеталар куя ызначыт. Украиннар бик котырына. Ну без Быладимир Быладимирович Путинның акыллы җитәкчелеге астында бөтен кыенлыкларны да җиңәрбез». Шул урында Рәйсә җилкенә-җилкенә кул чаба башлады. Шактый гына чабып торгач, аптырап, кулларын җәйде, сез дә кушылыгыз, янәсе. Инде ничәмә-ничә еллар җыелыш күргән юк иде – онытылган бердәм булып гөрләтеп кул чабулар. Һи, без яшь чакта кирәген бирә идек инде учларның, утлар чәчри иде Леонид Ильичның акыллы җитәкчелеге астында! Чулак Галәү хәтта бер кулы белән алкышларга остарган иде.

Авыл яңа сулыш алачак икән дә бит бу табак бит депутат булып сайланса. Кызып китеп, мәктәп тә салырга сүз бирде менәтерәк. «Соң, – дип торып басты Али пужарник, – безнең мәктәп менә дигән! Хикмәт анда түгел. Авылдан, эш булмаганга, яшьләр китеп бетте, шуңа балалар да юк».

– Булышырмын! – дип вәгъдә бирде табак битле.

Шул арада клубка Атый дивана килеп керде. Күзен алартып, залны айкап чыкты. Айкыйсы юк, теге чибәр кыз белән чибәр егет һәмишә шул арткы рәттә. Кочаклашып... Һәм мин янә «А-аh!» дигән сулкылдык авазны ишетеп калдым. Аһылдады да бичара дивана, башын тотып тышка йөгерде.

Ә табак бит бөтен Рәчәй халкын бер булып укмашырга, бергә-бергә бер-беребезне беркетеп куярга өнди иде. Ахмак! Әнә арткы рәттәге ыспай егет, беркемнән кыенсынмыйча, дөньяның иң чибәр кызын кочып утыра, ә безнең дивана Атый кеше күзеннән качып, гарьләнеп каядыр олакты әнә. Ничек аларны берләштереп булсын?

– Марат Артуровичны якташ дисәк тә була, аның әбисе безнең авылдан икән, – дип, Рәйсә шатлыгын без фәкыйрьләр белән бүлеште. – Аны депутат итеп сайласак, ялгышмабыз. Районнан да шулай әйттеләр.

Аптырыйм мин кайбер иптәшләргә, районнан әйткәч, булган бит инде, аш пешкән, кем әйтмешли, сайлыйбыз бер тавыштан; нишләп йөри бу табак бит сүз озайтып, интегеп, акча туздырып... Тәртибе шулайдыр хәтә, акча туздырмый гына ярамыйдыр. Депутат буласың килсә, кансирт куй, дип язганнардыр дакументларына. Гади халыкның күңелен тап, кәефен күтәр, ягъни мәсәлән.

Шәп җырладылар. Берсе чыгып биеде дә. Күңелле булды. Без клубтан чыкканда, күк йөзен кара болыт томалап алган, салмак кына яңгыр җиле исә

иде. Битемә бер тамчы да тамгандай булды хәтта. Явып та китүе бар моның. Кәефебез тагын да күтәрелде. Рәйсә кычкырып җибәрде:

– Менә шундый ул Марат Артурович! Безгә яңгыр алып килгән!

Авыл башлыгы бит үзе, әлифне таяк дип белергә тиеш; кайдадыр укып та йөргән атлы булды, модный күлмәкләр киеп; нәрсә сөйләп торган була бит егерме беренче гасырда! Болар шундый, болар Аллаһы Тәгаләнең дә өлешенә керергә күп сорамаслар.

– Кешеләр! Кешеләр! – Кулын болгап безгә таба Атый дивана йөгерә иде. – Кешелә-әр!

Барыбыз да диванага таба борылдык. Кешеләр, ди бит, авыз тутырып.

– Мин абага чәчәге таптым!

– Нәрсә? Ни сөйли ул?

– Дивана ни сөйләмәс...

Әлмира кортка минем янга килеп баскан икән, сөяк бармагы белән эчемә төртте, тыным кысылып, бер минут катып тордым, билләһи газыйм.

– Нәрсә таптым, ди ул? Төн уртасында.

– Абага чәчәге! – дидем мин, тын алып.

– Ә?

Табак бит, Атыйга ымлап, Рәйсәгә борылды:

– Кем бу?

– Игътибар итмәгез, авыл җүләре ул, – диде Рәйсә.

Дивана исә сөрәнен сала бирде:

– Анда! Болында! Абага чәчәге янып утыра!

Сәет һәрвакыттагыча йомшак җәеп катыга утырта торган тавышы белән Атыйга үгет-нәсихәт укый башлады:

– Алай ярамый, Атый улым. Төнлә болай кычкырып йөрмә, бар, өеңә кайт, ял ит...

Тик Атый – бөтенләй үк дивана түгел лә ул! – аның сүзенә колак салмады.

– Абага чәчәге! Яна! Балкый!

Рәйсә дә, тавышын калынайта төшеп, сүзгә кушылды:

– Бар, кайтып ят, Атый. Монда синнән башка да проблем җитәрлек.

– Валлаһи! Абага чәчәге! Кып-кызыл!

– Алдыйсың, – диде чибәр кыз. – Абага чәчәге әкияттә генә була ул.

– Анда! Болында! Абага чәчәге!

Дивананың ачыргаланып кычкыруына кайтырга чыгучылар да кире килде, анда-монда капка тавышлары ишетелде. Инде бераздан клуб алдына кеше сыймый иде.

– Бөтен авылны уятты дивана!

– Дивана ул алдый белми, – диде Али күршем. – Кем белә, бәлки тапкандыр да. Берәр кызыл чәчәк.

– Исеңдәме, сугыштан соң Корбан абзый кинәт хәлләнеп киткән иде. Алты почмаклы йорт җиткерде, түбәсен калай белән япты.

– Кулы һөнәр белә иде, – дип, Али шик тулы күз карашын минем борынга терәде. – Аннары ул Германиядән бер чумадан энә апкайткан.

– Һөнәрлеләр күп иде. Синең һөнәрең юк идеме? Энә белән дә ерак китеп булмый. Абага чәчәген тапкан, дип сүз чыккан ие, исеңдә юкмыни?

– Шәкүр каракны да шулай сөйлиләр иде бит, абага чәчәген авызына каба да, күренмәс булып, ат абзарына үтә. Син күр дә мин күр аннары атны... – Сәет үз сүзеннән үзе көлеп куйды.

Әмма табак бит көлмәде, Сәеткә якынрак елышты.

– Мөмкин хәлме соң бу, хәзрәт?

– Алланың кодрәте зур, – дип, Сәет тагын кыска гына көлде.

Бер малай – районда укып йөрүче бишәүнең берсе булса кирәк – хыялланып алды:

– Авызга кабасың да чәчәкне – рәхәтләнеп әллә кайларга керәсең. Банкка! Кибеткә!

– Бәлки, бу безгә Алла шәфкатедер? Авыл белән кредитта утырабыз, – диде алтын тешле бер кортка.

– Барып карарга кирәк! – дип кычкырды кемдер.

– Ну яшәп күрсәтер идек!

Чибәр егет ачу катыш өмет белән диванага төртеп алды.

– Алдыйсың бит, падла?

– Әйдәгез, барып карыйбыз. Әгәр алдаса, тотып тукмарбыз, – диде чибәр кыз.

Барыбыз да сораулы карашыбызны табак биткә юнәлттек. Ул бит депутат буласы, районда шулай әйткәннәр, акны карадан аера беләдер, юл күрсәтсен безгә.

– Дивана юл күрсәтсә, барып карарга була, – диде булачак депутат. Күреп торабыз, аның күзе яна, төшемле эшне алар бит әллә кай төшләре белән сизә, мәтәлеп кенә китим.

– Атый болыны моннан ерак түгел, – дип, Рәйсә табак битнең сүзен җөпләде. – Хәзрәт ни әйтер тагын.

Сәетнең дә борын сизгер, мондый эштән читтә каламы инде? Киттек шулай бөтен авыл белән болынга. Дивана алдан җилдерә, без дә калышмыйбыз. Кемдер инде машинасын да кабызып чыккан, фара яктысы бөтен дөньяны айкап бара.

Теге малай һаман хыялыннан аерыла алмый әле, пышылдарга тырышып әйтә салды:

– Күзгә күренмичә, беләсезме, мин кая керер идем?

– Оятсыз! – дип бер кыз аның кәпәчен бәреп төшерде. Малай, аптырап, кәпәченә иелде.

– Кремльгә! – диде ул. Анда нишләргә уйлагандыр, беркем дә сорап мәшәкатьләнмәде, һәркем үз хыялы белән мәшгуль иде.

Болынга килеп җиттек, дивана туктап калды. Анда-монда караштырды.

– Менә монда ие... – дип эзләнде ул. – Монда гына ие бит...

Барыбыз да абага чәчәген эзләргә керештек. Без капшап карамаган үлән калмагандыр якын-тирәдә. Абага чәчәгенең исе дә юк иде.

– Падла! Әйттем бит, алдады! – дип, чибәр егет дивананы сугып аударды.

– Тондыр берне! Күпме эшне калдырды! – Чибәр кыз, егетенә көч биреп, бер урында сикергәләп алды.

– Алдады! – Рәйсә, чәрелдәп, дивананың чәченә ябышты. – Безне бер хәл, ул бит кунагыбызны, кадерле депутатны алдады.

– Провокатор! – дип кычкырды кадерле кунак. – Хөкем итәргә кирәк, ул бит рөхсәтсез генә күпме халыкны җыйды. Санкциясез...

Дивана чайкала-чайкала аягына басты.

– Таптым, – диде карлыккан тавыш белән. – Менә ул! – Аның кулындагы кып-кызыл чәчәк, әйтерсең лә безнең барыбызны да нурга коендырып, җемелдәп яна иде. Барыбыз да сүз әйтергә дә кыймый тораташтай калдык.

Беренче булып табак бит телгә килде:

– Йә, кем, җүләр, кабып кара әле чәчәгеңне!

Дивана, кызыл чәчәкне күкрәгенә кысып, тик кенә тора бирде.

– Кап, диләр сиңа! – Чибәр егет, йодрыгын йомарлап, диванага якынлашты. – Кап!

– Әйе! Бәлки, ул шайтан таягының чәчәгедер...

– Җәһәт бул!

Дивана чәчәкне акрын гына авызына китерде.

– Кап!

Әйе, искә төшерсәм, хәзер дә дерелдәп китәм: капты чәчәкне дивана һәм шундук безнең күз алдыннан югалды да. Һәммәбез шашып калдык. Менә бит алда нинди мөмкинлекләр! Һи, мондый тылсымга ия булгач, яши әле авыл, яши! Табак бит кенә алдап-йолдап үзләштерә күрмәсен, әнә күзе чәчәктән дә битәр яна.

– Җүләр, акыллым, син кайда? – дип, чибәр кыз сүз каткач кына аңга килдек.

– Чәчәкне авызыңнан ал! – дип кычкырды табак бит.

Ләкин диванадан тавыш-тын чыкмады.

– Атый, бәгърем... Булды, ышандык, бир чәчәкне, – дип инәлде Рәйсә.

– Чыгар чәчәкне, бирән!

– Безгә дә калдыр!

– Чолгап алыйк, кача күрмәсен!

Шул чакта дивананың хәлсез тавышы ишетелде:

– Мин аны ялгыш йоттым...

«Ахмак! Дивана!» – ди-ди, без аны эзләргә керештек, болын тапталып бетте, тик Атый дивана һавада эрегәндәй юкка чыккан иде. Хәтта тавыш та бирмәде мәрхәмәтсез. Нишлисең, язмагандыр безгә күренмәс кеше булып рәхәт чигеп йөрергә. Аның өчен дә дивана булу кирәктер. Башны иеп, бер-беребезгә карарга читенсенеп, авылга таба атладык. Теге чибәр кыз гына һаман өметен өзми иде әле, бездән калып та дивананы дәшеп маташты:

– Дивана акыллым, тавыш би-ир! Мин сине яратам!

Җавап булмагач, ул да, өметен өзеп, безгә иярде.

Кайтып киттек диванабызны югалтып. Шуннан соң инде аны бүтән күрүче булмады.

Күк йөзе аязды, тулып килгән ай безгә карап тыелалмый көлде, буаз болытлар, авылыбызны урап, каядыр көнбатыш ягына агыла иде.

## Нәзирә

Табибә хатынның соры күзендә кызгану чалымын искәреп алдым. Бер мизгелгә генә миңа караш ташлап алды югыйсә. Аннары, өстәлдәге кәгазьләрен актаргалап, сүрән тавыш белән әйтеп куйды:

– Иртәгә сәгать сигезгә ашамый-эчми килегез әле. Каныгызны тагын тикшереп карарга кирәк.

Йөрәгемнең өшеп куйганын сиздем. Ашказаным, тартылып, тамагыма менде. Аркага салкын тир бәреп чыкты.

– Ә монысы... начар булдымыни?

– Кабат тикшерергә кирәк! – диде табибә, кырыс кына. – Сау булыгыз.

Чыгып киттем. Һай, сау буласы иде дә бит, тик сау кеше беренче тикшерүдә

үк сау буладыр инде ул. Алай дисәң, табиблар да гел ялгышып тора. Иртәгә күз күрер, борынны бөтенләй төшермик әле...

Поликлиникадан чыкканда яңгыр сибәли иде. Аяк астында кар катыш ком буткасы. Гыйнвар бит бу! Әле кичә генә телевизордан тоташ кара киемле бер поп «керәшен суыклары» вәгъдә итеп нинди сөендергән иде бөтен илне. Каратуннар күзенә карап торган көнебез. Бәлки, берничә тәүлектән килеп җитәр аның вәгъдә иткәне. Мәскәүдәге көн торышы Казанга шул арада күченә иде, гадәттә.

Ярар ла, сәламәт булсаң, кышкы яңгырдан да ямь табып була. Ләкин мин хәзер бераз аңгыраеп калган идем. Үзәк паркка таба борылып, автобус тукталышына чыгарга тиеш булсам да, мин кире якка – Вишневский урамы буйлап түбән очка төшеп киттем. Киткәнче поликлиниканың биш катлы соры бинасын кабат күздән кичердем әле. Без студент чакта аның беренче катында «Таң» ресторанны, өстәге катлар шәһәргә килгән авыл хезмәтчәннәре өчен кунакханә иде. Заманында беренче катта без шактый еш кунак булдык. Өч тәңкәгә рәхәтләнеп сыйланырга була иде ресторанда.

Караңгы төшеп килә иде, ул инде күземне әчеттереп миемә үтәргә маташа; күк гөмбәзенең исә түбәнәюен лепкәм белән сизәм, менә-менә мине сытар төсле; тик бөтенләй үк төшеп китмәс ул, аны күтәреп торган офыклар шәһәрдә күренми генә бары. Элек түрә-кара дәваланып ята торган затлы хастаханә бакчасын урап торган таш дивар буйлап Шмидт урамына кадәр төштем дә җир асты юлыннан сулга борылдым. Мин монда күптән булганым юк, караңгыны биткә сылап, һәмишә карлы яңгыр ява, әмма барыбер күренә иде әле – безнең яшьлек узган урам түгел инде бу. Юк, бөтенләй үк җир йөзеннән себереп түгә алмаганнар, ахрысы: әнә теге почмак йорт ипи кибете иде. Еш кына без аннан җылы күмәч сатып ала идек. Авызда эреп тора иде инде, э-эх... Нәзирә шушы урамны аерата ярата иде. Бигрәк тә язгы кичләрдә – терелеп киткән карт юкәләрнең хуш исенә уранып йөрергә гадәтләнгән идек. Урам аулак, тыныч һәм аны яшеллек күмгән иде. Ике якта да ник бер таш йорт булсын. Тик агач йортлар гына. Ике катлылар шактый, аларның инде беренче ятажы кирпечтән була гадәттә. Таза, нык утыралар. Монда йөргәндә, күңел әллә нинди сәер халәттә була – болар бит инде гасыр башында ук булган, бәлки, теге гасырда ук! Урам шуннан соң әллә ни үзгәрмәгән дә. Ике як тротуарга җәелгән плитә-плитә ак ташы да сакланган. Мөгаен, ул заманнарда урам түшәлмәгән булгандыр, канау буйларын куе үлән басып киткәндер. Аларның тамыры корымаган әле, койма буйларында шыгырдап утыручы карт тирәкләрнең, юкәләрнең аяк астында ишелеп чыкканнар да үзара пышылдашып ни турындадыр серләшәләр. Һәр йортның түрендә җимеш бакчасы күренә. Иркен яшәгәннәр шәһәрнең бу ягында. Чын хуҗаларча. Кайбер йортларның укасы әле дә коелып бетмәгән. Бу – Казанның өске, ару ягы, патша вакытында монда татарның эзе дә булмаган, билгеле. Монда зур мәгъмүрләр, бай интеллигентлар, шәһәрдә кыш уздыручы алпавытлар яшәгән. Шуларның зәгыйфь шәүләсе әле дә кайбер кичләрдә коймаларга сыенып каядыр ашыга сыман. Хәзер инде биредә бөтенләй бүтән кешеләр тора. Коммунизм төзүчеләр. Алар өйләрнең эчен вак тартмаларга бүлгән, ишегалларын иске такталардан корыштырган чалыш-чолыш кетәкләр, утын сарайлары белән тутырганнар. Ә кайбер йортларның капка-коймалары юк, мөгаен, сугыш елларындамы, соңракмы, каерып-сүтеп, ягып бетергәннәр.

Алар биек кенә таш нигез өстендә такта белән тышлап, сарыга буялган, парадный ишеге һәм дүрт тәрәзәсе урамга караган йорт янына туктыйлар иде.

Иясез малны эт җыймас – кайчандыр сагызы суыртылмаган нарат бүрәнәләрдән салынган йорт инде шактый какшаган, капка-коймасы да шактый тузган, капкасы бөтенләй артка таба авышып тора... Нәзирә шул капка төбендәге шомарып беткән эскәмиядә утырырга ярата иде. Миңа сыенып... Хәзер генә мин аны бөтен төгем белән аңлыйм. Чын, асыл хатын-кыз бигрәкләр дә йорт җанлы була бит ул. Нәзирә шундый асыл кыз булган, тик мин ул чакта аны аңларлык кешемени?! Мин ул чакта бит дүңгәләк, очраклы җил дә мине әллә кайларга тәгәрәтеп китәчәк иде. Китте дә шул, Нәзирәдән бик еракка алып китте.

– Син беләсеңме соң, – диде Нәзирә, шул капка төбендә соңгы тапкыр утырганда. – Бу нинди йорт?

– Нинди дип... – Мин артка каерылдым. – Элек сары булган инде бу мотлак. – Без аның белән юри шулай иске сүзләр кыстырып сөйләшә идек.

Нәзирә борынын җыерды.

– Һе, сары... Әмирхан Еники сурәтләгән йорт бу! Хәтерлисеңме, Зөфәр Сабитов өйләнер алдыннан йорт сатып ала... Шушы йорт инде ул...

– Әйе, мондый йортың булса, өйләнергә дә булыр иде.

Нәзирә елмайды. Белмим, йөзен әллә язгы кичнең тыгыз зәңгәрсу һавасы сырып алгангамы, аның елмаюы миңа мәэюс булып тоелды. Әйе, хәзергечә әйтсәк, өметсез елмаю иде ул. Күңеленнән ул миңа кул селтәгән иде инде. Үзем дә беләм – төплелек җитми, тормыш итәр өчен ни кирәк – берсе дә миндә юк! Нәзирә, әлбәттә, бу мәсьәләдә башка кызлардан берни белән дә аерылып тормый. Ул минем томанлы киләчәк белән нишләсен? Киләчәккә өметләрне түбә итеп өскә җәеп булмый. Нигез юк, буласы да күренми. Ә ул тиздән укуын тәмамлый, аңа инде егерме ике яшь – кызлык гомере кыска... Бер атнадан ул диплом алачак, юрист! Аны инде кайсыдыр район үзәгенә эшкә җибәрәләр. Ә мин кем? Диплом якларга кертмәделәр, эшкә алырга беркем җыенмый. Торырга урын юк, кесәдә җил уйный... Иң кызганычы – башымда уйный ул. Зөфәр Сабитов... Нәзирәгә шуның ише ышанычлы, булдыклы кеше кирәк. Ул бәхетле булырга тиеш. Мин аңа уңышлар теләп кул болгармын. Акрын гына поезд кузгалып китәр, вак кына яңгыр сибәләр, вагон тәрәзәсендә аның юеш йөзе соңгы тапкыр чалынып алыр...

– Нәзирә... Нәзирә... – дип, иңеннән кочтым мин аның. – Нигә син безнең әдәбият бүлегенә кермәдең? Нигә юрист булырга уйладың? – Әйтерсең лә бөтен хикмәт шунда!

– Әни... – диде ул акрын гына, – рөхсәт итмәде. Минем ялгышны кабатлама, диде. Ул бит үзе сезнең бүлекне тәмамлаган иде.

– Нәзирә... Нәзирә... Синең исемең үк әдәби термин...

– Әйе, урта гасыр шәрекъ әдәбиятында киң таралган иҗат ысулы, поэтик форма. – Нәзирә күңелсез генә көлеп куйды. Ул, юрист буларак, һәрнәрсәгә төгәл билгеләмә бирә иде. – Башка бер авторның әсәрен өлге итеп яисә аңа җавап итеп языла ул нәзирә...

– Ләкин нәзирәче үз әсәренә өр-яңа төсмерләр өсти...

Нәзирә минем сүзне кисте:

– Ни генә дисәң дә, беренчел түгел инде ул! – Аның шулай сүзне кисәк кенә бүлә торган гадәте бар иде, кинәт урыныннан торды да, борылып, яңадан иске йортны күздән кичерде. – Әйдә! Кайтырга вакыт.

Без поездлар үтеп йөри торган ерымты өстенә сузылган тар күпергә таба киттек. Нәкъ каршыда аның тулай торагы иде.

...Хәзер дә мин менә шул күпергә туктап, поезд юлына карап торам. Инде караңгы, берни дә күренми, җил көчәйде, карлы яңгыр йөземә бәрә; ләкин мин анык беләм: аста юл бар, ул еракка-еракка сузылган – теләгәндә барыбер каядыр кузгалып була, юл сине барыбер каядыр алып китәчәк. Тик кая гына барма, иртәме-соңмы вагоннан төшеп калырга туры килә...

Перронда үз поездыңны көткәндә, нинди бәхетле син! Хәер, андый чакта ниндидер бәхет турында уйламыйсың да, аңа синең вакытың да юк, сүз белән аңлатып булмаслык әлеге төшенчәгә кагылышлы нәни фәлсәфәне син кирәксенмисең дә, нигә ул? Әнә ике рельс, бер-беренә тиң булып, офыкка таба сузылган, алар аерылмый да, кавышмый да, искиткеч мөкәммәл янәшәлек! Синең гомерең дә үз көен югалтмыйча шундый юлдан бик озак алга тәгәрәр сыман. Әле син гомер юлының чуалып китү куркынычын башыңа да китермисең.

Әле дөньяда яз тантана итә! Шундый язгы көннәрнең берендә, инде кичкә авышканда, көләч юкәләрнең хуш исен ияртеп, мин «Таң» ресторанына килеп кердем. Кичкә таба Казан рестораннарына керү ул елларда шактый кыен булса да, безнең монда юл такырайган, ишек төбендә торучы швейцар үзебезнеке – кул биреп күрешкәч, үткәреп җибәрде. Күкрәкне киереп (мондый хөрмәт теләсә кемгә тәтеми), сул якка борылдым. Барысы да таныш, барысы да якын: түшәмдә зәп-зәңгәр төтен тирбәлә, пычак-чәнечкенең тәлинкәләргә бәрелгән авазын басып, зал түрендәге бәләкәй сәхнәдә дүрт кешелек ансамбль тавыш куптара. Җырчы белән барабанчы чем-кара сакаллы, бөдрә чәчле ике юантык ассирияле, гитара асканы минем ахири Рәшит – ул күбрәк япон тактасын уйната; саксофон өрүче Штейнберг дигән яһүд, фәкыйрегез монда очраклы әләкте, дигән сыман читтәрәк басып тора. Мин кергәндә, олы корсагына ике кулын кушырып, ассирияле Каландарян дәртле татар җырын, кисәкләргә бүлеп, корт күчедәй гүләп утыручы халаяк өстенә ыргыта иде: «Тәвәккәллә, тәвәккәллә, тәвәккәллә, иркәм!» Шактый таушалган өч хатын белән ике авыл агае әлеге музыкага яраклашмый гына үз көйләренә биеп маташа. Мин, урын эзләп, залга күз йөгерттем. Әнә теге очта кемдер берүзе аерым өстәлдә утыра түгелме соң? Мин төпсә күтәреп шул якка ашыккан официант хатынга эндәштем:

– Гуля! Хәерле кич, бәгырь... Урын тап әле миңа.

Ул, башын нәзакәтле борып, сүзсез генә мине үз артыннан иярергә ишарә ясады. Өстәл янында ялгызы утыручы абзый юк-бар кешегә охшамаган иде. Ул үзе гади киенгән сыман: бераз таушалганрак зәңгәрсу лавсан костюмнан, кара сызыклар төшкән ак күлмәккә зур төенле кызыл галстук таккан; зур коңгырт күзле, төз итләч борынлы, маңгае киң, кыска итеп алдырылган чәче кайчандыр бөдрә булган ахрысы – лепкәсенә буйсынмыйчарак ята... Чырае шешенке. Шәһәргә берәр семинарга килгән колхоз рәисе булса кирәк. Перси... Болар, гадәттә, мондый сәфәрләргә бер капчык акча белән йөри. Мең мәшәкатьле эштән, хатын мырлавыннан арынып, бер тугарылып аласы! Ул миңа күз генә төшереп алды да кулындагы фужерын авызына китерде.

– Рөхсәт итегез, – диде Гуля, йөзенә елмаю кундырып, – бу егет монда утырсын әле?

Абзыйның тавышы куе иде, идарә итәргә өйрәнгән тавыш:

– Студентмы?

Таныш иде миңа бу тавыш, ишеткәнем бар иде кайдадыр. Тик искә төшереп

интегәсем килмәде, музыка шаукымы инде мине биләп алды, кимендә бер атна арынып булмаячак: тәвәккәллә, тәвәккәллә, тәвәккәллә, иркәм!

– Студент, тагын кем булсын, – дип, Гуля аны җөпләде.

– Утырсын! – дип, абзый, чын хөкемдарларча кулын җәеп, мин фәкыйрьгә үзенең рөхсәтен бирде. Шунда гына мин аның шактый кызмача икәненә төшендем. – Тагын бер графин китерегез, – диде ул Гуляга. – Студентка итле ризык... Кәбәб... Кыздырылган үрдәк... Әфлисун соусында, – дип өстәде ул. – Лә оранж...

Гуля кеткелдәп көлде:

– Баш өсте, император!

Бераздан ул бәрәңге боткасы белән ике котлет, салат, чәй китерде. Коньяк салынган графинны өстәл уртасына утыртты, буш рюмканы җәһәт кенә миңа таба шудырды. «Рәхмәт, сеңлем», – дип, абзый Гуляның бил турысына җәһәт кенә кулын тидереп алды. Әйе, юк-бар кеше түгел бу... Гуляның шат йөзенә караганда, кесәсенә шактый мул чәйлек кергәнгә охшый. Абзый шәп! Бик тиздән «Калхуз – диңгез, без – парахут, теләгәнчә йөзәбез!» – дип җырлап җибәрергә дә озак калмаган.

– Йомырка тәбәсе яратасыңмы? – дип сорады ул кинәт.

– Үлеп, – дидем мин бәрәңге боткасын авызга озаткан арада.

– Дөрес эшлисең... Йомырка тәбәсе! – дип кычкырды ул Гуляга. – Студент чагында ярата идем мин дә, – дип зарлангандай, миңа рюмкасын сузды. – Хәзер төсен күрәсем килми. Әйдә, танышу хөрмәтенә...

Мин каршы килмәдем. Танышып ук бетмәсәк тә, коньякны дусларча йотып куйдык.

– Кайсы факультетта укыйсың?

– Филология!

– Татарныкындамы әллә?

– Әйе.

Ул, җанланып, кулын миңа сузды:

– Бир кулыңны, коллега!

Мин гаҗәпләнмәдем, безнең бүлектән егетләр киң профильле булып чыга, араларында колхоз рәисләре дә шактый. Абзый да шундыйлардан, мөгаен. Менә ул, кулын өскә чөеп, күзен яндырып, шигырь дә укый башлады:

Аңласаң аңла хәлемне, аңламасаң, синең эш...
Мин бүген яшьлегем белән саубуллашырга тиеш!

Ресторан түрендәге ансамбльнең дә гөрелтесен басып китте бу. Якын-тирәдә утыручылар, кашык-чәнечкеләрен куеп, башларын безнең якка борды. Абзыйның тавышы сафланып, төбендәге ташлары аерымачык күренгән тау елгасына охшый башлады. Кайда ишеттем соң мин моны? Авылдамы? Каландарян җырлавыннан туктады, бөтен зал тын да алмый абзыйны тыңлый иде.

Тауларга йөгереп миним – яшеннәр оясына.
Кешеләр: «Юләрме әллә», дип уйласа уйласыннар![5]

Минем каршымда, чыннан да, каядыр өскә алгысынган шук малай, бөтен

[5] Равил Фәйзуллинның «Саубуллашу» шигыреннән.

йөзе белән балкып, мондагы төрле кавемнән хасил халаякны сүз иркенә иярткән иде. Хәер, сүз ирке микән соң бу? Залның яртысы аның ни сөйләгәнен аңламый да бит. Тавышы шулай сихерләде барыбызны да... Ул сүзен тәмамлауга, барысы да дәррәү кул чаба башлады. Абзый, үз кадерен яхшы белгән мәшһүр артисттай, иренеп кенә баш иде.

– Йә, кем шигыре? – диде ул миңа.

Үз шигырен укыды микәнни, дип уйладым мин. Туфракта кайнашучылар, гадәттә, романтик була, әнә бу да яшеннәр оясына менмәкче...

– Шәп шигырь! – дип, юкә чөй кыстырдым мин. – Үзегез яздыгыз мәллә?

Абзый яхшы күңелле иде, башта киң учы белән битендәге мәсхәрә чалымын сөртеп төшерде.

– Их, син, студент, шактый ук надан икәнсең бит, таем. Тукай белән Җәлилдән башка татар шагыйрьләрен ишеткәнең бармы соң?

Мин эндәшмичә генә фужердан су уртлап куйдым. Йөзенә бәреп әйтәсе килгән иде дә бу гыйбадның... Равил Фәйзуллинның үзе белән табында утырган кеше мин! Тик телемне тыеп калдым. Аның кесәсеннән сыйланып утырганда, ничек тавыш күтәрәсең? Мондый чакта хәтта Равил Фәйзуллинның да, нинди генә көрәшче шагыйрь булмасын, тыны чыкмас иде. Тавыш күтәрергә бүген бу абзыйның гына хакы бар! Без менә шулай рестораннарда да конформизмга өйрәнеп сабак алган буын.

– Ю-у-ук! Син аңлый алмас идең мине – студент син... Кефир малае!

– Зөлфәт... – дидем мин, ваемсыз гына, белү тантанасын эчемә йотып.

Абзый миңа кызыксыныбрак карады, бөтенләй үк беткән кеше түгел икән, янәсе.

– Иң яраткан шагыйрең кем? – дип, сул күзен кыса төшеп сорады ул.

Мин аны тәмам аяктан егарга теләп ярып салдым:

– Хуан Рамон Хименес!

– Әйе, – диде ул, күзен дә йоммыйча, – Антонио Мачадо аның хакында югары фикердә булган. – Аннары, хәйләкәр елмаеп, сигаретын кабызды. – Испан телен беләсеңме?

– Урысча тәрҗемәдә укыйм... – Ялганларга кыймадым, шайтан белсен, бәлки, ул универда испан телен өйрәнгәндер, гәрчә моңарчы чит телне иркен белгән студентны очратканым булмады. – Сез беләсезме әллә?

– Ипи-тозлык, – дип, тыйнак кына елмайды ул. – Университетта алман телен өйрәнгән идем. Итальян теленнән соң испан теле җиңел китә.

Менә сиңа авыл гыйбады! Сырадан соң аракы әйбәт китә, дигәндәй генә сөйләнеп утыра.

– Чәчүне бетереп килдегезме? – дип, мәүзугны үзгәрттем мин.

– Андый эшләр белән минем хатын шөгыльләнә. Ул ярата бакча мәшәкатен. Бераз булышкан атлы булам инде. Бүген менә алмагачлар кәүсәсен акшарга буяп кайттым.

– Сез авылныкы түгелмени? – дидем мин, аптырап.

Ул зур башын артка ташлап, ботын чаба-чаба рәхәтләнеп көлде, безгә якын тәрәзә пыяласы зеңгелдәп куйды хәтта.

– Аңлашылды! Бу бит персидәтелләр ресторspringы. Син инде бер авыл мокытын кармакка эләктердем, дип эчтән сөенеп... Шагыйрь әйтмешли, күңелең мәтәлчек ата иде. – Ул, кесәсеннән шакмаклы кулъяулык алып, күзеннән атылып чыккан яшен сөртте. – Мокытлык бар инде ул бездә, яшерен-батырын түгел... – Минем бакчага таш атты бугай. – Кәефең төшмәсен, соң

мин үзем дә студент булган кеше бит, үтәли күрәм сезне. Ә болай авылда туган кеше мин, кәнишне. Ырымбур даласында.

Исемен сорарга, кем булуын белешергә мән җитмәгән бит шунда. Соңыннан күпме үкендем шуңа, күпме тиргәдем үземне. Тик үкен-үкенмә, терсәкне тешләп булмый иде.

Без кайтырга чыкканда, төн уртасы җитеп килә иде инде. Урамнар тынып калган. Хәзерге кебек төнне көннән аермаслык шайтан туе – машиналарның бер-бер артлы выжылдап үтеп торуы юк иде әле. Вакыт та салмаграк ага иде. Һәрхәлдә хушлашырга, саубуллашырга күпмедер вакыт табыла иде.

Студентлар шәһәрчегенә керер алдыннан, ерымты өстендәге тар күпердә без Себергә ашыгучы Абакан поездын озатып калдык. Астагы поездның куәтле ухылдап алга томырылуыннан без басып торган тар күпер бөтен гәүдәсе белән сизелер-сизелмәс дерелди, менә-менә ике ярны тоташтыру вазифасыннан ваз кичеп, үзе дә гүя ерак билгесезлеккә кузгалырга җыена иде. Поезд җиле яр өстендәге сирень куакларын кайнатып алды, күзне әчеттереп, җиһанга шәмәхә ис таралды; кайдадыр якында сандугач, нигә мин мондый язгы кичтә тынып калдым әле, дигәндәй, үзен битәрләп, өздереп сайрый башлады.

Поездлар көнбатышка да, көнчыгышка да ары-бире тиң чапкандыр, әмма хәзер, нилектәндер, гел Себергә ашыгучылары гына күз алдына килә... Алар ул якка җиңеләеп тә, үзләренә күрә бер тиле ашкыну белән дә, әйтерсең лә башларын югалтып, җилдерә – андагы киңлекләр, андагы мөмкинлекләр, канны кузгатып, безне дә алгысыта иде. Юк, көнбатышка, Мәскәүгә ашкынучы поездларны мин бөтенләй искә төшерә алмыйм.

– Ул шушында яшәгән иде, – диде табындаш абзый, уйларымны бүлеп.

– Кем? – дип сорадым мин саксыз.

– Нәзилә... – Ул кулын сузган яктагы өч катлы бинаның тәрәзәләре балкып тора, сап-сары диварлары да аермачык күренә, әле кем йокласын бу вакытта... Бина иске, Сталин вакытында ук салынган, шуңа да түшәме биек, стенасы калын. Ул заманнарда бит берне салганнар, әмма берәгәйле итеп. Бу тулай торак та, күрәсең, аспирантлар, яшь галимнәр өчен махсус салынган булгандыр. Әлбәттә, кайбер бүлмәләр элек-электән укуда өлгер, «җәмәгать эше» дип аталучы матавыкта иркен йөзүче студентларга да эләгә. Аларны шулай яшьли иркәләп, кызартып үстерәләр иде.

Без ун-егерме адым атларга да өлгермәдек, әлеге тулай торак, сары төсе белән язгы зәңгәрсу караңгылыкны ертып, гүя үзе каршыбызга килеп басты.

Сизеп торам, абзый бик дулкынлана – абына язып, бинаның урам ягына чыкты, сул яктан өченче тәрәзә каршында туктап калды. Тәрәзә караңгы иде. Нишләргә дә белмичә, мин дә кыенсынып кына шунда килеп бастым. Сәер абзый булып чыкты бу... Нишләмәкче була икән? Шушы тәрәзә артындагы бүлмәдә кайчандыр аның бик кадерле кешесе яшәгәнен аңлаган идем инде. Мөгаен, сөйгән кызы булгандыр. Һәм бу мәхәббәт гаять фаҗигале тәмамланган ахрысы. Югыйсә чын мәхәббәт буламыни ул?!

Яз галәмәтедер, дип уйлыйм хәзер, дөньялыктагы түбән гөманнар белән бу затлы язгы төннең кадерен җуясым килми, абзыйның аңында вакытлар буталган иде ахрысы – ул ике учын авызына китереп кычкырды:

– Нәзилә-ә!

Зыялы, инде шактый өлкән – кырыктан өстә! – кешедән мин моны көтмәгән идем. Читкә тайпылырга өлгермәдем, тагын шул ук зарыккан тавыш, тәрәзәгә бәрелеп, тирә-юньгә таралды:

– Нәзилә!

Шул чакта ут кабынып китте дә чәчләре тузгыган бер кыз тәрәзәгә капланды. Йа Хода, бу бит минем белән бергә җиңел атлетика төркемендә йөри, безгә спорт залы итеп бирелгән ташландык иске чиркәү эчендә атнага ике тапкыр сәгатьтән артык йөгерәбез. Озын торыклы, миннән бераз калкурак та бугай. Исемен генә хәтерләмим, юридик факультетта укый шикелле; бик эре күренгәнгә, танышырга кыймадыммы соң... Хәер, бездә кызлар шулкадәр күп иде, барысы белән танышып та бетәрлек түгел. Кайчандыр бергә укыганнар белән мин һәмишә танышып йөрим.

Әлеге кызны күргәч, абзый бөтенләй шашкандай булды, үзен-үзе белештермичә: «Нәзилә-әм!» – дип кычкырып, тәрәзәгә таба омтылды. Чак тотып калдым, Алла саклады. Кызның бу матавыкка исе китмәде, кулын болгап елмайды да юкка чыкты. Шул минутта ук тәрәзәдә ут сүнде.

Абзый, башын иңемә салып, сулкылдый-сулкылдый елый иде. Мин аны юатырга теләп, аркасына каккаладым, бик бетеренмә, янәсе, андый гына хәлләр була; нинди хәлләр була? – анысы миңа караңгы иде ул вакытта.

Кутуй урамына чыккач, шактый озак такси көттек. Ниһаять, калтырча гына бер «Москвич» килеп туктады. Тәрәзәдән битен өч көнлек сакал баскан тау кешесе башын тыкты:

– Куда нады?

– Гарифҗанов урамына! – Абзый инде тәмам тынычланган иде, машинага утырыр алдыннан шакмаклы кульяулыгы белән битен, борынын сөртә-сөртә, кыенсынган кыяфәттә башын читкә борып акланды:

– Ышанасыңмы, теге кыз нәкъ Нәзилә иде. Суйган да каплаган. Ышанасыңмы?

– Ышанам! – Нигә ышанмаска, төрле хәлләр була дөньяда. Хәзер инде мин дә тәгаен беләм: кырыктан соң кызлар чибәрлектә бер-берсенә тиң була бара...

– Рәхмәт! – дип кулымны кысты абзый. – Әйбәт җегет син.

Икенче көнне дәрескә барам дип чыксам – теге кыз Әбҗәлил тукталышында басып тора! Яз галәмәтедер, дип уйлыйм хәзер, һәм бүтән дөньяви гөманнар белән бу искиткеч танышуның кадерен җуясым килми; мин бу иртәдә, үземә охшамаганча, гаять тә кыю идем, туп-туры кызга таба киттем. Уң кул чугын йөз турындарак селеккәләп: «Сәлам!» – дип кычкырдым.

Ул миңа шундый гаҗәпләнеп карады!

– Сез... – дип сүзен башлаган иде, аннары көмеш чишмә челтерәгәндәй (тапталып беткән чагыштыру өчен таләпчән укучымнан кичерү сорыйм) көлеп җибәрде. – Кем белән йөри идең син төнлә? – Аның шулай гади, үз итеп сүз башлавына кинәнеп, башыма кан йөгергәндәй булды.

– Белмим... Юк, беләм... Мин аның белән кичә генә таныштым... Ул саубуллашты...

– Синең беләнме? – Ул тагын челтерәде.

– Яшьлеге белән...

– О-о, алайса эшләр җитди.

– Әйе, уен эш түгел.

– Нигә минем тәрәзә каршында саубуллаша соң ул?

– Анда аның сөйгән яры яшәгән ахрысы. Нәзилә исемле...

Кызның йөзе кинәт үзгәрде. Әйтерсең лә аңа бәз тастымал яптылар. Ап-ак ирене беравык хәрәкәткә килергә интегеп торды да, ниһаять, тонык авазлар кысылып чыкты:

– Нәзилә – минем әнинең исеме...

Мин көтелмәгән фараздан куырылып куйдым. Һәм кыз аны раслады!

– Студент чакта ул да шул бүлмәдә торган. – Бераз тын алгач, ул мин куркып көткән сорауны бирде: – Кем иде ул теге кеше?

– Белмим, – дип җилкә сикерттем мин. Чыны да шул иде. Без ул абзый белән кешечә танышмадык та бит. Кичәге очрашу да мөкаддимәсе һәм ахыргы сәхифәләре югалган иске кулъязма уку белән бәрабәр булып калды. Эчтәлеген аңлыйсың, ләкин кем язган, кайсы дәвердә – анысы билгесез.

– Сез аның белән бүтән очрашмыйсызмы?

– Юк. Без очраклы гына күрештек...

Ул арада троллейбус килде. Гадәттәгечә дыңгычлап тутырылган әрдәнә кебек иде эчтә, барысы да дәрескә ашыга; көч-хәл белән почмакка кереп кысылдык. Кыз бөтенләй минем кочакка кереп бетте.

– Мин Нәзирә булам... – Җылы нәзек бармаклары минем учымны эзләп тапты. – Син инде ике занятиене калдырдың. Физрук эттән алып эткә салды үзеңне. Будем исключать, диде, шулай дәвам итсә...

– Әйе шул. Иртәгә йөгереп килермен.

– Йөгерешче! – дип көлде Нәзирә.

– Бүген кич белән нишлисең? – дидем, кыюлыгымны җыеп. – Киного бармыйбызмы? «Мир»да шәп комедия күрсәтә башлаганнар. Финнар белән бергә төшергәннәр. «За спичками». Әкәмәт көлке, диләр. Леонов, Вицин...

– Әйе шул, Гайдайныкы! Аның инде гел шулай – көлкесез булмас. Билет булыр микән соң?

– Табабыз! – дип мактандым мин.

Сүз белән мавыгып, Ленин бакчасын узып китә язганбыз икән – троллейбус бушап калгач кына аңга килеп, ишеккә ташландык.

– Кичәге абзыйны чынлап белмисеңме? – диде ул. Дәрескә керер алдыннан без яшь Ульянов һәйкәле янындагы эскәмиядә бераз утырып алдык. Юристлар колонналы төп бинада укый икән. – Мин бит син кычкырасың дип торам. Нәзирә, дип ишеттем... Белгән булсам...

Теге абзый кычкырганны белсә, һәм әнисенең исемен ишетсә, безнең каршыга йөгереп чыгасы булган икән...

Инде шактый якынайгач, серләребез сыя башлагач, моңсу гына әйтеп куйган иде ул:

– Мин әтине бөтенләй хәтерләмим. Әни дә аның турында берни сөйләмәде. Хәзер менә җентекләп сорашыр идем дә... – Аның әнисе ун еллар элгәре үк йөрәк өянәгеннән үлеп киткән икән. Нәзирәне әбисе багып үстергән.

– Әбиең дә әйтмиме? Ул бит кияве хакында нидер белергә тиеш.

– Берни дә белми. Бәлки, минем әти бөтенләй юктыр да...

– Әти катнашыннан башка гына бала яралмыйдыр ул, – дидем мин, йөземә фәлсәфи уйчанлык чыгарып. – Киләчәктә генә ни дә булса уйлап тапмасалар...

Нәзирәнең йөзен кызыл тимгелләр басып китте.

– Башыңны җүләргә салып торма инде! Уйнаштан туган мин, беләсеңме шуны? Уйнаштан! – Ул саубуллашып та тормыйча тар күпергә таба йөгерде.

Әтисез-әнисез тома ятим булып, җиһанда япа-ялгыз калуның фаҗигасен мин ул вакытта аңлый алырлык яшьтә түгел идем шул. Өлкәнәйгәч, табигый рәвештә әти-әнисез калгач та, ачы югалту сагышы җанда даими сызып тора, ә бала чагында, үсмер чакта үксез калсаң? Дөрес әйткәннәр: кеше хәлен

кеше белми үз башына төшмәсә... Мин дә Нәзирәнең бу һич көтелмәгән истерикасына аптырап, үземне гаепле сизеп, тулай торакка таба атладым. Без яшәгән тугыз катлы бина да моннан ерак түгел, уңга борылып бераз баргач, юл аша гына чыгасы.

Аны районга озатканда, вокзал буш сыман хәтердә калган.

– Мин сине бүтән күрмәм инде, – диде ул моңсу гына.

– Юкны сөйләмә, безнең хәзерге Татарстан бик бәләкәй бит ул. – Аның кыяфәте шулкадәр дә кызганыч иде, ирексездән күземне яшердем. – Монда һәркем бер-берсен таный, – дип арттырдым мин. – Кайтып эшкә урнаш әле, хәлеңне белергә килеп тә төшәрмен. Син инде мине прокуратурада, үз кабинетыңда көттереп кенә кабул итәрсең. Әмма тәбәссем белән! Форма сиңа килешәчәк... Теләсә нинди кием сиңа килешә... – Мин аны кочаклап алдым.

– Юатма, – диде ул, мине сак кына читкә этеп. – Мин бит сизәм, без соңгы тапкыр саубуллашабыз.

Поезд кузгалып китте. Юк, ул вакытта мин берни сизмәдем. Хәзер генә ул йөрәгем өзгәләнә. «Кал!» – дип нигә кычкырмадым? Хәер, хәзер үкенүдән ни файда... Юк бит инде ул. Һәм мин дә юк.

Карлы яңгыр көчәйде. Тар күперне чыгып, күптән төсен җуйган өч катлы иске тулай торакка таба атладым. Ишегалдында инде сирень куаклары да, кибарәнә утыручы чал өянкеләр дә юк. Әллә ничә йөк бетон субайлар китереп аударганнар, нидер төзергә җыеналар ахрысы. Шундый кыйммәтле җирне буш яткырмаслар хәзерге заманда.

Менә ул беренче катның сул яктан өченче тәрәзәсе. Форточкасы ачык, эчтән миңа таныш булмаган музыка ишетелә.

– Нәзирә-ә! – дип кычкырдым мин, җиһанда тылсым барына ышанасым килеп. – Нәзирә!

Пәрдә артында берничә шәүләнең бөгелә-сыгыла биегәне күзгә чалынды. Тулай торак та каядыр билгесез тарафка кузгалырга теләгәндәй кымшанып куйды.

– Нәзирә-әү... – дип инәлдем мин.

Кинәт тәрәзә пәрдәсе тартылды да пыялада чәче шарлавык булып җилкәсенә коелган бер кызның кыяфәте пәйда булды. Ул мине күргәч елмайды, кулын болгады...

Җиһанда тылсым бар ул! Һичбер шик юк ки, тәрәзәгә капланып минем белән саубуллашучы – Нәзирә үзе иде. Еллар аша теге абзыйның куе тавышы колагымда яңгырагандай булды: «Айныдым да аңладым мин, шундый итеп аңладым! – Мин яшьлегем белән тагын саубуллаша алмадым...»



Фирүзә
Җамалетдинова

# ТАРИХ БОРЫЛМАГАН ЕЛЛАР ЮК

## Сүз калган

Безнең гомер күргән падишаһлар!
Шаккатырлык Тарих үзе дә.
Ярты юлдан кире борыл, имеш,
Коммунизм төзе-төзе дә.

Борылдыкмы? Алга барышмы йә,
Чамаларлык хәл дә калмаган.
Ак өметләр күптән суга баткан,
Хыялларны утлар ялмаган.

Илнең үткәннәрен Тарих язган,
Патшалары киткән... Сүз калган.
Алар телендәге ул сүзләрдә
Ачыла гына бара һәр ялган.

...Коммунизм төзеп булмаса да,
Юлларны гел төзеп торалар.
Һәр чорда да бер үк мәгънә бирә
«Булдырабыз!» яки «Ура!»лар.

Патша белән Шагыйрь Тарих буйлап
Гасырларны бергә кичкәннәр.
Һәм еш кына, телен кисәлмәгәч,
Шагыйрьләрнең башын кискәннәр.

Падишаһлар килә-китә торган,
Ялганнарда заман, чор янган.
Башын иеп кояш карап торган,
Баш киселгән... Барыбер Сүз калган.

---

Фирүзә ЖАМАЛЕТДИНОВА – *шагыйрә, прозаик; «Толымлы ай», «Җирбизәк», «Хикәяләр» һ.б. китаплар авторы. Һ.Такташ исемендәге әдәби премия лауреаты. Казанда яши.*

Тарих – гадел, шагыйрь – үткен күзле,
Һәр икесе шундый дан алган.
Киләчәкнең ачык капкасыннан
Барыбер Сүз керә иң алдан!

## Ком сәгате

Дөньяның күзәтәм агышын,
Ком ага тын гына, моң гына.
Суларга кыймыймын – тыңлыймын,
Вакытмы каплана тыныма?

Тавышын ишетмим Вакытның,
Тик күрәм: ага ул ком булып.
Чорларга күмелеп калганы,
Җуела барганы йомылып,

Сибелеп киткәне җилләргә,
Яңгырга чыланган бүртеге –
Барсы да ул минем халәтем –
Гомерем минем ком бөртеге.

Ә комда – хәрәкәт, алгысу,
Вакыт ул мин булып чыгаммы?
Тик миңа бәйләнгән елларның
Җитәрме мәңгегә чыдамы?

Шуңа да тын гына агам шул,
Ул җепне, Илаһым, өзмә Син.
Мин менә нәкъ бүген күзаллыйм
Ком өйгән тауларның тезмәсен.

Ни кылып өлгердем? Җавабым?
Бар галәм тыңлый күк, дөнья тын.
Ашыгам... Тикмәгә түгелдер,
Ком ага... Әлегә ага ком...

## Иң зур сер – гомерем

Һай, озак яшәлде бу җирдә,
Утларга төшелде... Пешелде...
Дөньяның мин тамчы белмәгән
Нихәтле серләре чишелде.

Чишелми калганы – бер галәм,
Тагы да бер гомер җитмәслек.
Аһ, булсын иде лә бу яшәү
Тормышның гайрәте чикмәслек.

Яшьлегем мәңге тез чүкмәслек,
Картлыкка камзуллар текмәслек,
Буш орлык чәчмәслек бу җирдә
Заты юк иген дә икмәслек.

...Мин күрдем кояшның кызарып
Пешүен, үзеннән качуын.
Тын гына сер түгеп тәрәзгә,
Айның төн пәрдәсен ачуын.

Мин күрдем үзенә сыешмый
Йөгергән утлы җил тынуын.
Мин күрдем, өшегәч, үзәктән
Ялкынның дерелдәп торуын.

Яз көттем үземә килер, дип,
Яз саен бар җиһан яшәрде.

Мин көткән үткәнгә әйләнде.
Дөньяда, һай, озак яшәлде...

Давыл да бер тына икән шул,
Утлар да бер сүнә икән ул.
Өметләр ягына талпынып,
Тик күңел җилкенә икән ул.

Югалткан – тапканнан кадерле,
Һич болай булмас дип йөр-йөр дә
Тукталып кал, имеш...
Ә баксаң,
Шундый әз яшәлгән бу җирдә!

Утларда, суларда чыныккан
Мәңге яшь сулыкмас күңел шул.
Иң зур сер – гомерем... Тик никтер
Яшәгән кебек тә түгел шул.

## Җырым минем

Син миңа канатлар куясың,
Таны, дип, үзәнен, кыясын.
Күтәр, дип, җиһанны югары,
Биектә моңнарның юллары,
Җырым минем!

Син мине үз итеп киләсең,
Елата-елата көләсең.
Җанымны телемләп теләсең,
Шул мәлдә гөлләргә төрәсең,
Җырым минем!

Сүзләрне алларга мин манам,
Көнем юк, төнем юк, ял гынам.
Ташлама мине, дип ялынам,
Тик шулай тормышка ялганам,
Җырым минем!

Гомерме мәңгелек? Ел саны?
Җан һәм җыр югалмас, бел аны.
Яктылык, нур җый да күңлемнән,
Сакла син, җылыт син дөньяны,
Җырым минем!

## Барыбер кадерлең мин синең

Хатамны күрүгә тиргисең,
Ә үзең, кадерлем – син, дисең.
Мине сүз үтерә, ә синең
Китмидер шикелле һич исең.

Сүзләрең кош, гүя...
Минем күк
Уеңны кушмыйсың, бүлмисең.
Мине сүз яшәтә, син шуны
Белмисең. Ничекләр белмисең?!

Табигать салганы үзгәрмәс,
Булмышың шулдыр ла, җисемең...
Тиргисең... пышылдыйм тын гына:
«Барыбер кадерлең мин синең!»

## Мөгаен

Көмеш болытларның күзе көлә,
Бөтен җиһан чумган якты сергә.
Йолдызларның йөрәк тибешен күр! –
Мөгаен, бер шагыйрь туган җиргә.

Сызгырды җил... Каен дертләп куйды,
Сыенасы килеп өянкегә.
Ә ай күктә тынычлыгын җуйды, –
Мөгаен, бер шагыйрь туды җиргә.

Ялгызлыктан айга кыен булмас,
Күктә ни бар – яшәр бергә-бергә.
Давыл үтте шау могҗиза эзләп –
Мөгаен, бер шагыйрь туды җиргә.

Яшәп кара шунда үзең булып,
Бөтенесен бер йөрәккә төр дә.
– Дөнья матур! – диеп дәшәр өчен,
Мөгаен, бер шагыйрь туды җиргә.

Ай күк сабырлыкта яшәү авыр,
Һәм җиһанга тимәсен һич кер дә!
Давыллары – давыл, җил – җил булыр, –
Мөгаен, бер шагыйрь туды җиргә!

Тереклекнең сулаганын тоеп,
Яшәр өчен сөеп, бергә-бергә,
Бар галәмне төреп якты сергә,
Мөгаен, бер шагыйрь туды җиргә...

## Шәһри Болгар, саумы!

Шәһри Болгар, саумы! Туфрагыңны
Минем дә бер килде күрәсем.
Бабамнарның рухы булып шыткан
Чәчкә төшләренә керәсем.

Гөлләр чәчен Идел җиле тарый,
Үз итүе җилнең – чәч тарау.
Бу килүем – үткән гасырларга
Башны борып бары бер карау.

Ә карарга кирәк үткәннәргә,
Киләчәккә шунсыз юллар юк.
Борылырга кирәк үткелләргә
Тарих борылмаган еллар юк.

Халыклар юк тарих күрми калган,
Башкайларны ташлар басканда.
Бер борылып карагандыр әле
Шайтани зат – явыз баскын да.

Бу җирләрдә бары тарих яши,
Тарих исән, һәм ул безнеке!
Җаным бүген шәһри Болгарныкы,
Ә чәчәкләр, бәлки, көзнеке?!

Җиңүчеләр кайда? Алар да юк,
Без җиңелгән булыйк ди, ярый...
Тарих кала икән... Кала эзләр...
Чәчләремне сөеп җил тарый...



Юныс
Сафиуллин

# ЙОСЫФ ҺӘМ ЗӨЛӘЙХА

МЮЗИКЛ

**2 ПӘРДӘ, 13 КҮРЕНЕШТӘ**
**(Кол Галинең «Йосыф китабы» буенча иҗат ителде)**

Катнашалар:
Я к у б – гаилә башлыгы.
Р а у и л, Ш ә м г у н, Я һ ү д, Л ә б и, Р ә й я л у н, Я ш ь җ ә р, Д а н – Якубның беренче хатыныннан туган уллары.
Й о с ы ф – Якубның Рәхиләдән туган улы.
И б н е - Й ә м и н – Йосыф белән бер үк анадан туган абыйсы.
Д и н ә – Якуб тарафыннан асрамага алынган кыз.
З ө л ә й х а – Мәгъриб патшасы Тәймус кызы: яше егермедә чакта, урта яшьләрдә, өлкән яшьтә.
З ә й т ү н ә – Зөләйханың караучы кызы, пәри затыннан.
К ы й т ф и р – Мисыр патшасы, фиргавен токымыннан.
Р ә й я н – Кыйтфирның туганы.
Д ә г ы й р у л ы М а л и к – Мисыр сәүдәгәре.
Б ә ш и р – аның колы, соңыннан вәзир.
Б е р е н ч е, И к е н ч е, Ө ч е н ч е, Д ү р т е н ч е, Б и ш е н ч е, А л т ы н ч ы, Җ и д е н ч е, С и г е з е н ч е – Мисыр хатын-кызлары.
И к м ә к ч е.
Ш ә р а б ч е.
К ы т а й (х ы т а) б и ю ч е л ә р е (Зөләйха хезмәтендә).
Г р е к (р у м и) а л ы п л а р ы (Зөләйха белән килгән цирк осталары).
С а к ч ы л а р.

Юныс САФИУЛЛИН (1947) – *драматург; «Әллә өйләнергә инде?», «Пар канат», «Рәфкать Бикчәнтәев» һ.б. исемдәге китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

## 1 ПӘРДӘ

### 1 күренеш

*Борынгы Кәнган сәхрасында кечкенә бер ыру рәвешендә яшәп яткан ишле генә гаиләнең йорт-җире. Й о с ы ф йокыда. Саташа. Алдан йөгереп И б н е - Й ә м и н , аның артыннан атасы Я к у б керә.*

И б н е - Й ә м и н .

Атам, күр, Йосыф һаман саташа, әнә!

Я к у б .

Саташуы бит төшләнүеннән генә!
Мин дә бүген, улым, куркыныч төш күрдем:
Анагыз Рәхилә елый-елый килеп
Әйтте: зинһар, сакла Йосыфымны диеп.

И б н е - Й ә м и н .

Ә никтер ул минем төшләремә керми,
Миңа да бит авыр, нигә шуны күрми?
Йосыфын кайгыртa – мин дә үз баласы...

Я к у б .

Улым, сиңа монда йорт саклап каласы!
Әнә, кырга эшкә китә туганнарың, –
Җиңгәләрең тизрәк хәзерләсен табын!
Динәгә әйт, җәһәт су китерсен монда!

*Ибне-Йәмин чыга. Д и н ә су китерә. Йосыф түшәгенә торып баса. Каушый.*

Й о с ы ф *(карана, эзләнә. Әтисен күргәч, аңа йөгерә).*

Әткәй!
Кайда ай һәм кояш, кайда унбер йолдыз?
Нигә болай калдым икән япа-ялгыз?!

Я к у б *(Динәдән суны ала).*

Алар төшеңдәдер, нинди төш күрдең соң?

Й о с ы ф *(Якуб биргән суны эчә).*

Нурлы кояш, тулган ай һәм унбер йолдыз,
Шул төшемдә сәҗдә кылды миңа төп-төз!

*Якуб Йосыфка сөйләмәскә ишарә итә. Касәне алып Динәгә бирә дә, «кит», дип ишарә ясый. Динә китә башлый, тик кызыксынуы җиңгәч туктала.*

Төш мәгънәсен, атам, ничек юрап була?
Ходавәндәм миңа нинди язмыш кыла?

*Динә ишек төбендәге паласны рәтләгәндәй итә.*

Я к у б *(уйларыннан айнып).*

Ходай Тәгаләнең рәхмәтләре илә
Сиңа олы белем, зур дәрәҗә килә!
Кояш һәм ай нуры төшкән һәммә җирдә
Иманлы Йосыф дип таралачак даның,
Булыр Мисыр кебек патшалыгың,
Башын ияр сиңа хәтта абыйларың!

Й о с ы ф *(шаккатып, дулкынланып).*

Хәтта абыйларым миңа баш иярме?
Алар да әллә мине патша диярме?!
Ә нигә соң Ходай мине сайлады икән?!
Миннән лаеклырак булмады микән?
Атам, кара, мин, чыннан да, бик матур бит,
Беркем әйтми абыйларымны матур дип.
Атаем, мин Мисырда патша булу белән,
Кәнганнән сине Мисырга алып киләм!

*Динә бу сүзләрдән куркып йөгереп китә.*

Я к у б .

Хак Тәгалә чиксез кодрәт – алгучы да,
Масайсаң бернәрсәсез калдыручы да!
Шуңа, улым, тәкәбберлектән ерак йөр,
Кеше хакын бөтен нәрсәдән дә өстен күр!
Ләкин, улым, әманәттер, яхшы тыңла,
Төшеңне һичкемгә дә син мәгълүм кылма!
Хәтта туганны да котырта бит шайтан.
Абыйларың белсә, хәлләр булыр яман!

*Туганнар керә башлый. Ата алдында Йосыфны оялтырга тырышалар.*

Я һ ү д .

Кардәшебез Йосыф иркә дә соң бигрәк!

Р а у и л .

Иркә кайда, шунда була ялкау имгәк!

Ш ә м г у н .

Ник бармыйсың, Йосыф, безнең белән кырга?!
Ярдәм итәр идең маллар сугарырга!

Я һ ү д .

Көне-төне без мал артыннан йөрмәктә,
Михнәт чигеп, елкы-сыер, куй көтмәктә!

Я к у б .

Балаларым, күрәм, авыр эшләрегез,
Әмма Йосыфны сез юкка битәрлисез!

Ш ә м г у н .

Без эштән кайтканда, һәрчак ята йоклап!

Я к у б *(тавышын күтәрә төшеп).*

Чөнки көне-төне күчерә ул китап!

Т у г а н н а р .

Күчерә ул китап, күчерә ул китап!
Китап, китап, китап! Китап, китап, китап!

Р а у и л .

Атабыз, безгә мал табучылар кирәк!

Я к у б .

Мал табучы кирәк, китап язучы сирәк!
Мал табыгыз, иблистән дә сакланыгыз!
Арагызга керсә иблис ләгыйнь уе,
Дулар көнчелекнең явыз кара туе!
Йосыф улым, уянгансың, юынып ал!

*Уллары әрле-бирле сугылып йөри башлый, Якуб Йосыфны иартеп чыга.*

Я һ ү д.

Динә дөрес әйткән! Йосыф патша, дин, ә!

Л ә б и.

Аны өстен күрә, дөрес әйткән Динә!

Я һ ү д.

Атабызга Йосыф бездән кадерлерәк!

Л ә б и.

Ул Йосыфны бездән өстен күрә, димәк?!

Р ә й я л у н *(мыскыллап)*.

Иманлы Йосыф бит китап күчерә!

Я ш ь җ ә р.

Туганнары ялан кырда мал эчерә...

Д а н.

Йосыф бит без түгел – Рәхилә баласы!

Р а у и л.

Атабыз гел мактый, изге, дип, анасы!

Д а н.

Хезмәтчегә саный Йосыф абыйларын!

Р ә й я л у н.

Кем генә соң аңлар кеше кайгыларын!

Р а у и л.

Әткәй өчен Йосыф тугры гүзәл бер җан.

Ш ә м г у н.

Әткәй берни белми – куенында елан!

Д и н ә *(йөгереп керә)*.

Кычкырмагыз, миңа эләгер, атай сизсә!

Т у г а н н а р.

Кычкырабыз – бәла килә өстебезгә!

Д и н ә.

Нигә генә әйттем, кушачак куарга,
Үз баласы түгел бит – алды асрамага.

Р ә й я л у н.

Куа алмас, Динә, без сине яклабыз,
Үз сеңлебезне саклагандай саклабыз!

Р а у и л.

Динә, Йосыф төшен тагын бер кат кабатлачы,
Монда җиде үлчәп, бер кат кискән яхшы!

Д и н ә.

Нурлы кояш, тулган ай һәм унбер йолдыз,
Шул төшендә сәҗдә кылган аңа төп-төз!

Я һ ү д.

Унбер йолдыз, диме? Ансы бездер инде!

Ш ә м г у н.

Бүлмә! Тагын нидер дигән идең, Динә?

Д и н ә.

«Хәтта абыйларым миңа баш иярме?
Алар да әллә мине патша диярме?!
Ә нигә соң Ходай мине сайлады икән?
Миннән лаеклырак булмады микән?
Атай, кара, мин, чыннан да, бик матур бит,
Беркем әйтми абыйларымны матур дип».
Булдымы инде, әткәй күргәнче китим!
*(Кача-поса китә.)*

Р а у и л .

Йә, Йосыфтан ни көтәргә безгә?
Бу төш аша бәла килә өстебезгә!

Т у г а н н а р .

Кара язмыш юраган атабыз безгә!

Ш ә м г у н .

Әгәр Йосыф төше чынга аша калса,
Әгәр дә ул, чыннан, патша булып алса,
Һәммәбез дә аңа коллык кылыр булса,

Т у г а н н а р .

Булыр бу эш безгә иң бәхетсез кыйсса!

Я һ ү д .

Рәхилә Йосыфы хәйлә кормак була,
Төшен сөйләп, бездән өстен чыкмак була!

Р ә й я л у н .

Атабыз төпчеген бездән артык сөя!

Л ә б и .

Күрми торса аны, йөзе кара көя!

Я ш ь җ ә р .

Бездән ике тапкыр артык өстен күрер!
Мирасны да аңа күпкә артык бирер!

Д а н .

Атайдан Йосыфны аерырга кирәк.
Алып китик кырга, юк итәргә кирәк!

Я ш ь җ ә р .

Атабыз янында без генә калалсак,

Д а н .

Аның сөеклесе без генә булалсак,

Я ш ь җ ә р .

Атабызга яхшы тәрбия кылырбыз!

Д а н .

Шул рәвешчә генә бәладән котылырбыз!

Т у г а н н а р .

Алып китик кырга, шунда ачыкларбыз!

*Йосыфның чәчләрен тарый-тарый, Я к у б  керә. Туганнар сәҗдәгә егыла.*

Т у г а н н а р .

Кадерле атабыз, исраил атабыз,
Көн дә каршыңдабыз, синә җан атабыз!

Р а у и л .

Йосыф кадерлебезгә, кардәшебезгә,
Рөхсәт ит, әткәй, иркен дөнья күрергә.

Ш ә м г у н .

Йосыф безнең белән маллар көтеп йөрсен.
Зиһне артсын, шунда күңле күтәрелсен!

Й о с ы ф .

Атам, җибәр кырга туганнарым белән!

Я к у б  *(чәч тараудан туктап)*.

Бу уеңнан, Йосыф, канлы яшьләр түгәм!
Улларым, Йосыф беркая да бармас.

Күргән төшемнән һич җаным тынгы тапмас.
Рәхиләмне күрдем, бик кайгылы иде:
Кырда унбер бәрән көттең, Якуб, диде,
Бәрәнеңнең берсен тартып алып, бүре
Куе чытарманның эчләренә керде.

Ш ә м г у н *(аягүрә басып)*.
Кайгырма, атабыз, Йосыфны сакларбыз.
Барлык бүреләрне тураклап ташларбыз!

Й о с ы ф *(тезләнә)*.
Рөхсәт ит, атаем, мин дә кырга барыйм,
Абыйларым белән матурлыкны карыйм.

Д а н .
Күргәннәрен кайтып сиңа сөйләп бирсен,
Үзе сөенгән күк сине сөендерсен!

Я к у б .
Ботак керсә тишеп, сукраер күзең,
Кара кодрәт сукса, кулдан китәр көчең!

Й о с ы ф .
Якуб атам, мине сөюеңне беләм,
Дәлиллисең моны нинди эшләр белән?

Я к у б .
Тезлән, дисәң, улым, тезләнергә риза *(улы янына тезләнә),*
Барырга рөхсәт юк, көтә алда иза!

Й о с ы ф *(Якубның янына тезләнә, иңеннән коча)*.
Ходаемнан хөкем булса,
Көймәм батар, –
Ходай кушса, баткан көймәм өскә калкыр!
*(Әтисе белән тора.)*

Я к у б *(Йосыфның чәчләрен үрә, өстенә ап-ак күлмәк алып кидерә)*.
Аллаһ бөек, күнәм, ярый, юл чыгыгыз! *(Улларына.)*
Төпчегемне саклап, хөрмәтләр кылыгыз!

Я һ ү д .
Юлда ул армас, чиратлап күтәрербез. *(Йосыфны күтәрәләр.)*
Чиксез кадерләрбез, хөрмәт күрсәтербез!

*Пәрдә*

**2 күренеш**

*Мәгъриб җирләренең патшасы Тәймус сарае. З ө л ә й х а сатәшулы йокыда. «Зөләйха төше». Сәхнәгә караңгылык иңә. Кыз торып баса, аңа таба патша киемнәрендәге Й о с ы ф килә. Төш музыкасы.*

З ө л ә й х а .
Менә тагын, егет, син төшемә кердең,
Менә тагын нурлы йөзләреңне күрдем.
*(Ары таба көйләп әйтә.)*
Акылымнан язам кемлегеңне белми,
Кешеме син, әллә явыз җен-пәриме?

Й о с ы ф *(көйләп җавап бирә)*.
И, Зөләйха, мин дә синең кебек кеше,
Ходай кодрәтеннән яратылган бер җан.

Сине миңа язган, мине сиңа язган,
Кавышулар килер безгә Хак Алладан!

З ө л ә й х а *(көйләп).*

Өченче ел инде бертуктаусыз янам,
Торган урыныңны, әйтче, егет, зинһар,
Син патшамны шуннан барып эзләп табам,
Мәхрүм итмә бар нәрсәдән, әйт, син кайдан?

Й о с ы ф *(көйләп).*

Хәтерлә шуны: мин Мисыр хөкемдары.
Очрашу Мисырда, теләсәң килерсең,
Сабырлыгың белән эшлә бу эшеңне.
Сабыр булсаң гына, син мине күрерсең.

*Сәхнә яктыра. Зөләйха уяна. Елый-көлә. З ә й т ү н ә  аны тотып ала.*

З ө л ә й х а *(уяна).*

Хәтерлә шуны: мин Мисыр хөкемдары.
Очрашу Мисырда, теләсәң килерсең! *(Елый, көлә.)*

З ә й т ү н ә .

Чү, Зөләйха, алай бәргәләнмә, зинһар!
Һич курыкма, монда менә сакчың Таш Сын бар!
Таш Сын Ходам, Зөләйха кабат төш күргән,
Төшенә бит тагын теге ләгыйнь кергән!

З ө л ә й х а .

Юк, ул егет Мисыр хөкемдары икән,
Аның һәрбер сүзе, хәрәкәте күркәм!
Бик елагач кына ачты йөрәк серен.
Аның йөзе янган уттай балкый иде,
Мин – синеке, диде, син – минеке, диде.
Сине миңа язган, мине сиңа язган,
Кавышулар килә, диде, Хак Алладан!

З ә й т ү н ә .

Кит, явыз көч, үзем дә пәри затыннан!
Зөләйхамны барыбер синнән тартып алам!
Тфү, тфү… тфү! *(Зөләйханы Таш Сын каршына китерә.)*
Әйдә, тезләник Таш Сын каршысына!

*(Таш Сын каршына тезләнеп рәхмәт укыйлар. Таш Сынны иркәләп үбәләр.)*

Рәхмәт догабызны кабул итче, Таш Сын,
Кылган һәр догабыз, кайнар теләгебез
Кабул була күрсен, күңелеңә ашсын!

З ә й т ү н ә .

Сөйлә, әйдә, аңа ниләр күргәнеңне,
Курыкмый гына әйт, изге теләгеңне!

З ө л ә й х а .

Мисыр хөкемдары минем теләккәем,
Шуны сорап тибә ярсу йөрәккәем!
*(Таш Сын сүзсез тора. Зөләйха кабатлый).*
Мисыр хөкемдары минем теләккәем,
Шуны сорап тибә ярсу йөрәккәем.

З ө л ә й х а .

Дәшмисең? Дәшмәү – ризалык билгесе ул!
Таш Сын, атам Тәймуска син киңәшче бул!
Каршы килмәс сиңа, сөекле әткәем,
Мисырга барам, шунда ул бәгырькәем!

*Пәрдә*

**3 күренеш**

*Сәхра. Кое. Туганнары Яһүдне Йосыф җилкәсенә бәйләп куйган хәлдә, аны чыбыркылап куып керәләр.*

Й о с ы ф .

Зинһар, ял бирегез, абыйларым, ардым
Намаз укырга да инде соңга калдым!

Д а н .

Күргән ялган төшең файда итмимени?!
Безне алдаларга тешең үтмимени?!

Й о с ы ф .

Туганнарым, нигә болай итенәсез?
Җиңелрәк булыр әгәр үтерсәгез!

Я һ ү д .

Йә, булды, җитәр, бауны чишегез,
Бу мескен өстеннән мине төшерегез!

Я ш ь җ ә р .

Гуаһ итсен башта ялган төш күрүен,
Без телибез аның гафу үтенүен!
Кичермәслек гөнаһ – атабызны алдау,
Бу мәңгелек җәза, көтә канлы богау!

Й о с ы ф .

Төшем минем һич кенә дә ялган түгел,
Сезне дә саф хисләр белән сөя күңел.
Ышанмыйсыз икән, риза – үтерегез!

Ш ә м г у н *(пычак белән янап)*.

Үтермәсләр, димә, аһ син мәлгунь бер җан!
Атабызны безгә каршы куйган елан!

*(Пычагы белән бауны кисә. Яһүд белән Йосыф икесе ике якка авып китә. Йосыф торып сәҗдәгә баса.)*

Р а у и л .

Намаз укымакчы, әүвәл тәһарәт ал!
Ләби, ярдәм итче, кулларына су сал!

*Ләби җирдә яткан Йосыфка кое суын алып сибә.*

Л ә б и .

Юдым күлмәгеннән канлы зур тапларны!

Я ш ь җ ә р .

Күңле кара калды – су гына пакьлармы?

Р ә й я л у н .

Атабыз юк монда чәчеңне үрергә.

Р а у и л .

Атасы булмаса, бар олы агасы,
Ризамын чәченнән өстерәп йөрергә!

*Чәченнән тотып өстерәп йөртә.*

Ш ә м г у н .

Син мәкерле җанны хәзер үтерәбез,
Ялган төш юравын шулай бетерәбез!

Й о с ы ф .

Нинди гаеп ахыр миннән сез таптыгыз?
Бу гыйбрәтле хәлне миңа аңлатыгыз!

Р ә й я л у н .

Ялган төшләр сөйләп бездән өстен чыктың,
Газиз атабызның сөеклесе булдың.
Гаделлекне боздың, бердәмлекне җуйдың,
Уртак мираска син нәфсе кулың суздың!

Й о с ы ф .

Хәлем мөшкел, күңелдә зар, тәндә яра,
Йөрәгемне газап-михнәт чорный бара,
Ни кызганыч, атам Якуб мәхрүм кала,
Ул соң сездән нинди җавап ала ала?

Ш ә м г у н .

Тагын кызгандыра, бу юлы мин түзмәм,
Телен өзеп алып, телемнәргә теләм!

*Йосыфка ташлана, тик аның көлүен ишетеп туктап кала.*

Син нидән көләсең, акылдан яздыңмы,
Үткен пычак күреп, шулай шат булдыңмы?

Й о с ы ф .

Уйлар идем элек һәммәгезне сөеп, –
Абыйларым – минем сакчыларым, диеп:
Алар оранлылар, киек арысланнар,
Тия алмас миңа иң явыз дошманнар!
Явыз дошманнарым сез булып чыктыгыз,
Юк гаепләр тагып мине сыттыгыз...
Бу тәнемдә әгәр йөз мең җаным булса,
Барын сезнең өчен кылыр идем фида!

Я һ ү д *(сөңгесе белән Шәмгун пычагын сугып төшерә)*.

Йәгез инде, җитте, үтермәгез аны,
Ялгыш үтерсәгез, үч алачак каны!

Д а н .

Аһ син, Яһүд, уртак антыбызны боздың,
Йосыфны кызганып, ярдәм кулың суздың,
Шулай итеп изге антыбызны сыздың,
Үз башыңа кайтыр бу вафасызлыгың!

Я һ ү д .

Үтерүләр бер дә гаделлектә булмас,
Кардәш карендәшен мал суйгандай суймас!
Алда җавап көтә, Аллаһыдан куркыйк!
Ахирәткә һич тә гөнаһ төяп бармыйк.

Я ш ь җ ә р.

Йосыф җинаяте гафу кылынмаслык,
Үтермибез, дисәк, башка чара табыйк!

Я һ ү д.

Киңәшем шул: әнә, Гъад казыган кое,
Ташлыйк коега, ачы аның суы.
Ходай кушкан икән, үләчәк коеда,
Исән калуы да Ходайның кулында!

Т у г а н н а р.

Ташлыйк коега, ташлыйк коега!
Ходай әмре җитеп, үлем бирер шунда!

*Йосыфны, кулдан кулга тапшырып, коега таба җибәрәләр.*

*Пәрдә*

**4 күренеш**

*Мисыр. Кыйтфирның Зөләйха өчен хәзерләткән сарае. Зөләйханың Таш Сыны аллы-гөлле чәчәкләр белән бизәлгән.*

З ө л ә й х а.

Ничәнче көн инде менә килгәнемә,
Юк бит үзен читтән күргәнем дә.

З ә й т ү н ә.

Йә, тынычлан, зинһар, Мисыр хөкемдары
Кунак җыя икән синең хөрмәтеңә!
Салдырган ул сарай синең хөрмәтеңә,
Бизәкләрен кара, алар нинди затлы.
Шикләнәсең икән, кабат укып карыйк,
Атаең Тәймуска язган җавап хатын. *(Укый.)*
«Кем теләсә мине, аны мин теләрмен,
Йөз мең теләк белән аны каршыlармын,
Мал-милкемнең барын аңа багышлармын,
Чын күңелдән кабул кылам Зөләйханы!»

З ө л ә й х а *(Таш Сын каршына тезләнә)*.

Әтием биргән Таш Сын, олы көчең күрсәт!
Ай ярымнар булган авыр юллар үткәч,
Өч елдан да артык кавышулар көткәч, –
Ник күренми соң ул, Мисыр хөкемдары,
Буш сарае белән каршылады бары!
Җаным белән сөйдем, Мисырына килдем,
Мисыр буйлап аны күпме эзләп йөрдем.
Күрешүләр көтәм, ә ул суза һаман.
Сагыш басты мине, утларында янам!

З ә й т ү н ә.

Чү, тыңлыйкчы әнә: быргы тавышлары! *(Ишеккә бара.)*
Ни дип хәбәр бирә Мисыр хөкемдары?

Ш ә р а б ч е *(күренә)*.

Әзер булыгыз, ди, зур кунаклар килгән:
Бәйрәм белән котлый, очрашасыз тиздән! *(Югала.)*

*Грек (руми) музыкасы астында төрле хәрәкәтләр ясап, алыплар чыгып тезелә. Грек музыкасын Кытай музыкасы алыштыра. Зөләйха берничә бию хәрәкәте ясый. Шул ук мизгелдә кытай биюче кызлары да кереп аңа кушыла. Зәйтүнә биеп китә.*

З ө л ә й х а *(залдагы һәркемне сәламләгәч, Зәйтүнәгә).*

Инде хөкемдарны эзләп табып җиткер:
Өзелеп-өзелеп аны көткәнемне,
Мең-мең газап күреп, вәгъдә өчен түзеп,
Дәһшәт белән тулы юллар үткәнемне!

*Зәйтүнә чыккач, кабат Таш Сын каршына тезләнә.*

Морадыма җитәм, җаным кебек сөйгән
Мисыр газизенең асыл йөзен күрәм!
Кавышулар якын, шуңа шөкер итәм.
Барча малым бүлеп фәкыйрьләргә илтәм!
Таш Сын Ходам, болар минем вәгъдә сүзем,
Йөрәк очрашуны көтә, бирче түзем,
Йөрәк кенә түгел, көтә ике күзем!

*Зәйтүнә керә.*

Караучы газизем, йә күрдеңме үзен?!

З ә й т ү н ә.

Фиргавеннәр белән шыгрым тулган заллар,
Кая карасаң да бүләк – затлы маллар!
Яңа кереп басты аның сакчылары,
Фиргавеннәр һәм дә Мисыр хөкемдары!

З ө л ә й х а.

Шатлык тулып таша, кайнап тибә йөрәк.
Кунакларны биеп каршыларга кирәк.

*Кытайларның бию көйләре кабат яңгырый башлый. Зөләйха, затлы тәхеткә утырып, Мисыр хөкемдарын каршыларга хәзерләнә. Залда бию. Залга кергән К ы й т ф и р, Р ә й я н һәм башка фиргавеннәр Зөләйха белән үзләре арасында барган биюгә сокланып карап торалар.*

З ө л ә й х а *(Зәйтүнәгә).*

Кунаклардан кайсы Мисыр хөкемдары?

З ә й т ү н ә.

Танымыйм шул аны, төштә күрдең бит син...

З ө л ә й х а.

Мисырга чакырган егетне мин күрмим!

К а р а у ч ы к ы з.

Алайса рөхсәт ит, барып белеп килим.

З ө л ә й х а *(кызны туктатып, аяк өсте күтәрелә).*

Хөрмәтле кунаклар, мин Мәгъриб кызымын,
Эзләп килдем монда бәхетем йолдызын,
Тик күрмәдем никтер Мисыр Хөкемдарын.

*Шаяртып көлә.*

Чакырды да качты, тәмам аптырадым!
Әйтегезче табып, ай кояшын көтә:
Дөньябыз аяусыз, гомер бик тиз үтә,
Табып өлгермәсә егет сөйгән ярын,
Бушлык кочып калыр, югалтыр ул барын!

*Кыйтфир биючеләр арасыннан Зөләйхага килә башлый. Әмма алыплар, төрле хәрәкәтләр ясап, аның юлын ябалар. Биюче кызлар читкә китә.*

Чакырыгыз инде Мисыр хөкемдарын?
Янәшәмдә көтә аны затлы урын!
Кайда соң син, нурлым – Мисыр хөкемдарым?!

Кыйтфир.

Кыйтфир, диеп ата, мин ул хөкемдарың,
Мин ул синең эзләп тапкан асыл ярың!
Монда син килгәндә, мин тол калган идем,
Кара кайгы баскач, күренмичә йөрдем.

Зөләйха *(түзми, атылып Кыйтфирга бара, грек алыплары аңа юл биреп кала, кыз, сөртенеп китеп, Кыйтфирның кочагына ава, Кыйтфир аны, тотып алып, күкрәгенә кыса).*

Мисыр хөкемдары, Мисыр хөкемдары!
Кайда тулган айдай балкып торган йөзең?!
Бал-шикәрдән татлы булган затлы сүзең?!
Кайда төшкә кергән Мисыр хөкемдары?!

*Кыйтфирдан этелеп, Караучы кыз карамагына күчә.*

Кыйтфир.

Мин ул – кайнар теләк белән каршылаучы,
Мал-милкемнең барын сиңа багышлаучы.
Миңа шатланмавың җанга сагыш салды,
Өзгәләнә, елый Мисыр хөкемдары!

Зөләйха.

Көтә мине бүтән Мисыр хөкемдары!
Аңа вәгъдә бирдем, биргән вәгъдә – иман!
Аны миңа язган, мине аңа язган,
Син сөйләгән сүзләр һәммәсе дә ялган!

Рәйян.

Кыйтфир энесе мин, бар халыктан сораш,
Бөек Кыйтфир чынлап Мисыр халкына баш!

Мисыр хатыннары:

Беренче һәм Икенче.

Мәгъриб кызы хаталанды, хаталанды!

Өченче һәм Дүртенче.

Бөек Кыйтфир чынлап Мисыр хөкемдары!

Бишенче һәм Алтынчы.

Кыйтфир кызны ихлас кабул кылып алды.

Җиденче һәм Сигезенче.

Зөләйха кыз аңа хәзер хатун булды!

*Зәйтүнә хәлсез Зөләйханы тәхетенә илтеп утырта.*

Р ә й я н *(хат күрсәтә)*.

Тәймус ибне Талус хаты – атаңнан:
«Атым Тәймус ибне Талус, бел син анык,
Бер кызым бар минем, сиңа багышланган,
Шундый тәкъдир язган аңа Таш Пот Ходам
Күрәм, дисәң яучылар җибәр имди.
Хакыйкатьтер, сиңа кызымны тапшырам.
Мең дөягә мәһәр-җиһаз төяттерәм,
Мең качырга төрле нәрсә йөкләттерәм, –
Ул йөкләрдә затлы байлык булыр имди.
Тагын мең кол, мең караучы кызлар булыр,
Алар синең сараеңда хезмәт кылыр,
Һәр әмреңә буйсынырга әзер торыр,–
Кайсы хыта, кайсы руми булыр имди».

З ө л ә й х а .

Аһ! Атам язган хат ничек сезгә эләккән?! *(Һуштан яза.)*

К ы й т ф и р .

Гүзәл язды һуштан, итегезче ярдәм!

*Зөләйхага ярдәмгә омтылган Кыйтфир якыннары юлына грек алыплары каршы төшә. Фиргавеннәр, чигенә барып, сарай залыннан ук чыгып китәргә мәҗбүр булалар. Залда Зөләйха янында тезләнеп торучы Кыйтфир белән энесе Рәйян гына торып кала.*

З ә й т ү н ә *(Кыйтфирга)*.

Борчылма, хөкемдар, кыз кайгысы кыска,
Мәхәббәте кайтыр, кайгырмагыз юкка.
Зөләйха бик арды, сез дә ял итегез.
Зөләйха үзгәрер, ышанып көтегез!

К ы й т ф и р .

Мин ышанам аңа, амин, шулай булсын,
Ходай бу гүзәлне миңа насыйп кылсын!

З ә й т ү н ә .

Бик еракта калды Зөләйханың иле,
Кайтып китә алмый, ул синеке инде!

Р ә й я н .

Бик акыллы киңәш, абый, кабул итик,
Зөләйха терелсен, сабыр гына көтик.

*Кыйтфир белән Рәйян чыгып китә. Зәйтүнә алыплар белән биючеләргә дә китәргә боера. Зөләйха аңга килә.*

З ө л ә й х а .

Аның исме Йосыф, нинди матур исем,
Тулган айдай балкып кабат төшкә керде!
Җитәкләшеп бергә Мисыр карап йөрдек,
Син – минеке, диеп, мин – синеке, диеп!

З ә й т ү н ә .

Саташма, Зөләйха, зинһар, сабырлык кыл!
Атаң биргән Кыйтфирның хатыны бул!

З ө л ә й х а .

Кыйтфирга беркайчан хатын булып бармам,
Йосыфымны сөям, аны эзләп табам!

З ә й т ү н ә.
Әйттеме соң, нигә монда чакырганын,
Үзен хөкемдар, дип, нигә алдаганын?

З ө л ә й х а.
Ихлас иде Йосыф, нигә алдаласын!
Артыгын мин аннан сораша алмадым,
Балдан татлы сүзләр әйтте – аңламадым,
Нурлы йөзен туйганчы карый алмадым!

З ә й т ү н ә.
Балдан татлы тик бер сүзен хәтерләче!

З ө л ә й х а.
Балдан татлы сүзнең эчтәлеге әче.
Болай үртәде ул, «сабыр ит», янәсе. *(Көлә.)*
«Сабырлыктан морад хасил була» икән. *(Көлә.)*

К а р а у ч ы  к ы з.
Теге төштә дә бит сабыр булчы, дигән...

З ө л ә й х а.
Сабырлыгым минем дөрләп янды күптән,
Көтә-көтә мин бит тәмам сулып бетәм,
Җыеныйк та Йосыфны без эзләп китик!

З ә й т ү н ә.
Зинһар, кушкан җирдә сабыр итеп көтик!

З ө л ә й х а.
Хатыны булыпмы шушы карт Кыйтфирның?

З ә й т ү н ә.
Хатыны булырсың, сарайда торырсың! –
Көтеп Йосыфыңны, ахыр кавышырсың!

З ө л ә й х а *(мыскыллы)*.
Йосыф өчен яратылган саф гәүдәмне
Пычраттырыргамы шул карт фиргавеннән?!

З ә й т ү н ә.
Тынычлан, сөя алмас сине Кыйтфирың,
Хәйләләрем белән сезне аерырмын.
Хаҗәте чыкканда, аңа мин барырмын,
Син булып киенеп, янында калырмын!

З ө л ә й х а *(Таш Пот каршына тезләнә)*.
Таш Пот Ходам, тик син генә минем ярдәмчем,
Өметем – кавышу, шуны тизләтсәңче!
Йосыфны ит тизрәк Мисыр хөкемдары,
Мин – Зөләйха булыйм аның тугры яры!

*Пәрдә*

**5 күренеш**

*Кәнгандагы кое. И б н е - Й ә м и н  керә, елый-елый эзләнә. Коедан тавыш килә.*

К о е д а н  к и л г ә н  т а в ы ш:
Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, ләә иләәһә иллаллаһ!

И б н е - Й ә м и н  *(йөгереп коега бара)*.
Өч көн, өч төн йөрдем сине кырдан эзләп,
Син исәнсең икән, Ходайга мең рәхмәт.

Син үлгән, дип, әти канлы яшьләр түгә,
Сакламагансыз, дип, абыйларны сүгә.
Син тагы аз гына түз, мин бау табамын,
Шуның белән сине коедан аламын.

Ш ә м г у н *(тыңлап торган җиреннән атылып чыга да Ибне-Йәминне тотып бугазына пычак тери)*.

Атабызны безгә каршы котыртучы көчек,
Эзләп йөрмә, дидек, тәки каптың килеп!
Суеп үзеңне дә коега салырмын,
Шунда Йосыф белән бергә тончыгырсың!

Я һ ү д *(к ү р е н ә)*.

Шәмгун, Ибне-Йәмин әллә тотылдымы?

И б н е - Й ә м и н.

Үтерәләр! Аһ кем анда, коткарыгыз!

Ш ә м г у н.

Атабызга сатмак булдың абыйларың,
Әнә шул зур гөнаһтан коткарырбыз!

Я һ ү д.

Хыянәтең өчен бирелә бу җәза,
Юкса безне көтә өйдә бәла-каза!

*Ибне-Йәминне аяк астына бәйләп салалар.*

И б н е - Й ә м и н.

Берни эшләмәдем болай җәзаларлык.

Я һ ү д.

Абыйларын олы итеп карамагач,
Киңәшләрен киңәш итеп санамагач,
Авыр җәза тиешлеген аңламагач...

Ш ә м г у н.

Менә шушы пычак бугазыңа керер!

Я һ ү д.

Бәлкем, Ибне-Йәмин акылына килер?
Атабызга ачмас абыйлары серен.

И б н е - Й ә м и н.

Серегезне белмим, күрдем әтиемнең,
Йосыф, дип, агызган канлы күз яшьләрен,
Мине дә үтерсәгез, ул сукыраячак.

Ш ә м г у н.

Абыйлары серен ул бик теләп ачачак,
Өйгә кайту белән, безне ул сатачак,
Ата һәммәбезне урамга куачак!
Барлык мирас шушы икәүгә калачак!

Я һ ү д.

Без бит унау, алар ике бөртек кенә!
Ике бөртек күмәк янында чүп кенә!

Ш ә м г у н *(пычагын болгап)*.

Икесе дә безгә, безгә буйсыначак,
Азлар буйсынырга тиеш күпчелеккә!

Я һ ү д.

Йә син безне сатмам, диеп ант эчәрсең.

Ш ә м г у н.

Яки шул коега кадалып төшәрсең!

*Пычагын бугазына тери.*

И б н е - Й ә м и н.

Икебез дә үлсәк, атабыз түзәрме?
Каным ага, каным белән чыга җаным!
Аһ, үләсем килми, җитәр, абыйларым!
Валлаһи, ант итәм, серләрне саклармын!

Я һ ү д *(яфрак куеп, ярасын бәйли)*.

Акылың бар икән, безне тиз аңладың,

Ш ә м г у н *(аягындагы бауны чишә)*.

Атла, әнә, көтү көтә абыйларың!

Я һ ү д.

Аларга да ант ит, серне тануыңны.

Ш ә м г у н.

Юкса җимерерләр сугып танавыңны!

*Югалалар. Якында гына абыйлары белән очрашулары ишетелә. Юл ягыннан сәүдәгәр М а л и к һәм чиләкләр белән бау тоткан Б ә ш и р кол керә. Артта дөяләр үкерә, сакчылар тавышы ишетелә башлый.*

М а л и к.

Бәшир колым, менә кое, су алырсың.

*Бәшир шундук эшкә керешә.*

Арыкларга суны тутырып салырсың,
Дөяләребезне иплəп сугарырсың.

Б ә ш и р *(чиләк бәйләнгән бауны тарта)*.

Әнә, хуҗам, кара, килә әллә кемнәр,
Салмасларммы зыян, алар анда күбәү!

М а л и к.

Нык алыплар – минем тугры сакчыларым!

Б ә ш и р.

Чиләк бигрәк авыр, тутырган күк алтын!
Көч бетте, чиләкне, чыгара алмыймын...

М а л и к *(ярдәм итә)*.

Ычкындырма, мин дә менә булышамын!

*Йосыфны күреп иелә.*

Чиләккә ябышкан, углан, миңа тотын!

Б ә ш и р.

Ләхәүлә, җен дип торам, алды котым.

Й о с ы ф.

Мин җен түгел, мине Ходай сайлап алган!

Б ә ш и р.

Ходай сайлаганын коеларга атмас.

Й о с ы ф.

Үкенерләр әле, Йосыф патша булгач!
Йосыфка бәһа юклыгын белеп алгач!

М а л и к .

Бәһаң шулай ук кыйммәтме, ничә алтын?

Й о с ы ф .

Беркем түли алмас миңа тиеш хакым!

М а л и к .

Таш Поттан бу миңа искиткеч зур бүләк,
Ир баласыз идем бит, угыллы булдым!

*Туганнар аларны алка булып чолгап алалар. Абыйларын күргән Йосыф, куркуга төшеп, ирексездән Малик күләгәсенә сыена.*

Я һ ү д .

Бу безнең кол – иртән кырга качып китте!
Кяфер, аны табып, үзенеке итте.
Кайтарыгыз безгә качкан колыбызны,
Дәвам итәсегез килсә юлыгызны!

М а л и к .

Кайтарырга риза – риза булса үзе!

Р а у и л .

Безгә хуҗа була алмый коллар сүзе.
Бирмәсәгез әгәр безгә миннәт белән,
Һәлак булыр һәммәгез дә михнәт белән!

М а л и к .

Әйтеп торам кабат, алыгыз, ул – азат!
Минем колым булса, күрмәс иде газап!

*Ибне-Йәмин килеп Йосыфны коча. Туганнар моңа ачулана. Шәмгунга ым кагалар. Малик белән Бәширне дә камалыштан чыгармыйлар.*

Ш ә м г у н *(Ибне-Йәмингә төртеп).*

Тиз онытты́ң, бала...

*Ибне-Йәмин куркып читкә киткәч, Йосыфны тотып ала.*

Без сатарбыз хәзер сине әнә аңа.

Й о с ы ф .

Кяфер бит ул, кол итәмсез мине шуңа?!

Ш ә м г у н .

Сайла-сайла, бездән булсын яхшылык, –
Бер ягыңда үлем, бер ягыңда коллык!

Й о с ы ф .

Җәллад ясаганчы туган абыйларны,
Мең артыктыр кяфер колы булулары!

*Шәмгун Йосыфны Малик янына илтеп тезләндерә.*

М а л и к *(хәйләкәрләнеп).*

Янә әйтәм, риза мин, колыгыз – азат,
Бер сүзсез кайтарам, ул сезнеке кабат!

Л ә б и .

Тыңла, кяфер: сатабыз бу колны сезгә,
Шарты шулдыр: илтегез бик ерак җиргә!

М а л и к *(Бәширгә)*.
Бәшир колым, алып кил кәгазъ-каләмем!

*Бәширгә сакчылык итеп, Шәмгун, Дан, Яшьҗәр озата бара.)*

Беләсезме бөти язу кирәклеген?
Санап чыгу тиеш анда колыгызны
Сатарга мәҗбүр иттергән сәбәпләрне.
Тик аптырыйм, ничек сатмак кирәк аны,
Сездән артык күрке, гакълы, гадәтләре!

Я һ ү д .
Әткәебез бала килеш сатып алды,
Үсә төшкәч, безгә хәтәр көндәш булды.
Тора-бара инде явызланды тәмам,
Атабызга да баш булды мәкер белән!

*Бәшир өч туган карамагында Маликка кәгазь, каләм китерә.*

М а л и к *(язу әсбапларын сузып.)*
Ничә төрле гаебе бар, таныклагыз!
Дөрес булсын сату-алу шартларыбыз:
Сатарга ризалык бирдеме атагыз?

Я һ ү д .
Атабыз ризалык биргәнгә сатабыз!

Р а у и л *(яза)*.
«Колыбызның нәкъ өч төрле гайбе бардыр...»
Качучыдыр...

Ш ә м г у н *(өсти)*.
Урлаучыдыр...

Я һ ү д *(дәвам итә)*.
Алдакчыдыр.

М а л и к .
Аңладым, гаепләре белән сатып аламын,
Ләкин юк кулымда сыңар бер алтыным,
Төрле-төрле комачым күп, бар атласым!

Л ә б и .
Тыңла, кяфер, без моңарга баралмыйбыз.

Р ә й я л у н .
Кулыбызга комач-атлас алалмыйбыз.

Я ш ь җ ә р .
Риза түгел без һич мондый сәүдәгезгә.

Т у г а н н а р .
Бу колыбыз өчен акча бир син безгә!

М а л и к .
Каян алып? Менә карагыз соң санап.

*Янчыгын чыгарып, акчаларын җиргә сибә.*

Бар монда тик унсигез тәңкә-йармакъ!
Ризалашсак табам бик күп кирәк-ярак...

*Туганнар акчаларны җыеп алалар.*

Я һ ү д .

Унсигез йармакъны синнән санап алдык.

Р а у и л *(таныкламаның соңгы юлларын яза)*.

«Барыбыз да бу сәүдәдән разый калдык,
Колыбызны сатуны без мәгъкуль таптык
Гаепләрен санап таныклама яздык».

Я һ ү д .

Риза булып моңа менә куллар куйдык.

*Таныкламага куллар куелып, Маликка бирелә.*

Ш ә м г у н .

Тик, кяфер, ышанма бу ялганчы сүзенә!
Аягыннан бау-богавын чишә күрмә.

Т у г а н н а р .

Мисыргача синең күзәтүдә барсын,
Ризыгы су һәм арпа икмәге булсын!

*Туганнар читкә китә. Акча бүлешкән тавышлары гына ишетелеп тора. Бәшир бөти-таныклама һәм язу әсбапларын кәрванга илтеп килә.*

М а л и к .

Ник еглыйсың, углан, нидән кайгыларың?

Й о с ы ф .

Саубуллашмый китте туган абыйларым!
Рөхсәт бирсәң, яннарына барыр идем,
Бер туйганчы карап-күреп калыр идем.

М а л и к .

Күрмисеңме, алар сиңа ниләр кылды,
Теләделәр алар синнән аерылмакка,
Сатты алар сине миңа арзан хакка,
Йармакъ-тәңкә – кыйммәтсез ул, ул шундый вак,
Бер алтынның хакы мең дә дүрт йөз йармакъ,
Синең өчен алды алар шундый аз хак...
Бу бит өстеңнән чын-чынлап мыскыл кылмак.

Й о с ы ф .

Алар моны шулай кирәк диеп белде,
Теләкләре, морадлары шундый иде, –
Алар шуннан да артыкны белми инде,
Һәркем үзенә лаекны эшли инде.
Бер тәкәбберлегемә баш булалмадым!
Бәямне төшерде әнә шул масаюым!

*Малик, күңеле тулып, Йосыфка «рөхсәт» дигән хәрәкәт ясый, ул киткәч, күзен сөртә-сөртә, ташка барып утыра. Туганнары Йосыфны каршылый.*

Т у г а н н а р .

Йосыф, син безнеке түгел, кире борыл,
Сатып алды сине кяфер, син аңа кол!

Й о с ы ф .

Туганнарым, миннән тәмам туйдыгыз сез,
Атаемнан мине мәхрүм кылдыгыз сез,

Оҗмах биреп, тәмуг сатып алдыгыз сез,
Ходай рәхмәтеннән мәхрүм калдыгыз сез.
Азат идем, коллыкка төшердегез сез,
Егълый-егълый атабыз да калыр күзсез,
Зинһар, атабызны саклап йөртегез сез!
Аһ, кызганыч, ничек коллык кылырмын мин,
Фиргавеннәр коллыгында торырмын мин,
Олыларым, тагы күрерменме сезне, –
Аерылырга тәкъдир мәҗбүр итте безне.
Бу язмышны Тәңредән дип белү кирәк,
Хак хөкеменә коллар разый булу кирәк.
Ризалыкны бирү кирәк җәзасына, –
Буйсынып баш иик Ходай казасына.

*Туганнар кочаклашып елаша башлыйлар.*

Яһүд.
Йосыф энем, сине кире алыр идек.
Рауил.
Кулың алып, тәүбәне дә кылыр идек.
Ләби.
Сатудан да кире кайткан булыр идек.
Рәйялун.
Әмма ләкин атабызга ниләр диик?
Шәмгун.
Атабызга тагын ялган әйталмабыз.
Яшьҗәр.
Сине кире атабызга илталмабыз.
Дан.
Бу эштә без һичбер чара кылалмабыз.
Рауил.
Син түз инде...
Шәмгун.
Бу михнәткә.
Яһүд.
Йосыфыбыз!
Туганнар.
Иманлы Йосыфыбыз!
Йосыф.
Тәүбә, әстәгъфирулла!

*Туганнар китә. Малик, Бәширне ияртеп, һушсыз калган Йосыф янына бара.*

*Пәрдә*

**6 күренеш**

*Мисыр. Сарай. Зөләйха ялгыз. Зәйтүнә йөгерә-атлый керә.*

Зәйтүнә.
Кабат җаның туңган, ятасың урында,
Уйлыйсың һаман да үлемең турында.
Базарга чакырдык, анда да бармадың...

З ө л ә й х а *(торып утыра)*.
Нигә соң, нигә киңәшеңне тыңладым,
Синең сүзең белән карт кыз булып калдым.
Җиде ел бит үтте, бигрәк әрәм булды,
Йосыф белән тәки кавыша алмадым!

З ә й т ү н ә .
Аһ, Зөләйха, сизә күңел, кавышырсыз,
Бер-берегезне әле сез табышырсыз,
Бер-берегезгә берегеп ябышырсыз.

З ө л ә й х а .
Җиде ел бит инде хәтта төшкә керми.
Туктат алдауларны, алар берни бирми!
Өметсезлек йөзләремне дә сулдырды,
Озын кара чәчләремә чал кундырды!

З ә й т ү н ә .
Түз генә, йөзләрең кабат алсуланыр,
Озын кара чәчләрең үз төсен алыр!

З ө л ә й х а .
Ахмак бит син, кызый, Мисырдан ук куам!

З ә й т ү н ә .
Мин кыз түгел күптән, син аны беләсең!
Кусаң, Кыйтфирыңны, әнә, үзең сөярсең!

*К ы й т ф и р белән Р ә й я н ашыгып керә.*

К ы й т ф и р .
Зөләйхам, син юкка базарга бармадың!

З ө л ә й х а .
Авыру мин, Кыйтфир, зәгъфрандай саргайдым!

К ы й т ф и р .
Өйдә генә яту ул сулышны кисә,
Терелтер сине тиз, кояш нуры тисә.

Р ә й я н .
Зөләйха бикәбез, без сине көтәбез,
Синең белән бергә базарга китәбез.
Дәгыйр улы Малик анда сәүдә итә,
Алып кайткан колын күрсәң, нәкъ фәрештә!

З ө л ә й х а .
Дөньясыннан туйдым, мине үлем көтә. *(Бөркәнеп ята.)*

К ы й т ф и р *(көн дә шундый сүзләр ишеткәч бик исе китми)*.
Базар кыза бара, бөтен Мисыр шунда.
Яше-карты – барсы Йосыф кол янында.
Йөз нурлары аның көн яктысын каплый,
Сатып алыр өчен беркем акча тапмый.

*Зөләйха башындагы бөркәнчекне ача, тыңлый башлый. Кыйтфир белән Рәйян зал буйлап йөренәләр.*

З ө л ә й х а *(Зәйтүнәгә)*.
Йосыф, диләр, ник саталар аны, кем ул?

З ә й т ү н ә .
Адәм баласына охшамаган бер кол.

Өндәүчеләр аны бик тә мактадылар,
Алучылар һичбер гаеп тапмадылар.
Буе, дисәң – буе зифа, сылу үзе,
Йөзләре дә бик күрекле нурлы икән,
Теле матур, саф чишмәдәй, тугры сүзе,
Җитмеш ике телне белгән галим икән.

Зөләйха *(торып утыра)*.

Галимлеккә ул соң кайларда ирешкән?

Зәйтүнә.

Иң гаҗәбе – аңа унике яшь икән!

Зөләйха.

Унике яшьтә галимме – ялганлыйлар!

*Кабат капланып ята.*

Зәйтүнә.

Ансы инде безгә нәмәгълүм – караңгы.
Мәгәр беркем аны сатып алалмады.
Кыйтфир газиз шунда диде: «Үзем алам,
Энҗе-мәрҗән, гәүһәр-якут барсын салам,
Чын бәһасен тизрәк игълан кыл син!»
Малик әйтте: «Үлчәвемә алтын сал син,
Авырлыгы аның Йосыф кадәр тартсын!»
Кыйтфир шундук мондый шартка ризалашты,
Шундук хәзинәчесен дә чакыртты,
Алтын арты алтын һаман килә торды,
Хәзинәдә алтыннары һич калмады,
Үлчәүгә ул нәкъ биш йөз мең алтын куйды, –
Алтыннары Йосыф кадәр тарталмады.

*Зөләйха кабат торып утыра. Кыйтфир белән Рәйян гәпләшеп якынаялар.*

Кыйтфир.

Өстәп шушы алтыннарга затлы атлас куйдым,
Ефәк парча, мисык-гамбәр барсын җыйдым.
Гәүһәр-якут, энҗе-мәрҗән тагын куйдым,
Барлык малым Йосыф кадәр тарталмагач,
Йосыф колны мин дә сатып алалмагач,
Мисыр малы аңа бәһа булалмагач –
Саташырлык дәрәҗәдә гаҗиз калдым!

Рәйян.

Мисыр малына без кушсак *(Зөләйхага ымлап)* Мәгърибнекен?

Кыйтфир.

Кушар идем, хәлдән килсә, бар мәшърикнекен!

Рәйян.

Чакырыйк әле, әйдә, Маликнең үзен!

Кыйтфир.

Ишетик шул, әйдә, сәүдәгәрнең сүзен!

*Кыйтфир белән Рәйян чыгып китә.*

Зөләйха.

Бер кол өчен Мисыр малы җитмәс, имеш,
Юк, бу кол артында сер булырга тиеш.

Мондый бәя Малик нәфесе түгелме?
Үлчәү дигәннәре дә әле дөресме?
Дөрес икән, ничек җиңел килә алтын?
Аеры үлчәсеннәр Кыйтфир алтыннарын.

З ә й т ү н ә.

Халык белән тулган сарай мәйданнары,
Кайтты капчык-капчык Кыйтфир алтыннары.
Йосыфны китерде Малик якыннары
Йосыф кулын үбә Мисыр хатыннары.

З ө л ә й х а *(тәрәзәгә омтыла)*.

Аһ, Таш Пот санәм, кол түгел бу – Йосыф үзе!

*Һуштан язып егыла, Зәйтүнә аны урынга илтеп яткыра. Залга К ы й т ф и р , Р ә й я н һәм башкалар керә. Зөләйха янына киләләр. Аны торгызып утырталар. М а л и к Й о с ы ф ны ияртеп керә.*

К ы й т ф и р.

Зөләйха, кадерлем, күз салчы бу колга,
Балабыз булмады, без мохтаҗ угылга!

*Зөләйха йөзен учы белән каплый.*

Р ә й я н.

Сыңары белән булса да аңа күз сал,
Форсат бар чагында син аны күреп кал!

К ы й т ф и р.

Кадерлем, ул лаек улыбыз булырга,
Безнең белән бергә патшалык кылырга!

*Зөләйханың битен ача. Әмма Зөләйха кабат һушсыз кала. Аны Мисыр хатыннары уратып ала.*

Тынычлык! Зөләйхам минем авырып китте.
Терелер ул, мәҗлесебез дәвам итсен!
Дәгыйр улы Малик, сиңа мондый сүзем:
Йосыф бәһасенә дөнья малы җитмәс,
Бүләк ит син миңа җитмәгән кадәрен!

М а л и к *(баш ия)*.

Мин риза, тик әүвәл үзе белән сөйләшәмен!

*Йосыфны читкә алып китә. Рәйян Кыйтфир белән икенче якка юнәлә.*

Б е р е н ч е һ ә м И к е н ч е х а т ы н.

Зөләйхабыз чирле түгел, чибәр иде.

Ө ч е н ч е һ ә м Д ү р т е н ч е х а т ы н.

Бөтен Мисырны балкыткан гүзәл иде.

Б и ш е н ч е һ ә м А л т ы н ч ы х а т ы н.

Күптәнме соң әле чирләп киткәненә?

Җ и д е н ч е һ ә м С и г е з е н ч е х а т ы н.

Аһ, бик борчылам аның бирешкәненә.

З ә й т ү н ә.

Ун ел инде аны ниндидер корт кимерә...

Хатыннар *(куркынып читкә китәләр).*
Ко-о-о-рт?!
Зәйтүнә.
Юк-ла инде, әллә нинди төшләр күрә,
Keме беләндер очрашырга тилмерә.

*Хатыннар кабат якын киләләр.*

Беренче хатын.
Гүзәл Зөләйхабыз...
Икенче хатын.
Гүзәл Зөләйхабыз...
Өченче хатын.
...аңына килде!
Дүртенче хатын.
...аңына килде!
Бишенче хатын.
Күзләрен шар ачты...
Алтынчы хатын.
Күзләрен шар ачты...
Җиденче хатын.
Мине күргәч көлде!
Сигезенче хатын.
Мине күргәч көлде!

Зөләйха.
Килдегезме? *(Торырга итә, кабат хәле китә.)*
Зәйтүнә.
...хәле начар, күрдегезме.
Зөләйханы саф һавага күчерикче,
Табиб биргән даруларны эчерикче.

*Хатын-кызлар Зөләйханы балконга алып чыгалар.*

Малик.
Йосыф, Кыйтфир шартына мин риза булам,
Шул бәһагә җиткән кадәр түләү алам.
Әйтче, зинһар, нигә кулларыңа нурлар иңгән?
Әле мондый хәлне мин беренче күрәм!
Йосыф.
Кемлегемне сиңа хәзер сөйләп бирәм,
Сөйлим сиңа моны, ләкин бер шарт белән:
Кешеләрдән сакла минем бу серемне,
Иманлы Йосыф, дип атадылар мине.
Олы бабам Хак Ходаның тугры колы
Атам минем Якуб булыр, Исхак углы.
Малик.
Аһ, зур гөнаһ алдым, әйткән булсаң элек,
Сатмас идем, пәйгамбәрлегеңне белеп.
Илтер идем әткәеңә, азат кылып, –
Үзем калыр идем синең колың булып.

Й о с ы ф .

Бу мөмкинлек күптән инде үтеп китте,
Җавап булып минем тәкәбберлеккә,
Тәңребезнең хөкеме булды, чара бетте.
Хак әмеренә буйсыныргa вакыт җитте.

М а л и к .

Тыелырмын Йосыфны беләм диюдән,
Менә сату таныклыгын да бирәм!

*Кесәсеннән танытманы алып, Йосыфка тапшыра.*

Бу сереңне, пәйгамбәрем, белмәс һичкем,
Өстен һәммә эштән Ходай йөрткән хөкем. *(Тезләнә.)*
Пәйгамбәр, ялварам, чыкмады йолдызым,
Юктыр минем улым, бар тик алты кызым.

Й о с ы ф *(кул күтәреп дога кыла).*

Дәгыйр Мәлигенең җиде улы тусын!
Аталары кебек кешелекле булсын!

*Кыйтфир энесен ияртеп хәлдә Йосыфларга якынлаша.*

К ы й т ф и р .

Малик, инде килешенгән вакыт үтте,
Алыш-биреш шарты ничек булып бетте?

М а л и к *(башын иеп).*

Хөрмәтлебез Кыйтфир, Мисыр хөкемдары,
Мәңге яшь булсын безнең Зөләйхабыз.
Шулдыр сезгә сүзем, Йосыф һич кол түгел,
Кабатлап та әйтәм, Йосыф – ирекле гөл!
Куйган шартларымны инде онытыгыз,
Йосыфны алыгыз – угыллы булыгыз!

*Малик китә. Йосыф, Кыйтфир каршына тезләнеп, аның кулын үбә.*

К ы й т ф и р .

Зөләйха, Мисырда яңа бер көн туды:
Ниһаять, безнең дә үз углыбыз булды!

З ә й т ү н ә *(күренә).*

Зөләйхагыз эчте табиб даруларын,
Уятыйммы, аям?

К ы й т ф и р .

...савыкканчы йокласын!
Савыккач әйтерсең: Йосыфны сакласын,
Аны миннән дә күп артык олыласын! *(Китә.)*

*Зәйтүнә, Йосыфны ияртеп, Зөләйха янына уза. Сарайда тантана башлана.*
*Шәрекъ көйләре. Биюләр. Алыплар чыгышы.*

*Пәрдә*

**7 күренеш**

*Кыйтфирның Йосыфны уллыкка алганына алты ел вакыт узган. Зөләйханың Йосыф өчен төзеткән сарае. Таякка таянган К ы й т ф и р ны култыклап Р ә й я н керә.*

Р ә й я н *(алыпларга).*

Әй сез, Йосыф тәхетен монда китерегез!
Хөкемдарыбызны шунда күтәрегез!

К ы й т ф и р .

Туйдырды инде ул тәхетләрдә утыру да.

Р ә й я н .

Туры килде микән мондыйда утырырга?

*Алыплар Кыйтфирны тәхеткә утырталар.*

К ы й т ф и р .

Гаҗәп җайлы икән, бар тарафны күрәм.

Р ә й я н .

Йосыфны Зөләйха гел зиннәткә төргән.
Тәхете ярар, күр сарай бизәлешен, –
Күпме байлык монда сарыф ителмешен!
Түшәмнәрдә гади түгел җәүһәр кәндил,
Агачлары алтын, түшәмгә үк җиткән,
Җимешләре, төрле-төрле асылташлар,
Алтыннан чигелгән Йосыф рәсеме белән
Сарайдагы бар диварлар шыплап тулган.
Ни өчен соң шулчаклы мал исраф булган,
Боларны берничек аңлый алмыйм туган?!

К ы й т ф и р .

Йосыф безнең үз углыбыз булсын, дидем,
Кабул кылган, әнә, Зөләйха бу сүзем.
Хикмәтле сарайга сокланып туялмыйм,
Сине ни борчыйдыр, һич аңлый алмыйм?!

Р ә й я н .

Йосыфны Зөләйха артык узындыра,
Өч йөз алтмыш кием әзерләгән аңа.
Һәр көнне Йосыфка яңаны кидертә.
Бу эшләрен бөтен кеше гаеп итә,
Мондый киемнәрне син кимисең хәтта.

К ы й т ф и р .

Рәйян энем, исең китмәсен боларга,
Үзем куштым аны шулай олыларга.
Зөләйха эшләре – минем сүзләрдән,
Минем сүзләремне гадел дип белгәннән!
Сулышлар киңәйде ганбәр исләреннән.
Йөрәгем еш тибә рәхмәт хисләреннән.

Р ә й я н .

Һич килешми, азыну болар, йа Хода,
Йосыф патша булган! Мин кара кайгыда!

К ы й т ф и р .

Бу сарайны карап йөреп, мин дә ардым,
Җитәр, калганнарын иртәгә карармын.

*Авыр гына тора, тәхеттән төшкәндә, таягы таеп китә, алыплар аны тотып кала. Кыйтфирлар чыга. З ә й т ү н ә Мисыр хатыннарын ияртеп кайта. Залга кергәч, алар телсез калалар. Бер-берсенә матурлыкны күрсәтәләр, әмма тел әйләндереп сүз әйтә алмыйлар.*

З ә й т ү н ә.

Әйе-әйе, шулай-шулай, матурмыни?
Мин дә бит шулай дим, дөньяда юк инде.
Һич сабыры калмады – гыйшкы җиңде,
Барысы Йосыф өчен, газиз Йосыфныкы!
Әйе шул, әйе, минем дә бар өлешем,
Мин өйрәткәнчә бу сарайның төзелеше.
Сарай салу артык иде, дидегезме?
Әллә соң сез шуны да белми идегезме?
Теге чакта аның хәлен күрдегезме?

*Хатыннар аны урап ала.*

Зөләйханың бигрәк мөшкел иде хәле,
Алары сер булсын, әйтми торам әле.

М и с ы р х а т ы н н а р ы *(кинәт телгә килеп).*

Әйтмәсәң дә ачык, үлеп гашыйк булган,
Дәртен басар өчен, зур сарай салдырган!

З ә й т ү н ә.

Менә ансын мин әйтмәдем – бу сезнең сүз!

М и с ы р х а т ы н н а р ы.

Без әллә ниләр дә әйтербез, ә син түз.

З ә й т ү н ә.

Зөләйха изге, сез үзегез дә күрерсез.

М и с ы р х а т ы н н а р ы.

Ә изге булмаса, аңардан көләрбез!

З ә й т ү н ә.

Ак бәхетен күреп, әле кара көярсез!

Б е р е н ч е х а т ы н.

Монда Йосыфны сагынып килгән идем!

И к е н ч е х а т ы н.

Мин дә аны алты ел күрмәгән идем!

Ө ч е н ч е х а т ы н.

Үсеп җитеп, булган ди ул сылу егет!

Д ү р т е н ч е х а т ы н.

Йосыфны күрүе бит иң зур бәхет!

М и с ы р х а т ы н н а р ы.

Алып барчы безне Йосыф янына!

З ә й т ү н ә.

Ә кайда миңа дигән алтыннарыгыз?
Ярый инде, әйдәгез, ә юк, туктагыз,
Монда таба килеп ята Зөләйхабыз!
Бүген булмый, булмый, тизрәк китегез!

М и с ы р х а т ы н н а р ы.

Аһ, кайчангача шулай алдап йөртерсез?

З ә й т ү н ә.

Иртәгә тәхетендә утырган килеш күрерсез!
Хөллә итәгеннән дә хәтта үбәрсез!

Мисыр хатыннары.
Күрәбез, күрәбез, күрәбез, күрәбез!

*Хатыннар алтыннарын янчыкларга салалар, аһ-ух килешеп чыгалар.*

Зөләйха *(ярсып керә).*
Кайда Йосыф, нигә килми юынырга?
Көтәм-көтәм, белмим инде ни кылырга?
Зәйтүнә.
Унсигезе тулды, Йосыф күптән егет,
Юыныр үзе дә, йөрмәче борчылып!
Зөләйха.
Син, димәк, котырткан, йөри шуңа качып.
Ирек бирми чәчен тарап үрергә дә,
Теләми бит мине хәтта күрергә дә!
Ялган киңәшләрең тотып булам харап!
Зәйтүнә.
Булмый инде сиңа һич кенә дә ярап.
Зөләйха.
Могҗизалы сарай миннән төзеттерден,
Ун мең төрле нәкыш белән бизәттерден,
Энҗе-мәрҗән белән җиһазлансын, диден,
Диварларын бәллүр белән эчләттерден,
Кызыл алтын булсын, диден, агачлары,
Ефәк, алтын-көмеш булды яфраклары,
Диварларны бизәттерден җәүһәр таштан,
Атларны да саф көмештән ясаттырдың,
Атка алтын Йосыф сынын атландырттың!
Ник соң килми Йосыф, аны тәхете көтә,
Ул туганчы ук туган бәхете көтә!
Бар, тиз чакыр монда, Кыйтфир кушты, диеп!
Зәйтүнә.
Чакырам, тик аны аптыратма сөеп,
Син һаман карыйсың аңа бала итеп. *(Китә.)*
Зөләйха.
Бала итеп карый алмыйм шул аңа! *(Җырлый.)*
Унөч ел элек үк чакырды Мисырга.
Үзе тумас борын ничек чакыралган?
Тумаса да, төшкә ничек керә алган?
Ул тумаган килеш очраштык без ничек?
Бергә булырбыз, дип, вәгъдәләр бирештек,
Йә әйт, Йосыф, шуннан, нәрсәгә ирештек, –
Бала һәм карт хатын булып күрештек?
Чакыргач Мисырга, Йосыфым, үзең
Ник качасың миннән тыңламый бер сүзем?
Берәр сәгать күрми торсам синең йөзең,
Өзгәләнә йөрәгем, бирче, Санәм, түзем!

*Таш Пот сыны каршысына ава.* Й о с ы ф *керә.*

Йосыф.
Кыйтфир атам кайда? Ул чакырткан икән.

З ө л ә й х а .

Кыйтфир бик ошатты синең сараеңны
Үзеңнең әлегәчә юк бит кергәнең,
Күпме чакырып та кереп күрмәдең!

Й о с ы ф .

Кыйтфир атам ошатты, дисең, и анам,
Бу сүзеңә, кичер, мин ышана алмам.
Бу сарайда шайтан-ләгыйнь коткысы бар,
Нәфсе хуҗа монда, җаныма урын тар!

З ө л ә й х а .

Өч ел төзеттем бу сарайны сиңа,
Рәхмәтең шушы булдымы инде миңа?
Егерме ел элек син төшемә кереп...

Й о с ы ф .

И Зөләйха анам, сөйлә инде белеп,
Унсигезем тулды әле яңа гына!

З ө л ә й х а .

Тыңла, моннан нәкъ унсигез ел элек,
Егерме яшь тулганда, төшемә кереп,
Гүзәллегең белән тәмам гашыйк итеп,
Син чакырдың мине назлы күрешүгә!
Шуннан бирле беркемгә дә карамадым,
Сафлыгымны да тик сиңа багышладым,
Ә син моны берничек тә аңламадың,
Инде ник качасың, килгәч хөкемеңә?!

Й о с ы ф .

Синнән түгел, куркам шайтан коткысыннан
Былчыранудан, Ходабыз ачуыннан.

*Зөләйха, күлмәген салып, Таш сынның йөзен каплый. Зөләйханың эчке күлмәге дә энҗе-мәрҗән белән чигелгән. Аягында алтын тәңкәләр чыңлый.*

З ө л ә й х а .

Ачуланма, Таш Пот Ходам, күпне күрмә!
Менә, туклан, монда сиңа татлы хөрмә,
Синең алда һичбер гаебем юк минем,
Йосыф каршында да теләгем ак минем!
Иманлы Йосыф дип атыйлар бит аны,
Аның да бардыр бит тыпырчынган җаны!

Й о с ы ф .

Йа Зөләйха анам, син ни-нәрсә кылдың?
Чишенгдең дә җансыз Потны каплап куйдың.
Пот көчсез ул, кирәк түгел ябып кую,
Наданлык ул аңа Тәңре дип табыну, –
Изге эшкә яман эшне катыштыру.
Пот яралмыш кына, Алла – яралтучы!
Аннан качып котылалмый һичбер кеше,
Күреп тора Алла, һәрбер яшерен эшне.

З ө л ә й х а .

Буең-сының үсте, тәмам таң калырлык,
Сине күрү белән һуштан ук язарлык
Яңа туган айга охшаш бу кашларың,

Энҗеләрдәй тезелеп тора бу тешләрең,
Мишек-җофар исе чәчәдер чәчләрең,
Аһ, үз кулларым белән тарап үримче!

Йосыф.

Йа Зөләйха анам, тыңлачы сүземне,
Әйткәннәрем аша аңлый күр үзеңне!
Минем тәннән җаным чыкса, син абайла,
Күркәмлекнең хәтрә кадәр нуры калмас.
Мәңге яратам, дигән гашыйк ярым да
Череп барган бу гәүдәмә карый алмас.
Тышкы матурлыклар бер алдавыч кына
Кеше гүзәллеге җаны аша туа, –
Җан исә буйсына Хак Аллага гына!

Зөләйха.

Минем хәлем үзгә бу сүзләрдән айрык:
Минем синнән ваз кичәр дәрманым юк.
Сине сөеп, җанымны сиңа бәйләдем,
Алладан куркырга җитми көч-куәтем,
Фида кылдым сиңа барлык мал-мөлкәтем!
Кайда соң, Йосыфым, егетлек кодрәтең?!
Әйдә, утырыйкчы шушы тәхеткә,
Без чумарбыз икәү илаһи бәхеткә!

*Тәхеткә этеп китерә.*

Йосыф *(Зөләйхадан сакланып, тәхеткә менә).*

Имансызның җаны һич тә камил булмас,
Ходай каршысында берни кыла алмас.

Зөләйха.

Ялгышма, каршыңда мин – Зөләйха бары,
Иң бәхетсез җан бу: кабул итми аны,
Җаныннан да якынрак күргән яры.

Йосыф.

Төшләр безгә зур сынаулар алып килә:
Якуб атамны күрдем бүген төшемдә,
Яман эштән нәфсеңне тый, Йосыф, диде,
Тагын шунда кисәтүле аять инде:
«Уйнашлык кылучы кол булыр Иблискә!»

*Тәхеттән төшеп баручы Йосыф Зөләйхага орына, тегесе һуштан язып ава башлый, Йосыф аны тәхеткә утырта, Зөләйха аны үзенә тарта.*

Зөләйха.

Тукта инде, Йосыф, юкмы әллә ирлегең?!

*Йосыф, тартылып китеп, тәхеттән төшә башлый, киеменең аскы өлешен тотып тора торган бау, өзелеп, Зөләйха кулында кала. Залга кергән Кыйтфир белән Рәйянны күргән Йосыф тәмам каушауда. Инде Мисыр хатыннарын ияртеп Зәйтүнә дә күренгәч, ялангач ботларын ябар өчен, Пот өстендәге Зөләйха күлмәген ала. Зөләйха исә Йосыфның киеме белән каплана.*

Мисыр хатыннары.

А-а-а-а-һ!

Рәйян.

Кем рөхсәте белән кердегез сез монда?!
Сезне дә ташлаттырам төрмә-зинданга.
Бая минем ризыгыма агу салдылар!
Инде Зөләйхага да зур ау кордылар!

Зәйтүнә.

Бушатыгыз залны! Харап итәсез бит!

*Мисыр хатыннарын залдан алып чыгып китә.*

Рәйян.

Мин кисәттем, Йосыф патша булмакчы, дип.
Болар һәммәсе дә аның хикмәтләре!
Кәнган шымчысы үзе качып китсә дә,
Сатып алган агулаучылары әйтте.

Кыйтфир.

Алары кемнәр?

Рәйян.

Сарай хезмәтчеләре...

Кыйтфир.

Нинди эштә?

Рәйян.

Икмәкче белән шәрабче.
Зинданга яптым, хөкемеңне көтәләр.

Кыйтфир *(көч-хәл белән тәхет итәгенә утыра, Йосыфка).*

Йосыф, син ничек бу эшләргә баралдың?
Бу эшләрне эшләп бит син каралдың!
Вафасызлык эшләп, зур гөнаһлы булдың, –
Бөтен галәм алдында безне рисвай кылдың!
Зөләйха анаң күлмәген киеп калдың!

*Авырлык белән тәхеткә менә.*

Йа Зөләйха, ник син күлмәгеңне салдың,
Йосыфның киемен нигә киеп алдың?!

*Зөләйха елый-елый чыгып йөгерә. Зәйтүнә керә. Рәйян Йосыфтан күлмәген алып, Зәйтүнәгә бирә, тегесе Зөләйха артыннан чыга һәм Йосыфның киеме белән әйләнеп керә. Йосыф киенә.*

Рәйян.

Нишләп йөрде монда җиде ят хатыннар?

Зәйтүнә.

Зөләйхага гына әйтү тиеш аны!

Кыйтфир.

Чакырып китер каршыма Зөләйханы!
Һәм монда чуалган теге хатыннарны! *(Зәйтүнә киткәч.)*
Йосыф, ник әйтмисең, нәрсә булды, улым?

Й о с ы ф .

Тәңре күрер, күргәнендә һич ялгышмас,
Аның язган тәкъдирен кол аңлый алмас,
Тәңре угы һич тайпылмас юлдан читкә,
Каза угы ул максатка һәрчак җитә.

К ы й т ф и р .

Каза угы, дисең, гафу үтенмисең?

Й о с ы ф *(тезләнеп).*

Мин сәбәпче булдым мондый фетнәләргә,
Лаек мин һәртөрле усал шелтәләргә!
Мисыр хөкемдары, гафу ит колыңны!
Кызганмачы миннән төрмә-зинданыңны!

*Зөләйха һәм Мисыр хатыннарын ияртеп Зәйтүнә керә.*

К ы й т ф и р .

Йа Зөләйха, Йосыф синнән гафу сорый,
Гафу ит син углыбызны минем хакка!

*(Мисыр хатыннарына.)*

Мисыр хатыннары, сез дә бире килегез,
Сараебызга кереп нишләп йөрдегез?

М и с ы р   х а т ы н н а р ы .

Зинһар, гафу итче, Мисыр хөкемдары,
Максат – чынын белү, без илче нибары!

Р ә й я н .

Юк сүз сөйли алар, имеш, илчеләре,
Алдап-йолдап гайбәт җыеп йөрүләре!

З ә й т ү н ә .

Мисырның дүрт йөз хатыны җыелышкан
Ул мәҗлестә иләмсез зур гауга чыккан:
Зөләйхабыз хәлен сөйләп көлешкәннәр,
Зөләйха колына гашыйк, диешкәннәр.
Әмма бу хатыннар ышанмаган юк сүзләргә, –
Үзләре теләп әйләнгән илчеләргә!

К ы й т ф и р .

Монсы аңлашылды. *(Зөләйхага.)* Инде син бир җавап,
Ялвара Йосыфың, синнән гафу сорап!

З ө л ә й х а .

Гафу итәрмен мин аны, әгәр, Кыйтфир,
Шушы сарайга олы бер мәҗлес җыйсаң,
Миннән көлгән дүрт йөз хатынны чакырсаң,
Ул хатыннар көрсиләргә утырсалар,
Кулларына әфлисун, пычак тотсалар...
Алар каршыннан Йосыфны да уздырсаң!
Булыр миннән Йосыфка гафу-рахман!
Хатыннар да белер Зөләйха гаебен,
Тәңре дә күрсен миңа язган тәкъдирен!

Й о с ы ф .

Мәҗлес сынаулары миннән башка үтәр, –
Мине алда Ходай сынаулары көтәр.

Р ә й я н .

Ходай сынаулары түгел, төрмә көтәр!

К ы й т ф и р .

Төрмә көтәме-юкмы, тикшерү булыр.
Иртәгә сарайда зур табын корылыр!
Дүрт йөз хатынга чакыру җибәрелсен,
Хәзер үк эшкә бар сарай күтәрелсен!

*Пәрдә*

**8 күренеш**

*Шәрекънең дәртле көйләре. Идәннәргә җәелгән келәмнәр өстендә ашъяулыклар, аларда көрсиләр, көрсиләрдә пычак, әфлисуннар. Көрсиләр артында күп кенә хатыннар.*

З ө л ә й х а .

И Мисырның иң күрекле хатыннары,
Зурлап килүегез өчен мең-мең рәхмәт!
Җитешегез, алдыгызда төрле нигъмәт,
Әүвәл әфлисун турагыз, шуннан чыгар иң зур хикмәт!

*Хатыннар әфлисун турарга керешәләр. Залда ут сүнә, шулчак кулына кызыл алтык табак тоткан, йөзе искиткеч нур белән балкучы Йосыф керә. Хатыннар бертавыштан «Аһ!» дигән аваз салалар. Үзләре сизмичә, пычак белән бармакларын турыйлар. Йосыф югала, ут кабат яна. Хатыннар кискәләнгән бармакларын канлы кулъяулыкларга урыйлар.*

Б е р е н ч е   х а т ы н .

Валлаһидыр, бу коллары адәм түгел!

И к е н ч е   х а т ы н .

Түгел, түгел...

Ө ч е н ч е   х а т ы н .

Моның кебек кол булуы мөмкин түгел!

Д ү р т е н ч е   х а т ы н .

Мөмкин түгел!

Б и ш е н ч е   х а т ы н .

Моны күреп, ничек шашмый торсын күңел!

А л т ы н ч ы   х а т ы н .

Шаша күңел!

Җ и д е н ч е   х а т ы н .

Кол дип әйткәннәре чын фәрештә икән!

С и г е з е н ч е   х а т ы н .

Чын фәрештә икән!

З ө л ә й х а .

Инде белдегез авыруларым нилектән,
Туралды бармаклар, аны бер күрүдән,
Нәкъ җиде ел инде ул каршымда тора,
Гыйшкым шушы Йосыфка көннән-көн арта,
Гаҗиз булсам да, бармак тураганым юк,
Димәк, сабырлыгым сезнекеннән артык!

*Шомлы көй. Зәйтүнә елап керә.*

З ә й т ү н ә.

И Зөләйха, тол калдың – Кыйтфирың үлгән!

М и с ы р   х а т ы н н а р ы.

И Зөләйха, тол калдың, хөкемдар үлгән!

*Хатыннар югала. Зөләйха елап кергән Йосыфны юата башлый.*

З ө л ә й х а.

Олы кайгы төште безнең башыбызга.

Й о с ы ф.

Тәңре зур сынаулар куйды каршыбызга.

З ө л ә й х а.

Таш Сыныбыз илтә сине тәхетеңә.

Й о с ы ф.

Ходам мине дәшә тоткын бәхетенә.

З ө л ә й х а.

Зинданны миннән өстен санысыңмы?
Тоткынны котәләр анда типкәләргә!
Кулларым бирелгән сине иркәләргә,
Матурлыгың Хактан – сокланырга сөеп,
Рәнҗеттең, тоткынлык синнән өстен, диеп.

Й о с ы ф.

Рәнҗемә, Зөләйха, мин Ходайдан куркам
Үземә ярдәмгә Ходамны чакырам!

З ө л ә й х а.

Кыйтфир сине, патша итәм, дип ант эчте,
Өлгерә алмады, бакыйлыкка күчте.
Син зиндан сайласаң, Рәйян патша булыр,
Башыңа туктаусыз бәла явып торыр!

Й о с ы ф.

Язмышыбыз безнең Хак Тәңре кулында,
Бозыклык кылмау – колы ихтыярында.

З ө л ә й х а.

Йөрәгемдә, Йосыф, син салган зур яра,
Сөю утың белән ярамны дәвала! *(Йосыфка сарыла.)*

Й о с ы ф.

И Ходам, коткар безне гөнаһ кылудан,
Бозык эшләр эшләп оятка калудан,
Кыямәт көн Хак каршында хур булудан,
Ирешмәсен Иблис-ләгыйнь морадына!
Иманлыны Хак кодрәте табыштырыр,
Чын гашыйкларны мәңгегә кавыштырыр!

Р ә й я н *(керә).*

Әйе-әйе, зиндан белән кавыштырыр!
Абый үлгәч тә, уең гел бозыклыкта,
Боер, Зөләйха, ташлыйкчы тоткынлыкка!
Төзәлмәсә, чыгу юлын таба алмас,
Караңгы зинданнан мәңге котылалмас!

З ө л ә й х а.

Йосыф, мине күреп, акылын җуймагач,
Күңелдәге дәрткә дәрман табылмагач,

Миңа җаны-тәне белән буйсынмагач,
Сабырыма морад хасил булдырмагач!
Өметне сүндерде, йотсын үзен зиндан! *(Китә.)*

Р ә й я н .

Тәкәббер бу колны сарайдан алыгыз,
Фетнәчеләр кырына илтеп салыгыз!

Й о с ы ф .

Хөкемдар, миңа ярдәм ит төзәлергә:
Боер көне-төне китап күчерергә.

Р ә й я н .

Боерам, бу колга китаплар бирелсен,
Көн дими, төн дими шуларны күчерсен!

*Алыплар Йосыфны алып чыга.*

*Пәрдә*

## 2 ПӘРДӘ

### 1 күренеш

*Зиндан. Икмәкче җиргә ятып ауный, шыңшый, шуыша, җиргә йодрыклары белән төя. Шәрабче исә үз-үзе белән сөйләшеп йөри, кычкыргалап куя. Сакал-мыегы үскән Йосыф алардан артта тәрәзә каршында китап күчерә.*

И к м ә к ч е .

Үлсен иде, үлсен иде, мур кыргыры!
Зинданга тыгуына унбер ел тулды!
Унбер ел буе хәсрәт утында янам,
Унбер елда үлде хатын, үлде анам!

Ш ә р а б ч е .

Тукта, зинһар, кирәкмәгәнгә шаулама,
Китап күчерүчегә комачаулама.

И к м ә к ч е .

Булмый аңа берничек тә комачаулап,
Китап яза, намаз укый, бер дә харап,
Бирә алмыйдыр ул хәтта төш тә юрап.

Ш ә р а б ч е .

Нинди төш күрдең, йә сөйләп күрсәт,
Шуннан үземнекен сиңа бирәм сөйләп!

И к м ә к ч е .

Гарык булдым һәр тоткынга сөйләп йөреп,
Зиндан әхле рәхәтләнә миннән көлеп!

Ш ә р а б ч е *(Йосыфка күрсәтеп).*

Ул соң ни ди, ул да синнән көлмидер бит?

И к м ә к ч е .

Әйтеп торам, безнең кебек кеше түгел ул, дип.

Ш ә р а б ч е .

Юкка түгелдер лә китап күчерүе,
Әйдә, әүвәл сөйләп карыйк минем төшне.

И к м ә к ч е .

Сөйләп кара, бер дә аңа ышаналмыйм.

Ш ә р а б ч е .

Хөрмәтлем, унбер ел инде зинданда без,
Сүзсез булдың, шуңа сине без белмәдек.
Кол булгансың Кыйтфир белән Зөләйхага,
Рәхәттән сөргәннәр безне сөргән кебек,
Унбер ел буе түздең һәрбер җәзага.
Икмәкче белән без бүген төшләр күрдек,
Хәлеңнән килерме шуларны юрарга?

Й о с ы ф .

Белмим, атам Якуб юрый иде белеп,
Бөтен Кәнган юратыр иде аңа килеп.

Ш ә р а б ч е .

Атам – Якуб, дидең, ул бер пәйгамбәрдер,
Китап язгач, үзең дә изгеләрдәндер,
Сыныйк, атаң хикмәте сиңа күчмәгәнме?
Юрап бирче безгә төштә күргәннәрне:
Өч тәлгәш йөземне сыттым мин төшемдә,
Койдым аны Кызыл алтын касәләргә,
Шунда мәлик Рәйян берсен алып эчте.
Касә тулы килеш кабат миңа күчте?

Й о с ы ф .

Сөен, Рәйян сине азат итә тиздән,
Кайтыр сарайдагы элекке дәрәҗәң.

И к м ә к ч е .

Шулай юрый алсаң икән минекен дә:
Төштә бик күп икмәк куеп баш өстемә,
Илтә киттем мәлик Рәйян өстәленә.
Юлда кошлар икмәкләрне чукыдылар,
Чукып бетергәч тә юк булдылар.

Й о с ы ф .

Хәтәр икән, туган, синең күргән төшең,
Бик аяныч, гаять мөшкел синең эшең.
Рәйян тиздән кисәр ашаячак ашың,
Хакыйкатьтер, син шуны бел: бетә башың!

И к м ә к ч е .

Аһ, алай булмасын, күрмәдем бу төшне!

Й о с ы ф .

Хак җибәргән казаның кире кайтмас көче!

*Ак һәм Кызыл алыплар керә. Агы шат Шәрабче кырына килеп баса, Кызылы елап утыручы Икмәкчене ашыктыра башлый.*

Ш ә р а б ч е *(әйберләрен җыя).*

Әйтер сүзең юкмы, тапшырырмын, углан.

Й о с ы ф .

Кәнгандә бар Ягкуб, тереме мин – белми,
Күп елаудан сукырайган, һични күрми,
Эзләп табып, берәр Кәнган сәүдәгәрен
*(Беләзек белән йөзек чыгара.)*
Бүләк ит аңа әманәт беләзеген.
Ә бу йөзекне ул тапшырсын Ягкубка,

Иясе, дисен, зинданда – тоткынлыкта, –
Бер гаепсез хәсрәт кичә, дисен, синең күк,
Унсигез ел кавышу көтә нәкъ үзең күк.
Икегезгә ул бер дога өмет итә, –
Пәйгамбәр догасы максатка тиз җитә,
Инша-Алла, шуннан михнәтләр дә бетәр,
Сынауларда сынмаганны бәхет көтәр.
Шәрабче, бусы тугрылыгың өчен,

*(Сүрәләр язулы медальон бирә.)*

Күп тапкырлар сизәрсең изге сүзнең көчен.
Бу дөньясы килә-китә, вафасы юк,
Ахирәтне кайгыртканның бәһасе юк.

*Пәрдә*

**2 күренеш**

Зөләйха.

Аһ кырык биш яшемнән булдым мин карчык,
Карчык булганчы балчык булуың артык. *(Зәйтүнәгә.)*
Нигә әкиятләреңне сөйләмисең,
Ялган белән майламыйсың, көйләмисең?
Йосыф, диген, Мисырга, диң, патша булды,
Көтә Зөләйхасы белән кавышуны! *(Елый.)*

Зәйтүнә.

Йә, кырык биш яшь хатын-кызга күп түгел,
Яңадан чәчәк ата аларда күңел!

Зөләйха.

Алып кит син мине ерак сахраларга,
Мисыр салды мине газап-җәфаларга.
Каберем якын булмасын шушы Мисырга
Үләсем килми һич Йосыф Мисырында.
Китеп булсын иде кайтып туган якка.
Йосыфка мәхәббәтем чабудан тарта.
Зинданда үлмәгәнме әле – шуны бел!

Зәйтүнә.

Үлмәгән, китаплар күчерә икән гел!

Зөләйха.

Үлсә, туган якларыма китәр идем.
Зинданда да саклый бит әлеге дине,
Кайчанналәт сугар икән шушы динне!

*Тәмам юашланып калган Рәйян керә. Йосыфка төзеттергән тәхеткә менә.*

Рәйян.

Ун көн элек миңа хикмәтле төш керде,
Бөтен патшалыгым моңа хәйран инде!
Авыруыңны белеп борчымадым сине,
Бөтен җирдән юраучылар килде.
Юрый алмадылар хикмәтле төшемне.

Җитә алмас, диделәр, хикмәт гыйлеме,
Аңлатуы, диләр, моны мөмкин түгел,
Иңләп ала алмый моны безнең күңел.
Ярый, Зөләйха, борчылма, тизрәк терел.

З ә й т ү н ә .

Мәлик Рәйян, атна-ун көн элек моннан
Шәрабчене коткаргансың зинданыңнан,
Аңа да бит хикмәтле төш кергән булган,
Шәрабче төшен беркем юрый алмаган.
Шулай да берәүнең юш килгән юравы.
Нәкъ юраучы әйткәнчә коткарганнар аны.
Тагын болай диде Шәрабче хатыны:
Икмәкче дә төшен юраттырган икән,
Аның төшенә дә юрау төгәл килгән, –
Икмәкче башын җәллад балтасы өзгән.

Р ә й я н *(дулкынланып).*

Шәрабчене миңа табып китерегез!

Ш ә р а б ч е *( кызыл алтын касәләргә шәраб коя-коя керә).*

Падишаһым Рәйян, табасы юк мине,
Көн туыга яныңда – олылыйм сине!
Ходайга ялварам, намазлар укыйм,
Хак Тәгаләдән сиңа ак бәхет сорыйм!

Р ә й я н *(көлә).*

Мөселман динен тота башлагансың,
Ә бу харам эшеңне ташламагансың.

Ш ә р а б ч ы .

Хак Ходайның дине саф күңлем өчен.
*(Медальонны ача, үбә.)*
Ә бу эшем мәлик сиңа ярар өчен.

Р ә й я н .

Ярый, куй бер читкә һәм әйт миңа шуны:
Төрмәдә төшеңне сиңа кем юрады?

Ш ә р а б ч е .

Булды андый хикмәт, җиһан шаһы Рәйян
Утыра зинданыңда бер гыйбри углан.
Хикмәт гыйльмен Тәңре-Сөбхан биргән аңа,
Хикмәтле төшне бары ул юрый ала.

Р ә й я н .

Тиз алып кил ул угылны каршыма!

*Шәрабче китә. Караучы хатын-кыз Рәйянга шәраб алып килә, Рәйян шәрабне кире кага.*

Бу төшемне әгәр дөрес юрый алса,
Сере нидә икәнлеген ачып салса,
Аны мин бүгеннән үк вәзирем итәм!

З ө л ә й х а .

Ул угыл зинданга ничек керде икән?

К а р а у ч ы х а т ы н - к ы з .

Шәрабчегә әйткән: «Бу каза – Тәңремнән!»

Р ә й я н .

Тоткынлыкны күрде икән ничә еллап?

Караучы хатын-кыз.

Унбер ел утыра, ди, китап язгалап!

Зөләйха *(аягына торып баса).*

Мәлик Рәйян, әйтә алам: Йосыф кол бу! Рәйян.
Без зинданга ташлаткан Йосыф угылмы?

Зөләйха.

Әллә үз кулларың белән чыгарамсың?

Рәйян.

Ни телисең, башка чарам бармы соң?
Тукта, әйт, моннан ни зыян – чыгарсам ни?
Йосыфның безгә зыяны тиямени?
Зиндан йолкып ата арадан чүпләрне,
Патша итә Йосыф кебек зирәкләрне!

*Аяклары чылбырда булган, чәч-сакаллары биленә җиткән Йосыфны алып кереп, Рәйян каршына тезләндерәләр.*

Зөләйха.

Йосыф, зинданны ник миннән артык күрдең?

Йосыф.

Бу казаны миңа бүләк итте Тәңрем,
Шуңа синең алда юк һичбер гаебем.
Безнең барчабызны Иблис бозмак булды,
Безгә бар мәкерле гамәлләрен кылды.

Шәрабче *(Йосыфка гына).*

Атаң Якуб елый-елый дога кылган...

Йосыф.

Амин. Кабул булсын, атам, кылган догаң!

Рәйян.

Тыңла, Йосыф, җиде симез сыер күрдем,
Һәркайсының аркасына менеп йөрдем,
Берсеннән берсенә шулай күчә килдем.
Күрдем янә җиде сыер – болар арык,
Бар да хәлсез, бар да беткән арыкланып,
Ач торганнар бугай шуңа алар ябык, –
Симезләрен ашады шул җиде арык.
Тагын күрдем тулып җиткән җиде башак,
Янә корып-кибеп беткән җиде башак,
Бодайлары менеп китте күккә очып, –
Калды бары тик өч бөртек, җирдә торып.

Йосыф.

Нәкъ җиде ел буе илдә иген уңар,
Төрле нигъмәт-азык белән дөнья тулар,
Аннары җиде еллык корылык китә,
Ачлык-кытлык фетнәсе Мисырны тетә.
Шуннан соңра Тәңре кыла мәрхәмәтләр,
Исәннәргә бирә шатлык-рәхәтлекләр.
Шуңа, Рәйян, җиде ел тоташтан иген игегез,
Уңышны аз тотып, башакта саклагыз!
Шуннан соң җиде ел еллык корылык булыр,
Алдагы уңыштан орлыкка калдырып,
Җиде ел буе иркенләп тукланыгыз!

Шуннан соң килүче ел башка булачак,
Аллаһы Тәгалә мул яңгыр яудырачак!
Ачлыктан исән калучылар ныгыячак,
Җимеш хутында үсемлек мае чыгачак,
Сыер, дөя һәм сарыклар савылачак!

Р ә й я н .

Сакчы, тиз салдыр Йосыфтан зынҗырларын!
Бирегез аңа киемнең асылларын!
Тоткынлыктан азат итәм, иректә кал,
Барлык вәзирләремә дә баш булып ал!

Ш ә р а б ч е *(Йосыфка гына).*

Кабул булды менә атаң догалары!

Й о с ы ф .

Әмма көрәселәребез безнең алда әле!

Р ә й я н .

Аңламадым, Йосыф, риза буласыңмы?
Бүгеннән үк минем янда калырсыңмы?
Вәзирлекне иңнәреңә алырсыңмы?
Минем белән бергә хөкем кылырсыңмы?

Й о с ы ф .

Иляһ миңа зур мәмләкәт насыйп кылды,
Зөләйха аябыз, нәрсә әйтер икән?

З ө л ә й х а .

Мин бүген үк Мисырыңнан китәм,
Вәзирлек кыл, яшә, мин комачау итмәм.

Й о с ы ф .

Һичберәүгә ярдәмеңнән син баш тартма,
Җәберләнгәннәрне тар коеларга атма.
Салып бәла утларына, яла якма,
Мескеннәргә ихлас миһербанлык сакла.

*Рәйян белән Йосыф китә. Аларга Чәчтараш, Киендерүче ияргә. Зөләйха Зәйтүнә белән бергә чыга. Бәйрәм тантанасы яңгырый.*

*Пәрдә*

**3 күренеш**

*Кәнган. Якубның ярлы йорты. Урамнан бик моңлы авазлар килә. Бер баланың: «Абыйлар, ачтан үләм, ярдәм итегез!» дип ыңгырашуы ишетелә. Түрдә – ап-ак сакаллы, тәмам бетәшкән Якуб. Сул ягында Якубның ачлыктан хәлсезләнгән уллары ята. Ишектән Якубның тагын берничә улы абаланып диярлек керә.*

Р ә й я л у н .

Ник бер тамчы яңгыр төшсен икән күктән.

Я ш ь җ ә р .

Коеның да суы инде күптән кипкән.

Д а н .

Эссе җил бар нәрсәне көйдереп үтте.

Л ә б и .

Кырыбызда бөтен нәрсә янып бетте.

Я һ ү д.

Өметсезлек – һәр яңа көн кайгы ташый.

Ш ә м г у н.

Кеше анда берсен-берсе тотып ашый!

Д и н ә *(кереп тезләнә).*

Абыйлар, ачтан үләм, ярдәм итегез!

Ш ә м г у н.

Ничек керсәң монда, шулай чыгып кит!
Югыйсә үзеңне *(пычагын болгап)* суеп ашыйбыз бит!

Я к у б.

Улларым, уйлашыйк, болай яшәп булмый,
Мисыр якларына сәфәр чыгу кирәк.
Бар нәрсәне сатып, икмәк табу кирәк.

Я һ ү д.

Атабыз, анда да хөкем сөрә шул ук ачлык!

Р а у и л.

Бездән инде анда күпләр китте качып,
Күпләр хәтта барып та җитә алмаган.

Ш ә м г у н.

Атам кушса, мин хәзер үк юлга чыгам.

Л ә б и.

Атам кушса, мин дә Шәмгунга кушылам

Я к у б.

Мисырдагы хәбәрләрдән мин хәбәрдар,
Тугыз ел элек вәзире алышынган,
Игенчелекне дә үз өстенә алган,
Ашлык-игеннәрне бик күпләп иктерткән,
Сuктырмый гына кибәннәргә өйдерткән,
Суккан бөртекне амбарларга бикләткән!
Мисырда җиде ел буе иген уңган,
Вәзир ярдәмендә Мисыр бик баеган!
Башлангач соңра бездәгедәй корылык,
Тирә-як илдә халык баргач кырылып,
Барысы да игенгә дип Мисырга агыла,
Игенне башта алтынга сатып ала.
Икенче ел бирәләр ат-качырларын,
Өченче ел – ефәкләрен-комачларын,
Дүртенче ел – терлекләрен, йорт-җирләрен,
Бишенче ел бирәләр угыл, кызларын,
Үзләре дә кол булганнар алтынчы елын.
Йә, угланнар, инде юлга җыенгыз,
Уныгыз бер йодрык булып тупланыгыз!
Икмәкле Мисыр ягына кузгалыгыз,
Бар булган йонгыбызны алып барыгыз,
Хөкемдарына бик иплән ялыныгыз,
Хак Тәңрегә чын күңелдән табыныгыз!
Михнәтләрдән коткаручы бер Ул гына.

Т у г а н н а р.

Хак Тәңрегә чын күңелдән табынабыз,
Михнәтләрдән коткаручы, син Раббыбыз!

*Пәрдә*

**4 күренеш**

*Зөләйха алачыгы. Ул урында ята.*

З ә й т ү н ә .

Йосыф тагын йөртә гаскәрен яланда,
Бу юлы чыкмаска булдыңмыни анда?
Йосыф килгән саен шунда барыр идең,
Йосыф йөргән юлга чыгып басар идең,
Читтән генә аны тыңлап торыр идең.

З ө л ә й х а .

Сукырайдым мин, колагым да ишетми,
Йосыф йөзе һаман күз алдымнан китми.
Газиз идем – тол, гарип гаҗиз калдым,
Йосыф гыйшкы белән янып, ким-хур булдым.
Ә ул һаман күз алдымда көлеп тора,
Зифа буй-сыннары белән йөреп тора.
Мисырда мин олуг хатын булган чакта,
Кешеләргә җитәкчелек кылган чакта,
Газиз Йосыф минем колым гына иде,
Илаһына гыйбадәтләр кыла иде,
Гел шул Илаһ әмренә буйсына иде,
Илаһ аңа, әнә, олуг дәүләт бирде!

*Көч-хәл белән күтәрелә, капшанып кына Таш Потны эзли.*

Кайда соң син, каһәр суккан, Таш Пот Ходам?
Таба алсам, сине хәзер җиргә орам!
Бу көнгәчә сиңа хәлләремне сөйләдем,
Синнән ярдәм юклыгын һич белмәдем.

*Таш Потны җиргә этеп төшерә. Таш Пот ватыла.*

З ә й т ү н ә .

Аһ, Зөләйха, нишләдең, зур гөнаһ бит бу!

З ө л ә й х а .

Гөнаһ икән, читтә торсын, син аны ку!
Чукып алып, асыл ташларын сатып кайт,
Ташларны ашап булмый, ипи алып кайт!

*Зәйтүнә Таш Пот башын алып чыга, Зөләйха, капшанып кына, калган кисәкләрне дә табып, алачыгыннан тышка ташлый.*

Хак Тәгалә, кылган гөнаһларым кичер,
Зөләйханы Йосыфның диненә күчер,
Догаларымны мин сиңа багышладым,
Ләә илаһа Иллалаһ Мөхәммәде Рәсуллуллаһ!

З ә й т ү н ә *(ашыгып керә).*

З ө л ә й х а .

Таш Пот башын миннән алдылар!
Кемнәр алды, каян килде ул явызлар?

З ә й т ү н ә .

Йосыф һәм Рәйян мине танымадылар,
Таш Сын башын күреп бик усалландылар,

Зөләйхадан урлаган, дип бәйләнделәр,
Минем артымнан озак куа килделәр.
Тукта, алар инде ишек артында йөриләр!

*Зәйтүнә кача. Таш Сын башын тоткан Йосыф белән Рәйян керә.*

Йосыф.
Әссәламегаләйкем, хуҗа өйдәме?
Рәйян.
Өйдә юк, ахрысы, җавап бирмәде.
Зөләйха.
Ни йомыш белән йөргәнегезне белик?
Рәйян.
Хөкемнән качкан карак хатынны күрик!
Зөләйха.
Хөкемгә тартырлык нинди эш эшләгән?
Рәйян *(Сын ватыкларын күрсәтә).*
Таш Сынны ватып сатарга теләгән!
Зөләйха.
Ул гаепле түгел, Сынны үзем ваттым.
Йосыф.
Кеше Сынын ватарга бар идеме хакың?
Зөләйха мөлкәте иде бу, әйт, кем син?
Зөләйха.
Һични күрми торган сукыр бер карчык мин.

*Таш Сын башын капшый, аннары акрын гына Йосыфның йөзенә кагыла, кычкырып.*

Йосыф бит син?! Сукырайсам да таныдым,
Ә син мине күзле килеш тә танымадың!
Зәйтүнә *(керә).*
Бәшир вәзир эзли сине, мәлик Рәйян,
Бик ерак җирләрдән кәнганлеләр килгән,
Сәлам китергәннәр Якуб пәйгамбәрдән.
Рәйян.
Якуб пәйгамбәр, диләрме, мин бит белмим.
Йосыф.
Бар, чакыр Бәшир вәзирне, монда керсен!

*Караучы хатын-кыз чыга. Бәшир белән әйләнеп керә.*

Йосыф.
Йә Бәшир, әйт, нәрсә сорый кәнганлеләр?
Бәшир.
Икмәккә дип алмашка йон китергәннәр.
Йоннары күп түгел, икмәк бик аз тияр.
Йосыф.
Күбәүме үзләре?
Бәшир.
Унау. Ай-йай кыю Шәмгун дигәннәре.

Й о с ы ф .

Мәлик Рәйян, болар минем абыйларым,
Җылы кабул итеп, азрак икмәк биреп,
Озатырга иде, кабат килегез, дип, –
Килгәч, икмәкне бушка алырсыз, диеп.
Әмма шарты да барлыгын алар белсен!
Шарты: Якуб нәби дә алар белән килсен,
Килсен янә хатыннары, балалары,
Нәкъ җитмеш өч кеше булыр алар бары!

Р ә й я н .

Йа Йосыф, борчылма, уңай хәл итәрбез.

Б ә ш и р .

Кирәк икән, Мисырга ук күчерербез!

*Бәшир Рәйян артыннан чыга.*

Й о с ы ф .

И Зөләйха, кайда синең дан һәм малың,
Зифа буең, озын чәчең, хуп җәмалың,
Кайда тулган айдай балкып торган йөзең,
Ничекләр итеп син бу хәлләргә төштең?

З ө л ә й х а *(җырлый).*

Тышкы матурлык чүп, дидең, хәтерлимсең,
Инде хәзер миннән шуны син телимсең?
«Тышкы матурлыклар, дидең, алдау гына,
Кеше гүзәллеге җаны аша туа,
Җан исә буйсына Хак Аллага гына!»
Менә мин дә буйсындым синең Ходаңа.
Әйе, кулдан китте тәмам бөтен нигъмәт,
Бере калмый юкка чыкты мал вә мөлкәт,
Вәләкин һич кимемәде гыйшык-хәсрәт,
Бертуктаусыз гыйшык утым яна көйрәп.

Й о с ы ф .

Гыйшык уты яна икән – аны күрү кирәк,
Әмма эчкә яшерелгән шул ул йөрәк.
Зөләйха икәнеңне дә раслау кирәк,
Син әлегә чит бер карчык кебегрәк.
Гыйшыклыкта тугры булып кала алган,
Гыйшык зарын аңлауга дәгъва кылган
Зөләйханы хатынлыкка сүзсез алам, –
Әгәр шушыларны ул дәлилли алса!

З ө л ә й х а *(капшанып кына Йосыфка бара, кулы камчыга орына).*

Рәхим итеп, бу камчыңны бир кулыма,
Кирәк булган дәлилне ул сөйләр сиңа, –
Сөйләмәсә дәгъвам ялган гына була.

*Зөләйха камчы белән сөйләшкәндәй камчыга йөзе белән орына да аңа сулышын өрә һәм камчыны кире Йосыфка суза, ут камап алган камчы Йосыфның кулын пешергәч, ул аны атып бәрә.*

Күрдеңме, Йосыфым, инде аңладыңмы,
Камчыга ут кабуга син таң калдыңмы?

Кулыңны пешергәнгә дә түзмәдеңме?
Шушы ут кырык ел көйдерә бәгъремне!

Й о с ы ф.

Бу гыйбрәтле хәл, монда михнәтле хикмәт.
Бетеп михнәтләр, килергә тиеш рәхәт.
Хак Ходамнан рөхсәт сорап карыйм инде... *(Теләк тели.)*
Вәгъдә көнен Өмет өзми көткәннәрдән,
Хак кушканча сабыр итә белгәннәрдән
Бу Зөләйхаң рәхәтлеккә лаек инде,
Ходавәндә, ходавәндә, ризалык бир,
Зөләйханы никах кылып алыйм инде!

З ө л ә й х а.

Сүзләреңнән, Йосыф, миңа хәсрәт килде,
Ни әйтсәң дә, мин хатын-кыз бит инде.
Җамалымның күрке китте, малым да юк,
Күзем сукыр, үзем ямьсез котсыз карчык.
Өметсез бер шайтан гына дигән сүз бар,
Хак Тәгалә, күзләремнең нурын кайтар.
Йосыф йөзләренә тиң ит йөзләремне,
Йа Ходаем, булсам иде Йосыфка тиң пар...

*Караңгылык иңә, яшен яшьнәп, күк күкри, җил исә, урамнан куркынган*
*З ә й т ү н ә атылып керә.*

З ә й т ү н ә.

Зөләйха, берни күрмим, шундый караңгы!
Күк күкри, яшен яшьни, дөнья буталды,
Аһ, яндыра, бөтен җанымны ут алды!

*Кабат балкыган яктылык бер-беренә таң калып карап торган Зөләйха белән Зәйтүнәне яктырта. Алар элеккечә яшьләр һәм матурлар.*

З ә й т ү н ә.

Чү, Зөләйха, тик тор, зинһар, дим, селкенмә, –
Көзге табып күрсәтәм моны үзеңә! *(Йөгереп чыга.)*

Й о с ы ф.

Сөбхан Алла, ходавәндә бу кем кызы, –
Кайдан килгән монда якты күк йолдызы!
Тулган айга охшап тора синең йөзең,
Матурлыгың – бүләге ул Тәңребезнең!

*Көйләп дәвам итә.*

Йә Зөләйха, хәтерлимсең теге көнне,
Бозык эшкә өндәдең син анда мине,
Андый эшне ул чак әгәр кылган булсак,
Килмәс иде безгә бу бәхетле морад.

З ө л ә й х а *(көйләп җавап бирә).*

Йосыфым син минем, сөеклем син минем,
Йөзләремә бәрмә инде ул гаебем.
Саклап калды кодрәт белән Тәңре үзе,
Ул фетнәдән сине, мине – икебезне.

## ТАТАР ТЕЛЕ

*Вы, прадеды наши, в недоле*
*мукою запудривши лик,*
*на мельнице русской смолили*
*заезжий татарский язык.*
Я.Смеляков

Туган җирең – Идел буе,
Һәр телнең бар Туган иле.
Туган җирең кебек назлы,
Җырдай моңлы татар теле.

Ак алъяпкыч бәйләсәләр,
Өзелеп тора кызлар биле.
Кызлар кебек шат чырайлы,
Ачык йөзле татар теле.

Халкың кебек уңган да син,
Хезмәттә син көне-төне.
Ир-егетләреңдәй дәртле,
Гайрәтле син, татар теле.

Фәннән сине аерса да
Гасырларның афәт җиле,
Аксакалларыңдай олпат,
Акыллы син, татар теле.

Ассалар да, киссәләр дә,
Үлмәдең син, калдың тере.
Чукындырган чагында да
Чукынмадың, татар теле.

Яндың да син, туңдың да син,
Нишләтмәде язмыш сине?!
Дөньяда күп нәрсә күрдең,
Әй мөкатдәс Тукай теле.

Төрмәләргә дә яптылар
Җәлил белән бергә сине.
Төрмәләрдә дә килмешәк
Булмадың син, татар теле.

Зинданнарны ярып чыктың,
Ялкынланып чыктың кире.
Хәтта фашист тегермәне
Тарта алмады анда сине,
Әй син батыр татар теле!

Кабатланмас үткәннәрең –
Гасырларның яман чире.
Кабатлар сине гасырлар,
Татар теле – дуслык теле.

**Нажар НӘҖМИ**

Й о с ы ф .

Саклап калды, әйе, безне Тәңре үзе,
Йосыф белән Зөләйханы – икебезне.

З ө л ә й х а *(гади сөйләм).*

Рәхмәт яусын аңа – миңа сине бирде,
Теләк-максатларым бүген кабул булды,
Йөзем күрке һәм дәүләтем кайтты кире,
Рәхмәт-шөкер кылам аңа көне-төне.

Й о с ы ф .

Рәхмәт-шөкер кылыйк аңа көне-төне!

*Пәрдә*

**5 күренеш**

*Мисыр. Йосыф Кәнгандагы атасы өенә охшатып салдырткан йорт. Буяучылар диварларга соңгы нәкышләрне төшерә. Бәшир вәзир аларны күзәтә, өйрәтә. Алыплар өстәлләр, көрсиләр күтәреп керә.*

Б ә ш и р .

Өстәлләр, көрсиләр кирәкми, алыгыз,
Идәнгә йон паласлар җәеп салыгыз,
Киез паласларга җәймәләр җәегез,
Шунда мул итеп табын хәзерләгез.

З ә й т ү н ә .

Үзем җәям идәнгә йон паласларны! *(Булышып йөри.)*

*Й о с ы ф белән З ө л ә й х а керә. Уенчы уен коралында Кәнган көен уйный. М а л и к Д ә г ы й р у л ы кереп баш ора.*

М а л и к *(бик шат).*

Мәлик Йосыф, догаларың кабул булды,
Инде малайларның алтынчысы туды!

Й о с ы ф .

Әлһәмделилләһи, шөкер Раббыбызга!
Бәхет бүләк итсен Ходай барчабызга!

*Б ә ш и р белән М а л и к рәссамчы янына баралар. Р ә й я н керә.*

Р ә й я н .

Йосыф, кылганнарың тәмам таң калырлык,
Килгән иде Мисырга шундый корылык,
Бөтен илләр ятканда ачтан кырылып,
Синең аркаңда Мисыр яши сау булып.
Ходай биргән нурлы йөзләреңне күрәм,
Сыйфатларың күреп көн дә гаҗәпләнәм,
Эшләреңә синең тәмам хәйран калам,
Һәрчак гадел хөкем кыласың син, углан.
Әйтче, кайдан килде син Йосыфка болар?

Й о с ы ф .

Бирде Тәңрем-Сөбхан!

Р ә й я н .

Пәйгамбәр дип таныйм сине, мөэмин булам,
Ислам динен лаек күреп кабул кылам, –

Сиңа кулым биреп, булам чын мөселман.
Миннән бигрәк шаһлык сиңа лаек углан.
Абый сине патша итәм, дип ант эчте,
Вәгъдә үтәлмәде – бакыйлыкка күчте,
Ходай каршындагы бурычымны үтим,
Үз кулларым белән сине патша итим –
Мисырда йөрсен изге Йосыф әмере.
Бөтен халыкка таратыйм бу хәбәрне! *(Чыгып китә.)*

*Алыплар тәлинкәләр чөеп керәләр. Югарыдан бик зур поднос кебек нәрсә төшә. Анда төрле тәгамнәр.*

Йосыф.

Зөләйха, мин башка киемнәрне киим,
Мәҗлестәгеләрдән танымасын һичкем.

Зөләйха.

Абыйларың, туганнарың?..

Йосыф.

... хәтта әтием!

Зөләйха.

Йосыфым, нинди кием табып китерим?

Йосыф.

Зөләйхам, каршыла бары кунакларны!
Бәшир вәзирем, сиңа сүзем калган икән.
Мин хәзер дәрвиш суфый булып киенәм,
Кул изәүгә: «Суфый, кер, – дип! – чакырырсың, –
Бәетче суфый бу», – дип таныштырырсың!
Атам белән дә шуны ук кабатларсың,
Минем ишарә белән барып алырсың.

*Йосыф китә. Бәшир белән Зөләйха туганнарны алып керә. Туганнар гаҗәпсенеп өй эчен күзәтәләр.*

Яһүд.

Кеше ышанмас моңа бу үз өебез!

Рауил.

Әллә инде сихерләндекме үзебез!

Рәйялун.

Насыйп итте Хода могҗиза күрергә!

Ләби.

Тыңлагыз, уйнап тора Кәнган көйләре!

Дан.

Һушымны алды татлы ризык исләре.

Ләби.

Табынга утырырга да вакыттыр инде!

Бәшир.

Тагын берникадәр түзегез инде!

Зөләйха.

Кунакларым, чакырам Якуб нәбине!

*Зөләйха белән Бәшир дә чыга.*

Яһүд.

Хатун үзе безгә хезмәт кылып йөри.

Р а у и л .

Бу вәзир бездән бик күп алтын көтә бугай.

Ш ә м г у н .

Шуның өчен хатун кунак итә болай.

Р ә й я л у н .

Безне эти аркасында хөрмәт итә Ходай.

*Зөләйха Бәшир белән керә.*

З ө л ә й х а .

Кадерле кунаклар, Якуб нәби арган...

Б ә ш и р .

Мәҗлес башлансын, ди, кушыла бераздан!

Ш ә м г у н .

Нигә болай зурдан кубып сыйлыйсыз сез?

Б ә ш и р .

Мисыр патшасы кушканны үтибез без!

*(Уенчыга уйнарга ишарә ясый.)*

Каршы алыгыз, Кәнганле кунакларым,
Суфый бәетче керә, ямьләнер табын!

*Дәрвиш суфый кыяфәтенә кергән, ап-ак сакаллы Йосыф күренә.*

Й о с ы ф .

Мактау шөкер һәм дан булсын бер Аллага,
Мөлке даим, үзе мәңге ул мәүляга,
Моннан соңра хикмәт таба күчәчәкмен,
Бер угылның әхвальләрен ачачакмын, –
Барыбызга бу кирәкле, гыйбрәт имди!

*(Бәет сөйләгәндәй көйләп сөйли башлый.)*

Унике бертуган иде алар элек,
Үсте алар уйнап-көлеп һәм сөенеп,
Әмма атага никтер якынайды төпчек,
Шуннан соң башланды арада көнчелек.
Җитмәсә төпчекләре бер төш күрде,
Атасы әлеге төшне юрап бирде,
Син Мисырның патшасы буласың, диде.
Туганнары бу юрауга хәйран калды,
Алдап төпчекне сәхрага алып барды,
Шунда алар аны коега салды.

Ш ә м г у н .

Белми сөйли – аны кырда бүре ашый!

Й о с ы ф .

Белеп сөйлим: алдап Якубтан алалар,
Чишендереп, Гад коесына салалар,
Котылырга аңардан ният кылалар!

*(Кыйссаны көйләп дәвам итә.)*

Соңра кайтып атага ялган сөйлиләр,
«Төпчегеңне бүре ашап китте», – диләр.
Аталары елап канлы яшьләр түгә,
Абыйлары эш үткәч кенә үкенә.

Я һ ү д .

Коедан чыгарылгач, ул кая киткән?

Йосыф.

Коедан котылгач, абыйлары килгән,
Колыбыз, дип аны ялган сату кылган,
Сәүдәгәрдән алар сукыр тиен алган,
Өч гаебен санаган, таныклык язган!

Шәмгун.

Бу суфый юри кергән, ара бутый ул!

*Сикереп тора башлаган Шәмгунне сакчы алыплар кире утырта!*

Йосыф.

Алайса туганнарыңа сорау бирик,
Алар ничек уйлый икән, шуны белик,
Ялган сөйләдеме икән әлеге төпчек, –
Буталганмы патша? Буталмаса ничек?

Шәмгун.

Ничекләр генә белмәк мөмкин соң аны?
Ашаган бит явыз бүре ул угланны!

Яһүд.

Инде оҗмах түрендәдер аның җаны!

Йосыф.

Ата юравы ялган булып каламы?
Төпчеге Мисыр патшасы булмаганмы?
Инде ярый, монда бер таныклама бар,
Аны сезнең Кәнган телендә язганнар.

*(Туганнарына бөти бирә.)*

Моны Мисырда беркем укый алмады,
Чөнки гыйбричә язылган бу язулар.

*Танытма туганнар кулында йөри.*

Рауил.

Суфый, без дә бит бу язуны аңламадык.

Шәмгун.

Мәгънәсенә төшенеп җитә алмадык.

Ләби.

Укып, без дә сезгә аңлата алмабыз.

Рәйялун.

Аңламаслык язылган бу язмагыз.

Йосыф.

Бәлкем, укып бирер аны Якуб нәби...

*(Бәширгә ишарә ясый.)*

Яһүд.

Ул бит сукыр, ничек укый алсын?!.

*Сукыр Якубны җитәкләп Малик Дәгыйр улы керә. Туганнар каушый.*

Малик.

Зөләйха, рәхмәт яусын Якуб нәбигә,
Йосыф дип исем кушты ул төпчегемә!
Минем Йосыфның да йөзе нурлы булыр,
Кешеләргә ул күп-күп игелек кылыр.

Й о с ы ф .

Якуб нәби, монда бер таныклама бар,
Улларың да аны укый алмадылар,
Гыйбричә язылса да танымадылар!
Укып бирсәң икән шул бөтине безгә.

Я к у б .

Укып бирер идем, әгәр күрер булсам.

Й о с ы ф .

Аксак бик күп йөри, сукыр күпне күрә.
Укы!

Я к у б .

Укый алмыйм!

Ш ә м г у н .

Җитте, суфый! Сукыр ничек укый алсын?

*Р ә й я н керә, сак һәм акрын үтеп, Йосыф белән Зөләйха янәшәсенә баса.*

Й о с ы ф .

Якуб нәби, укы! *(Әтисенең күзен үбеп сыпыра.)*
Гаделлек өстен чыксын җир йөзендә!

Я к у б .

Бу ни?! Күрәм бит мин, рәхмәт сиңа, Ходай!
*(Тanытманы укый.)*
«Йосыф атлы бу колыбызны сатабыз,
Ризалык бирде моңа безнең атабыз,
Йосыф колның нәкъ өч төрле гаебе бардыр:
Качучыдыр, урлаучыдыр, ялганчыдыр!»

З ө л ә й х а *(каушап сикереп тора).*

Йосыф – кол, дидегезме? Ул нинди Йосыф?

*Зөләйха Йосыфка омтыла, әмма Бәшир аны тынычландыра.*

Р а у и л .

Әти, башка укыма! Ялган таныклама!

Якуб.

«Унсигез йармакъны кулыбызга алдык,
Синең белән бу сәүдәне тәмам кылдык,
Һәммәбез дә бу бәһагә риза булдык,
Шуны раслап имзаларны куйдык».

Ш ә м г у н .

Атабыз, зинһар, ышанма, болар ялган!

Я к у б *(елый).*

Таныкламада менә сезнең кулларыгыз!
Сез Йосыфны ул вакытта алдадыгыз,
Бергә сәйранга чыгарга чакырдыгыз,
Сөйгән угылымны миннән аердыгыз,
Аерылу утында бәгърем яндырдыгыз!
Кайда минем Йосыф, кайда туганыгыз?!

М а л и к *(Якуб каршына елап тезләнә).*

Йосыфны абыйларыннан мин сатып алдым,
Йосыфны Кыйтфирга бүләк итеп бирдем.
Аерылганда Йосыфка мин антлар иттем:

«Сине белгәнемне беркем белмәс», – дидем.
Вәгъдә – иман, серне синнән дә сакладым,
Йосыфыңа биргән вәгъдәне сатмадым.

Р ә й я н .

Йосыфны бәлаләргә салганыгыз өчен,
Җинаятьчеләргә хөкем каты булыр!

*Алыпларга ишарә ясый. Алар, дүрт озын сөңге белән алдан һәм арттан килеп, каушап калган туганнарны тезләндерәләр һәм сөңгеләрне бугаз турыларында бәйләп куялар.*

Сезнең сыңар кулыгызны кистерермен,
Һәммәгезне муйныгыздан астырырмын,
Барчагызны мин җәзалап үтертермен,
Бер гөнаһсызны җәберләгән өчен!

Д и н ә .

Абыйларыма, зинһар өчен, тимәгез,
Иң зур гаепле кеше монда Динәгез!
Әләкләдем мин барып абыйларыма,
Минем әләк тора бу фетнә башында.

Р ә й я н .

Читкә кит, синең белән сүз соңрак булыр!

Й о с ы ф .

Рәхмәт, малик Рәйян, әйткән сүзеңә,
Тик хөкем итүне калдыр үземә!
*(Өстеннән дәрвиш җиләнен сала.)*

З ө л ә й х а .

Аһ, Йосыфым, нинди казалар күргәнсең?!
Мин сабырсыз булгач, зинданга кергәнсең,
Гафу сорап ялварам, хәләл җефетем!
Иманымны югалтмау минем өметем!

Р ә й я н .

Абый сине патша итәм, дип ант итте,
Вәгъдә үтәлмәде – бакыйлыкка күчте,
Ходай каршындагы бурычымны үтим,
Үз кулларым белән сине патша итим.
Мисырда йөрсен изге Йосыф әмере.
Бөтен галәмгә таратыйк бу хәбәрне!

*Рәйян Йосыфка, таҗ кебек баш киемен кидереп, кулына патшалык билгеләрен бирә дә чыгып китә. Сарайдагылар «Йосыф малик!» дип сәҗдәгә егылалар.*

Р а у и л .

Бозык эшләребез өчен үкенәбез,
Андый юлга без моннан соң һич кермәбез,
Оныкларыбызга да гыйбрәт итәрбез,
Ялынабыз, инде безне кылчы азат,
Ходайдан алдык болай да бик күп газап!

*Йосыф атасы каршына бара, тезләнеп башын ия. Күтәрелә. Атасы аны: «Йосыфым – исән!» – дип елап кочагына ала.*

Йосыф.

Йа абыйларым, күтәрегез башыгызны,
Багышладым бөтен бозык эшегезне,
Гафу итәргә мин бүген риза сезне,
Кичерсә әгәр атабыз гаебегезне!

Якуб.

Иманлы Йосыфның хәлләре хикмәтле,
Ходай биргән язмышы бик тә гыйбрәтле,
Нинди генә авыр сынаулар үтмәде,
Иманына һич тә хыянәт итмәде.
Иблис ләгыйньгә ул сөенеч бирмәде,
Явызлыклар каршында һич тезләнмәде,
Сабырлыгы белән барсын җиңә белде,
Шуңа Ходай аңа өстенлекләр бирде,
Кояш һәм ай яктысы төшкән бөтен җирдә,
Иманлы дип танылуга ирештерде!

Яһүд белән Шәмгун икесе бергә.

Кичерә күр без аңгыраларны, атабыз,
Хәтта кичермәслек булса да хатабыз,
Ходайдан бик куркып, синә җан атабыз!
Моннан ары иблисне шатландырмабыз!

Якуб.

Гафу итүне һәм гафу ителүне
Хак Тәңребез иң зур бәхет итеп биргән...
Нишлим инде, хатагызны ярлыкадым,
Бөтен гөнаһ эшегезне гафу кылдым,
Бүген Ходай Тәгаләдән рәхәт алдым, –
Ходаем сезгә дә рәхәтлекләр кылсын!

*Сакчы алыплар, Бәшир ишарәсе белән, туганнарны сөңгеләрдән азат итәләр.*

Туганнар *(көйләп әйтә).*

Күп сынаулар куя фани дөньялары,
Җиңел түгел иман нурын саклаулары,
Җиңел түгел икән үзең булып калу,
Һичбервакыт алданмаслык уяу тору,
Намусыбызга кер кунмаслык оя кору!
Ата-анабыздан фатиха алулар,
Ахирәтне чын күңелдән кайгыртулар.


*Караңгылык булып ала. Бөтен нәрсә бутала. Мисыр хатыннары туганнар белән әвәрә килергә тотына... Котырткыч музыка башлана.*

Йосыф *(өзгәләнеп).*

Наданнарга гына берни бирми кыйссалар,
Зиһенлеләр акылын алар баеталар!
Иманга килүчеләргә гыйбрәт алар –
Мәрхәмәтле юллардан алып баралар!

*Музыка тына. Бозыклык булып төшкән караңгылык күренешеннән сәхнә арына. Аталары Якуб һәм дә мөселманча киенгән Йосыф белән Зөләйха аяк астына туганнар елый-елый ташлана. Шатлык көйләре яңгырый.*

*Пәрдә*



Җәүдәт
Дәрзаман

# ТӨШЛӘРЕМӘ КЕРЕП САГЫНДЫРА

## Йөрәкләр сулык-сулык...

«Ирек» дигән изге сүзне
Дисбе сыман тезде еллар.
Еллар тезгән дисбеләрне
Сытты сукмак, изде юллар.

Ирек булып килгән язлар
Яфрак койды, көзләр булып.
Матди көрлек, рухи хөрлек
Калды бары сүзләр булып.

Юллар изге булмыйдыр шул,
Сәдакалар биреп кенә:
Ул юллардан бар да йөрде,
Тик йөрмәде... ирек кенә.

Аны еллар тагын тезде
Халык күңеле дисбесенә,
Акылларның аңлысына,
Йөрәкләрнең хислесенә.

Сүз ирегә булып килә,
Тагын килә якты язлар –
Бар тавышка чыңламакчы
Сыкрап кына сызган сазлар.

Чыңласыннар!
Тыңласыннар
Аны изге юлдагылар:
Чыксын күңел зинданыннан
Хак сүзләре кулдагылар.

---

Җәүдәт ДӘРЗАМАН (1945) – *шагыйрь, прозаик, публицист; «Күзле кычыткан», «Чорлар кайтавазы», «Җир авазы» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. А.Алиш һәм С.Сөләйманова исемендәге әдәби премияләр лауреаты. Казанда яши.*

«Сүз иреге» дигән сүзләр
Кайта кабат,
Набат булып.
Хокук кайта!
Тик йөрәкләр
Никтер һаман сулык-сулык...
Сулык-сулык...

## Ул – ышаныч

Бу тормышта сине ни яшәтә?
Ни көч бирә, дисең, замандаш?
Ник сорыйсың? Минем җавабым да
Синең соравыңа аваздаш.
Ул – ышаныч.

Шул ышаныч канат кагындыра,
Күккә чөя, җирдә кабындыра.
Ерак араларны якынайта,
Янып сөйгән ярны сагындыра.

Шул ышаныч, авырлыклар килсә,
Якын дуслар, диеп, җан ата.
Төннәрендә йолдыз саната да
Таңда кайчак борын каната.

Бу тормышта сине ни яшәтә?
Ни көч бирә, дисең, замандаш?
Тойгансыңдыр.
Минем җавабым да
Синең соравыңа аваздаш.
Ул – ышаныч.

## Авыл

Авыл, авыл!
Безнең тамыр синдә,
Ябалдашлар монда булса да.
Сулыгып-сулыгып күңел сине сагына,
Шатлык белән тулы булса да.

Авыл, авыл...
Өсләреңдә давыл –
Яңа тормыш сине туздыра.
Безнең тарих, ахры, узганнарда
Кылынганны күпкә уздыра.

Уздырса да давыл, туздырса да,
Синең  тамыр – безнең тамыр ул.
Сөт калыр, Ватан китәр –
Татар авылы, барыбер, калыр ул!

## И балачак!

И балачак! Синдә калган инде
Чебиләгән ялан тәпиләр.
Синдә калган яшел болыннарда
Печән чапкан ябь-яшь әтиләр.

Синдә калган, балакларны төйнәп,
Балык сөзеп йөргән инешләр.
Төшләремә кереп сагындыра
Әрәмәндә җыйган җимешләр.

И балачак! Синдә калган инде
Яшерен яну, яшерен көюләр.
Күңелең төшкән зәңгәр күзле кызның
Тик шәүләсен күреп сөюләр.

Калган, калган, барысы да калган,
Уелып калган синдә, балачак.
Синдә калган барлык хис-тойгылар
Йөрәгемдә мәңге калачак!

## Мин яшим синең өчен

Кемнәр ни өчен яшидер –
Мин яшим синең өчен.
Гомер буе дәртләндергән
Бер назлы көең өчен.

Кемнәр ни өчен яшидер –
Мин яшим синең өчен.
Балаларга җиткерә алган
Туган тел, җырың өчен!

Кемнәр ни өчен яшидер –
Мин яшим синең өчен.
Сине-мине үксетмәгән
Иделем, илем өчен!

## Кыз бала

Бер ал чәчәк үсеп чыккан
Олы юл читләрендә.
Кояш нуры балкып тора
Ягымлы битләрендә.

Әй сөенә бәхетенә,
Дөньяга туганына!
Шаян җилнең күк буйлатып
Болытлар куганына.

Аның дөньяда барлыгын
Күреп алган кай ара.
Таҗларына куна-куна,
Күбәләкләр шаяра.

Безли-безли бал кортлары
Кытыклый керфекләрен.
Тарый-тарый, саный-саный
Шул керфек бөртекләрен.

Таҗлар җилпеп очар әле
Офыклар аръягына.
Узмасын тик өсләреннән
Дегетле арба гына...



Ралия
Кәримова

# МАЙРА

ФАНТАСТИК ХИКӘЯ

Җәйнең иң кызу көннәре иде. Чамасыз кыздырган кояштан һич качып котылыр әмәл юк. Майра ишегалдына чыкты да хәлсезләнеп йомшак утыргычына таба юнәлде. Кәнәфи култыксасындагы кызыл лампа янып торган ноктага баш бармагын тидерде. Шунда ук табло яктырды, саннар биешеп, аның кан анализын, химик составын күрсәтте. Бераз тайпылыш бар икән шул! Чыкканда бәдрәф аша үткән иде, бәвел анализы яхшы булгач, кырыендагы таблода яшел ут янып, күңелле музыка уйнап калды. Йөз кырык сигез яшьлек Майра, бераз тынычланып, оныгының улын – Трейлны көтә башлады. Ишегалдында акрын гына татарча моңлы җыр ишетелә, җиләс һава агымы тарала. Ишегалдын каплап алган зәңгәрсу гөмбәз аша кояш нурлары үтеп, эссегә чыдам ясалма үсемлекләрне төрле төсләргә буйый кебек. Ханым, кәнәфиендәге элемтә төймәсенә басып, торыны Трейлның хәзерге минутта кайда булуын тикшерде, кайтып килү траекториясенә күз салды. Акыл көче белән тиз генә аралашу мөмкинлеге булса да, Трейлны эшеннән аерып борчымады. Ул Җир шарының төрле катаклизмнар ноктасына – тетрәүләргә, цунамиларга очкычыннан махсус импульслар җибәреп, аларны бастыра, тынычландыра. Икенче төймәгә басуга, Майра каршысында кечкенә өстәл җәелде дә, салкын сулы озынча стакан пәйда булды. Бу су – энергетик сыекча, хәл керткеч эчемлек иде. Ул суын эчеп тә өлгермәде, таныш гүелдәү тавышын ишетеп, күккә карады. Ишегалды каплавычының түгәрәк ишеге кырыйга шуып ачылуга, өстә көмешсыман скафандр кигән торыны – Трейл күренде. Ул Майраның каршысына ук килеп төште.

– Gut morgan, Maira! – диде егет, елмаеп.

– Нишләп әле миңа немесчә эндәшәсең? Үзебезчә әйт! Бөтен телләрдә дә сөйләшә алганыңны беләм лә инде.

– Әй, дуслар белән аралашкан идем, – диде ул, тиз генә сөйләм ешлыгында үзебезнең телгә – татарчага күчеп. – Хәлең ничек?

– Трейл, син миңа исемем белән түгел, «әбекәй» дип эндәш, улым! Нишләптер хәлем бетеп тора әле.

Трейл җиләс һава режимын көйләде, әбисенә карап алды да лабораториянең элемтә төймәсенә үрелде. Шунда ук ниндидер могҗизалы көч Майраны лаборатория эченә күчерде. Кечкенә генә роботлар аның эчке органнарын тикшерә башлаганда, ул йокыга талган иде инде.

Икенче көнне Майра яхшы кәеф белән уянды. Тәнендә җиңеллек, гәүдәсендә көч булуын тойды. Доктор-роботлар аның кан тамырларын чистартканнар, йөрәгенең каплавычын – клапанын алыштырганнар икән! Җирдә яшәүче аз санлы барлык кешеләр дә ярымроботлар булып беткән иде инде, шуңа да Майра төрле могҗизаларга ияләште, гаҗәпләнмәскә өйрәнде. Тормышта гаҗәеп үзгәрешләр булса да, анда тереклек юкка чыга, гадәти тормыш сүнеп бара, шунысы иң зур фаҗига! Шулай да торыны белән аралашырга

---

Ралия КӘРИМОВА – *шагыйрә, прозаик; «Мин – табигать баласы», «Бәхет бүләк итеп», «Яшәү яме», «Ташлы туфрак» исемле китаплар авторы. Түбән Камада яши.*

ярата Майра, бик күп нәрсәләрне аңардан өйрәнде. Әле дә Трейл белән икәүләп кечкенә капларга салынган төрле составтагы пасталарны авыз иттеләр, төшке аш шул иде.

– Оныгымны сагынып беттем, ул кайчан кайтыр икән инде? – Майра җавап көтеп Трейлга карады.

Егет «сагынып беттем» дигән сүзләрнең мәгънәсенә бик төшенеп җитмәсә дә, сүзнең этисе турында икәнен белеп:

– Әти шушы айның унбишенче көнендә Җирдә булачак! – диде. Планетаара очкычның кайту көнен төгәл белә инде ул.

– Майра, әй лә, әбием! Син элек ничек яшәвегез турында бик кызык сөйли идең, тагын сөйлә әле!

Трейл аның янәшәсенә үк күчеп утырды. Әбисе сөйләгәннәрне ул әкият кебек кабул итә: кызык булган бит элек, күктә төрле-төрле кечкенә кошлар очып йөргән, ә җирдә хайваннар яшәгән. Нишләп алар ризыкны утта пешерделәр икән, туклыклы пасталар, порошоклар булмады микәнни? Майра сөйләве буенча, кешеләр элемтә өчен нindидер телефоннар, компьютерлар кулланганнар икән. Менә бу искелек! Җирдә әле ул вакытта урманнар шаулап торган, яшелчә-җимешләр үскән, суларга чиста һава булган ди. Майра боларны җентекләп, сагынып сөйли, исенә төшерә.

– Озак яшәү серләрен ул вакытта белмиләр иде әле, – дип башлады ул бүген сүзен. – Элек кешеләр җитмеш-сиксән яшьләргә кадәр генә яшиләр иде.

Трейл бу сүзләргә ышаныргамы-юкмы дигән кебек, күзләрен зур ачып, бик гаҗәпләнеп карап торды. Аннары әбисе тагын сөйләп китте:

– Бабаң миңа үләр алдыннан, миннән калып, карчык, син дә бик озак яши алмассың, мин сине теге дөньяда көтеп торырмын, дигән иде. Җир шарында мондый үзгәрешләр булачагын, киберкешеләр яшәячәген без күз алдына да китерә алмадык! Ул вакытта кешенең тузган әгъзаларын да алыштырып куя белмиләр иде. Ә Җиребез әкияттәгедәй бик матур иде, челтерәп чиста сулы чишмәләр ага, талларга кунып сандугачлар сайрый, гөлләр чәчәк ата, җимеш бакчалары шаулап үсә иде ул чакларда. Кешеләр бер-берсе белән аралашып, ярдәм итешеп, дус булып яшәде, һич оныта алмыйм! Хәзер бу кояш көйдергән буш диярлек Җирдә тормыш бетеп бара бит! Чөнки күпләр байлык артыннан гына кудылар. Нишләдек соң без?! Экология дип сөйләндек кенә, сакламадык шул Җир-Ананы, кадерен белмәдек...

– Әби, син кире элекке тормышыңа кайтыр идеңме?

–- Яшәү бик җиңел булмаса да, элек күңелле иде, бик кайтыр идем, улым. Тик ул тормышны хәзер каян аласың?

Шулай сөйләшеп утырырга ярата лар алар. Беркөнне Майра үз ешлыгында көчәйткеч аша оныгы тавышын ишетте.

–- Игътибар: Майра, Трейл, сак булыгыз! Безгә чит планеталарның тереклек ияләре һөҗүм итә! Җирдә яшәү өчен шартлар бетә. Әзерләнегез, бүген без Андрамеда йолдызлыгына күченеп китәчәкбез. Безнең очкыч-кораблар ...нче киңлектә, ...нче параллельнең ...нче градусында сезне көтә.

– Улым, Трейл, скафандрыңа кереп бикләнгәнче, кислородыңны тикшер! Бар, бар тизрәк, әтиең әйткән урынга оч!


– Майра, организмыңа кертелгән күрсәтмәдә сиңа өч йөз ел гомер билгеләнгән, әле син аның яртысын да яшәмәгәнсең бит! Һәлакәт башланганчы, әйдә, китәбез! Әйдә, скафандрыңа кереп утыр тизрәк!

– Юк, Трейл, мин Җирдә калам! Бәлки, космик Акыл кушуы буенча, берничә йөз елдан кире бу планетага кайтып, аны чистартып, яңа тормыш тергезеп җибәрерсез... Хуш, улым, үзеңне сакла!

Трейл, бик борчылып, тиз генә әбисен килеп кочаклады, үрелеп кулларын үпте дә, борылып, очкычына таба атлады. Гүелдәү тавышы ишетелде. Кавырсын түбәдәге түгәрәк ишек ачылып китүгә, җил исеп куйгандай булды. “Маай-рааа...” дигән тавыш кайтаваз булып яңгырады.

– Хуш, кадерлем, сау бул, Трейл, әбиеңне онытма-а-аа! Ах! Бу ни хәл тагын?

Йомшак урындыгында йокымсырап киткән Мәһирә апа күзләрен ачып җибәрсә, һаман да көләч кояш елмаеп тора, тирәктә кошлар сайрый. Ә ишегалдында кечкенә Тәбрис белән чабышып уйнап йөргән ап-ак кәҗә бәтие аның сөт исе аңкып торган кулларын ялый иде.



Георгий
Ибушев

# ЧИТТӘ ӨЗГӘЛӘНГӘЧ АҢЛЫЙСЫҢ

## Яфрак өздем

Яфрак өздем.
Җил, яңгырдан уңган
Көзге яфрак өздем үрелеп.
Офык сыман
Уттай өрәңгеләр
Бара иде инде сүрелеп.

Үзәннәрдә
Ята иде томан,
Ап-ак кырау сарган үрләрне.
Күзгә күренеп
Сүнеп, уңып бара
Балкып, көлеп торган көз яме.

Тик көзләрдә
Була торган моңсу
Казлар каңгылдавы күкләрдә.
Уйга чумып,
Гомер агышында
Сагышланып калган бер мәлдә.

Яфрак өздем.
Шушы көзләр төсе
Сеңеп калсын, диеп, җанымда.
Күкләр иңләп
Җанны телә-телә,
Киек казлар киткән чагында.

---

Георгий ИБУШЕВ (1957) – *Татарстанның халык артисты. «Рәхмәт сиңа, җыр» исемле китап авторы. Казанда яши.*

***

Ай калыккан, бозлы тәрәз аша
Күрәм аның кыйгач сүрән төсен.
Тагын күрәм, күрше морҗасыннан
Күккә таба күтәрелә төтен.

Шыгырдата карны киез итек –
Кемдер узып бара, танып булмый.
Боз эретәм, тәрәзәгә өреп,
Зәңгәрсу кич, карларда нур уйный.

Шундый тыныч, аяз, җиңел һава,
Серле бизәк тәрәз өлгеләре.
Йолдызлардан энҗе тама сыман,
Әкияттәге кебек кар көртләре.

Кич салкыны өреп, мин эреткән
Пыялага сыза каурый бизәк.
Агачларны ап-ак бәскә төреп,
Кышкы салкын йөри төнне бизәп.

## Балачакны сагынып

Мин каядыр китеп барам сыман
Күз иярмәс гомер юлыннан.
Атлап киткән идем сабый чакта
Бик кыюсыз гына бу юлдан.

Балачагым йөгереп, көлеп калды
Гөлләр үскән матур болында.
Үсмер чагым: кулларымнан тотып:
«Уйна әле, – диде, – шушында».

Ә мин – шаян – бер кайгысыз үсмер
Яшьлегемә таба йөгердем.
Әллә сиздем, әллә сизми калдым –
Япь-яшь егет булып өлгердем.

Шундый җыйнак, көчле һәм яшь,
Хисләр ташый, ярсу йөрәгем.
Ә барыбер кайчак сагышланып,
Балачагым, сине эзләдем.

Алдалады гомер, яшьлегемне
Алып калды юллар чатында.
Үтте гомер, ике җиткән улым –
Яшьлегемдер кебек каршымда.

Күз читемә борчу-мәшәкатьләр
Әкрен генә төште сызылып.
Чигә чәчләремә аклык кунды,
Олыгайдың, диеп, бәс булып.

Кычкырасым килә яшьлегемә:
«Кайтыйк!» – диеп ямьле болынга.
Кайчакларда сыенасым килә
Җаным белән бала чагыма.

## Август

Көннәр инде башка,
Төне кара,
Йолдызлары аның яктырак.
Август, август!
Биеклеккә дәштең,
Күк гөмбәзең белән ялтырап.

Йолдызларның
Яктысына карап,
Җаным очты өскә, биеккә.
Илтер сыман
Киек каз юллары
Галәм дигән чиксез киңлеккә.

Мин югалмам,
Йолдыз яктысыннан
Шәм коярмын, сүнми торганын.
Чиксезлектән
Күрермен мин җирнең
Улым, диеп, кулын сузганын.

Яктылыктан
Тизрәк очармын мин,
Җылылыгын саклап җиремнең.
Йолдызларны
Көнләштереп, җирнең
Мин – җырчысы, улы, диярмен.

## Кайтып киләм әле

Кайтып киләм әле. Сагындырды.
Тугайларны йөреп чыгармын.
Мәтрүшкәләр инде чәчәктәдер,
Чат тавыннан җиләк җыярмын.

Әйләнермен басу сукмакларын,
Инде арыш башак җыйгандыр.
Юкәләрдән татлы, баллы һава
Урамнарга җәелеп тулгандыр.

Күршеләр һәм авылдашлар белән
Сөйләшермен, кызык аларга.
Сорашырлар: «Кай якларда йөрдең,
Нинди яңалыклар Казанда?»

Инеш аша салган ташлары да
Кадерле бит аның, төшемдә –
Шул ташларны, болын, үрләр күрәм
Ялгыз имән Чат тау өстендә.

Кайтам әле, кайтам, җан жылытып
Болыннарда килә ауныйсым.
Кадерләрен туып үскән җирнең
Читтә өзгәләнгәч аңлыйсың.

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*

# ТАТАР ИЛЕНӘ РӘХИМ ИТ!

Миңа соңгы елларда берничә мәртәбә Кавказда, Рәсүл Гамзатов, Кайсын Кулиевларның туган якларында булырга туры килде. Мине анда дуслар чакырды. Шагыйрь дуслар. Әлбәттә инде, Каф Тауларының биек түбәләренә карап сокланып, тау араларындагы тирән упкыннарны да, куркыныч тарлавыкларны да, таудан шаулап агып төшкән чишмә-елгаларны да, ап-ак, кояшта күзне камаштыра торган кар яткан тау түбәләрен дә күп күрдем мин.


Әйе, Рәсүлнең дә, Кайсынның да артында таулар яткан. Аларны шул таулар шагыйрь иткән. Соңгы елларда без Рәсүл Гамзатовның, карачай-балкар шагыйрьләренең, авар шагыйре Мөхәммәд Әхмәтовның (Магомед Ахмедов) һәм балкар шагыйрьләре Кайсын Кулиев, Кәрим Отаров һәм Муталип Беппаевның шигырь китапларын татар укучысына тәкъдим иттек. Кавказда алган тәэсирләрдән үзем дә күп кенә шигырьләр яздым. Рәсүл дә, Кайсын да безнең Сибгат Хәким, башкортларның Мостай Кәрим, Нажар Нәҗмиләрнең кордашы – бер заманда яшәгәннәр, бер чорда иҗат иткәннәр. Аралашып, очрашкалап торганнар.

Быел Кабарда-Балкар Республикасының халык шагыйре, Ленин премиясе лауреаты, СССР һәм РСФСРның Дәүләт премияләре лауреаты Кайсын Кулиевның (1917-1985) тууына 100 ел тула.

Кайсын Кулинең хәтта бер чорда Казанга күченергә уйлап йөргән чаклары хакында да сөйлиләр. Булгандыр да. Балкарларны туган җирләреннән, нигезләреннән аерып Кыргызстанга сөргән авыр еллар бит. Әнә шул елларда сугыштан кайтып, туган нигезен, әнисен, туганнарын күрергә зар-интизар булганда, башына нинди генә уйлар кереп карамагандыр. Ләкин Кайсын Кули үз халкы белән була, аннан аерылмый. Ул күргән авырлыкларны, казаларны үз иңендә күтәрә, үз йөрәгеннән кичерә. Шигырьләре дә әнә шуңа күрә сөекле халкына, туган җирләренә, тауларына, аның тарлавыкларына, кыя-ташларына тирән мәхәббәт белән сугарылган.

Кайсын Кулиевның шигырьләрен моңа кадәр урысча гына укыганым булды. Тәрҗемә – тәрҗемә инде. Бигрәк тә төрки телдән урысчалаштыру, бөтенләй башка шигырь калыбы, башка җөмлә төзелеше. Татар шагыйрьләренең дә шигырьдәге хис-кичерешләрен урыс телендә төгәл биреп бетерә алмаганын беләбез. Балкар теленнән урысчага күчергәндә дә шул ук нәрсәдер инде ул дип уйлый идем. Чынлап та шулай икән. Кайсын Кули үз туган телендә бөтенләй башкача яңгырый. Балкар дусларым миңа аның үз туган телендә чыккан күптомлыгын бүләк иттеләр. Һәм мин аны татарчага аударырга булдым. Әлбәттә, бу китапны укучы балкар телен беләдер дип уйламыйм, ләкин балкар шагыйренең шигырьләре татар телендә ничегрәк яңгыравы һәркем өчен дә кызыклы булыр. Татар һәм балкар телләре бик якын, бераз аралашканда, бер-беребез белән бик тиз аңлаша башлаган булыр идек. Тик андый аралашу мөмкин түгелдер шул – безгә бер-беребездән шактый ерак араларда яшәргә язган. Шулай да бер нәрсә юаныч бирә, ул – әдәбият, безнең язучылар, әсәрләр, шигырьләр, китаплар. Әйдәгез, бер-беребезнең китапларын, шигырьләрен укып яшик. Шигырьләр безнең арадагы күперләр булсын, шагыйрьләр – илчеләр, арадашчылар. Татар дөньясына рәхим ит, Кайсын Кули! Балкар шагыйренең хисләрен татар күңеленә алып кер.

**Рафис КОРБАН**



Кайсын
Кулиев

# МИН ҖЫРЛАДЫМ ЯШӘҮ ТУРЫНДА

## Язгы күкрәү

Бәрелдеме бер-беренә ике тау,
Әллә арба таудан аска очтымы –
Яңгырады тарлавыкта күкрәү,
Тау башында уйнап торды очкыны.

Бу беренче язгы күкрәү авазы
Тарлавыкка гына сыеп калмады,
Тәгәрәде, таштан ташка бәрелеп,
Күкрәп торды бөтен Каф Тау аллары.

Карт-корылар, тыңлап күкләр күкрәвен,
Хәтерләде авыр сугыш юлларын:
Гөрелтесен тынмый аткан тупларның,
Давылларда үткән яшьлек елларын.

Еракта-еракта яңгырый күкрәү,
Кыядан кыяга барып орына.
Хикәят кебек тоела ул миңа
Киләчәк һәм үткән көннәр турында.

* * *

Шагыйрьләрнең йөрәгеннән үтә
Җир йөзенең барлык юллары.
Аңа барып тия, кайда гына
Атылса да мылтык уклары!

Кем өчендер төн карасы ятса
Кара шәүлә булып гүренә,
Шагыйрь өчен – анасының кара
Шәле булып бары күренә.

Чаларса да, сабый булып кала,
Ышанычын тәмам җуйса да,
Анасына сөеп караган күк
Карый шагыйрь бөтен дөньяга.

Сабый бала беренче кар күреп
Сөенсә дә, шагыйрь шатлана.
Кемгә төбәп атылса да уклар,
Шагыйрь йөрәгенә кадала.

## Мәңгелек Тау[1]

Мәңгелек Тау, шундый исем биргән
Сиңа халкым, сөеп-яратып.
Сиңа карап намаз укыган ул,
Йортын салган сиңа каратып.

Сиңа карап тәрәзәсен уйган,
Синең якка ачкан ишеген.
Яшь аналар, синең хакта җырлап,
Тибрәткән сабый бишеген.

Синең яктан көн яктырган таңда
Сиңа карап кына ай чыккан.
Син таулының иң зур байлыгы, дип,
Фәкыйрьлеген фәкыйрь оныткан.

Мөһаҗирләр булып яшәгәндә,
Сине төштә бик еш күрдек без.
Читтә синең белән горурланып,
Бәхетлеләр булып йөрдек без.

Эшен башлап, балкар дога кылса,
Сиңа карап кылган ул аны.
Син – халкымның горурлыгы минем,
Син – намусы аның, вөҗданы.

Мөэмин булсам да мин, кыйбла эзләп,
Синнән читкә китеп калалмам.
Синнән китеп әҗәл тапканда да,
Каберемдә тынгы табалмам.

Мәңгелеккә килми җиргә кеше,
Беләм әҗәл бер көн аласын.
Без китәрбез мәңге кайтмаска дип,
Син – Мәңге-Тау, мәңге каласың.

Җирдән киткән
синең итәгеңдә
Кеше канын койган затлар да.
Син калгансын, сине саклап шәһит
Киткәннәрнең данын сакларга.

Мәңгелек Тау, мин үлсәм дә, рухым
Мәңге синең янда калачак.
Онykларым сиңа, миндәй сөеп,
Гашыйк күзләр белән багачак!

[1] Балкарлар Мәңгелек Тау (Мәңге-Тау) дип Эльбрус тавын атыйлар.

* * *

Мин пәйгамбәр түгел үзем болай.
Ачышлар да ясамадым бугай.
Әмма ләкин булса җырымда
Нидер биек таулар турында,
Йә күкләрнең зәңгәр балкышы,
Тау суының җитез агышы,
Өрек ботагының тармагы,
Тарлавыкның кырыс тарлыгы, –
Бәхетле мин – Хода бәндәсе.
Яшәвемнең шунда мәгънәсе.

Пәйгамбәрлек күрмим үземдә.
Әмма сезгә әйткән сүземдә
Ишетелсә буран тавышы,
Өзелеп төшкән яфрак сагышы,
Чапкан үләннәрнең әрнүе,
Сулган бакчаларның кайгысы, –
Шатланам мин әнә шуңа да,
Шул бит инде бәхет дөньяда.

Мин пәйгамбәр сүзен әйтмәдем.
Ләкин минем җырда әйткәнем
Хәтерләтсә сезгә кырларның
Тургайлары сузган җырларын,
Чегемдагы ташлы юлларны,
Аналарның арык кулларын,
Аналарның моңлы күзләрен...
Йөрәк кайгысы һәм куану,
Сабыйларга карап юану, –
Мин шуларны яздым җырымда,
Пәйгамбәрлек күрмим мин монда.

Мин тормышны сөйдем, җырымда
Мин җырладым шуның турында.
Ак түбәтәй кигән тауларны,
Яшел язны, ап-ак кышларны,
Кыш агарткан тирәк-талларны,
Яз уяткан җырчы кошларны.
Менә шулар минем җырымда.
Мин җырладым яшәү турында.

# ХАК ТАРИХНЫ КАЙТАРУ ЮЛЫНДА

«ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ»

*«Казан утлары» журналының 5-6нчы саннарында Вахит Имамовның «Карабәк» исемле тарихи романы басылып чыгуга, ул тарихчы галимнәр арасында гына түгел, ә киң катлау укучылар арасында да зур кызыксыну уятты, бәхәсләр тудырды. Журналыбыз редакциясенә юллаган сораулар, телефоннан шалтыратулар да күп булды. Шуларны истә тотып, редакциябездә бер төркем галимнәр «түгәрәк өстәл»гә җыйналды. Фикер алышуларда тарихчылар һәм әдәбият галимнәре, фән докторлары* ***Дамир ИСХАКОВ, Фаяз ХУҖИН, Илдус ЗАҺИДУЛЛИН****, фән кандидатлары* ***Җәмил МӨХӘММӘТШИН, Рамил ХАННАНОВ****, прозаик* ***Камил КӘРИМОВ*** *һәм роман авторы үзе –* ***Вахит ИМАМОВ*** *катнашты. «Түгәрәк өстәл»дә фикер алышуларны журналның баш мөхәррире* ***Илфак ИБРАҺИМОВ*** *алып барды.*



**Илфак Ибраһимов:**

*– Татар халкының дәүләтчелеге тарихына багышланган фәнни хезмәтләр белән янәшә әдәби романнар, бәяннар, очерклар, поэмалар язылып тора. Шуңа да карамастан, бу тема һаман да колач җитмәслек булып кала. Ш.Мәрҗәни исемендәге Тарих институты әнә 7 томлык тарихыбызны бастырып чыгарды. Хак тарихыбызны әлегәчә өйрәнеп бетә алмыйбыз.*

*Тарих фән өчен кирәк булса, тарихи әдәби әсәрләр күпсанлы укучыларыбыз өчен кирәк. «Карабәк» романын тарихчыларыбыз ничек кабул итте икән?*

**Илдус Заһидуллин:**



– Тарихи романнар язылуның берничә алшарты бар, шулар булганда гына бу жанр яши дип уйлыйм. Тарихи роман, беренче чиратта, язучы шәхесе белән бәйле. Вахит Имамов – «чумып» тарихи эзләнүләр алып барган шәхес, ул – төрле чорлардагы милләтебез язмышы белән бәйле вакыйгаларга, күренекле шәхесләр язмышына мөрәҗәгать итеп, әдәби әсәрләр генә түгел, очерк-мәкаләләр, публицистик хезмәтләр иҗат иткән автор. Нурихан Фәттахтан эстафета каләмен кабул итеп, шушы юнәлештә иң актив эшләүче язучы, дип әйтер идем. Икенчедән, татарга кагылышлы тарихи роман сәясәткә барып тоташмый калмый, ягъни Русия шартларында бу хакта язарга «рөхсәт бирелгән» булу шарт. СССР таркалу, коммунистлар партиясен таркату элеккеге тоталитар, тыюларга корылган идеологияне юкка чыгарды, яңа темаларны чикләүләрсез яктыртуга юл ачылды. Өченчедән, тарихи әсәрләр, гадәттә, тарихи хезмәтләр язылгач, чыганаклар басылгач дөнья күрә. Чөнки тарихчылар борынгы чыганакларда теркәлгән вакыйгаларны бер җепкә тезеп аңлатырга һәм, шул рәвешле, тарихи барышны тергезергә омтыла. Татарстанда соңгы ике дистә елда Алтын Урда иң күп сөйләнә һәм языла торган темаларның берсенә әверелде. Суверенитет елларында ул сәяси хезмәт тә башкарды: татарларның бүтән милләтләр белән тигез хокуклылыгын һәм Мәскәү дәүләтенең Алтын Урдадагы урыс олысыннан үсеп чыгуын пропагандалады. Дүртенчедән, милли идеология шанлы тарихи темаларга мохтаҗ, бигрәк тә милли күтәрелеш яки кризис вакытларында

тарихи әсәрләргә ихтыяҗ арта. Әдәби сүзнең тәэсире тарихи хезмәтләргә караганда күпкә көчлерәк икәнен искәртсәк, тарихи әсәрләрнең татар укучысының тарихи хәтерен яңартуда мөһим роль уйнавы тагын да аңлашыла төшәр.

Гомумән алганда, Алтын Урта дәүләте заманында мәйдан тоткан шәхесләр, дәүләт эшлеклеләре, аларның гамәлләре – иҗат әһелләре өчен бетмәс-төкәнмәс чыганак. Вахит Имамов – шушы бай чыганаклар сакланган мәгарә ишегенә ачкыч ятатып кергән язучы. Яңа роман татар язучысының «үз дәүләтен» ничек сурәтләве һәм бәяләве ягыннан да кызыклы.

Әйтик, сакланып калган чыганакларның күбесендә Аксак Тимер белән Туктамыш сугышларын, мөнәсәбәтләрен тасвирлаганда, бер шәхесне генә күкләргә чөеп бәяләү өстенек итә. Чөнки Аксак Тимер махсус рәвештә сарай елъязмачыларын, тарихчылар яллаган, үзенең җиңүләре хакында яздырган. Алар исә хуҗаларының җиңелүләрен дә киләчәк җиңүләргә әзерлек, дип бәяләгән. Низамеддин Шами, Шәрәфеддин Йәзди «Зафарнамә»ләрендә һәм XV гасыр башында язылган башка хезмәтләрдә Туктамыш – бигрәк тә 1385 елдан башлап актив тышкы сәясәтен җәелдергәч, Аксак Тимер белән Азәрбайҗан һәм Иран җирләре өчен каршылык килеп чыккач, походлар ясый башлагач, яхшылыкка начарлык белән җавап бирүче шәхес, үз сүзендә тормаучы ялганчы кеше, ә Аксак Тимер гадел хаким буларак күрсәтелә. Биредә чыганакларга тәнкыйди караш сорала. Бу язмаларда теркәлгән Туктамышны гаепләүләрне автор Аксак Тимердән әйттерә кебек, ә менә Туктамышны акларга дәлилләр җитә микән? Туктамыш хан образын тагын да ачыграк – Җучи нәселе вәкиле, үзенә тиешле Алтын Урданы ныгытучы һәм аның көчәюе өчен җан атучы дәүләт җитәкчесе буларак күрәсе килә.

Романда Алтын Урдада сәяси кризис вакытындагы сугышлар, ханнар алмашу хакында күп язылгангамы, еш кына алар вәхши, канэчкеч шәхесләр буларак күзаллана башлый. Әйтәсе килгәнем – Алтын Урда төрки халыкларның, шул исәптән безнең бабаларыбызның уртак дәүләте, дип сөйлибез икән, аның уңай якларын калкурак сурәтләү зарур, гәрчә бу бөек дәүләт язучыларның махсус шәрехләвенә мохтаҗ булмаса да. Әсәрдә караңгы төсләр куелыгына бүгенге татар публицистикасында гел тискәре якны калкытып күрсәтүче һәм «самобичевание»гә нигезләнгән фикер сөреше йогынты ясаган кебек тоелды.


Гомумән алганда, Вахит әфәнденең бу катлаулы темага алынуы – зур батырлык.

**Фаяз Хуҗин:**



– Әсәрне без кызыксынып кабул иттек, әмма ажиотаж булмады, ыгы-зыгы, шау-шу күтәрелмәде. Игътибардан читтә калдырмавыбызның сәбәбе шул: Вахит Имамов – татарларның башлыча урта гасырлар чорына караган тарихи романнары белән һәм халкыбызның киләчәк язмышын билгеләүдә әһәмиятле роль уйнаган тарихи вакыйгаларга үзенең шәхси, фәндә кабул ителгән рәсми концепцияләргә туры килеп бетми торган бәяләмәләре белән киң катлам укучылар арасында танылу алган язучы. Кызганыч, тарихчылар арасында «Казан утлары»н даими укып, бүгенге татар әдәбияты белән танышып баручылар сирәк. Шуңа күрә галимнәребезнең күбесе бу романны әлегә укымады да, тизрәк китап булып чыгуын көтәләр.

**Җәмил Мөхәммәтшин:**



– Тарихыбызга багышланган татар телендәге әсәрләрне бармак белән генә санарлык. Шуның өчен Вахит Имамовның «Карабәк» романын укучылар бер бәйрәм кебек көтеп алды. Роман татар тарихының бик четерекле чорын – Алтын Урда дәүләтенең таркалу елларын күрсәтә. XIV йөзнең икенче яртысында башланган, Чыңгыз хан варислары арасында барган тәхет өчен көрәш, ул көрәшкә кулында гаскәре булган әмирләрнең һәм бәкләрнең кушылуы бердәм татар дәүләтенең таркалуына китерә. Элегрәк дәүләте булган Болгар, Кырым, Хәрәзем җирләрендә идарәчеләрнең, үз җирләрен, мал-мөлкәтләрен саклап калу өчен, әлеге көрәштә теге яисә бу ханны

яклап чыгулары табигый хәл. Моның ачык мисалы – романда яхшы тасвирланган Карабәк образы.

**Дамир Исхаков:**



– Карабәк шәхесенә бәйле нәсел һәм мирас мәсьәләсенә яңачарак та карарга мөмкин. Гадиләштереп әйтсәң, Туктамыш хан бит инде ул, Мангышлактан чыккан. Аның бабаларының биләмәләре шунда булган. Аннан Туктамыш ханның дүрт үз кабиләсе булуы билгеле: ширин, барын, аргын һәм кыпчак.

Карабәкнең шәҗәрәсен карыйк. Аның бабалары Бачман солтанның нәселе бит инде. Бабаларының тарихын язганда, Төркия дә искә алына һәм аннан соң анда сүз Александр Македонский – Искәндәр турында да бара, ягъни шәҗәрәдә аңарга тоташтыру да бар. Моның ни өчен шулай булуының үз аңлатмалары бар. Урта Азия ул гади төбәк түгел. Шуңа күрә Карабәкнең нәселләре мәсьәләсен караганда, аның үзенең дә кем булуын яхшырак аңларга мөмкин. Болар аерым язуны таләп итә.

Кайвакыт Аксак Тимер бик көчле гаскәр белән килгән, шуңа күрә Алтын Урда каршы тора алмаган, дип тә әйтәләр. Билгеле, Аксак Тимер гаскәре көчле булган, ләкин бит ул килгәндә, Алтын Урда нинди хәлдә яшәгән?! Әгәр Кара чумалар килеп чыкмаган булса, шәһәрләрдә бик күп кеше кырылып бетмәсә, Аксак Тимер монда якын да килә алмас иде. Ул бит, ни дисәң дә, бер нойон токымыннан чыккан шәхес кенә. Чыңгызыйлар ныгып утырган йөзләп шәһәре булган Идел буе төбәгенә болай гына үтеп керә алмаслар иде. Шуңа күрә монда сәбәпләр күптөрле. Романда язылган әйберләр бик әһәмиятле һәм кирәкле булсалар да, башка сюжетларны да киңрәк кертергә мөмкин иде. Кертү ысулын әйтә алмыйм. Ул – язучы эше.

Шуны да истә тотарга кирәк. Тикшереп караган идем, мәсьәлән, минем мәгълүматлар буенча, Карабәк XIV гасыр ахыры – XV йөз башында яшәгән булырга тиеш (шәҗәрәдә калган даталар буенча).

**Вахит Имамов:**



– Ни кызганыч, әдәбиятыбызга тарихи романнар җитми. Гәрчә Тарих, Археология институтлары, Фәннәр академиясе галимнәре соңгы елларда саллы-саллы тарихи китаплар әзерләп чыгарса да, ул җыентыклар күбесенчә рус телендә нәшер ителде һәм тәүге чиратта татар теле һәм әдәбияты, тарих укытучыларының һәркайсына барып ирешмәде. Һәр укытучыга өләшеп чыгу да аз, чөнки китаплар фәнни телдә һәм бик тә метереклэп язылганга күрә, тарихи яктан әзерлексез мөгаллим анда бәян ителгән вакыйга һәм сәяси бәяне бәйнә-бәйнә һәм эзлекле рәвештә төшенә дә алмый. Татар тарихын һәрбер укучыга да мәҗбүри булмаган төгәллек-нечкәлекләрдән арындырып, фәкать төп кыйбласын һәм каймагын гына гади халык теле белән бәян итәсе, нәкъ шундый үтемле шивәдә язылган китапларны рус һәм татар телләрендә нәшер итәсе иде дә бит, ни кызганыч, алар бик санаулы. Шуңа безнең халык үзенең газиз тарихыннан гаять ерак.

**Илфак Ибраһимов:**

*– Без «Болгар дәүләте белән Алтын Урданы бербөтен итеп күзаллауга өйрәнеп киләбез. Болгар Алтын Урдага кадәр дә, Алтын Урда составында да гел алгарышта булган, дибез... Шул ук Вахит Имамов «Утлы дала» романында Болгарга татар-монгол яулары басып керүләрне сурәтләде. «Карабәк» романында Болгарның соңгы әмире Карабәк – Габдулла ханның Алтын Урда дәүләтен саклап калу өчен җан атып йөрүе, көрәшүе сурәтләнә. Туктамыш баскын Аксак Тимергә каршы ике тапкыр 200 меңлек гаскәр туплый. Һәр ике яу алдыннан Болгар әмирлегеннән өчәр-дүртәр төмән җайдак җыеп, Карабәк тә аның әләме астына баса. Шундый көчне Алтын Урда составындагы тагын кайсы олыс бирә алган соң? Әллә монда «әдәби якын килү» күбрәкме?*

**Илдус Заһидуллин:**

– Мин Алтын Урда чорындагы Болгар төбәгенә карата «Болгар дәүләте» сүзен кулланмас идем. Элекке Болгар дәүләте җирләре – 1236 елдан соң яңа оешып килүче Алтын Урдада – вилаять, олыс статусында яши башлый.

Аксак Тимер походка барганда, ташка яздырган текстка нигезләнеп, 1391 елгы Кондырча елгасы буендагы сугышта аның 200 меңнән артык гаскәрие катнашкан, дип әйтә алабыз. Туктамыш хан да шуның кадәр гаскәр җыйган, дип фаразларга нигез бар. 1395 елда өч көн дәвам иткән сугышта катнашучылар саны да якынча тигез булырга охшый. Бу вакытта Аксак Тимернең гаскәре тагын да күбрәк булган. Әлеге саннар ул заманның иң зур армияләре бәрелеше турында сөйли. Аксак Тимер белән Туктамыш арасындагы сугыш хәрәкәтләрен тасвирлаганда, автор тарихи чыганакларны оста файдалана.

**Фаяз Хуҗин:**

– Болгар Алтын Урдага кадәр дә, Урда составында да бай икътисады, димәк, хәрби көче һәм мәдәнияте ягыннан да алга киткән өлкә булган. Әмма Алтын Урданы һәм аңа кадәр чәчәк атып яшәгән Идел Болгарын (Болгарстанын) бербөтен итеп күзалларга тырышу тарихи дөреслектән ерак тора. Идел Болгары, исеменнән үк күренеп торганча – хәзерге Идел-Урал татарларының бабалары булган болгарлар дәүләте, Алтын Урда исә – монгол-татар яуларыннан соң әнә шул Болгар дәүләтен юкка чыгарып, аның биләмәләрен, халкын һәм, әлбәттә, башка җирләрне дә кушып барлыкка килгән төркиләр дәүләте. Ул дәүләтнең буйсындырылган халкын, шул исәптән болгарларны да, татарлар дип йөртә башлаганнар. Болгарлар, кайбер тарихчылар әйтүенчә, XIV гасыр урталарында килеп чыккан үләт (чума) эпидемиясе вакытында үлеп бетмәгән (күрше мордвалар, марилар һ.б. халыклар исән калган ич), Алтын Урда составында яшәүләрен дәвам иткән.

«Карабәк» романында башлыча XIV гасырның икенче яртысында булып үткән вакыйгалар сурәтләнә. Бик болгавыр заман бу, 20 ел эчендә тәхеттә 25 хан алышынган, барыбызга мәктәп елларыннан ук таныш Мамай һәм Туктамыш, Идегәй һәм Аксак Тимер, алар белән янәшә Болгар ханы Габдулла (Карабәк) яшәгән һәм көрәшкән чор. Аларның барысы да илнең таркала баруына борчыла, дәүләтнең бөтенлеге өчен көрәшә, бары тик шул максаттан чыгып кына тәхеткә омтыла кебек. Әмма тәхет берәү генә, дәгъвачылар күп. Алтын Урданың бердәмлеген саклап калу өчен, ихластан көрәшүчеләр арасында Туктамышның «уң кулы» Карабәк тә бар.

Романда сурәтләнгән вакыйгалар шулкадәр ышандыра ки, күпвакыт тарихи дөреслеккә туры киләме алар, килмиме дип уйлап та тормыйсың. Кайта-кайта укыганда гына, кайбер төгәлсезлекләргә тап буласың. Шуларның берничәсе турында әйтеп үтмәкче булам. Кызганыч, автор болгарларны бөтенләй «оныткан». Болгар шәһәреннән чыккан кешеләр бар («болгарлылар»), ә болгарлар, күрәсең, теге чума вакытында кырылып беткәндер – аларны автор бер тапкыр да телгә алмый.

**Илдус Заһидуллин:**

– Берничә җирдә әйтелә бит!

**Фаяз Хуҗин:**

– Аның каравы, Туктамыш әмере белән Болгар олысын яңадан күтәрү өчен «бушап калган» элеккеге болгар җирләренә кырым татарларын, кыпчак-бәҗәнәкләрне, кыргызларны, тагын әллә кемнәрне күчереп утырта. Берьюлы 15 меңнән артык олау башындагы ирләр (күбесе үзләренең гаиләләре белән!) килеп төпләнә безнең якларга. Күчмәннәрнең гомуми санын 200 меңгә тиңләргә дә мөмкин. Алар составында бик күп гаскәриләр. Габдулла хан үзе дә кырымлы Гәрәйләр нәселеннән дип күрсәтелә (ә без аны һәм аның Алтынбәк белән Галимбәк атлы улларын болгарлардан дип йөри идек). Без, бүгенге татарлар, шуларның токымнары булабыз инде. Уйланырлык нәрсәләр бар монда. Саннар артык күпертелгән, минемчә.

Тагын бер төгәлсезлек. Туктамыш хан Болгарга, Карабәк янына килә: «елга буйлап, кораб илә менә», Чулман тамагындагы Айгыр тавын да үтә, «ике тәүлектән соң Ага-Базарга килеп җитүе бар». Соң, елга (Идел) буйлап күтәрелеп, Кама тамагына

килеп җиткәч, Болгарны узып киткән була ич инде ул. Каманың Иделгә кушылган җиреннән Болгарга кадәр 30 гына чакрым, аны үтү өчен ике тәүлек кирәк түгел. Шуңа охшаш төгәлсезлек Туктамышка урыс кенәзлекләреннән килгән сугышчыларга бәйле сөйләшүләр барышында киткән: «Муром каласыннан Иделгә килеп җиткәнче, – ди Рязань кенәзе Алексей, – Мукшы урманнары аша узасы бар». Һич алай түгел, мукшылар бит алар Болгардан көньяктарак яшәгән. Туктамышның Болгарда булу-булмавы да – бәхәсле мәсьәлә.

Аннан соң Җидесу ул, искәрмәдә күрсәтелгәнчә, Амударья белән Сырдарья арасы түгел (бусы аның Мәвәэннәһер дип йөртелә), ә Балхаш күле белән хәзерге Алматы шәһәре арасындагы артык зур булмаган бер өлкә.

**Җәмил Мөхәммәтшин:**

– Романда Габдулла хан белән Карабәк бер шәхес итеп бирелә. Тарихта Урдада акча суккан Габдулла, риваятьләр буенча билгеле Болгар ханы Габдулла һәм шәҗәрәләр буенча билгеле Карабәк бар. Хан Габдулла Азакта – хиҗри белән 764-766 елларда, Урдада – 767-771, Шәһрел-Җәдидтә 766-767 елларда тәңкәләр суга. Бакыр акчалары бары Азакта гына сугылса, Кырымда Габдулла хан исеменнән акча сугылмый. Габдулланың 782 елны Сарай әл-Җәдидтә сугылган акчалары да бар. Туктамыш хан идарә иткәндә, Габдулла ничек акча суккандыр – тарихта билгесез. Риваятьләр буенча, Болгар ханы Габдулла Аксак Тимер тарафыннан Кара пулатта яндырып үтерелә. Шәҗәрәләр буенча билгеле булган Карабәкнең Габдулла хан белән бер кеше булуы турында тарихи фактлар юк.

**Вахит Имамов:**

– Әмма шәҗәрәләр Карабәкнең Габдулла хан булуын раслый.

**Җәмил Мөхәммәтшин:**

– Габдулла ханны соңгы Болгар әмире булган, дип әйтеп булмый. XIV гасыр ахыры – XV йөз башында Болгарда Гали-Дәрвиш акча суга. Ул акчалар бары Болгар шәһәрендә генә табыла һәм аларны риваятьтәге Галимбәк белән бәйләргә мөмкин. Бу вакытта Болгарда бакыр акчаларга күпләп «ук һәм җәя» тамгасын сугу (маркировка) да оештырыла. Ул Гали-Дәрвиш акчалары белән бер чорда яисә аннан соңрак сугыла. Димәк, Габдулла хан үтерелгәннән соң, Галимбәк, Болгарга кайтып, шәһәрне торгызырга тырыша һәм XV йөз башында Шадибәк исеменнән дә акча сугуны оештыра. Болгарда Шадибәктән башлап Олуг Мөхәммәдкә кадәр булган ханнар акча суга. Шул исәптән, Болгарда Шадибәк бакыр акча да суга. Димәк, XV гасырның 20нче елларына кадәр Болгар шәһәре үзенең әһәмиятен югалтмый. «Ук һәм җәя» тамгасы белән көмеш акчалар 1418 елларда, Олуг Мөхәммәднең беренче идарәсе чорында, ягъни Болгарда (Казанда) Гиясэтдин хан идарә иткәндә сугыла башлый.

XIV гасырда Урта Иделдә бер миллион ярым кеше яшәгән, дигән мәгълүмат бар (Алтын Урданың чәчәк аткан чорында бу сан күбрәк булган). Таркалган, ике мәртәбә (1391, 1395 елларда) таланган илдә 200 мең гаскәр җыю мөмкин түгел. Әдәбиятта күрсәтелгән 50 мең дә зур сан.

**Дамир Исхаков:**

– Карабәк белән Габдулла ханны тәңгәлләштерү ул – Марсель Әхмәтҗановның эше. Ул шәҗәрәләр аркылы шундый нәтиҗәгә килде. Шуңа күрә язучының андый хакы бар. Әмма башка версияләр дә булырга мөмкин. Габдулла хан дигән шәхес булган инде ул. Бакыр акчаларда да бар бит аның «Абдаллаһ» дигән исеме. Кайсы нәселдән булуы гына шөбһәле. Әмма аны Карабәк белән тәңгәлләштерүне тарихи чыганаклар нигезендә исбат итеп булмый. Инкарь итеп тә булмый. Шулай да Марсель Әхмәтҗанов үз дәлилләрен китерде. Бу бөтенләй ялгыш караш түгел, ә бер фараз. Әмма Карабәкнең «бәк» дигән атамасы үзе үк аның чыңгызый түгеллеген күрсәтеп тора, ул – нойоннар нәселеннән килгән князь. Алтын Урда составында чакта, болгарлар берничек тә элита була алмый. Анда элита төркемнәре фәкать тик чыңгызыйлар белән бәйле төркемнәр арасыннан гына чыгарга мөмкин. Болгарлар алар, күп дигәндә, сәүдәгәр яки сугышта катнашучы рядовой сугышчылар була алган. Төп хәрби төркемнәр һәрберсе кабиләләр белән бәйле. Туктамыш ханның, әйтик, үзенең дүрт кабиләсе булган икән, шул

шәхесләр соңыннан карачы бәкләр булып торганнар да. Башкалар юк анда. Йә ясак түләүче, йә сәүдәгәр буларак акча эшләп йөрүчеләр генә. Ә хакимлек итүче элита ул – бөтенләй башка төркемнәр. Шуңа күрә болгарлардан хан ясау тарихи дөреслеккә туры килми. Карабәкнең нәселе калган, чөнки аның бабасы – Бачман солтан. Алар югары дәрәҗәдәге кешеләр булган. Әмма барыбер статус ягыннан бер баскычка түбән торганнар. Бачман солтан бит ул – мөстәкыйль хөкемдар. Аның туганнары арасыннан кемдер хан да булган. Әмма монголлар кул астына эләккәч, бер кабилә бәкләре буларак кына калганнар.

**Вахит Имамов:**

– «Карабәк» романы – яшерелгән тарихны кайтаруда бер адым. 1236 елдан – Бату хан яулап үткәннән соң – 1438 елга – Казан ханлыгы оешкан елга чаклы тарихыбыз һаман караңгылыкта калдырылды, әдәбиятта, хәтта тарих фәне китапларында да әлеге чор бәян ителмәде. Элеккеге болгар халкы кая киткән, борынгы Болгар җирендә татар халкы ничек тамыр җәйгән? – әлеге теманы еллар буе урап үтүне кулай санадылар. Шуңадырмы, әдәбиятта һәм халык иҗатында Туктамыш ханны – булдыксыз һәм кансыз, ә Идегәй морзаны милли байрак рәвешендә күтәрү кебек хилафлык тамыр җәйде. Инде романның төп герое Карабәккә тукталабыз икән, ул, гомумән дә, бүгенге буын өчен дөм-караңгы шәхес.

Романда әйтелгәнчә, Карабәк – ул 1361 һәм 1367 елларда ике мәртәбә Алтын Урда дәүләтенең тәхетенә утыруга ирешкән Габдулла хан. Ә 1360-1380 елларның Урда тәхетендә 25 хан алышкан иң болганчык, иң аяныч вакыт булганлыгын тарих белән кызыксынучылар аз булса да ишетеп белә. Әлеге мәхшәр 1380 елда тәхеткә Туктамыш хан менгәч кенә туктала. Зиһенле һәр хакимгә туздырылып-таланып беткән өлкәләрне кабат аякка бастыру да, шул ук вакытта тәхеткә дәгъва итеп, аңа куркыныч тудырырдай аксөякне үз ягына аудара белү дә кирәк. Нәкъ менә шул максаттан, Туктамыш 15 ел чамасы элегрәк хан дәрәҗәсен йөрткән Габдулла-Карабәкне үз янына чакыртып ала һәм, үзе теләгәнчә халык, байлык туплап, аңа борынгы Болгар ханлыгы җирләренә әмир сыйфатында юнәлергә әмер бирә. 70-80ләп данәдә табылган шәҗәрәдә бәян ителгәнчә, Карабәк-Габдулла үзенең кул астына әүвәл Кырымдагы Гәрәй кабиләсенең зур өлешен, аннары Кавказ итәгендә, Идел тамагында, Җаек һәм Сакмар буйларында яшәгән татарларны җыеп ала һәм 17 мең олау (!) күләмендә Болгар олысына килеп урнаша. Ул чорларда мөселман гаиләләрендә балаларның бик күп булуын истә тотып, тарихчылар бер олау яки бер тирмәне 20 кешедән исәпли. Ләкин күчмәннәрнең ерак юл узуын, үзләре белән яңа җирдә кирәк булачак сугыш, тормыш-көнкүреш, төзелеш коралларын, вак-төяк малтуарны, карт-коры, бала-чаганы да «төяп» баруын күз алдында тоткан очракта да бу кадәр халыкның 150-200 меңнән дә ким булмавы ачык. Бүген Актаныш, Сарман, Мөслим, Әгерҗе, Минзәлә, күршеләрдәге Краснокама, Илеш, хәтта ерак Урал итәгендә, Нократ буйларында яшәгән Гәрәй кабиләсе варислары – әнә шул 1380 елларда ук безнең җиргә килеп төпләнгән күчмәннәр дәвамы ул.

Инде әйттем, бүгенге буында искиткеч тә хилаф риваятьләр яши. Әнә, Алтынбәк белән Галимбәкне Болгар дәүләтендә Бату явы килү алдыннан яшәгән соңгы Габдулла ханның балалары итеп тә күрсәтәләр. Хәтта Биектау районындагы Иске Казан кирмәнен дә шул чордагы Габдулла хан юллаган угыллары нигезләгән, имеш. Бу әкияткә әле тагын кирмән нигезе астына кеше урынына эт суеп салу, моны ачыклагач, Габдулла ханның «эт суеп салгач, ошбу кала этләр кулына калачак икән», дигән хорафат аша кул селтәгәнен дә мисалга китерәләр. Шушы ялган еллар буе яши, яңадан-яңа буыннарга күчә. Ә югыйсә чишелеш гап-гади: ул риваять вә ул хорафат фәкать Казан каласы рус патшасы тарафыннан яулап алынгач, ягъни 1552 елдан соң гына, анда да үз-үзебезне юату максатыннан уйлап табылган бит!

Асылда башкача. 1395 елда Кавказдагы Терек елгасы буенда Алтын Урда гаскәрен икенче мәртәбә тар-мар иткәч, Аксак Тимер Идел буендагы Хаҗитархан, Үкәк, Кырымдагы Садак калаларын яндырып юк итә һәм, Туктамыш ханны эзәрлекләп, Болгар олысына да килеп җитә. Болгар олысының соңгы әмире Карабәк-Габдулла хан үзенең уллары Алтынбәк белән Галимбәкне Казан тарафына

юлларга мәҗбүр була. Берничә мең җайдак биреп, Туктамышны урыс җиренә җибәреп яшерә, үзе исә соңгы төмәннәре белән Аксак Тимер гаскәрен каршылый. Әмма яуда янә тар-мар ителеп, уникe яраны белән бергә Аксак Тимер кулына эләгә, ә баскын әмир аларның башларын чаптырып үтертә. (Карабәк качырган улларының берсе – Галимбәк соңрак Казан каласының әмиренә әверелә, анысын 1438 елда Олуг Мөхәммәд хан юк итә.)

**Илфак Ибраһимов:**

*– «Карабәк» романы моңарчы тарихи шәхесләр булып торган ике каһарманны яңача тасвирлый, яңача бәяли. Без өйрәнгән тарих дәреслекләрендә Куликово кырында хурлыклы рәвештә җиңелгән Мамай мирза романда чын-чынлап милли каһарман буларак сурәтләнә, ә дастаннарда дан җырланган Идегәй мирза хыянәтче итеп күрсәтелә. Гәрчә Р.Фәхреддин дә Идегәйне мөртәт дип атый. Вахит Имамов бу яңа бәяләмәсе белән тарихи әдәбиятка, чыннан да, яңалык алып килә бит. Тарихчылар әлеге яңалыкны кабул итәме? Әйдәгез, әүвәл әдипнең дәлилләрен тыңлыйк та аннан үз фикерләребезне җиткерербез.*

**Вахит Имамов:**

– Шушы чорның канлы тарихын күздән кичергәндә, Мамай яки Идегәй морзаларны да урап үтеп булмый. Мамай – 1367 елда Карабәк-Габдулланы тәхеттән куып төшергән, ә 1380 елда инде Туктамыш ханның Сәйран каласыннан килеп утыруына да каршы чыккан аксөяк. 15 ел чамасы Сарай белән тәхет тирәсен бертуктаусыз бутап яшәсә дә, Мамай морза – чит илләрдән дошман чакырып китергән һәм Урданың бөтенлегенә зыян-зәүрәт салган сатлык түгел. Ул пырдымсыз һәм гаярь, үзе туктаусыз алыштыра торган ханнарны үз кубызына биетергә, хәтта Сарайга агылучы ясакның бер өлешен талап баруга да күнеккән. Мәскәү каласында утырган яшь Дмитрий кенәз хан казнасына тиешле ясакның бер өлешен китермәгәч, өстәвенә Тверь белән Суздаль кенәзләре дә Мәскәүдәге Дмитрийны чакырып торгач, Мамай морза аны акылга утыртырга карар кыла һәм аның өстенә юнәлә. Тарихка Куликово сугышы буларак кергән яу 1380 елның сентябрь аенда булып уза. Рус тарихчылары аны, күкләргә чөеп, «Алтын Урда игосын алып ташлау», дип лаф орса да, ул дәүләткүләм игътибарга алырдай яки рус иленең язмышын хәл итәрдәй җитди яу да түгел. Инде гел, бәлки, булгандыр да, дигән күзлектән караганда да, анда берничә рус кенәзе генә берләштерелгән гаскәр җыюга ирешкән, шул ук вакытта Суздальдагы Константин белән Тверьдагы Михаил Мәскәү кенәзе Дмитрийны яклаудан баш тарткан һәм Мамай морза белән кушылырга вәгъдә биргән. Мамай морза алып килгән төмәннәр дә һичничек тә Алтын Урда гаскәре булып исәпләнә алмый. Алар – Урданың фәкать бер өлеше, Кырым ярымутравыннан килгән сыңар олыс гаскәре генә. XIX гасырда гына Донской кушаматы тагып күккә чөелгән Дмитрий кенәз анда һичбер төрле җиңүгә ирешмәгән. Үзенең кенәз киемнәрен һәм әләмен яллы бояр Бренкка биреп, Дмитрий хәтта яу кырыннан качкан, аны соңыннан, кич белән, урман эчендәге агач төбеннән эзләп тапканнар. Мамай морза исә алдан ук вәгъдәләшкән Литва кенәзе Ягайло белән Тверь кенәзе Михаилның ант бозуын һәм килмәячәген, ә Дмитрийның исә качуын аңлагач, сугышчыларын әрәм итмәү максатыннан, төмәннәрен алып, яу ахырын да көтмичә кайтып киткән. Дмитрий кенәзнең нинди дәрәҗәдәге сәргаскәр булуына тагын бер өстәмә: Алтын Урда хакиме Туктамыш хан 1382 елда нибары дүрт төмән гаскәр белән якыная башлауга ук, «данлыклы» Дмитрий кенәз, Мәскәү каласын һәм андагы көмәнле хатынын ташлап, Костромага качкан. Урда яугирләре биш көн буена Мәскәү урамнарында тантана иткән... Аңлашыладыр: рус тарихчылары тәкрарлаган уйдырма белән асыл вакыйгалар – җир белән күк арасы...

Идегәй морза тарихына килеп төртелсәк тә, шулай. Әллә үз кавеме – мангыт шагыйрьләре, әллә Алтын Урда дәүләтенең бөеклеген инкяр иткән төркемнең максаты нигезендә туган дастан буенча, Идегәй морза бүгенге көнгә чаклы халык хәтерендә уңай герой саналып йөри. Ә югыйсә ләгънәт белән телгә алудан башкага

лаек булмас, татар тарихында кабахәт Шаһгалидән дә яманрак сатлыкҗан ул. Татар халкының асыл тарихы тартып алынган һәм кырык йозаклы мәгарәләр эченә кертеп яшерелгән. Шуңа күрә Аксак Тимер яуларын да тирән белмибез бит. Идегәйнең әтисе Балтыкчы үзенә буйсынучы мангыт кабиләсеннән гаскәр бирүдән баш тарткан өчен, Туктамыш хан әлеге бинең башын чабып өзә. Рәнҗетелгән Идегәй Аксак Тимер канаты астына качып китә дә, Сәмәрканд әмирен Алтын Урда дәүләте өстенә алып килә. 1391 елда Болгар олысындагы Кондырча, 1395 елда Кавказдагы Терек елгасы буенда ике зур яу була (аларны ике яктан да 95шәр мең сугышчы бәрелешкән Бородино явы белән янәшә куймалы да түгел). Ике яуның да һәркайсында ике яктан да 200әр мең җайдак катнаша, һәр яуда ике яктан да 100әр мең ир-егет һәлак була. Ягъни, шушы ике бәрелештә генә дә мөселман дөньясы 400 мең ирен югалта! (Бородино сугышында французлар – 35, руслар ягыннан 55 мең кеше һәлак була.) Әле аннан соң да яулар дәвам итә, Болгар олысында узган бәрелешләр һәм Карабәк-Габдулланың һәлакәте турында алда әйтеп үттем. Тагын да өстәсәм, Аксак Тимернең фәкать берүзе өчен Болгар җиреннән биш мең яшь егет белән кызны әсирлеккә алып китәләр. Димәк, Аксак Тимер яулары вакытында мөселман дөньясы ким дигәндә ярты миллион улын югалткан. (Әле 1402 елда Аксак Тимер белән төрек солтаны Баязит Елдырым белән буласы яу да бар, анда да йөз меңләгән корбан.) Аксак Тимер сәрбазлары Алтын Урда җиреннән яртышар миллион санынча ат, сыер-үгез һәм сарык алып киткән. Тол калган хатыннарны, ятим сабыйларны санап бетергесез. Бу афәтнең чишмә башында сатлык Идегәй морза тора. Ни галәмәт, кайсыдыр мөтәгалим тәкъдиме буенча, шушы сатлыкҗан морзаны Болгар җирендә кичә генә калыккан аллеядагы ханнар арасына да илтеп бастырганнар. Минем «Карабәк» соңгарак калгандыр инде, ләкин мәшһүр Риза Фәхреддин әсәрләрен дә укып карамаганнар. Ә газиз мөфтиебез бер гасыр элек үк Идегәй турында «татар дәүләтенә Аксак Тимердән кала икенче булып зыян китергән явыз мөртәт», дип бәя биргән инде!..

**Дамир Исхаков:**

– Идегәйне тискәре шәхес буларак тасвирлауга мин каршы. Аны бит сәяси контексттан чыгып карарга кирәк. Идегәй хәрәкәт иткән вакытта, инде Алтын Урда таркала башлый һәм анда үзара көрәш башлана. Һәрбер бөек, кулында көч булган әмир тәхеткә үз ханын утыртырга тырыша. Чөнки шуның тирәсендә соңыннан туплана һәм шуның тирәсендә яши ул. Ә бит бу вакытта хансыз гына идарә итү мөмкинлеге әле тумаган була. Соңрак килеп чыга ул, мәсәлән, мангыт бәкләре Урта Азиядә үзләре дә хан була башлый. Әмма бу вакытта ханны тәхеткә утыртмыйча идарә итү мөмкинлеге булмый. Таркалып барган дәүләттә үзара сугышта катнашкан кешеләрне бүгенге күзлектән ничек тискәре шәхес булган дип әйтәсең?! Алар хакимлек өчен үзара көрәшкән. Билгеле, ул бүгенге күзлектән начар күренәдер. Ләкин ул вакыт өчен бу – бердәнбер мөмкин булган сәясәт. Шуңа күрә Идегәй бу вакыйгаларда катнашкан, алай гына да түгел, берникадәр вакыт дәүләтнең бердәмлеген саклап тотып та тора алган. Аның заманында бераз бердәм булып торганбыз. Билгеле, андый сугышлар вакытында зыянсыз булмый. Алар бер-берсен тар-мар иткән. Соңрак булган вакыйгалар күзлегеннән, ул, бәлки, тискәре күренештер. Ләкин анда бүтән вариант булмаган, шул гына. Хакимият ихтыяры шулай корылган анда. Бәкләр ханны тәхеткә утырткан һәм алар шул мөмкинлек өчен көрәшкән. Тарихтагы вакыйгаларга бүгенге күзлектән бәя бирү ул – бик үк дөрес түгел. Шул вакыттагы сәясәттән чыгып карарга кирәк. Ул сәясәт ничек корылган, аның механизмнары нинди? Ә без теге чорга үзебезнең бүгенге бәяне кертәбез.

Идегәйнең Аксак Тимерне алып килүенең бит шулай ук мантыйгы бар. Идегәйнең бабасының борынгы биләмәләре – Урта Азиягә бик якын җирләр. Ягъни аларның реаль мөнәсәбәтләре Урта Азиядәге башка биләмәләр белән булган. Шуңа күрә фикерләре күпмедер вакыт туры килгән. Әгәр, мәсәлән, Идегәй Дон буенда яшәсә, ул, бәлки, башка сәясәт алып барыр иде. Ә Урта Азия эчендә бүтән таяныч юк бит. Нинди мөмкинлек бар, шуннан файдаланганнар. Ул, гомумән, феодаль чор өчен

феодалларның үзара сугышлары – гадәти күренеш. Урыслар да үзара шулай ук сугышкан.

**Илдус Заһидуллин:**

– Романда сурәтләнгән вакыйгалар дәүләтнең таркалуга йөз тоткан көчсезләнү вакытын колачлый. Кризиска алып баручы факторлар көчәйгәндә, җәмгыять тормышында тискәре күренешләр өстенлек ала, әсәрдә дә бу тенденция ачык чагыла.

Илдәге торгынлык хан сараендагы атмосферага турыдан-туры бәйле була. Бөек Монгол дәүләтендә дә, аның дәвамчысы Алтын Урдада да тәхеткә утырту турында махсус канун булмаган. Әйтик, Чыңгыз хан үлгәч, тәхеткә, килешү буенча, аның өченче улы Үдегәй утыра. Алтын Урда ханнарының гаилә тормышы полигамия, күп хатынлылыкка нигезләнгән. Бу тәртип ислам динен кабул иткәнче үк күзәтелә. Нәтиҗәдә, тәхеткә дәгъва кылучылар саны бик күп була.

Алтын Урданы куәтле дәүләт итеп таныткан Үзбәк ханнан (1312-1342) соң озак та үтми, 1360 елга Җучи ханның улы Бату нәселеннән тәхеткә утыручы варислар бетә. Сәбәбе – ханнарның тәхеткә көндәшен юк итеп утырулары яки, тәхеткә ия булгач, ир-туганнарын үтертүе... Бату хан варислары калмагач, Алтын Урда тәхетенә дәгъва итүчеләрнең географиясе киңәя. Алтын Урда бит ике сәяси һәм хәрби пландагы өлештән – «канаттан» торган. Ак Урда (уң, Көнбатыш «канат») белән Бату идарә итә, Күк Урда (сул, Көнчыгыш «канат») белән идарә итүне ул үзенә буйсынган абыйсы Урда Иҗәнгә тапшыра. 1460 елдан соң бушап калган тәхет өчен көрәшкә Күк Урдадан нәсел варислары кушыла, аларга Ак Урдадагы җирле элита вәкилләре белән, монда калыплашкан иҗтимагый тәртипләр белән исәпләшергә, яраклашырга да кирәк була. Икенче төрле әйткәндә, сәяси тормышта кланнар мөһим роль уйный башлый. Нәтиҗәдә, шушы егерме елдан артык дәвам иткән «болганчык» вакыт аралыгында тәхеттә ике дистәдән артык хан утыра. Илдәүләттә сәяси тотрыклылык бетә.

Туктамыш хан, Алтын Урда тәхетендә тулы хокуклы хуҗа буларак, бәкләр бәге Мамайны җиңеп, дәүләтне берләштерүгә, үзәкләштерүгә ирешә. Аның тышкы сәясәте дә дәүләт мәнфәгатьләренә буйсындырылган була.

Алтын Урдада күчмәннәр яшәгән олыслар белән турыдан-туры идарә итү һәм армия белән җитәкчелек бәкләр бәге кулында булган. Бу җаваплы кәнәфине көчле һәм талантлы шәхесләр биләгән. Дәүләт башлыгы итеп фәкать Җучи нәселе вәкилен генә тану тәртибе бәкләр бәкләрен хан итеп үзләренә буйсынган шәхесләрне билгеләүгә этәргән. Мондый гамәлләрне башка олыс җитәкчеләре танырга теләмәгән. Мамай, Идегәй кебек бәкләр бәкләре ил өстеннән хакимлек урнаштырырга теләсәләр, икенчеләре үз олысларында хуҗа булуны алга сөргән.

Роман якын киләчәктә аерым китап булып басылып чыгар дип көтәбез. Шушы уңайдан кереш рәвешендә авторның яки берәр тарихчының Алтын Урда хакимияте антропологиясе турындагы зур булмаган язмасы урнаштырылса, яхшы булыр иде. Бу язма әсәрдә сурәтләгән вакыйгаларның мәгънәсен тирәнрәк аңларга ярдәм итәр дип уйлыйм. Мондый язма романда җитенкерәмәгән тарихи даталар мәсьәләсен дә хәл итә алыр иде кебек.

Мамай мирза – законсыз рәвештә хакимиятне үзләштергән бәкләр бәге. Идегәй исә, Аксак Тимерне чакырып, дәүләтне харап иткән шәхес. Аның кабат илне берләштерү омтылышы Алтын Урданың элекке гайрәтен кире кайтара алмау мәгълүм булган шартларда, таркалу алдыннан бер көчәнү кебек кабул ителә. Әлбәттә, әлеге тарихи шәхесләргә, аларның гамәлләренә бәя бирү катлаулы, ул бәяләр һич кенә дә бертөрле була алмый.

**Фаяз Хуҗин:**

– Бу очракта мин күбрәк «Карабәк» авторы яклы. Соңгы елларда Идегәйне бик нык күтәрдек. Чынлап торып карасаң, аларның бөтенесе бер иш инде – тәхеткә утырып, үз мәнфәгатьләрен кайгыртучылар. Әлбәттә, тәхеткә утыргач, илең турында да уйларга мәҗбүрсең. Патшаларны идеаллаштыру ягында түгел мин. Әкиятләрдә генә була андый патшалар.

**Җәмил Мөхәммәтшин:**

– Игътибар итик: Куликово кырында җиңүче дә, җиңелүче дә булмый. Русьның мөстәкыйльлек алуына әле йөз ел бар. Мамай, Кырым олысы гаскәрен җитәкләп, руслар белән көрәшә. Безгә ошыймы, ошамыймы, ул вакытта татар гаскәрен оештырып, әйдәп баручы бүтән хан да, әмир дә булмый. Мамай – урысларның риваятьләренә, мәкаль-әйтемнәренә кергән шәхес. Аннан соң ул – Бирдебәк хан кияве. Шул елларда икенче Бирдебәк тарафыннан акча да сугыла. Тарихта бу фактка аңлатма юк. Биредә дә ханнарны алыштырып торган Мамайның кулы уйнамады микән?! Шуның өчен дә романда аңа зур урын бирелгән.

Идегәйгә килсәк, татарны Идегәй әмир шәхесе түгел, ә «Идегәй» дастаны күбрәк кызыксындырды. Дастанны тарихи чыганак буларак өйрәнү, андагы шәхесләрне чынбарлыкка туры киләме, дип тикшерү юк дәрәҗәсендә. Бәлки, киләчәктә дастан герое белән чын Идегәй арасында аерма зур икәне ачыкланыр.

Бу олы шәхесләрнең тарихи роле турында сүз барганда, XIV йөзгә хас чынбарлыкны истә тотарга кирәк – халыкны үз артыңнан ияртү, таркалып барган дәүләтне берләштерү өчен, Чыңгыз нәселеннән булу шарт. Мамай, Идегәй булдыра алмаган эшне Туктамыш хан башкарды. Уралдан башлап Днестрга кадәр булган бөтен татар җирләре унбиш елга булса да бер хан кулы астында берләште.

**Илфак Ибраһимов:**

*– «Карабәк» романында үзебезнең Идел-Чулман төбәгендә яшәүчеләрнең тормышы шактый тыгыз яктыртылган. Биредәге таулар, елгалар, кала-салаларның атамалары да, каһарманнарның шәҗәрәләренә кадәр «ачып бирү» дә бар. Болар, әлбәттә, әдипнең җитди эзләнүләре нәтиҗәсе бит. Монда гөманлау, фаразлау гына була алмыйдыр.*

**Фаяз Хуҗин:**

– Вахит Имамов – үзе яза торган чорның тарихын тирәннән өйрәнгән әдип. Мин моны аның әсәрләрен даими укып баручы кеше буларак ышанып әйтәм. Әдәби әсәр язу – фәнни хезмәт язу түгел, әлбәттә. Әмма барыбер тарихи романдагы вакыйгалар һәм аларны тудыручы шәхесләр күпсанлы һәм төрле характердагы чыганакларда, шул исәптән архив документларында сакланып калган фактларга нигезләнеп тасвирланган бит. Кызганыч, барлык фактлар да елъязмаларга теркәлеп калмаган, бу очракта инде аларны аңлатканда, фаразлау ысулын да кулланмыйча булмый. Аңлашыла ки, язучылар әлеге ысулны тарихчы-галимнәргә караганда күбрәк файдалана.

**Җәмил Мөхәммәтшин:**

– Идел-Урал җирләре – борынгы болгарлар яшәгән төбәк. Тарихта билгеле булган болгар исеме астында берләшеп, дистәләгән кавем-кабиләләр яшәгән. Аларның үз телләре яисә гомумтөрки телнең аерым диалектлары булуы билгеле. Мәсәлән, Мәхмүд Кашгарый сувар кешеләре телен искә ала. Романда барган вакыйгаларга, ягъни XIV йөз ахырына кадәр болгарлар теленә карахани татарлары, кыпчак телләренең тәэсире зур була, һәм бер татар теле формалаша. Бу процесс болгар кабер ташларында чагылыш таба. XIV йөзнең беренче яртысында ташъязмаларда тел аерымлыгы – «р», «җ» (җүр) һәм «з», «й» (йөз) – ярылып ятса, XIV йөзнең икенче яртысында «з», «й» (йөз) теле генә кала. Ләкин «җ»ләштерү татар телендә сакланган. Романда сәед Низами картның «җ»ләштереп сөйләшүен, мишәрләргә хас «канә» сүзләрен куллануны авторның уңышлы бер алымы дип санарга кирәк.

Романдагы вакыйгалар XIV йөзнең ахырына караганга, исемнәрдә һәм атамаларда ташлардагы болгар исемнәре чагылмый. XIII-XIV йөз ташларында төрки-татар исемнәре Болгар олысының көньяк (Тат. Калмаюр, Ульян өлкәсе) һәм көнчыгыш (Азнакай) өлешендә киң таралган була. Кала, тау, елга атамаларына килгәндә, татар чыганаклары юк диярлек. Кабер ташларында Болгар, Сувар, Биләр, Чирмешән исемнәрен атап китәргә була. XVII-XVIII гасырлардагы рус чыганакларына таянып, без XIII-XIV йөзләрдә дә алар шундый ук исемдә булган, дип кабул итәбез. Чыннан да, бүгенге авыл атамаларының күбесе шул чорда яшәгән яисә авылга нигез салган кеше исеме белән бәйләнгән.

**Илфак Ибраһимов:**

*– Әйдәгез, романның әдәбилегенә дә тукталыйк әле. Миңа калса, Вахит Имамов фольклорчы буларак та ачыла кебек. Халыкчан тел, мәкаль-әйтемнәр, риваятьләр күп кулланыла. Романдагы вакыйгалар тыгызлыгы берничә романга җитәрлек түгелме?*

**Илдус Заһидуллин:**

– Романда автор Алтын Урда дәүләте күләмендәге вакыйгаларны «өченче зат» исеменнән тасвирласа, Болгар олысы турында Карабәк исеменнән дә сөйли. Романда Карабәк дәүләтнең бердәмлеге, көчәюе өчен көрәшүче каһарман буларак тасвирлана. Карабәк – татар историографиясендә билгеле тарихи шәхес. Ягъни роман татар чыганаклары нигезендә язылган. Бигрәк тә Марсель абый Әхмәтҗанов тырышлыгы белән, Карабәк һәм аның дәвамчыларының шәҗәрәләре күпләп фәнни әйләнешкә кертелде. Авторның Болгар олысы шәхесләренә бәйле сюжеты шушы мәгълүматларга нигезләнгән.

**Фаяз Хуҗин:**

– Романның сәнгатьчә эшләнеше тел-теш тидерерлек түгел, дип саныйм мин. Әйе, халык мәкальләре, әйтемнәр, риваять-легендалар да күп һәм бик урынлы кулланылган биредә. Әмма «мәгарәдәй сузылган тынлык», «келәм кебек йомшак, нәфис су һәм аның хәтфә суыклыгы», «чыбыркысын шартлатып, малларын кузгаткан көтүченеке төсле яңа фәрман», «түшенә салган чәч толымнарының кар астыннан типкән чишмәләрдәй уянып сулкылдавы» кебек чагыштыруларны уңышлы дип әйтмәс идем. Тагын бер нәрсә. Вахит Имамов яшь кызлар турында сүз кузгатуга, аларның бөтен матурлыгын, нәфислеген укучыда эротик хисләр уятырлык дәрәҗәдә җентекләп тасвирларга ярата. Кайчакта хәтта, артык мавыгып, әйтеләсе төп фикерен дә онытып җибәрә. Начар, димим, әлбәттә, ә менә кайсы яшьтән башлап укырга рөхсәт итәрләр икән бу романны? Болай да тар укучылар даирәсен тагын да тарайтмасмы әлеге эротик күренешләр, дип кенә шикләнүем.

**Җәмил Мөхәммәтшин:**

– Тарихи роман ул – әкият түгел. Шул чорның атмосферасын, вазгыятен чагылдыру өчен, үткән тарихны аңлау сәләте булган автордан зур осталык таләп ителә. Осталык белән бергә үткән тарихны чагылдыру алымнары, төрле чаралар белән вакыйгаларны ачып бирү дә сорала. Кайбер вакыйгалар, исем-атамалар, тарихи урыннар таныш икән, ул укучыда кызыксыну уята. Романдагы Болгар һәйкәлләре, Ага-Базар, Чатыр тау, Татарстанның елга, авыл исемнәре – шундыйлардан. Халык хәтерендә сакланган риваятьләр дә шулар исәбеннән. Күмәк тормышның нәрсә икәнен белмәгән, туган нигезеннән аерылып, шәһәрләшкән халыкка романны аңлау, вакыйгаларның эзенә төшү өчен, бу бер нигез булып тора.

Автор туган якның табигатен, елга-күлләрен, дала-тауларын гаҗәеп үз итеп, зур осталык белән тасвирлый. Дала белән урман очрашкан җиргә Аллаһы Тәгалә байлыкны мулдан биргән. Чиста сулы елгалары, балыклы күлләре, куе үләнле көтүлекләре һәм мул уңыш бирүче сөрү җирләре – яшәү өчен бөтен шартлар бар. Бу җирләрне яратмый, аңа мәдхия җырламый мөмкин түгел.

Туктамыш ханның җиңелүе Алтын Урданың тәмам таркалуына кереш булды. Шадибәк һәм аннан соңгы ханнар әле утыз еллар дәвамында Урданың төрле шәһәрләрендә, шул исәптән Болгарда, акча сукса да, Урданың утрак тормышлы үзәкләре Болгар, Кырым, Сарай, Хәрәзем, Хаҗитархан арасындагы тыгыз бәйләнешләр өзелә. Һәр өлкә үзен мөстәкыйль итеп тоя башлый һәм, күп тә үтми, яңа дәүләтләр – Казан, Әстерхан, Кырым ханлыклары, Нугай урдасы барлыкка килә. Бу – гаҗәеп катлаулы һәм тулысынча өйрәнелмәгән вакыйга. Мин романның дәвамында татарның яңа мәркәзе Казанның үсеп китүен, аның татарларның башкаласына әйләнүен чагылдырыр идем. Ә атаклы шәхеслэрдән романнар язылырга лаеклы, Казан, Мәскәү, Кырым тарихына да ят булмаган Нурсолтанны атар идем.

**Камил Кәримов:**



– Тарихи әсәрләр – бүгенге татар әдәбиятының алтын фонды. Алтын искерми – бәясе генә арта, язучы картаймый – тәҗрибәсе генә арта.


Вахит Имамовның яңа романы конкрет адреслы. «Ерак бабам бөек Карабәк рухына багышлыйм», дигән эпиграфтан соң, ирексездән, Габдулла ханның холкында, кылган гамәлләрендә, сөйләмендә роман авторының үз чалымнарын эзли башлыйсың. Бихисап авылларның һәм географик атамаларның морзалар, бәкләр, яугирләр исеме белән тарихка кереп калуы Идел-Чулман-Агыйдел буйларындагы халыкның Карабәк кавеменнән яралганлыгына ышандыра башлый. Димәк, Актаныш төбәге әле бүген дә бу шәҗәрәнең дәвамы дигән сүз. Автор, вакыйгаларны эзлекле рәвештә һәм шагыйранә сурәтләп, үз максатына ирешә дә. Ә без, Казаннан кырык чакрымда бүленеп калган, чукындырылып бетмәгән сала сабыйларына, ханнар төбәгенә карап, тел шартлатырга гына кала.

Туктамыш белән Карабәк Аксак Тимергә каршы тора алмыйлар һәм... биш мең сылуны кол итеп биреп җибәрәләр...

Быел җәй, «ТЮРКСОЙ» чакыруы буенча, төрки илләрнең Казакъстанда үткәрелгән китап күргәзмәсендә катнаштым. Төркестан, Чемкент (Шымкент) калаларында сәяхәттә йөргәндә, шунысына да игътибар иттем: чүлдән җәннәт бакчасына әверелгән бу төбәкләрдә ханәкәдәй сылулар бихисап иде. Һәм алар, казакъча, русча, үзбәкчә сөйләшсә дә – барысы да Актаныш кызларына охшаган кебек иде.

Башка романнарыннан аермалы буларак, «Карабәк»нең күләме зур түгел. Беләбез, дөнья тарихы – ул яулап алулар тарихыннан гыйбарәт. Ләкин автор бу юлысы сугыш-орышларны кыска тота: аның чапкыннары бүгенге поездлар ике-өч тәүлек үтәрдәй Хива-Үргәнеч-Кырым-Болгар арасына «эһ!» дигәнче барып килә; унике яшьлек кызларның ханнар куенына керүләре дә «чия төшен» «пәп итү» кебек кенә бик тиз сурәтләнә; туры сөйләмнәр, озын-озак вәгазьләрдән арынып, мәкаль һәм афоризмнар белән алышына... Нәтиҗәдә, болар барысы да әсәрнең сәнгатьчә кыскалыгына китерә. Кыскалыкта – осталык, дияр укучы!..

**Рамил Ханнанов:**



– Мин әсәрне ике катламнан тора, дип саныйм: укучыны тарих белән мәҗбүри рәвештә таныштыру, ягъни фәнни-мәгълүмати катлам һәм әдәби-нәфис, укучы җиңел кабул итә торган, шул ук вакытта бераз әкияти-фантастик катлам. Беренчесе кабул итү өчен бик катлаулы. Даталар, вакыйгалар хроникасы, исемнәр, тарихи фактлар артыгы белән мул бирелгән. Романның бишенче бүлегеннән генә әсәргә керә башлыйсың. Тәүге бүлекләрдә абзац саен дистәләгән кешене башын чабып, чәнчеп, кадап, агулап һ.б. үлем төрләре белән бакыйлыкка озату «матур әдәбият» төшенчәсенә хилафлык китерә, ата-бабаларыбызны вәхшиләр, ерткычлар дәрәҗәсендә ямьсезли.

Икенче катлам исә бик җиңел укыла. Хисси бер ләззәт белән шул ханнарга, бәкләргә «ияреп йөрисең», далалар буйлап Болгар дәүләтен төзешергә «барасың», сугышларында, кылыч тотып, яугирләрчә «орышасың», дәүләткүләм мәсьәләләр хәл кылынганда, үзеңчә «киңәш бирәсең». Укырга рәхәт, күңелне ризалык хисе били. Бу инде әсәрнең әдәби кыйммәте турында сөйли.

Укучы буларак, сагайткан берничә урынга тукталасым килә. Без укып үскән Нурихан Фәттах, Мөсәгыйт Хәбибуллин әсәрләреннән аермалы буларак, «Карабәк» романының теле заманча. Геройлар миңа үзебезчәрәк сөйләшә кебек тоелды. Әсәрнең, тарихи роман буларак, лексикасы эшләнеп бетмәгән, дияр идем.

Ундүртенче бүлек шулай ук күңелдә ризасызлык уята. Карабәкнең (хан бит!) берничә малай-шалай белән зур юлга чыгуы, Актаныш якларындагы барлык

авылларның бүгенге атамаларын санап соклануы, бер авылга килеп керүгә, очраган татар (ул заманда татар булдык микән әле без?!) кызы, печән чабулары, кибәннән егылып төшүләре, бернинди сакчыларсыз кырда йоклап ятуы, очраган бер кызга өйләнеп йөрүләре, Карабәк белән янәшәсендәгеләрнең сөйләшү стиле мине, гомумән, ышандырмады. Бу бүлек романны тарката, камиллегенә зур зыян китерә, дип саныйм. Китап итеп чыгарганда, аны йә төшереп калдырырга, йә үзгәртергә кирәк.

**Илфак Ибраһимов:**

*– «Алтын Урда» дәүләте... Бу темага күпләр алынып карады: Александр Сегеньның «Тамерлан»ы, Анатолий Егинның «Үзбәк хан» романнары. Евразия киңлекләрендәге дәүләттә безнең борынгы бабаларыбыз көн иткән. Хәзерге Европа киңлегендә, Рәсәй дәүләтендә дә безнең кардәшләребез яши. Бу халыкларның язмышын ни көтә? Халыкларны берләштерү зарурмы бүген?*

**Илдус Заһидуллин:**

– Киләчәктә дөнья картасында зур төркем кешеләр ресурсларына ия булган дәүләтләр һәм дәүләт берләшмәләре генә калачак, дигән теория бар. Бу исемлеккә, беренче чиратта, Кытай һәм Һиндстанны кертәләр. Безнең илебез дә, Россия империясе һәм СССР мирасын файдаланып, элекке союздаш республикалар, бүген мөстәкыйль дәүләтләр булган төрки мәмләкәтләр белән икътисади элемтәләрен ныгыта. Киләчәктә бу өлкәдәге хезмәттәшлектә төрки халыкларның уртак дәүләте булган Алтын Урда мирасы нинди роль уйнар, моны әйтүе кыен. Чөнки бүген Русия белән мондый хезмәттәшлек мәдәни һәм цивилизацион яктан тәңгәл килми, бер үк вакытта төрки халыклар үзара бәйләнешләрен көчәйтергә тиеш, дигән фикерләр дә ишетелә.

**Фаяз Хуҗин:**

– Алтын Урда күпмилләтле дәүләт булган, яшәү гомеренең озынлыгы 200 елдан артык. Шул вакыт эчендә яңа халыклар формалашкан (мәсәлән, нугайлар, кырым татарлары), булганнары исә юкка чыкмаган, исемнәрен алыштырып булса да яшәүләрен дәвам иткән (кыпчаклар, болгар-татарлар). Алтын Урда цивилизациясе – борынгы тарихыбызның олы бер чоры. Ул тарихны әле тагын да тирәнрәк итеп өйрәнәсе бар. Әмма шул чор белән артык мавыкмыйча гына. Халкыбызның тарихы күптамырлы – шуны онытмаска кирәк. Милләтебезнең киләчәген булдыруда тарихи хәтер зур урын алып тора. Вахит Имамов, үзенең элгәреге һәм бүгенге каләмдәшләре кебек, шул хәтерне саклауга зур өлеш кертә.

**Җәмил Мөхәммәтшин:**

– Бер дәүләт тә, кешеләр кебек үк, мәңгелек түгел – туалар, үсәләр һәм дә бакыйлыкка күчәләр – Алтын Урда, Советлар Союзы. Русиянең дә таркалуын көтеп ятучылар аз түгел. Евразия киңлегендә, Кырымда, Себердә булсын, Идел буйларында татарлар үз җирләрендә яши. Бу җирләрдә алар килмешәк түгел. Һәр урында татар мохитен саклау мөмкин дә түгелдер. Дәүләт тарафыннан татар кешесенә үз җирлегендә туган телен, динен, гореф-гадәтләрен саклау өчен шартлар тудырылса, халыкның киләчәге өметле. Һәрнәрсәнең үз вакыты бар. Бу мәсьәләдә татарларны берләштерәбез, дип ашыгырга да ярамый. Мамай, Туктамыш, Идегәй язмышларын истә тотыйк.

**Илфак Ибраһимов:**

*– Тарих – кизәк, кагылдисаң, исе чыга, – дип язган иде бер шагыйребез. Тупасрак, әлбәттә. Безгә үткәннәрдә «чокынмаска» тәкъдим итүчеләр дә бар. Әмма үткән белән киләчәк арасында «бүген» бар. Бүген – ул хәтер. Халык хәтере... Тарихи хәтер... Хәтерен җуйганнарны «манкорт», диләрме?*

**Җәмил Мөхәммәтшин:**

– Үз тарихын белмәгән милләтнең киләчәге юк. Бер-бер хәл чыкмагае, дип тарих битләрен актарудан туктарга ярамый. Яңадан-яңа чыганаклар ачыла, археологлар

тарафыннан яңа әйберләр казып чыгарыла. Шулар арасыннан берсен генә әйтеп узыйм. Апас районы Каратун авылында Көнчыгыш Ауропада иң зурларыннан булган, 25 мең көмеш акчадан торган, 32 килограммлы хәзинә табыла. Ул – Туктамыш хан казнасы. Тимур Болгарны алгач, Туктамыш ханга куркыныч яный һәм ул, казнасын ташлап, Идел аша чыгып, Себер ягына китәргә мәҗбүр була. Шуңа өстәп үтим, Тәтеш янында XIX йөздә һәм 1950 елларда шул ук чорга караган 10-15 мең акчадан торган өч хәзинә табыла. Димәк, тарихи риваятьләрдә һәм романда сурәтләнгән вакыйгаларның төпле нигезе бар.

**Дамир Исхаков:**

– Төрле сөйләшүләр булды. Бер нәрсәгә игътибар итәргә кирәк, минемчә. Телисезме-юкмы, Алтын Урда ул – татарның төп дәүләте. Хәзер аның мирасына дәгъва итүчеләр күбәя бара. Сез, бәлки, игътибар итмисездер. Безгә иң куәтле көндәш Казакъстан булачак. Казакъларның нигезләре – фәкать казакълар составына кергән Нугай Урдасының бер өлешендәге халкы һәм, тарихи сәбәпләр аркасында, аларның биләмәсе составына кереп киткән Алтын Урданың калдыклары.

Монда чыгыш ясаучыларның сүзләреннән дә күренә, Болгарга ябышып яту һәм Кырым татарлары баштан ук аерым халык булып формалашкан икән, дигән сүзләр – болар барысы да ялгыш фикерләр. Андый юл белән без бердәм уртак татар дөньясын булдыра алмыйбыз. Ә чынлыкта бердәм уртак татар дөньясы бар. Шуңа күрә сөйләшүләр алып барганда, үзебезнең милли, героик шәхесләрне дөрес күрсәтергә кирәк. Шул исәптән, милли мәнфәгатьләрне истә тоту шарт. Бездә төрле шәхесләргә карата тискәре карашлар булырга мөмкин. Мәсәлән, Казан ханлыгына килеп, аны җимереп киткән шәхес, дип, Шаһгали турында тискәре караш әйтелә. Әмма берәү дә Шаһгалинең Олы Урданың ханы булуын уйламый. Ул бит чынлыкта, шул Олы Урда юкка чыгар алдыннан, йортсыз калган һәм Казан аркылы булса да Олы Урданың нәселен торгыза алырмын, дип өмет иткән. Шуңа күрә ул монда русларга ышанып килгән бит, миңа Казан ханлыгын алып бирерләр, дип уйлаган. Бу, билгеле, наив караш. Шаһгали турында Катанов тарафыннан тәрҗемә итеп бастырылган мәкалә бар. Төп нөсхәсе сакланмаган, рус телендә ул. Шаһгали, үләр алдыннан, елап утыра һәм: «Балаларыма калдырырга йортым юк, русларга юкка ышанганмын икән», – дип әйтә. Шундый трагик шәхесләр булуын онытмыйк. Әлеге мәсьәләдә үзебезнең милли мәнфәгатьләрдән чыгып та эш йөртергә кирәк.

**Илфак Ибраһимов:**

*– Изге урын буш тормас, дигән әйтем ни дәрәҗәдә әдәби иҗатчыларга кагыладыр, әйтүе кыен. Әмма хак тарихыбызны язарга алынган Ш.Мәрҗанидән алып, Н.Фәттах, М.Хәбибуллин, Р.Батулланың эшен лаеклы дәвам итүче Ф.Бәйрәмова, В.Имамов кебек әдипләребезнең менә бүген армый-талмый иҗат белән шөгыльләнүләренә сокланабыз... Зур рәхмәт аларга һәм, әлбәттә, Вахит каләмдәшебез, Сиңа!*


*Алдагы «түгәрәк өстәл»ебез Фәүзия Бәйрәмованың «Һиҗрәт» романы буенча булыр. Әлбәттә, романның икенче кисәге «Казан утлары»нда басылып чыгуга.*



*Язучыларның Тукай клубында үткән чираттагы бер җыелышыннан соң. Утырганнар (сулдан уңга): Гомәр Бәширов, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Гариф Ахунов, Риза Ишморат, Рәйсә Ишморатова, Әмирхан Еники, Фәүзия Бәйрәмова, Заһид Хәбибуллин; арттагы рәтләрдә: Шаһидә Максудова, Лена Шагыйрьҗан, Җәүдәт Дарзаман, Флёра Низамова, Нәҗип Нәккаш, Роберт Миңнуллин, Солтан Шәмси, Нәбирә Гыйматдинова, Туфан Миңнуллин, Мәнирә Субаева, Эльмира Шәрифуллина, Мансур Вәлиев, Рашат Низамиев, Фәиз Зөлкарнәй, Фәннур Сафин, Асия Минһаҗева, Риф Гатауллин. 1982 ел.*



*Нефтьчеләрнең Бөтенсоюз слётында. Уңнан сулга: композитор Нәҗип Җиһанов, шагыйрь Мөхәммәт Садри, галим Гыйлем Камай, журналист Венера Ихсанова, шагыйрь Әдип Маликов. Әлмәт. 1962 ел.*




*Шагыйрь Фәнис Яруллин. 1980 ел.*



*Күренекле әдәбият галимнәре. Татар совет әдәбияты, шул исәптән Муса Җәлил тормышы һәм иҗаты турында җитди хезмәтләр авторы – Рафаэль Мостафин (1931-2011) һәм Роберт Бикмөхәммәтов (1929-1995). Казан. 1989 ел.*

# ХАЛКЫБЫЗ ЯШӘГӘНДӘ, СӘНГАТЬ ЯШӘР!



*Сәнгать фәннәре докторы, Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы, язучы* ***Мөхәммәтгали АРСЛАНОВ*** *белән «Казан утлары» журналының баш мөхәррире* ***Илфак ИБРАҺИМОВ*** *әңгәмәсе.*

***– Гали әфәнде, иң әүвәл үзегезнең гап-гади дә, шул ук вакытта кеп-кечкенә, әмма төш кенә булган Түмерҗә авылы, үзегезнең нәсел-нәсәбегез белән таныштырып үтсәгез иде.***

– Әңгәмәне туган авыл, туган туфрак, туган нигез темасыннан башлап китүең өчен рәхмәт. Минем өчен изге булган Түмерҗә исемен атау белән үк, күңелдә Дәрдемәнднең:

*И туган илнең һавасы,*
*Рәнҗемим, зинһар, күтәр!*
*Рәнҗемим, зинһар, күтәр!*

– дигән юллары чыңлый башлый. Түмерҗә, беренче моң-сагышлар, хыяллар, уйнап үскән чишмә буйлары, аның көмешсыман саф, чиста, салкын суы, безне нindидер биеклеккә күтәргән туган җир һавасы искә төшә. Тырыш-эшчән, самими-ихлас, шул ук вакытта акыллы-тәртипле, талантлы, җырга-моңга бай халкы сагындыра аның.

Барыннан да бигрәк, шушы җирлектә табигатьтән бирелгән мөкатдәс кан, дөньяда берни дә алыштыра алмый торган изге сөт, анам сөте газиз миңа.

Үзара сөйләшкәндә: «Минем авылым картада бар, сезнең Түмерҗә юк», – дигән сүз ычкындырганың бар. Дөрес түгел, бар ул карталарда. Хәтта XVIIIгасыр ахыры карталарында да күренә.

«Кем без, каян килгәнбез?» дигән сораулар куелса, каумебезнең Кырым, Арал диңгезе якларыннан, Алтын Урда дәүләте таркалгач, XIV гасырда күчеп килүе мәгълүм. Казан ханлыгына кермәгән безнең төбәк, Нугай Урдасы җирләрендә яшәгән Гәрәй кабиләсе вәкилләре. Ул вакыттагы административ бүленеш буенча Түмерҗә, Такталачык, Чалманарат, Түбән Гәрәй, Югары Гәрәй, Ямалы, Бурсык һ.б. авыллар Гәрәй түбәсенә караган. Ерак бабаларыбыз вотчинниклар булган. Үзләренең били торган җирләре, елга-күлләре, урманнары булган. Сулыкларын, үзләре эшкәртмәгән җирләрен арендага биреп, хуҗалык итү өчен бик кирәкле акча эшләгән алар. Нәсел-нәсәпкә килгәндә, шушы авылга нигез салган Усәин, Урәзмәт бабаларыбызның дәвамчылары без. Сүз уңаеннан әйтеп үтим, соңгы елларда нәселебезнең шәҗәрәсен төзү белән шөгыльләндем. Мәскәү, Казан, Уфа, Оренбург архивларында эшләргә туры килде. Егерменче буынга кадәр тамыр җепләрен суза алдым. Кырым якларыннан килгән алда аталган Усәин бабай нәсел агачының унынчы буыны булып тора.

Әти-әнием Гыйльмегали һәм Нәгыймә гомер буе колхозда, төрле эшләрдә эшләделәр. Җырларда җырланганча, биш бала үстек без. Иң кечесе – мин. Өчебез укып, югары белем алдык. Ничек яшәгәнне әйтеп тормыйм. Сугыштан соңгы еллар буыны булганга, болай да аңлашыла.

***– Түмерҗәне, галимнәр авылы, диләр. Мин, шәхсән, Түмерҗә авылының башлангыч мәктәбен галимнәр мәктәбе, аның укытучыларын галимнәр галиме, дияр идем. Ничәмә-ничә фән докторы, фән кандидаты чыксын әле шул мәктәптән! Алар арасында врачлар да, биологлар да, сәнгать әһелләре дә, шагыйрьләр дә бар. Бер гаиләдән берничә галим үсеп чыккан. Һәм, әлбәттә, Сез – сәнгать фәннәре докторы, Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы, күренекле театр белгече Мөхәммәтгали Гыйльмегали улы Арсланов та бар. Театрга да мәхәббәтне шул ук мәктәп уятты микән?***

– Синең сүзләр хак. Кечкенә булса да, өч фән докторы, берничә фән кандидаты биргән ул. Галимнәрнең икесе Татарстан Фәннәр академиясе әгъзасы, халыкча әйтсәк, академиклар. Балага төпле белем нигезләре башлангыч мәктәптә салына. Беренче укытучыңның кем, нинди шәхес булуы аеруча мөһим. Түмерҗә башлангыч мәктәбендә озак еллар укыткан Мөзәккирә апа Госманова белем бирү ягыннан да, тәрбия, юнәлеш бирү бабларыннан караганда да лаеклы зат иде. Күз алдына китерегез, кырык биш минут дәвамында бер класста утырган, дүрт сыйныфта укыган егермеләп балага яңа тема аңлатырга, өйгә бирелгән эшләрне тикшерергә, сорап билгеләр куярга, кабат өйдә шөгыльләнү өчен бурычлар билгеләргә. Боларның барысын да башкарып өлгерү өчен никадәр оешканлык, педагогик осталык кирәк булганын чамалап кына белеп була. Әмма балада омтылыш тәрбияләү, максатчанлык сыйфатларын булдыру иң элек гаиләдә эшләнәдер, мөгаен. Безнең әнкәй мәрхүмә: «Улым, укыган кеше кайда да югалмый, тамагы тук, өсте бөтен була. Нәрсәгәдер ирешәсең килсә – укырга кирәк!» – дип үстерде. Ач-ялангач заманда, ашарга бер кабымлык иписез утырганда, бик үтемле мотивация иде бу.

Мәктәп кешене төрле яктан тәрбияли. Шул исәптән әдәбиятка, сәнгатькә мәхәббәт ягыннан да. Күп укый идем мин. Үзебезнең авылныкын гына түгел, күрше Теләкәй, Такталачык мәктәп, авыл китапханәсе фондлары белән тулысынча танышып чыктым. Китап тәрбияләгән, укып үскән буын без. Шул ук вакытта безнең тормышта җыр-музыка, сәхнә дә зур урын алып тора иде. Авылдагы бер генә мәдәни чара да безнең катнаштан башка үтми иде. Теләкәй сигезьеллык, Такталачык урта мәктәпләрендә укыганда да шулай булды ул. Сәхнәдән шигырьләр укый, җырлый идем. Кайбер көннәрдә дәрес аралары тоташ репетициягә әйләнә иде. Классташым Әлфия Мусина белән (соңрак Әлмәт, Минзәлә театрлары артисткасы) Хөсәен Әхмәтовның «Ике аккош» җырын башкарып, район смотрының беренче бүләген, лауреат исемен алган чаклар әле дә истә.

***– Алга таба гомер юлында Сезне театрга мәхәббәт йөртә. Әмма зур сәнгатькә килү шактый урау юллар белән булган...***

– Сәнгать, театрга булган мәхәббәт мине иң элек Әлмәт Татар дәүләт драма театрына алып килде.1965-1966 елларда режиссёр Габдулла ага Юсупов анда театр студиясе оештырган иде. Бу студиядән соңрак Камил Вәлиев, Луиза Солтанова, Дамира Кузаева, Әлфия Мусина кебек зур сәнгать осталары үсеп чыкты.

Миңа әлеге студиядә бары бер генә ел укырга туры килде. Соңрак армия хезмәтенә алындым. Өч ел армия хезмәтендә булып кайтканнан соң, театрга карата мәхәббәт Казанга тартты. Биредә Ленинград мәдәният институтының филиалы ачылган иде.

1970 ел. Педагоглар – курс җитәкчесе профессор Ширияздан Сарымсаков һәм ассистент Роберт Батуллин режиссура бүлегенә шәкертләр кабул итте. Бер урынга дүрт кеше идек. Без, алты егет һәм алты кыз, татар бүлегенә кабул ителдек. Актёрлык осталыгы, режиссура, сәхнә теле, сәхнә хәрәкәте, бию буенча дәресләр... Һәм, ниһаять, диплом спектакле – Шәриф Хөсәеновның «Зөбәйдә – адәм баласы» әсәре.

Институттан соң бер ел Актаныш халык театрының режиссёры булып эшләдем. Ел эчендә Аяз Гыйләҗевның «Көзге ачы җилләрдә», Әнгам Атнабаевның «Мәхәббәт турында җыр» пьесаларын сәхнәгә куйдым. Республика смотрында катнашып, 35 халык театры арасында лауреат исемен яулап алдым. Ул спектакль турында комиссия рәисе Туфан Миңнуллин «Халык театрының спектакле әнә шундый булырга тиеш», дип үрнәк итеп язып та чыкты.

Актаныштa уңышлы гына эшләп килгәндә, халык театры спектакле белән Казанга баргач, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һем тарих институтының сәнгать бүлеге мөдире Баян Гыйззәт белән таныштым, һәм ул мине аспирантурага укырга чакырды. Тиз арада әзерләнеп, шул ук елның көзендә аспирантурага кердем. Җитәкчеләрем итеп Мәскәүдән күренекле театр белгече, сәнгать фәннәре докторы Константин Рудницкий, Казаннан филология фәннәре кандидаты Баян Гыйззәт билгеләнде. Бүгенге көндә алар икесе дә мәрхүмнәр. Урыннары җәннәттә булсын. Алар мине җитәкләп дигәндәй фән дөньясына алып керделәр. Кандидатлык диссертациясен – 1984 елда, докторлыкны 1993 елда яклап, гыйльми дәрәҗәләргә лаек булдым.

***– Милләтебезнең сәнгать фәннәре, аерым алганда, театр белеме фәне кайчан һәм ничек формалашты, үсеш алды?***

– Татар халкының меңнәрчә еллык мәдәнияте, сәнгате бар. Бу – искиткеч зур байлык. Мәгълүматлар бик борынгы заманнардан ук туплана килгән. Әйтик, сакланып калган урта гасыр әдәбияты һәйкәлләренең иң элгәреләреннән булган Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасында, соңгырак чорларга караган Сәйф Сараи, Котби, Мөхәммәдьяр әсәрләрендә, XIX йөзнең икенче яртысында яшәгән Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри хезмәтләрендә ул чорлардагы сәнгать әсәрләре, аларның халык тормышындагы урынына бәйле җитди күзәтүләр табарга була. Сәнгать турында системалы фикер йөртү, даими эзләнүләр XX йөз башында аеруча алга китә һәм бу хәл сәнгатьне өйрәнә торган фәннәр тууга җирлек хәзерли.

Күп кенә фәннәрне милләт төшенчәсе белән берничек тә бәйләп булмый торгандыр. Аларның милләте юк. Һәрхәлдә, милли физика, милли химия, милли математика дигән сүзләр, төшенчәләр, килешегез, абсурд буларак яңгырый. Әмма шул ук вакытта фәннең бары аерым милләткә генә кагыла торган өлешләре, юнәлешләре бар. Әйтик, тел, әдәбият, фольклор, этнография, сәнгать төрләрен (театр, музыка, кино), тарихны һ.б. өйрәнә торган фәннәр (филология, искусствоведение, тарих). Алар халыкның йөзен, милли үзенчәлекләрен ача. Аларны өйрәнү халыкның милли үзаңын тәрбияли, милләт буларак менталитетын билгели. Шуңа күрә дә аларга аерым игътибар бирергә, сакларга, үстерергә кирәк.

Сәнгать фәннәренә килсәк, алар төп өч компоненттан формалаша: оператив тәнкыйть, сәнгать тарихы һәм теория. Шушылар арасыннан иң элек тәнкыйди фикерләү дөньяга килә. Әйтик, татар театрының туган вакытын 1906 ел дип билгеләсәк, театр тәнкыйте дә шул ук елны мәйданга чыга. Шул чордан татарның беренче театр тәнкыйтьчеләре Габдрахман Кәрам, Гыймад Нугайбәк, Заһид Нуркин, Ибраһим Биккулов – Казанда, Кәбир Бәкер – Оренбургта, Сәгыйть Рәмиев – Әстерханда, Самат Шәрәфетдинов Уфада үзләренең тәнкыйди-иҗтимагый эшчәнлекләрен башлап җибәрә. Аларның көндәлек матбугат битләрендә урын алган мәкаләләрендә бу сәнгать төренең аерым әсәрләре, узган театраль сезон йомгаклары нәтиҗәләре чагылыш таба. 20нче елларда татар театрының 20 еллыгы белән бәйле рәвештә, бу төр сәнгатьнең тарихы, үсеш тенденцияләре, проблемалары, узган юлы турында шактый төпле, фактик материалга бай булган, В.Мортазин-Иманский һәм Т.Ченәкәй язган «Татар театры тарихыннан» һәм коллектив авторлар тарафыннан төзелгән «Татар театры (1906-1926)» китаплары басылып чыга. Әлеге хезмәтләр безнең театр фәненең нигез ташлары, беренче нәтиҗәләре булып саналырга хаклы. Әмма аннан соңгы елларда М.Мәһдиевның «Уен һәм сүз техникасы», «Театр эше», «Театр», Г.Айдарскийның «Театр сәнгате» исемле гомуми театр сәнгате теориясен пропагандалаган китаплары басылып чыкса да, татар театр фәне алга таба зур үсеш ала алмый. 40нчы еллар башында З.Солтанов, К.Шамил, Н.Исәнбәт, Г.Кутуй кебек әдәбият һәм сәнгать әһелләре татар театры тарихын язарга омтылыш ясап карыйлар, тик башлаган эш ахырга кадәр барып җитми. 1950-1960 елларда Р.Усманова, Х.Гобәйдуллин, Х.Кумысников язган кандидатлык диссертацияләре театр сәнгате турындагы фәннең алга таба үсеш баскычы була.

Бүгенге көндә Татарстанда шактый гына алга киткән музыка, рәсем, сынлы һәм гамәли сәнгать фәннәрендә дә шундый ук үсеш юлы күзәтелә. Октябрь инкыйлабына

кадәр һәм аннан соңгы елларда музыкаль фольклористика өлкәсендә Гайса Еникеев, Гата Исхакый, Гыйлаҗ Сәйфуллин, Солтан Габәши, сынлы, гамәли сәнгать буенча П.Дульский, Г.Девишев, Л.Поздеева хезмәтләре билгеле булса да, бу төр сәнгать фәннәре бары тик 60нчы елларда гына ныклап гамәлгә куела.

1968 елда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты каршында сәнгать секторы оешу Татарстан сәнгать фәне үсешендә әйтеп бетергесез зур һәм мөһим адым булып тора. Шушы чордан башлап татар халкының сәнгате республикада системалы, планлы рәвештә өйрәнелә башлый. Сәнгать секторының беренче җитәкчесе итеп әдәбият һәм театр белгече, филология фәннәре кандидаты Баян Гыйззәт билгеләнә.

***– Инде хәзер сүзне, чынлап та, фәнгә бәйләп дәвам итсәк тә ярыйдыр.***

– Мин баштан ук татар режиссура сәнгатен өйрәнергә керештем. Төп белемем буенча режиссёр булганга, җитәкчеләрем шулай хәл итте. Беренче язган хезмәтемдә актёр һәм режиссёр Хөсәен ага Уразиков иҗаты 30-40нчы еллардагы татар режиссура сәнгате контекстында каралды. Икенче, өченче һәм дүртенче монографияләрем татар режиссура сәнгате һәм аның талантлы режиссёрлары турында. Моннан соң Хөсәен ага турындагы диссертациямне киңәйтеп, 15 табаклык китап итеп бастырганнан соң, остазым Шириаздан Сарымсаков эшчәнлегенә багышлап монография яздым.Соңгы ике китабымның берсе «Җыен» фонды тәкъдиме белән татар театрының атасы Габдулла Кариевка багышланып эшләнде. Икенчесе – 40 ел буена җыелган, Мәскәү, Петербург, Казан, Уфа архивлары, музей фондлары, шәхси архивлар тупланмалары материаллары нигезендә язылган артистлар, режиссёрлар, драматурглар, сценограф-рәссамнар, композиторлар – гомумән, театрда эшләгән, спектакль тудыруда катнашкан бөтен шәхесләр турындагы мәгълүматлар тупланмасы булган татар театры сүзлек-белешмәсе. Бусы инде галимнәр өчен генә түгел, бәлки бөтен театр сөючеләребезгә дә кирәкле. Мин үземне бик бәхетле дип саныйм. Бүгенге көндә басылып чыккан 12 китабым бар. Болардан тыш 500гә якын газета-журнал, төрле җыентыкларда дөнья күргән мәкалә-рецензия, иҗат портретлары, аерым шәхесләрнең хезмәт юлына анализлар...

Әле басылырга өлгермәгән тагын бер хезмәтем бар. Ул да булса – «Татар театры елъязмасы. 1917-1941». Аңлашылганча, хезмәт күрсәтелгән еллар аралыгында театр тормышындагы барлык вакыйгаларны эченә ала. Ул вакытлы матбугат, архив, музейлардагы беренчел материалга нигезләнеп язылган. Билгеле булганча, 1929 елга кадәр бездә газета-журналлар гарәп графикасы, 1940 елга кадәр яңалифтә чыккан.Хәзер аларны белүче бик юк. Шулай булгач, елъязманың кирәклеге тагын да арта дигән сүз.

***– Театр белгечләре, гадәттә, театр тәнкыйте белән дә шөгыльләнә...***

– Бу кагыйдәдән мин да читтә калмадым. ТӘhСИдә эшли башлаган елларда ук мине Мәдәният министрлыгының яңа спектакльләр, концерт программалары кабул итү комиссиясенә керттеләр. Республикабыздагы Татар дәүләт академия, Әлмәт, Бөгелмә, Минзәлә, гастрольләргә килгән башкорт, рус, казакъ, үзбәк театрлары спектакльләрен карап, аларга рецензияләр язарга өлгерә идек. Хәзер генә бераз сүлпәнләндек. Күрәмсең, һәрнәрсәнең үз вакыты, мотивация дә кирәктер.

Фән белән шөгыльләнү, аның турында сөйләшү шактый мавыктыргыч булса да, аның турында күп сөйләсәк, укучыларыбыз ялыгыр. Иң дөресе, хезмәтләрне укып, алар турында фикер йөртүне аларга калдырыйк.

***– Педагогик эшчәнлегегез турында да әйтеп китү урынлы булыр. Фән белән параллель рәвештә Сез Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать институтында ассистент, өлкән педагог, профессор вазифаларын үтәдегез.***

– Әйе, аспирантурага укырга керү белән, остазым, ул вакытта режиссура кафедрасы мөдире Шириаздан ага Сарымсаков мине актёрлык осталыгы, режиссура дәресләре укытырга чакырды. Диссертацияләрне яклап, фәнни дәрәҗәләр алгач, татар театры тарихы, Татарстан мәдәнияте тарихы предметлары буенча лекцияләр укый башладым. Дистәләгән, хәтта йөзләгән шәкерт арасыннан артистлар, режиссёрлар, драматурглар

үсеп чыкты. Кайберәүләре педагогика белән шөгыльләнә. Районнарда мәдәният бүлеге мөдире булып эшләүчеләре дә булды. Хәтта берсе профессиональ җырчы булып та китте. Ходай кемнең күңеленә ни салган инде.

***– Гали ага, хезмәт биографиягезнең төп өлеше барыбер дә Татарстан Фәннәр академиясе, аның Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының сәнгать бүлеге белән бәйле бит.***

– Бүлектә мин мөдир булып 1994-2016 елларда эшләдем. Баштагы чорда 15 гыйльми хезмәткәр эзләнүләр алып бара иде. 2007 елда җитәкчелек үзгәргәч, 7 кешегә, соңрак аннан да азракка калдык. Татар халкының театр, музыка, сынлы-гамәли сәнгатен борынгыдан алып бүгенге көнгә кадәр өйрәнә идек. Хәзер соңгы төр сәнгать белән аерым бүлек шөгыльләнә. Бездә Б.Гыйззәт, М.Нигъмәтҗанов, З.Сәйдәшева, Ф.Хәсәнов, Х.Гобәйдуллин, И.Илялова, Ф.Кадыйрова, Һ.Мәхмүтов, Д.Гыймранова, Д.Вәлиева, А.Алмазова, Г.Сөләйманова, Г.Сәйфуллина, Г.Макаров кебек танылган, үз өлкәләрендә зур белемле галимнәр эшләде. Ни үкенеч, хәзер институт галимнәргә саега бара.

***– Әйдәгез, милли театрыбыз турында сөйләшик. Мең еллык әдәбияты булган милләтнең театры яше, тарихы ни өчен 110 ел белән генә исәпләнә? Әллә театр булу өчен Зиде, Эфос, Рим һ.б. шәһәрләрдәге амфитеатр бинасы булса гына театр буламы ул? Кыргызларның Манас дастанында каганатның корылтае алдыннан зур халык бәйрәме үткәрелүе язылган. Безнең Сабантуй дип торырсың... Гомумән, төрки халыклар театрдан нилектән мәхрүм? Дин ислам белән генә бәйле түгелдер шәт!***

– Профессиональ җирлектә эшләүче театр сәнгате туу өчен билгеле бер шартлар зарури. Иң элек халыкның утрак тормышта яшәве, аерым шәһәрләр тирәсендә туплануы кирәк. Күчмә тормышта, авыл шартларында театр берничек тә туа алмый. Ә безнең халыкның төп массасы утрак тормышка бары XIV-XVI гасырларда гына күчкән. Әлбәттә, шәһәрләр дә күп булган, хан сарайларында ниндидер күңел ачу кичәләре, җырлы-биюле мәҗлесләр оештырылган. Хәтта даими башкаручылар – җырчылар, биючеләр музыкантлар да булган. Ләкин бу әле профессиональ театр түгел. Ә халык тормышында, гореф-гадәтләрендә, йола, календарь, хәтта дини бәйрәмнәрдә дә театр элементлары булган. Шул ук кичке уеннар, аулак өйләр, туй мәҗлесләре циклы, син әйткән Сабантуйларда, җыеннарда, халык уеннарында да булган алар. Болар күп гасырлар буенча килгән. Ләкин беренче профессиональ милли труппалар бары XX гасыр башы казанышы. Күз алдына китерегез, Европа тибындагы театр сәнгате борынгы Грециядә безнең эрага кадәр V гасырда дөньяга килгән. Көчле дәүләт ярдәме, зур күләмле субсидияләр, син әйткән амфитеатрлар, колизейлар, профессиональ актёрлар, драматурглар. Ничек үсмәсен, чәчәк атмасын ул?! XVIII гасырда, караңгы урта гасыр инквизицияләре чорын үтеп, Италия, Франция аша театр сәнгате патша Россиясенә дә килеп керә. Дәүләт учреждениесе, оешмасы буларак, ул 1756 елда, Император театры исеме белән, патшабикә Елизавета указы нигезендә төзелә беренче рус театры. Игътибар итегез, рус театры да XVIII гасырда гына төзелә. Ә үз дәүләтчелеге булмаган татар халкында нинди шартларда барлыкка килә соң милли театр?

Патша фәрманнары, бай меценатлар, ниндидер бай матди җирлектә, дәүләт финанславы ярдәме белән түгел, бәлки гади халыктан чыккан зыялы, ләкин ярлы энтузиастлар тырышлыгы белән туган ул. Баштагы чорда күп каршылыклар булган. Шул ук дин әһелләре, кара байлар, карагруһ иске фикерле кешеләр. Ләкин алар барысы да акрынлап җиңелгән, артта калган.

***– Татар милли театрының миллилеге нинди сыйфатлар белән билгеләнә һәм аның үсеше, традицияләре, юллары нидән гыйбарәт? Бу мәсьәләдә шәхесләрнең роле? Сез бу хакта монографияләр кимәлендә күп хезмәтләр чыгардыгыз.***

– Шактый четерекле сорау. Милли театр, әлбәттә, иң беренче чиратта, милли драматургиягә нигезләнергә тиеш. Пьеса-спектакльнең төп элементы – эчтәлеге.

Спектакльдә теге яки бу дәрәҗәдә милләтнең яшәү рәвеше, гореф-гадәтләре, проблемалары, уй-фикере, хыяллары, уңай һәм тискәре геройлары, уңай һәм тискәре күренешләре, дөньяга карашы һ.б. – кыскасы, милләтнең башка халыклардан аерылып торган, үзенә генә хас, үзенчәлекле сыйфатлары, беренче чиратта, менталитеты чагылыш табарга тиеш. Боларга өстәп, тагын кием-салымы, костюмнары, киенү рәвеше, аеруча киң таралган үз-үзен тоту манералары, әйләнә-тирә мохит, ул яшәгән табигать шартлары – гомумән, милләт тормышының бөтен яклары тамашаның миллилеген билгелидер. Халык яшәгән саен, миллилек сыйфатлары үзгәрә. Искергәннәре югала, төшеп кала, яңалары барлыкка килә.

Спектакльләрдә миллилекнең чагылышы аерым шәхесләрдән тора. Мисал өчен, тамашаны сәхнәгә куйган режиссёр никадәр милләт тормышын, гореф-гадәтләрен һәм алда саналган бөтен үзенчәлекләрен яхшырак белсә, аңласа, сакларга, дәвам итәргә теләсә, шулкадәр алар тамашада чагылыш таба да. Татар режиссурасы турындагы хезмәтләремдә, әлбәттә, мин күпмедер дәрәҗәдә бу проблемага да кагылам. Гомумән алганда, миллилек, милли театр, тамашачы менталитеты – монографик планда аерым өйрәнелүгә лаеклы проблема.

***– Көнбатыш театр сәнгате борынгы, дибез. Көнчыгышта Япон, Кытай театрларында традициянальлек бик нык саклана бугай. Маскаларны гына күздә тотмыйм. Без кем арбасына утырдык? Үз арбабыз, велосипедыбызны уйлап таптыкмы?***

– Дөньяда күп кенә халыкларның борынгыдан килгән традицион формадагы театрлары бар. Мисал өчен Япониядә – Но, Кабуки, Бунраку, Кытайда – Юань драмасы, Пекин операсы, Күләгәләр театры бар. Аларның бернинди башка театрларда да кулланылмый торган үз символикасы, пьесалары, сәхнәләре һ.б. була. Артистлар уены да бернинди импровизацияне, читкә чыгуны хупламый. Канунлашкан грим-костюмнар, интонацияләр, характерлар бозылырга, үзгәртелергә тиеш түгел. Без исә Көнбатышка йөз тотканбыз. Борынгы Грециядә туган Европа тибындагы театр формаларын алганбыз. Аның Рус дәүләтенә кайчан һәм ничек килеп керүе турында алда әйттем инде.

***– Һаман да милли сәнгатебезнең тамырларын барлыйсы килә бит. Музыкаль театр, әдәби театр, балет театры... Безнең бу өлкәләрдә шактый тыйнак урыныбызның сәбәпләре нидә?***

– Бүгенге көндә театр дигән төшенчә бик күп төрләрне үз эченә ала: драма, опера, балет, курчак, мюзикл, оперетта, пантомима, пародия, җыр, поэзия, әдәби, сатира, яктылык, күләгә, абсурд, бию, эстрада һ.б. Боларның һәммәсе дә бер халыкта булуы кирәк тә түгелдер. Милләткә кайсы театр төре якын, ул шуны сайлап ала, үз итә, үстерә. Син кулланган «музыкаль театр» термины астында мин халкыбыз арасында кирәклеге турында күптәннән фикер туган, милләткә якын булган музыкаль драма театрын ачу зарурлыгын хуплауны тоям. Шулай ук бездә әдәби театр формалары да яшәргә хаклы. Аларны ачу, үстерү өчен хакимияттә утыручыларның олуг ихтыяры, ныклы теләге кирәктер.

***– Быелгы Нәүрүз фестивале якут кардәшләребезнең театр сәхнәсендә ат уйнатуларын күрсәтте... Үзебезнекеләр Мәскәүдә югары бәяләр алып китте... Якутларда, гомумән, безгә үрнәк алырдай нинди сыйфатлар бар? Безнең республиканың башка театрларында хәлләр ничек?***

– Казанда инде традиция буларак уза торган XIII «Нәүрүз» театр фестивалендә быел 17 театр катнашты, 300дән артык кунак килде. Тамашалар башкаланың дүрт театры сәхнәләрендә – Г.Камал, К.Тинчурин исемендәге, Яшь тамашачылар (ТЮЗ) һәм «Әкият» курчак театрында уйналды. «Нәүрүз» афишасына төрле милли коллективларның 18 спектакле кертелгән иде. Фестивальнең төп бенефициантлары итеп Саха (Якутия) Республикасы театрлары чакырылган. Режиссёр Сергей Потаповның соңгы

елларда төрле милли театрларда куелган спектакльләр ретроспективасы да тәкъдим ителде. Республика театрлары күрсәткән тамашалар бу милләт сәхнә сәнгатенең актив, эзләнүчән, милли традицияләрне тирәннән үзләштергән һәм аларны югары профессиональ Европа театры казанышлары белән берләштереп, баетып, үзенчәлекле синтез тудырырга сәләтле булуын дәлилләде. Безнең күп кенә театрларыбызда эшләүче режиссёрларыбызга милли үзенчәлекләребезне, гореф-гадәт, тормыш-көнкүреш нечкәлекләрен, милли менталитетны җентекләп белү, аңлау җитешми. Ә бит бүгенге көндә үз милли мәдәниятеңне ил, Европа, төрле цивилизация казанышлары белән баетып тәкъдим иткәндә генә, башка халыкларда кызыксыну уятырга, дөньякүләм сәнгать мәйданына чыгарга мөмкин.

***– Дөнья глобальләшә. Кемдер салкын сугыш дәвере әйләнеп кайтты, ди. Кемдер кешелек дөньясы мәңге сугыш алды хәлендә булган, ди. Без – сугыштан соң дөньяга килгән буын. Сугышның ни икәнен үз җилкәбездә татыдык. Дөнья кая бара? Әлеге сорауны юкка бирмим. «Сугыш театры», «Сугыш сәнгате» дигән төшенчәләр бар хәтта. Бу шәһит киткән миллионнарның рухын рәнҗетмиме икән? Үтерү сәнгать буламыни? Галимнәр, Сез – сәнгать белгечләре, ник катгый сүзегезне әйтмисез?***

– Әйе, соңгы вакытларда, кызганычка каршы, дөньяда вазгыять шактый кискенләште. Күп дәүләтләр берләшеп, Россиягә каршы чыкты. Чит илләр радио, телевидение, вакытлы матбугатында әледән-әле «агрессор», «окупант», «террорист» дигән атамалар, гаепләүләр ишетелә. Сәбәбе дә бөтенләй юк түгел. Кырымда, Украинада, Сүриядә барган вакыйгалар, алар тарафыннан үзләренчә бәяләнеп, үзләренчә нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә. Әмма ни генә булмасын, кораллы бәрелешүләргә, чын сугышка барып җитәр дип уйламыйм. Элек тә, хәзер дә сәясәтчеләрнең илдәге халыкның канәгатьсезлегеннән, елдан-ел матди яктан начаррак яшәвеннән игътибарны читкәрәк юнәлтү өчен, бу алымны кулланулары бар иде инде ул. Дөнья сугыштан иң соңгы чиктә генә тукталып калган Кариб кризисы вакыйгаларын гына искә алыйк. Бу юлы да шулай булыр дип өметләник.

Сугышны сәнгатькә тиңләү, аны күңел ачу, баю объекты итеп карау, дөнья халкын куркыныч астына куеп, миллионнарның язмышы белән уйнау Бөек Ватан сугышында ил яклап шәһит китүчеләрнең изге истәлекләрен рәнҗетмичә кала алмый, әлбәттә. Әдәбият, сәнгать әһелләре һәм, гомумән, иҗат кешеләре моны бик яхшы аңлый. Үзләренең иҗат чаралары, мөмкинлекләре аша каршы көрәшә дә алар. Тик балта башкалар кулында...

***– Милли театр сәнгатебезнең тарихы – милләтебез тарихы. Милләтнең, республикабызның киләчәген ничек күзаллыйсыз? Безнең оныкларны ни көтә?***

– Мин дөньяга оптимист буларак карарга тырышам. Илдә дә, Татарстанда да бары да әйбәт, балалар, оныклар өчен илләр тыныч, күкләр аяз булыр, Ходай кушса. Ә халык яшәсә, исән-сау булса, милли театрыбыз яшәр, сәнгатькярләребезнең иҗаты үсәр, һәм аларга багышланган театр сәнгатенең тарихын, алга таба үсешен яктырткан фәнни хезмәтләр дә дөнья күрер дип өметләник.

***– Җавапларыгыз өчен рәхмәт. Сезне театр сөючеләр һәм укучыларыбыз исеменнән юбилеегыз белән котлыйбыз, исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.***

# БЕРЕНЧЕ МӨФТИЛӘРНЕ БИРГӘН ТӨБӘК

Беренче мөфтиләребезнең патша Россиясе шартларында ул дәрәҗәгә күтәрелүенә нинди мөмкинлекләр ярдәм иткән соң? Минем уйлавымча, тәүге мөфтиләрнең ил күләмендә танылуы аларның элекке мөселман дәүләтләренә чиктәш өлкәдә – Оренбург губернасының башкаласы янәшәсендәге Сәет бистәсендә танылу алуына бәйле. Хәзер Татар Каргалысы исемендә йөргән, император Пётр Беренченең кызы Елизавета фәрманы белән Сәет бистәсе буларак барлыкка китерелгән бу зур авылның ул елларда Урта Азия дәүләтләре белән сәүдә мөнәсәбәтләрен җайга салу өчен оештырылганлыгын алда яздык инде.

Мөхәммәтҗан Хөсәен улы 1777 елда Бохарадан туры Сәет бистәсенә әйләнеп кайта. Ш.Мәрҗани хәбәр итүенчә, Бохарада укыган елларында да бу бистәдә калган остазы һәм башка күренекле муллалар белән хәбәрләшеп торган. Ул Бохарадан кайткан елларда бу бистәдә Утыз Имәни дә әле укып һәм хәлфә булып көн күрә. Мөхәммәтҗан кайткач та алар бергә унбер ел чамасы бер авылда яшиләр. Бер-берсе белән белешкән, аралашкан булырга тиешләр. Шул хакта Утыз Имәнинең бай архивында кайбер язмаларның сакланган булуы да ихтимал. Әмма Совет хакимияте елларында ул архив белән эш иткән галимнәребез бөек шагыйрьнең бер мулла белән аралашу вакыйгаларына әһәмият итмәгәннәрдер, мөгаен.

Шиһабетдин хәзрәт китабының «Беренче мөфти» дип башланган бүлегендә Мөхәммәтҗанның туган елы күрсәтелмәгән. Ул бүлек: «Борындык исемле авыл кешеләреннән. Башлангыч белемне туган ягында алган, соңыннан Каргалыга барып, мелла Мөхәммәт әд-Дагыстани һәм башкалардан гыйлем ала», дип башлана. Шуннан соң хәзрәт булачак мөфтинең Каргалыда нинди китапларны укыганлыгын санап китә. «Бохарада казый Габделваһһабтан белем ала», дип яза. Шиһабетдин хәзрәт язганнардан аңлашылганча, Мөхәммәтҗан Зөя өязе Борындык авылында туган, шунда башлангыч белем алган була. Ә Татар энциклопедиясенең рус телендә чыккан 6нчы томында исә мөфти хәзрәтләренең Уфа өязендәге Солтанай авылында 1756 елда туганлыгы күрсәтелгән. Шул ук авыл исеме 1939 елда башкалада СССР Фәннәр Академиясе тарафыннан нәшер ителгән «Исторический архив» мәҗмугасында, профессор М.П.Вяткинның «Журнал Оренбургского муфтия» дип исемләнгән күләмле хезмәтендә дә кабатлана. Бу «журнал» дигәне Мөхәммәтҗанның кайчан, кайда ниләр эшләгәнлеген теркәп барган көндәлеге. (Мөфтигә нисбәтле бүлек 117 биттән башлана. Алдагырак битләрдә Кавказ халыклары иреге өчен көрәшкән Шамилгә багышланган язмалар бар.) Бу хәбәрләрнең кайсысы дөрес? Мөхәммәтҗан кайсы авылда туган? Архив киштәләрендә бәлки шул хакта тулырак мәгълүмат та сакланадыр. Әлегә ул мәсьәлә ачыкланмаган килеш кала. Шуларны белү өчен иң элек Мансур улы Хөсәен әл-Җәбәли әл-Борындыкый мулланың кайларда яшәгәнлеген ачыкларга кирәк.

Профессор М.П.Вяткин, очеркының кереш өлешендә, ниндидер архив язмаларына нигезләнептер, мөгаен, Мөхәммәтҗанны Бохара белән Кабулга укырга «коллегия иностранных дел послал», дип яза. Ягъни булачак мөфти Сәет бистәсендә укып йөргән елларында ук Оренбургтагы Чик буе комиссиясе белән элемтәдә торган булып чыга. Ә ул комиссиянең турыдан-туры башкаладагы әлеге министрлыкка

---

*Ахыры. Башы 9 нчы санда.*



*Шиһабетдин Мәрҗани*

буйсынып эшләгәнлеген хәбәр иткән идек инде. Мөгаен бу комиссиянең таможня бүлегенең бер бүлекчәсе Сәет бистәсендә урнашкан булгандыр. Сәүдә кәрваннары чит илләргә шушы авылда тупланып чыгып киткән бит. Мөхәммәтҗан шәкерт анда, остазы ахун Мөхәммәт әд-Дагыстани белән берлектә, нindидер йомышлар үтәп йөргәндер, күрәсең.

Бохарадан кайткач та Мөхәммәтҗанның шул комиссиядә эшләвен дәвам иттергәнлеге түбәндә китереләсе җөмләдән аңлашыла. Ул «кайткач та Россия дәүләте вәкилләренә һәм олыларына үзен мәгърифәтле һәм алар тарафдары итеп күрсәтә ала», дип яза Ш.Мәрҗани. Казакъ ханлыклары белән ике арада булгалап торган киеренкелекне хәл иткәндә дә, ул илдә үзара гаугалар чыкканда да Мөхәммәтҗан ахунның ул тарафка еш йөргәнлеге М.П.Вяткин хезмәтендә дә тасвирлана. Дөресрәге, профессор Вяткинның ул хезмәте башлыча шул вакыйгаларны аерым-аерым билгеләп, тасвирлап үтүгә багышланган да диярлек. Шул очерк эчтәлегеннән аңлашылуынча, Бохарадан кайтып әлеге комиссиядә бераз эшләгәч тә Мөхәммәтҗан муллага ахун дәрәҗәсе бирелгән була. Ләкин бу хезмәттә аңа ул дәрәҗәнең кайчан бирелгәнлеге күрсәтелмәгән.

Нәкъ шул елларда, Россия алдында артыграк баш ия башлаганы өчендерме, Әбелхәер ханны кайсыдыр ыруг старшиналары үтереп ташлый. Ханның варислары арасында тәхет тирәсендәге чираттагы ызгышлар булган берничә очракта ахун Мөхәммәтҗанның, күрше мәмләкәттә килеп туган бәхәсне хәл итү өчен, анда үзе генә дә, Миндияр Бикчурин белән бергә дә барганлыгы Вяткин хезмәтендә дә теркәлгән. М.П.Вяткин кулланган документлар арасында мөфти фамилиясенең кавказчалаштырып, яисә төрекмәнчәләштереп «Гусейнов» рәвешендә язылу очраклары да күзгә чалына.

* * *

Мөхәммәтҗан Бохарадан кайткан елларда иркен Оренбург губерниясе белән Екатерина патшабикәнең бик ышанычлы кешеләре – генераллар И.А.Рейнсдроп һәм бераз соңрак О.А Игельстром җитәкчелек итәләр. Патшабикәнең үзе кебек үк, болар икесе дә чит илдә тәрбияләнгән шәхесләр. Мин караштыргалаган китапларда Мөхәммәтҗан мөфтинең аеруча Игельстром барон белән килешебрәк эшләгәнлеге күзгә чалына.

О.А.Игельстром, бу төбәккә генерал-губернатор итеп билгеләнгәнче, 1768-1774 елларда Россия белән Төркия арасындагы сугышта катнашкан, шул елларда генерал дәрәҗәсенә ирешкән. Кече Кайнарҗа авылында уздырылган ике ил арасындагы солых килешүен төзүдә дә катнаша ул.

Екатерина патшабикә идарә иткән дәвердә Оренбург губернасы бик зур мәйданны биләгән.Ул вакытта губернаның чикләре Иделдән Уралгача һәм Нократ елгасы урталарыннан алып Каспий диңгезенәчә җәелгән була. Пугачёв фетнәсе бастырылгач та ул чордагы Россиянең зур бер өлешен биләп торган әлеге губерна җитәкчесе итеп Әби патша О.А.Игельстромны билгели. Һәм аңа ул катлаулы, күп милләтле биләмә белән ничегрәк идарә итәргә кирәклеге турында әледән-әле киңәшләр биреп тора. Ике арада йөргән хатларның бер өлеше 1886 елда «Русский архив» журналында, «Граф Игельстром архивы» өлешендә китерелә.

Патшабикәнең аңа язылган хат-фәрманнарыннан бер-ике өзеккә күз төшерик: «Подданствобызда торган һәм сез идарә иткән төбәктә яшәгән, яки шунда күчеп килгән халыкка карата бик сак мөгамәләдә булыгыз. Аларга карата җәбер кылмагыз, басым ясамагыз. Җәбер кылган тәкъдирдә, канун кушканча, аларга дөреслекне

табарга рөхсәт ителсен.» Икенче хатта мондый сүзләр дә китерелә: «Шул халыклар арасында диндәшләре яисә башка берәр начар ниятле кешеләр тарафыннан безнең өчен зарарлы үгетләр таратылмасын. Зарарлы үгетләрне... мөмкин кадәр йомшаграк чаралар белән туктатыгыз», диелә анда. Ягъни, дошмани сүз таратучы, гамәл кылучыларга карата чара күрсәгез дә арттырып җибәрмәгез, аларны тиктомалдан атып үтермәгез, дигәндәй итеп кисәтә Екатерина патшабикә. Әйе,тикмәгә генә татар халкы аны Әби патша дип зурламагандыр шул. Әби кешеләр шулай йомшаграк күңелле булалардыр инде. Бүген исә андый әби патшаларны сагынып сөйләргә генә кала.

Екатерина Икенче белән язышкан хатларыннан күренгәнчә, Игельстром үзе дә, әйтик, татар-башкортларга карата йомшаграк мөгамәләдә булуны яклый. Дини карашка бәйле эзәрлекләүләргә каршы булуын сиздерә. Урыннарда мәчетләр ачу кирәклеген хуплый. Әби патша да мөселманнар яшәгән төбәкләрдә мәчетләр төзергә рөхсәт бирү нияте барлыгын иң әүвәл Игельстромга хәбәр итә шикелле.

Яңа губернаторның мөселманнарга карата булган карашы, аларга беркадәр дини ирек бирергә кирәклеге турындагы фикере, мөгаен, Мөхәммәтҗан мөфти белән якыннан аралашу нәтиҗәсе дә булгандыр. Бу барон идарә итә башлар алдыннанрак кына Мөхәммәтҗан Хөсәеневне киң вәкаләтле Чик буе комиссиясенең ахуны итеп тә билгелиләр ич. Димәк, аның Бохарада үзләштергән белеменә, аралашу тәҗрибәсенә нигезләнеп, күршедәге мөселман мәмләкәте вәкилләре белән дипломатик сөйләшүләр алып бару осталыгын таныйлар. Аңа ышаналар. Ягъни, ул губерна чигеннән көнчыгыштарак урнашкан казакъ ханлыклары белән тыгыз элемтә тотучы түрәләрнең берсенә әверелә. Шул рәвешле булачак беренче мөфтигә багышлы рәсми язмалар СССР чорында нәшер ителгән тарихи документларга да килеп керә. Мәсәлән, Казакъстан галимнәре катнашында туплап чыгарылган «Собрание документов по истории колониальной политики царизма в Казахстане» хезмәтенең 4нче томында (1939 ел) шул чор вакыйгаларына байтак урын бирелә. Һәм анда мулла Хөсәенев шәхесе һәм эшчәнлеге еш искә алына.

Әйтик, 1780 елларда Кече Җөзнең байбахты ыруы батыры Сарым Датов ханлыктагы тәртипләргә һәм рус дәүләте басымына каршы баш күтәрә. Мөхәммәтҗан Хөсәенев белән Миндияр Бикчурин берничә мәртәбә анда булып, Нургали хан белән батырны килештерергә тырышалар. Үз дигәннәренә ирешә алмагач, губернатор кушуы буенча, Сарым Датовны һәм ханлыкка кергән ыру башлыкларын Оренбургка чакырып сөйләшергә карар кылалар. Шушы җыенда катнашкан күпчелек Нургали ханны тәхеттән төшерү кирәклеге турында фикер әйтә. 1785 елның ахырында ханның үзен, гаиләсен һәм якыннарын әүвәл Оренбургка китереп урнаштыралар. Ә бераздан соң аларны ил чигеннән ераккарак – Уфага күчерү карарына киләләр. Хан гаиләсенә Уфада бай торак йорт бирелә һәм еллык биш мең сум акча түләп торыла башлый. Бу гаугалы вакыйгалар һәм Кече Җөз тәхетенә Нургалинең энесен тәгаенләү мәшәкатьләрендә Мөхәммәтҗан мөфтигә дә катнашырга, атналап-айлап шунда яшәп, казакъ бәксолтаннары белән эш итәргә туры килә. Бу вакыйгаларда ул губернаторның адъютанты, Кавказлы мөселман кенәз Черкасский белән бергә йөри. Губернатор исеменнән башкарыласы чараларны алар бергә үтиләр.

Шушы хәлләрдән соң Екатерина патшабикә, губернатор белән мөфти фикерләрен хуплап, казакъ ханлыклары белән чиктәш калаларда һәм ханлыктагы кайбер торак урыннарында мәчетләр, мәктәпләр ачу кирәклеге карарына килә. Шул максат өчен губернага елына ике мең сумнан артыграк акча бүлеп бирелә башлый. Иң элек шул карар нигезендә Оренбург янәшәсендәге Меновый дворда һәм Троицк кальгасында яңа буралы мәчетләр калкып чыга. Әлбәттә инде, булачак граф Игельстромга шулай эшләргә кирәклеген искәртеп торучыларның берсе беренче мөфти хәзрәтләре булган, дип фаразларга тиешбез. Ә 1789 елның 28 февралендә патшабикә тагын бер куанычлы фәрманга кул куя. Ул фәрманда «...озакка сузмыйча Оренбург (янәшәсендәге) мәчет карамагында милли училище ачарга, аны кирәкле кадрлар белән тәэмин итәргә», диелгән була. Һәм шул мәдрәсә каршында казакъ балалары өчен махсус интернатмәктәп оештырылырга кирәклеге, ел саен ул мәктәпкә күрше ханлыкның һәр ыруыннан

ике бала кабул ителергә тиешлеге дә әйтелә. Шул балаларны анда тәрбияләп тоту өчен һәрберсе исәбеннән көненә бишәр тиен акча бүленеп биреләчәге дә ул фәрманда каралган була. Әлбәттә инде, бу мәктәп-мәдрәсәгә беренче чиратта хан һәм аның солтаннары балалары кабул ителгән. Шәһәрнең күренеклерәк гаиләләренең малайлары да ул уку йортыннан читләштерелмәгән. Әмма ул татар балалары хөкүмәт биргән биш тиен исәбенә кертелмәгәннәр.

Шул рәвешле Оренбургка якын бистәдә хөкүмәт исәбенә беренче мәдрәсә төзелә башлый. Ул уку йорты 1793 елда гына төзелеп бетә. Шуңа чаклы казакъ иленнән китерелгән балалар Сәет бистәсе мәдрәсәләрендә укыйлар.

**5**

Шушы ук елларда Оренбург шәһәрендә яшәүче мөселманнар саны да көннән-көн арта бара. Шәһәрнең кыйбла өлешендә – Урал суы буе иңкүлегендә гади татар бистәсе, үрге якта исә чик буе сагында хезмәт итүче татар, башкорт атлы казаклары урамнары барлыкка килә. Бераз соңрак ул урамнар «казачийлар бистәсе Форштат» дип йөртеләчәк. 1911 елда нәшер ителгән «Әхмәт бай» китабында Ризаэддин хәзрәт Фәхретдинов XX гасыр башында бу шәһәр халкының дүрттән бере мөселман кешеләре булуын яза. Шул губернага кергән башка шәһәрләрнең күпчелегендә дә ул дәверләрдә татар милләте вәкилләре саны шул чамада булган. Шәһәр халкы арасында башкорт, казакъ милләте вәкилләренең бик аз санда теркәлгән булуын да әйтеп үтү кирәктер. Шуңа күрә бу чик буе шәһәрләрендә яшәүче мөселманнарны татар дип атауда бер дә хилафлык юк.

Россиягә Төркестан ягыннан даими рәвештә килеп-киткәләгән төрле илчелек вәкилләре өчен Меновый двор бистәсе мәчетенең канәгатьләнерлек түгеллеген, анда сәүдә эше белән йөрүче гади халыкның күплеген, мәчет бинасының исә бик зур булмавын да әйтеп үтик. Әйе, ул мәчет фәкать атналап һәм айлап ком чүлләрен иңләп килгән кәрванчылар өчен генә төзелгән була ич. Югары дәрәҗәле чит ил түрәләрен һәм ханнарын кабул итәрдәй булмый. Шуңа күрә патша тәхете тирәсендә булган түрәләр дә Оренбург шәһәренең үзендә затлырак мәчет төзергә кирәклеген аңлыйлар. Әйе, губерна башкаласында мөселман динен тотучы кешеләр дә яшәүгә карамастан, монда әле рәсми рәвештә ачылган мәчет булмый. Шәһәр халкын гына түгел, мөфти Мөхәммәтҗанны да бу хәл бик борчый. Санкт-Петербургка бер баруында ул шул хакта император Александр Беренче даирәсенә кергән түрәләргә сүз каткан, шул рәвешле Оренбургта таш мәчет төзергә рөхсәт тә, акча да алынган, дип сөйлиләр. Бу императорны тәхеткә тәгаенләү мәҗлесенә чакырылган кунаклар арасында мөфти дә булгандыр, дип фаразларга кирәк. Әйе, император җәнаплары кул куеп билгеләнгән мөфтиләрнең Россия империясе тормышында дәрәҗәләре югары булган. Императорлар аларны кайбер вакытларда кабул да иткән дип язалар. Димәк, Мөхәммәтҗан мөфтинең дә Александр Беренчегә император таҗын кидерү вакыйгасында катнашуында шикләнерлек урын калмый. (Әйе, шулай икәнлегенә инану өчен башка патшаларны тәхеткә тәгаенләү чараларында мөфтиләрнең дә, ил күләмендә абруй казанганрак кайбер милләттәшләребезнең дә катнашу фактлары теркәлгән язмалар, истәлекләр сакланганын әйтеп китәргә кирәктер. Мәсәлән, 1881 елда император Александр Өченчене тәхеткә утырту чарасында мөфтидән тыш берничә татарның, шул исәптән Дәрдемәнд атасы Мөхәммәтсадыйк Рәмиевнең, 1894 тә исә Николай Икенченең инаугурацияләнү мәҗлесендә аның улы Мөхәммәтшакир Рәмиевнең катнашканлыгы мәгълүм. Мөхәммәтсадыйк хаҗиның император җәнапларын котлап бик тә кыйммәтле һәм үзенчәлекле бүләк тапшырганлыгы турында да риваятьләр йөри. Ул бүләк, имеш, бер пот чамасы алтын хакына торырлык булган икән, дип тә сөйлиләр.)

Әйе, XIX гасыр башында Санкт-Петербургта булганда Мөхәммәтҗан мөфти Оренбургта зур мәчет һәм аның карамагында абруйлы зур мәдрәсә ачу кирәклеген олуг түрәләр алдында раслый алган. Дөрес, әлегә шул фаразларны дәлилләрдәй архив документлары белән танышу мөмкинлеге булмады. Әмма Оренбургның беренче таш мәчетенең төзелү тарихын, аны төзер өчен кирәк булган акчаның дәүләт



*Оренбургның беренче таш мәчете*

тарафыннан бирелгәнлеген әйтеп язучылар бар. Ул мәчетне төзү рөхсәте 1801 елның ахырларында бирелгән дип фаразлана. Төзү эшенә 1802 елда тотыналар. Һәм 1805тә анда беренче намаз укыла. Шул ук елда анда мәдрәсә дә ачыла һәм Меновый двор бистәсендәге мәдрәсә шәкертләренең бер өлеше шәһәр үзәгендәге шушы уку йортына күчерелә. Бу мәдрәсәнең урам буйлап тезелеп киткән өч бер катлы бинасы әле Совет хакимияте елларында да сүтелмәгән килеш торды. Күрше төрки илләрнең хан, солтан балаларының XIX йөз башында шушында яшәгәнлеге һәм укыганлыклары турында кинаяле язмалар күренгәли. Әйтик, профессор Карл Фуксның 1826 елда Казанда Бүкәй Урдасы ханы Җиһангир белән очрашуга багышланган күләмле очеркында шул хакта хәбәр бар. Университет белән танышканнан соң, Җиһангир хан аңа Оренбург мәдрәсәсен тәмамлаучы энеләрен һәм шунда укый башлаган улларын киләчәктә шушы уку йортына җибәрәчәген белдерә.

Шунысын да әйтеп үтик, 1898 елдан бу мәдрәсә бинасында Галимҗан Ибраһимов та укый башлаячак. Ләкин инде ул вакытта бу мәдрәсәнең ярым ябык типтагы, хан-солтан балалары өчен дип тотылган чоры күптән үткән була. Бу вакытта инде Россиянең ил чигенең ерактагы Иран, Әфганстан якларына, Бохара әмирлеге «киртәләре»нә барып терәлгән чагы. Казакъ балаларын берничә дистәләп бергә туплап, хөкүмәт исәбенә бушлай укыту дәвере дә артта калган. Казакъ илендәге Акмәчет, Акмолалар, шул ил чигендәге Ташкент кебек калалар яңа уку-укыту үзәкләренә әверелгән чор була. Ташкентта 1870 елдан, Акмолада 1880 еллардан башлап казакъ телендә атналык газеталар да чыгып килгән чак.

Бөек әдибебез Галимҗан Ибраһимов Оренбург мәдрәсәсенә укырга керер алдыннан гына аның җитәкчесе итеп Кышкарда белем алган, Мәккә, Мәдинәләрдә ике ел дәвамында «белемен чарлаган» Мөхәммәдвәли мулла Хөсәенев билгеләнгән була. Шул көннән ул уку йорты «Вәлия» исемен йөртә башлый. Ул уку йортының төп юнәлеше «укымышлы муллалар» тәрбияләп чыгару була. Г.Ибраһимов әүвәл шул «Вәлия» мәдрәсәсендә укый. (Атасы аны үзе урынына мулла итеп калдырырга хыялланган була.) Әмма Галимҗан, монда алган белеме белән генә канәгатьләнмичә, Уфадагы «Галия» мәдрәсәсенә барып керә. Әдипнең хатыны Гөлсем апа Мөхәммәдова сөйләвенчә, «Вәлия»дә укып йөргәндә Галимҗанга Урта Азиядән кайтучы бер кардәше бик серле бер язма калдырып киткән була. Шул язма киләчәктә әдипнең «Коръән алладанмы, түгелме?» дигән хезмәтен язарга этәргеч бирә, дип искә алган иде Гөлсем апа.

Оренбург мәчетен төзергә рөхсәт алгач та мөфти хәзрәтләре аның имам-хатибы итеп Сәет бистәсе мулласы Габдессәлам Габдеррәхим улы әл-Бөгелмәви әл-Габдерине билгели. Ул муллага шул дәвердә, Бохара әмирлеге вәкилләрен каршылау алдыннан, Оренбург ахуны дәрәҗәсе дә бирелгән була. Габдессәлам мулла шул ук губернаның Бөгелмә өязе Габдерахман авылында туган. Авыл мәдрәсәсен тәмамлагач, Каргалыга килеп укыган. Аннары үзе укыган мәдрәсә карамагындагы мәчеткә имам итеп сайланган була. Мөхәммәтҗан мөфти бу кешенең зур эшләр башкара алуына ышанган, әлбәттә. Аның ярыйсы ук белемле булуын да чамалагандыр дип фараз итәсе кала. Һәрхәлдә, бу кешенең киләчәк язмышы мөфтинең хаклы булуын раслый. Алдарак әле без бу олуг шәхес белән тагын очрашачакбыз.

* * *

Әйе, Эчке эшләр департаменты штатында бүлек башлыгы рәвешендә исәпләнүче мөфтиләрнең Россия империясендә дәрәҗәсе дә, вәкаләте дә зур була. Алар үзләре теләгән вакытларда патша җәнаплары белән турыдан-туры элемтәгә керә алган, дип тә язалар. Петербургтагы һәм Кырымдагы патша сарайларының ишекләре алар өчен ачык булган диярлек. Мөхәммәтҗан үз вазифасын үтәгәндә империя белән өч шәхес җитәкчелек итә: Екатерина Икенче, аның улы Павел Беренче һәм Павел улы Александр Беренче. Шиксез ки, Әби патша идарә иткән елларда булмаса да, Павел һәм аның улы Александр тәхеттә утырган дәверләрдә Мөхәммәтҗан Хөсәеневкә алар белән танышу насыйп булгандыр дип фаразлыйк. Шул ук шәхесләрне тәхеткә тәгаенләү чараларына Россия белән чиктәш ил-дәүләт җитәкчеләре дә чакырыла торган була. Бохара, Казакъ, Хива ханлыкларыннан килүче кунакларны Оренбург чик буе шәһәрләрендә каршы алу һәм аларны башкалага озата бару бурычы да мөфтиләргә йөкләнгәнлеге мәгълүм. Соңрак дәвер мөфтиләренең андый вазифаларны башкарганлыгы турында документаль язмалар да сакланган. Мөхәммәтҗан Хөсәенев мөфти вазифасын үтәгәндә дә шундый ук тәртип гамәлдә булгандыр, мөгаен. Мөхәммәтҗан мөфтинең гомер чигенә якынлашканда Россиянең шәрәфле шәхес булып танылуын да әйтеп үтү кирәктер. Аның Казан университетының Алтын медале белән бүләкләнүе дә шул хакта сөйли.

* * *

Патшалар чорында гамәлдә булган мөфтиятнең эчке төзелешенә карата да берничә җөмлә өстик. Урыннардагы имамнар белән элемтә тоту, аларның үз вазифаларын ничек үтәгәнлекләрен күзәтеп тору бурычы йөкләнгән өч казый монда һәр өч ел саен сайланып куела торган була. «Башта казыйлар фәкать мөфтинең ихтыяры һәм теләге белән, «казый булырга фәлән һәм фәләннәр җибәрелсен» дигән аның язуы буенча билгеләнгәннәр», дип бәян итә Ш.Мәрҗани. Соңрак аларны, урыннардагы абруйлырак имамнар фикерен туплап, сайлап куя башлыйлар. Шиһабетдин хәзрәт китабында Мөхәммәтҗан мөфти заманында казый вазифасын үтәгән берничә исем генә теркәлгән. Һәм алар барысы да, мөфтигә электән үк таныш кешеләр булганлыктандырмы, Казан төбәгеннән билгеләнгән муллалар. Исемнәре бу китапта китерелгән казыйларның икесенең Мөхәммәтҗан вафатыннан соң берара мөфти булып торганлыклары да әйтелә. Ш.Мәрҗани иң беренче казый буларак Бәрәскә авылы мулласы Бикчәнтәй әс-Сабавыйны атый.«Дини идарә ачылгач, сайланмыйча гына, Мөхәммәтҗан мөфти соравы буенча Оренбургка казый булып бара», дип яза ул. Тәүге төркемгә кергән казыйларның тагын берсе Казаннан Әбүбәкер Ибраһим улы әл-Казани мулла була. Казый хезмәтен ул берничә нәүбәт башкарган.

Беренче мөфти вафатыннан соң аның кәнәфиен биләгән дип фаразланган мулла Габделҗаббар әл-Орнашбаши икән. Казый вазифасын үтәргә сайланганчы ул Сәрдә белән Орнашбаш авыллары имамы булган. Шиһабетдин хәзрәт аның берникадәр вакыт мөфти вазифасын үтәгәнлеге турындагы хәбәрне бу мулла абыйсының улыннан ишеткәнлеген яза. Димәк, шулай булу ихтималын тәгаен расламый. Татар энциклопедиясенең 2нче томында (7 б.) исә Габделҗаббар мулла мөфти вазифасын башкаручы буларак теркәлгән. Ул хәбәр, мөгаен, хәзрәт китабына нигезләнеп язылган булгандыр. Ләкин Ш.Мәрҗани, икеләнмичә, Мөхәммәтҗан вафатыннан соң бер ел чамасы вакытлыча мөфти булып торучы дип икенче бер казыйны – Әмин Дәмин улы әл-Җәбәли әл-Танавыйны күрсәтә. Тумышы белән Зөя өязе Танай авылыннан, ди. «Нәүбәт буенча Дини идарәгә казыйлыкка сайлана. Мөхәммәтҗан мөфти вафатыннан соң, аның урынына калып, вакытлыча мөфтилек вазифасын үти», – дип яза ул. Яңа мөфти билгеләнгәч, «ул тагын бер нәүбәт, сайланмыйча, мөфти үтенече буенча казый булып тора», ди.

Соңгырак дәвер казыйларыннан безгә ул урынга өч мәртәбә сайланган хәзрәт Ризаэддин Фәхретдинов (Оренбург губернасы Бөгелмә өязеннән), Габдерәшит казый Ибраһимов (Себер тарафындагы Тара каласыннан), Хәсәнгата хәзрәт Габәши (Казан өязеннән, дүрт мәртәбә сайлана), Гыйниятулла Капкаев (Пенза төбәге вәкиле) яхшы таныш. Алар – XIX йөзнең соңгы чиреге белән XX йөз башында татар мәктәп-

мәдрәсәләре эшчәнлеген заман шартларына якынайтып үзгәртү, татар матбугатын ачу һәм таратуга кагылышлы мәсьәләләрне кузгатуда да зур эш башкарган шәхесләр.

Алдынгы карашлы бу казыйлар һәм төрле тарафтан килгән муллалар, зыялылар катнашында 1898 елның гыйнварында Уфада зур җәмәгатьчелек җыены уздырылуын да билгеләп үтик. Ул җыенны оештыручыларның берсе казый Риза Фәхретдинов була. Ул җыенда «Сөйләм телен төзәтмәк, мәктәпне ислах итмәк» җәмгыяте дә оештырыла. (Бу җәмгыятьнең исеме һәм уставы шул җыелышта катнашкан язучы Фатих Кәриминең 1908 елда Казанда нәшер ителгән «Аннан-моннан» китабына кергән.) Истәлекләрдә хәбәр ителүенчә, ул җыелыш рәсми оешмалар рөхсәтеннән башка уздырылган була. Шул сәбәпле мөфти Мөхәммәдъяр Солтанов ул җыелышта катнашырга теләми. Мин авырыбрак торам әле, дигән сылтау белән аның үз авылына ук кайтып китүен искә алалар анда катнашкан кешеләр. Россиянең төрле төбәгеннән җыелган дин әһелләре һәм зыялылар арасында Казаннан «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе вәкиле Таһир Ильясов, Уфадан адвокат Әбүсогуд Әхтәмев (Казан университетын тәмамлаган хокук белгече), Бәләбәй каласыннан морза Хәйдәр Сыртланов, Уфа мөселманнары ахуны һәм «Госмания» мәдрәсәсе мөдәррисе Хәйрулла хәзрәт Госманов, Оренбургтан башлангыч мәктәпләр ачу һәм тотуда зур эшләр башкарган Габделгани бай Хөсәенев һ.б. була. Мөселман мәктәп-мәдрәсәләре эшчәнлеген үзгәртеп кору, милли язма тел тәртипләренә үзгәрешләр кертү максатыннан чыгып, шул эшләрне башлап җибәрү өчен ул мәҗлестә катнашучылардан күпмедер күләмдә акча да җыела. Ул җәмгыятьнең рәисе итеп Хәйрулла ахун Госманов сайланган була. Ләкин киләчәктә җәмгыять күзгә күренердәй зур эшләр башкара алмады, дип искә ала Ризаэддин хәзрәт Фәхретдинов. «Җәмгыять гайре рәсми булдыкыннан, эш башында утыручы чиновниклардан саклану тиешлегеннән, аның хакында һичкайда бернәрсә язылмады», дип тәмамлый хәзрәт шул җәмгыятькә багышланган истәлекләрен.

Мөхәммәдъяр Солтановның патша фәрманы белән билгеләнгән бишенче мөфти (1886-1915) булуына карамастан, башкала түрәләре алдында үзен бик сак тотканлыгы турында язалар. Мөфти кәнәфиенә ул 49 яшендә, «акыл утыргач» тәгаенләнә. XIX йөзнең соңгы чирегендә, казакъ, үзбәк, азәрбайҗан телләрендә газеталар чыгып килгән бер вакытта, Рәшит казый Ибраһимов һәм башкаларның аңа татарча газета чыгару өчен рөхсәт алышырга ярдәм итүен сораганлыгы, ләкин мөфти хәзрәтләренең андый эшкә алынмавы турында да хәбәрләр бар. Шундыйрак вакыйгаларны да истә тоткан татар зыялыларының да үтенечен искә алып бугай, 1915 елның урталарында чираттагы мөфти итеп «патша сарае утарында үскән» Петербург ахуны Мөхәммәтсафа Баязитовны билгелиләр. Аның атасы Гатаулла хәзрәт тә, соңрак Сафа мәхдүм үзе дә, Петербургта гади имам вазифасын үтәүдән тыш, патша сараен саклаучы һәм патшаларны даими рәвештә саклап, озатып йөрүче «Кавказ мөселманнарыннан» торган сак отряды мулласы да булган шәхесләр. Ләкин Сафа мәхдүмгә мөфти кәнәфиендә озак утырырга, игелекле эшләр башкарырга насыйп булмый. 1917 елның февралендә башланган түнтәрешләрдән соң аны Оренбург диния нәзарәте идарәсе рәисе вазифасыннан халык үзе азат итә. Шул елның май ае башында уздырылган Бөтенроссия мөселманнарының корылтаенда, демократик рәвештә имза салу нәтиҗәсендә, мөфти итеп Казан мулласы Галимҗан хәзрәт Баруди сайлап куела. Ил башлыклары карары белән мөфтиләрне билгеләп кую тәртибе бетерелә. Әлбәттә инде, ил күләмендәге андый зур кәнәфине биләүчене сайлап кую тәртипләре соңрак бераз үзгәртеләчәк. Хәзерге



*Галимҗан Баруди*

заманның күпсанлы төбәк мөфтиләренең төбәк җитәкчесе тәкъдимен истә тотып сайланганлыгы һәрберебезгә мәгълүм. Әмма революциядән соңгы бер дәвердә алар фәкать дин әһелләре тарафыннан сайланып куела торган булалар.

**6**

Алда әйтеп кителгәнчә, Мөхәммәтҗан мөфти 1823 елның декабрь ахырлары белән киләсе елның гыйнвар башы аралыгында вафат була. (Мөселманча ай һәм ел исәбе белән хәзерге заман ел исәбен төгәлрәк тәңгәлләү шактый читен.) Җәсәден Уфадан алтмыш чакрым ераклыктагы Атҗитәр авылы зиратында җирлиләр. Бу авыл һәм аның тирәләрендәге берничә мең дисәтинә җир аңа өлешчә хөкүмәт тарафыннан билгеләнгән, өлешчә сатып алынган була. Аның ике хатыны, бер улы, ике кызы булган дип фаразлана. Шиһабетдин хәзрәт мөфтинең Гайшә исемле бер хатынын гына искә ала. Гайшә Төркиядә затлы гаиләдә туган, ике ил арасында барган бер сугыш вакытында Россиягә эләгеп, Казан ратушасы рәисе Исмәгыйль Апанай улына икенчеме, өченчеме хатынлыкка бирелә. 1794 елда ул ире вафат булгач, тол калган яшь хатынына Мөхәммәтҗан мөфти өйләнгән, дип хәбәр итә Ш.Мәрҗани (220 б.). Мөфтинең кече кызы һәм кияве белән таныш булган Казан университеты профессоры Карл Фукс исә аның Кәримә исемле хатынын гына искә ала. Мөфти вафат булгач, император Александр Беренченең карары белән «Кәримә бикәгә мең ярым сумлык еллык пенсия билгеләнгән», дип яза ул.

Мөфтинең «тәртипсез вә тәүфыйксыз Мирзаҗан (Мирзакай) исемле углы»ның никахсыз рәвештә бер марҗа белән яшәвен, шуңардан «никахсыз уллары» булуын без шулай ук Шиһабетдин хәзрәт китабыннан укып беләбез. «Мөфтинең озак гомер итеп, 1860 елда вафат булган хатыны, ахыр гомерендә Уфага килеп, барлык мөлкәтен дин исламда тормаган шушы оныкларына васыять итеп калдыра», дип тә язган ул. Мөгаен бу бала да Кәримә улы булгандыр.

Мирзаҗан гаиләсенә бәйле вакыйгада олуг хәзрәт белән тулаем килешәсе килми. Гәүрләрне иманлы итү һәр мөселманның изге бурычы лабаса. Мөгаен, Мөхәммәтҗан мөфти дә имансыз киленен иманлы итү чарасын күргән, тагын бер саваплы гамәлне үтәгән булгандыр.

Исмәгыйль Рәмиевнең 1966 елда «Казан утлары» журналында басылган бик кызыклы,«Мәдрәсәдән – университетка» дип исемләнгән мәкаләсенә дә күз төшереп алыйк. Казанда беренче гимназия 1759 елдан эшли башлый. «1767 елдан анда татар телен укыту өчен татар классы ачыла. Баштарак анда татар теле, аннары гарәп, фарсы телләре дә укытыла», дип яза автор. Ләкин 1809 елга чаклы татар балалары бу гимназиягә кереп укымаган икән. Мәкалә авторы гимназия директорының шул елда язган исәп-хисап докладыннан түбәндәге юлларны китерә. «Мөфтинең улы да укырга керде. Ул русча, французча, татарча сөйләшә. Беркадәр гарәпчә дә белә. Мөфтидән үрнәк алып, бәлкем татар байлары да үз улларын гимназиягә бирерләр», дип тә хыяллана гимназия директоры. Бу өзекне укыгач аңлашыла ки – Мирзаҗан бу уку йортына килеп кергәнче кайсыдыр уку йортындамы яисә өй шартларындамы шактый зур тырышлык күрсәткән. Байтак телләрне үзләштергән булган.

Директорның уку-укыту идарәсенә язылган исәп-хисап хатыннан шунысын да ачыклыйсың – бу уку йорты татар балалары өчен бөтенләй үк ябык булмаган икән. Ләкин безнең зыялылар ул уку йортына балаларын Мирзакайдан соң тагын байтак вакыт үткәч кенә даими рәвештә китерә башлыйлар. Мөхәммәтҗан мөфти урыннардагы муллалар исеменә махсус хат язып таратканнан соң, 1820 елларгача монда тагын ике казакъ баласы белән Казан морзасы Мөхәммәт Алкин улы Шаһиәхмәт кенә укыганнар, диелә мәкаләдә. Якындагы губернияләр стипендияләре исәбенә монда кереп укучылар саны егерменче еллар ахырыннан, Казан уку-укыту идарәсе башлыгы итеп либерал М.Н. Мусин-Пушкин билгеләнгәч кенә арта башлый. И.Рәмиев китергән исемлектә стипендиат гимназист һәм студентларның күбесенең Оренбург губерниясе идарәсе тарафыннан бирелгән акчага укыганлыгын да билгеләп үтик. Ләкин ул вакыйгаларга хәтле әле тагын ун еллап вакыт узасы бар.

Ә Казан гимназиясе бусагасын беренче булып атлап кергән, килгән дәвердә берничә

тел белүе сәбәпле, директорда соклану хисе уяткан гимназист исә монда озак укымый. «Мөфти улы Мирзаҗан монда укуы һәм өлгереше белән бернинди дә эз калдырмый. Гаилә күзе астыннан ireккә чыккач, кала җирендә тәртипсезләнеп, рус кызына өйләнеп, өенә кайтып китә ул», дип хәбәр итә И.Рәмиев.


*Мөфтинең оныгы генерал Гобәйдулла Чыңгыз*

Мөфтинең олы кызы турында мәгълүмат бик аз. Аның бер казакъ солтанына кияүгә чыгуы, гомерен ерак дала шартларында уздырганлыгы турында кыскача гына хәбәр бар. Ләкин ул хәбәр дә документаль рәвештә расланмаган. Ә кечесе исә укуда да, тормышта да зур уңышларга ирешә. Шул кызга – Фатыймага багышлы мәгълүмат Россиянең бәк һәм морзалары тарихын чагылдырган бик саллы бер китапта да теркәлгән. Дөрес, анда кызның исеме аталмаган. Ә аның киявенең исеме дә, дәрәҗәләре дә ул бай белешмәлектә бар. 1886 елда Санкт-Петербургта нәшер ителгән «История родов русского дворянства» хезмәтенең икенче томындагы 55-56нчы битләрне ачыйк. Ул битләрдә кайбер казакъ иле ханнарына кенәз дәрәҗәсе бирелүе, аларның Чыңгыз нәселе варислары булганлыгын тану хәбәр ителә. Җиһангир исемле безгә бераз таныш ханның ике хатыны булуы, кече хатынының «Оренбург мөфтие кызы» икәнлеге дә әйтелә анда. Шул пардан аларның дүрт ир-егет Чингизидлар туган, диелә: Сәхибгәрәй, Ибраһим, Әхмәт, Гобәйдулла. Һәм ике кызлары булуы теркәлгән. Зөләйха исемлесенең «полковник Тәфкилевтә кияүдә» икәнлеге дә аерып күрсәтелгән.

Казан университеты профессоры Карл Фукс китабын кулга алсак, мөфтинең кече кызының Фатыйма исемле булганлыгын ачыкларбыз. Татарлар арасында табиб буларак та танылган Карл Фукс Фатыйма белән аның ире Җиһангир ханның 1826 елның көзендә Казанда булу вакыйгасына зур хезмәт багышлаган. Шушы көздә хан белән беренче мәртәбә очрашуын да искә ала ул.

Җиһангир хан белән якыннанрак танышып үтик. Алдарак без Кече Җөз ханы Нургалинең 1785 елның ахырында гаиләсе һәм якыннары белән үз иленнән Уфа шәһәренә сөрелүе турында әйтеп узган идек. Шул вакыйгадан соң аның тәхетенә энесен утыртканлыклары турында да сүз булды. Шуннан соңрак Нургалинең өлкән улы Бүкәй дә ул тәхеткә ия була. Ләкин ул тәхет тирәсендәге дәгъвалар тиз генә тынмый. Ишле хатын белән торган ханнарның уллары бер атадан тусалар да, еш кына алар төрле ыруг вәкилләре булып та саналалар бит. Һәр ыругның үз кешесен тәхет кәнәфиендә күрәсе килгәнлектән, алар арасында җитди генә бәрелешләр, бер атадан туган ир затларының бер-берсен үтерешүләре дә еш кабатланган. Шундый ук хәлләр Россия тарихында да булгалап торган ич. Әйтик, яшь Пётр патша белән аның апасы София арасындагы көрәшне ике ана вәкилләре арасындагы көрәш дип тә бәяләргә тиешбез. Дөрес, кайбер тарихчылар андый хәлләргә артык әһәмият итмәскә тырыша. Ә кайбер очракта хәтта патша варисы дип йөртелгән ул баланың чын атасы әлеге патша түгеллегенә күз йому очраклары да күзәтелә.

Кече Җөз ханлыгындагы вакыйгалар Оренбург губернаторын да, аның кул астындагы Чик буе комиссиясе кешеләрен дә бик борчый. Мөхәммәтҗан мөфтигә дә якын чик буенда барган бу гаугалы хәлләрдә еш катнашырга туры килә. Шул ызгыш, талашлардан котылу өчен бераздан соң Кече Җөз биләмәсен икегә бүлү карарына киләләр. Һәм 1812 елда, император Александр Беренче карары белән шул биләмәне бүлеп, Россиягә якын чик буе өлешендә яңа Бүкәй Урдасын оештыру килешүләренә кул куела. Бүкәй ханның оныгы Җиһангир егерме яшендә, 1823 елда, шул Урданың икенче ханы буларак тәхеткә утыртыла. Төркичә «бине-бине»ләп китерелгән шәҗәрәне русчалаштыргач, тәхеткә тәгаенләү фәрманында ул Җиһангиргәрәй Нургали улы Бүкәев рәвешендә языла.

Шушы яшь хан 1826 елда Николай Беренчене тәхеткә тәгаенләү тантанасында

катнаша. Шул вакыйгада катнашкан өчен император аңа һәм юлдашларына Россия империясе орденнарын тапшыра, кыйммәтле бүләкләр бирә. Шуннан соң хан, иленә кайтышлый, Казанда дүрт көнгә туктала. Бу хәл октябрь урталарына туры килә. Аны озата йөрүче солтан һәм старшиналары арасында үз мулласы, «нугай» Ает Мөхәммәт тә була. Хан гаиләсе Казан сәүдәгәре Муса өендә дүрт көн яши. К.Фукс аерып әйтмәсә дә, бу «Шурба Муса» дигән кеше дә, мөгаен, императорга таҗ кидерү вакыйгаларында катнашкан яисә сәүдә эшләре белән башкалага барган булгандыр. Хан белән алар шунда танышканнардыр, дип фаразлыйк.

«Ханга – 24 яшь. Европалыга тартым аксылрак йөзле... чибәр генә кыяфәтле, ягымлы карашлы. Рус телендә бик иркен сөйләшмәсә дә, һәр сүзне дөрес итеп куллана белә. Русча язуы да килешле, әйбәт... Рус һәм татар телләреннән кала фарсы, гарәп телләрен дә белә...» дип яза К.Фукс аның турында. Галимнең шушы сүзләренә таянып, без казакъ ханнарының элек-электән үк татар бәк-морзалары белән якыннан аралашып яшәгәнлекләрен дә чамалый алабыз. Яшь ханның рус телен яхшы ук үзләштерүенә килгәндә, башта казакъ кардәшләрнең 1957 елда чыгарган китабына да күз төшерик («Присоединение Казахстана к России», Мәскәү). Анда: «Җиһангир берникадәр вакыт Әстерхан губернаторы Андриевский өендә тәрбияләнә», дип язылган. Ә фарсыча, гарәпчә белемне кайда һәм кайчан үзләштерүе турында хәбәр юк. Андый хәбәрне укучыга җиткерер өчен татар мәдрәсәсен искә алырга кирәк булыр иде шул. Аның Оренбургның хәзерге Левашев урамында урнашкан беренче таш мәчете карамагындагы махсус мәдрәсәдә укыганлыгына бер дә шикләнәсе түгел. Алдарак без Әби патша карары белән бу мәдрәсәнең казакъ түрәләре балаларын укытыр өчен махсус ачылганлыгын әйтеп үттек ич.

Казанга килгән ханбикә Фатыймага унҗиде яшь тулган. Ул үзләре тукталган сәүдәгәр Муса өендә профессор Фукс хатыны, шагыйрә Александраны кунакка ала. Чәйдән соң алар диванга утырышып бик иркенләп гәпләшәләр. «Фатыйманың теле русча җырлап тора, бер дә рус кешесеннән аерырлык түгел» икән. Йөз-кыяфәте дә ягымлы, күркәм. Ул бик нәфис итеп тегелгән атлас күлмәктән, аның өстеннән затлы камзул кигән. Муенында зиннәтле муенса, калфагы җем-җем килеп торучы энҗе бөртекләре белән бизәлгән. Җиһангир Фатыймага өч ел элек, хан тәхетенә тәгаенләнү фәрманын алган елда өйләнгән. Шул туйдан соң ук диярлек Фатыйманың әтисе вафат була. Әнисенә, Кәримә бикәгә патша әмере белән зур гына пенсия билгеләнә. Фатыйма ханның яшь хатыны икән. Казанга сәяхәттә катнашмаган хатыныннан ханның ике улы – җиде һәм биш яшьләрдәге Искәндәр белән Зөлкарнәй бар, дип хәбәр итә К.Фукс.

Фатыйма кемнән һәм кайчан рус шагыйрәсе белән тиңдәш булырдай итеп русча сөйләшергә өйрәнгән соң? Профессор Фукс ул хакта берни дә язмый. Фатыйма туганда мөфтият инде Уфада урнашкан була. Димәк, аның бала чагының бер өлеше шушы калада узган. Җәй айларын алар, билгеле, Мөхәммәтҗан «алпавытның» ул вакыттагы «үз авылы»нда, Уфадан алтмыш чакрымдагы Атҗитәрдә үткәргәннәрдер. Хөкүмәт карамагындагы идарә башлыгы буларак, мөфти хәзрәтләренең үз балаларын Петербургның иң дәрәҗәле уку йортларында укытырга мөмкинлеге дә булган. Фатыйма да шундый уку йортларының берсендә беркадәр белем алгандыр, мөгаен. Казакъ халык шагыйре Олжас Сөләйманов та, 2007 елның көзендә Казанда булганда, шундыйрак фикер әйткән иде. Карл Фуксның истәлек язмалары да шул фикерне раслый.

Җиһангиргәрәй Бүкәй хан Саратов губернасы чигендәге үз утарында 1845 елда вафат була. Бу вакытта инде ул, хан булудан бигрәк, Россиянең рәсми рәвештә расланган кенәзе санала. Генерал дәрәҗәсендә була. Кенәз статусын алгач ул, һәм аның балалары, Чыңгызхан варислары икәнлекләрен яшермичә, Җиһангир Чыңгыз, Гәрәй Чыңгыз рәвешендә йөриләр.

Патша Россиясендә кенәз дәрәҗәсе бик сирәк шәхесләргә бирелгән. Димәк, ул шәхес һәм аның варислары патша нәсел-нәсәбе белән тиңләшә дигән сүз. XVIII-XIX йөзләрдә Россиядә рус милләтеннән булмыйча кенәз дәрәҗәсен алучылар күп түгел. Кайчандыр үз ил-мәмләкәтенә хуҗа булган, төрле яклап кысканнан соң, казакъ ханы

Әбелхәер кебек, «үз теләге белән» Россиягә кушылырга мәҗбүр ителгән грузин патшалары нәселе дә шундыйлардан. Нугай урдасы идарәчеләреннән Ырыс бәк (русча язмада Урус бәк, кенәз Урусовлар) белән Йосыф морза (кенәз Юсуповлар) варислары да шул бик кыска исемлеккә керә.

Соңгы чор казакъ ханнары, бигрәк тә Бүкәй Урдасы вәкилләре – кардәш-ыру төрки халыклар мәдәниятен үстерүгә билгеле бер күләмдә өлеш керткән шәхесләр. Җиһангир һәм аның варисларының Саратов губернасы чигендәге европача төзелгән утарына татарның зыялы кешеләре дә, Казан университеты галимнәре дә еш килгәләп йөргән. Җиһангир аларга бик кыйммәтле китап һәм кулъязмаларны табып һәм алып бирешүдә булыша торган була. Бу йорт-утар хуҗаларының Казан галимнәреннән Карл Фукс, Николай Катанов һ.б.лар белән еш аралашкан булуы бәян ителә. Бу традиция Җиһангир хан вафатыннан соң да дәвам иттерелгән. Фатыйма ханбикәнең озак гомер кичергәнлеге мәгълүм. Аның уллары Россия дәүләтенә хезмәт иткән кенәзләр булалар. Фатыйманың «История родов...» китабында Ходжа рәвешендә теркәлгән кызының язмышы әлегә миңа билгесез. Зөләйха, алда әйтелгәнчә, татар морзалары Тәфкилевләр килене була. Ә Тәфкилевләрнең язмышы Оренбург белән Каргалыга да элек-электән бәйле ич. Элек-электән Тәфкилевләрнең зур җир биләмәләре һәм затлы утарлары шунда була. Ул утар корылмалары әле Совет хакимияте елларында да бар иде. Оренбург янәшәсендәге ул утарда Ленин исемендәге данлыклы совхозның үзәге урнашкан иде.

## 7

Мөхәммәтҗан вафат булганнан соң икенче рәсми мөфти бер ел үткәч кенә билгеләнә. Аңа чаклы Оренбург төбәгендә бик зур вакыйгалар булып уза. 1824 елның сентябрь ае башында монда император Александр Беренче килеп китә. Аны каршылау, озатып йөрү, Төркестан тарафыннан император белән күрешергә дип килгән хан-солтаннарның көен көйләү кебек мәшәкатьләр ул җәйдә мөфти вазифасын вакытлыча башкарган Әмин Дәмин улы әт-Танавый белән Оренбург ахуны Габдессәлам бине Габдеррәхим әл-Бөгелмәви өстенә төшә. Шушы җәйдәге бик тә мәшәкатьле бурычларны үтәгәндә аеруча зур эшләр башкарып, Габдессәлам ахун император тирәсендәге түрәләрнең күңеленә хуш килгәндер, күрәсең. Император Александр киләсе елның җәй ахырларында аны мөфти итеп тану турындагы фәрманга кул куя. Һәм хәзерге Әлмәт төбәгенә кергән Габдерахман авылы кешесе шуннан соң унөч ел дәвамында ул вазифаны үти (1825-1838).

Мөхәммәтҗан мөфти бу мулланы халыкара мөнәсәбәтләр өлкәсендә электән үк сыный башлаган була. Иң әүвәл ул аны Бохарадан Россиягә илче булып килүче зур бер төркемне каршы алу эшләренә җәлеп итә. Бу вакыйга 1799 елда була. Аннары, алдарак хәбәр ителгәнчә, ул аңа Оренбургтагы таш мәчетне һәм чит ил шәкертләре өчен диебрәк төзеләчәк мәдрәсәне сафка бастыру бурычын йөкли. Алар төзелгәч, аны шул мәчетнең имам-хатибы һәм мәдрәсә мөдәррисе итеп билгели. Габдессәлам бу бурычларның барысын да тиешенчә үтәп, башкарып чыккандыр, күрәсең. Соңрак Хива ханлыгыннан килгән илчелек вәкилләрен каршы алу, озатып йөрү вазифалары да аңа йөкләнәчәк. Һәм ул, гадәттә, килгән кунаклар белән губерна түрәләре арасында арадашчылык йөкләмәләрен дә бик уңышлы башкарып чыгачак.

Әйе, бу мулла шактый ук өлгер, үткен һәм үз чорына күрә белемле кеше булган. Рус телен дә яхшы ук үзләштергәнлеге император җәнапларын каршы алу һәм озатып йөрү вакыйгаларында чамалана. Бохарадан һәм соңрак Хивадан килгән илчеләрне кабул иткәндә ул губернатор җәнаплары алдында да абруй казанып өлгерә. Ә инде 1824 елның сентябрендә Оренбургка император Александр Беренче килгәч, Габдессәлам ахун мөфти кәнәфиен биләрлек дәрәҗәдә тырышлык, өлгерлек күрсәтә. Мөфти буласы килеп йөргән кайбер көндәшләрен күпкә артта калдыра.

Император Оренбургта биш көн була. Патша җәнапларын каршыларга дип Бүкәй Урдасыннан да зур вәкиллек килә. Габдессәлам ахун элекке шәкерте, яңарак кына хан тәхетен биләгән Җиһангиргәрәй һәм аның өч бәк-солтаны белән бергә император тарафыннан кабул ителә. Шулай ук ул губернатор П.К.Эссен белән бергә императорны

шәһәрдәге хәрби казармалар, хастаханәләр һ.б. оешмалар белән танышып йөрү сәяхәтендә дә озата йөри.

Габдессәлам мулла мөфти кәнәфиен биләгән дәвердә исә Оренбургка булачак император Александр Икенче дә килә. Аның белән тәрбияче остазы шагыйрь Василий Жуковский да була. Шиһабетдин Мәрҗани китабында бу тарихи вакыйгалар искә алынмаган. Икенче мөфти эшчәнлеген бәяләгән бүлектә без фәкать түбәндәге ике җөмләгә генә игътибар итә алабыз. «Оренбургта булган Россия вәкилләренә үзен мәгърифәтле һәм алар белән бердәм итеп күрсәтә. Оренбург губернаторының таләбе һәм үтенече нигезендә мөфти була», диелгән анда. Һәм бу мөфтинең вафат булган 1254 елы (1838) да, җеназасының Уфада җирләнгәне генә хәбәр ителә хәзрәт китабында. Гаилә тормышына кагылышлы бер җөмлә дә язылмаган. Ш.Мәрҗани, ни сәбәпледер, Габдессәлам мөфти тырышлыгы белән Уфа каласында төзелгән яңа мәчет турында да искә алмый. Ә шул мөфти эшчәнлеген тасвирлап поэмалар иҗат иткән Гомәр Мөхәммәт улы әсәрендә ул факт теркәлгән, дип яза әдәбият галиме Мәсгут Гайнетдинов. Габдессәлам мөфти үтенечен үтәп, ул мәчетне Казан төбәгендәге Оры авылы сәүдәгәре Габделмөэмин Туктамышев-Хуҗасәетов үз акчасына төзеткән, дип яза галим.

Әйе, бу мөфтинең тормышына һәм эшчәнлегенә кагылышлы тулырак мәгълүматны Сәет бистәсе шагыйре Гомәр бине Мөхәммәт Каргалыйның аңа багышланган ике зур шигъри әсәреннән укып белергә булыр иде. Ләкин әле ул әсәрләрнең барын бүгенге заман укучысы белми диярлек. Башына чалма кигән затларга багышланган андый әсәрләр Совет хакимияте дәверендә кабат басылмадылар ич. Бохара, Үргәнеч кунакларын кабул итү вакыйгалары шагыйрьнең «Тәзкирәи Габдессәлам мөфти» (1832) поэмасында бәян ителсә, булачак Александр Икенче патшаны Оренбургта кабул итү күренешләре «Сәфәрнамаи шаһзадә Александр» (1837) дигән күләмле әсәрдә чагылыш тапкан була. Шаһзадә Александр Оренбургка 1837 елның июнендә килә. Мөфти буларак, Габдессәлам аны берничә көн дәвамында озатып йөри. Казакъ ханлыгы чигенә якын торган Тозтүбә каласына да шаһзадәне озатып йөрүчеләр белән бергә бара. Казакъ хан-солтаннары белән бергә оештырылган бик зур милли бәйгебәйрәмнең әйдәүчесе дә мөфти хәзрәтләре була. Ул бәйгедәге ат чабышы ярышларында һәм башка төр хәрби уеннар күренешен тасвир итүдә татар, башкорт атлы казаклары да, күрше казакъ ханлыкларыннан килгән җайдаклар да катнаша. Тәхет варисы уздырган, санаулы сандагы мөселман өммәте вәкилләре дә катнашкан зур мәҗлес тә, әлбәттә, мөфти Габдессәламнән башка узмый.

Бу сәяхәт вакытында булачак императорны укытучы-тәрбиячесе, күренекле шагыйрь Василий Жуковский озата йөргән, дидек. Мәгълүм ки, шагыйрьнең анасы Салиха татар нәселеннән була. Һәрхәлдә, без укыган еллардагы дәреслекләрдә шулай язылган иде. Хәзер ничектер. Әйе, хәзер бит күренеклерәк шәхесләрнең биографиясендәге татарга бәйле урыннарны төшереп калдыру тәртибе өстенлек итә башлады. Дөрес, шагыйрь үземе, яки биографиясен әвәләүчеләрме, аның анасының милләтен «турчанка» дип яздылар. Ягъни, ул элекке Касыйм ханлыгы биләмәсендәге Биләү шәһәрчегендә туган «төрек кызы» булып чыга. Икенче бер рус шагыйре – Константин Бальмонт та, кемгә ияреп тер, Урал төбәгендә туган анасын татар нәселеннән дип атаудан тартынып, «анам шигъри җанлы турчанка иде» дип яза ич. Шигърияткә яшьли күңел бирүем дә анам тәэсиреннән килә ди, 1914 елда «Нива» журналында чыккан автобиографик мәкаләсендә.

Жуковскийның анасы бер алпавытта хезмәт итә һәм шул кешедән бала таба. (Без укыган дәреслекләрдә аны алпавыт йортында «ключницей была» дип яздылар.) Патша Россиясе заманында шундый тотнаксыз алпавытлардан туган «атасыз» балалар адым саен очрап торган. Теләсә кайсы крепостной кызны алпавыт үз кәнизәге итә алган. Аннары ул кызны көмәнле килеш яисә яшь баласы белән берәр крепостнойга кияүгә бирә торган булганнар. Шундый ук язмышлы үги балалар арасында күренекле шәхесләрдән шагыйрь Афанасий Фетны, рәссам Орест Кипренскийны, Оренбург губернаторы генерал Василий Перовскийны һ.б. бик-бик күпләрне атап китеп булыр иде.

Салихадан туган Василий әз-ким генә булса да үз анасы телен дә белгәндер, дип фаразларга мөмкин. Бу очрак та шаһзадәне озатып йөрүче Габдессәлам мөфти белән җирле шагыйрь Гомәр Мөхәммәтев файдасына булгандыр, билгеле. Гомәрнең бер поэмасының рус теленә тәрҗемә ителү вакыйгасы да шул фаразны раслый сыман. Аның Петербург яисә Ташкент архивларында сакланган поэмаларын укый алган очракта, без ул тасвирлаган вакыйгаларны һәм шул вакыйгаларда катнашкан Габдессәлам мөфти эшчәнлеген тагын да тулырак итеп күзаллаган булыр идек. В.Жуковскийның да шаһзадәне озатып йөрүгә бәйле көндәлек язмалары да булган. Алар 1902 елгы «Русская старина» журналында нәшер ителгәннәр. Ләкин безнең Милли китапханәдә дә, Россия Фәннәр академиясе филиалы китапханәсендә дә ул журналның нәкъ шул 1837 елга караган көндәлек язмалары кергән саннары юкка чыккан икән. Шул сәбәпле бу олуг шәхеснең, патша җәнапларыннан тыш, А.С.Пушкин да аны үз остазым дигән шагыйрьнең Оренбург төбәгенә бәйле сәяхәтнамә язмалары белән әлегә танышып булмады...

Шагыйрь Гомәр Мөхәммәт иҗатын барлар вакыт та җиткәндер, шәт.

1910 еллар башында Гомәр Дәүләтьяров хәлфә Каргалыдагы бер мәчет чормасыннан Габдессәлам мөфтинең үз көндәлек язмаларын табып ала. Аларны Ризаэддин хәзрәт Фәхретдиневкә илтеп тапшыра. Һәм ул көндәлек язмалары 1913 елгы «Шура» журналының алты санында басылып чыгалар.

Алдарак әйтелгәнчә, Шиһабетдин хәзрәт Габдессәлам мөфти эшчәнлегенә, ни өчендер, бик аз туктала. Аның кылган эшләрен аерым искә алмый. Гаилә әгъзалары да бер дә телгә алынмыйлар. Бәлкем, Каргалы шагыйре Гомәр Мөхәммәт улының бу мөфтигә багышлап иҗат ителгән күләмле ике поэмасы барлыгын белгәнлектән, ул шулай эшләгәндер. Мөфтинең балаларыннан улы Гыйният кенә алда тасвир ителгән поэмаларның беренчесендә телгә алына, дип яза әдәбият галиме Мәсгуд Гайнетдинов.

Гомәр Мөхәммәт улының хәзергә мәгълүм булган өч күләмле әсәреннән ике поэмасы Петербург архивларында һәм берсе Ташкенттагы Көнчыгышны өйрәнү институтының кульязмалар бүлегендә саклана икән. «Тәзкирәи Габдессәлам мөфти» поэмасы – татар әдәбиятына үзенчәлекле яңалыклар алып килгән, татар тормышындагы кайбер үзгәрешләрне чагылдырган әсәр... Аның тагын бер мөһим яңалыгы – реаль вакыйгаларның гадәттән тыш географик киңлеге. Сөйләм Оренбург, Петербург, Таганрог, Уфа вакыйгаларына күчеп тора...» дип бәяли аларны М.Гайнетдинов. Әйе, шушы ике поэманың эчтәлеге белән таныш кеше Габдессәлам мөфти эшчәнлеген дә тулырак бәяли алачак. Шуның өчен генә булса да ул поэмаларны яңадан бастырып чыгару кирәктер. Кемнәребез алыныр икән шундый зур, кирәкле эшне башкарып чыгарырга? Шулай ук мөфтинең үз көндәлек язмаларын да бүгенге мөселман укучылары кулына кайтарып бирү зыян итмәс иде...

## 8

Шундый ук дәрәҗәдәге тагын бер шәхесне – гаскәри хезмәттән мөфтилеккә тәгаенләнгән Сәлимгәрәй Шаһингәрәй улы Тәфкилевне дә өлешчә Каргалыга һәм Оренбург төбәгенә мөнәсәбәте булган кеше дип санарга хаклыбыз. Ул 1865-1884 елларда дүртенче кеше буларак рәсми рәвештә мөфти кәнәфиен биләгән шәхес. «Татар энциклопедиясе»ндә Сәлимгәрәй мөфтинең 1805 елда Алабуга өязендә туганлыгы, 1885 тә Уфада бакый дөньяга күчкәнлеге теркәлгән. Шиһабетдин хәзрәт китабында Тәфкилев бәк-морзаларының Чыңгыз ханга барып тоташкан озын шәҗәрәсе китерелә. Шунда ук алар хакында «хан балалары токымыннан» дигән җөмлә дә өстәлгән. «Сәлимгәрәй 1852 елда хаҗ сәфәренә юнәлә. Истанбулда солтан Габделмәҗид хәзрәтләре янына кереп, аны сәламләп чыга», дип тә язылган анда. (Бу очракта сүз Төркия башлыгы турында бара. Башка төркиләр, шул исәптән казакълар илендә исә солтан дип хан балаларын атаганнар.) Бу хаҗиның бабасының атасы «Котлыгмөхәммәд морза, 1147 (1734) елда Россия гаскәре белән килеп, Оренбург шәһәренә нигез сала… Россия хөкемендәге мөселманнардан әлегәчә болар кадәр бай һәм дәүләт иясе булган кешеләр мәгълүм түгел», дип тә яза Ш.Мәрҗани. Әлбәттә,

бу очракта «мөселман» төшенчәсен «татар» сүзе белән алмаштыру кирәктер. Чөнки алдарак берничә мөселман өммәте вәкиленең Россиянең патша йорты вәкилләре генә йөрткән кенәз дәрәҗәсенә лаек булулары турында да сүз барган иде. Тәфкилевләр дәрәҗәсендәге байлык иясенә тиңләрдәй Кавказ төбәге мөселманнары да булгандыр, бәлки.

Сәлимгәрәй һәм аннан соң килгән Мөхәммәдьяр мөфтиләр элек дини дәрәҗәләргә ия булмаганнар. Алар икесе дә әүвәлрәк хәрби каста төркеменә кергән шәхесләр. Шул сәбәпле кайбер дин әһелләре аларны бик үк өнәп тә бетермәгәннәр. Сәлимгәрәй мөфтинең зурдан кубып башкарган тәүге эше буларак, бу дин идарәсенең Уфа шәһәрендәге бина-утарын төзеп бетерүе санала. Тәүге тарафтарак ул шуның белән шөһрәт казанган шәхес. Илнең төрле төбәгендә эшләп килүче мәчет, алар карамагындагы мәктәп-мәдрәсәләр белән танышуга да ул зур әһәмият биргән. «Сәяхәт кылырга ярата. Кешеләргә дус һәм яхшы күренергә тырыша... Теле белән әсир итә торган зат... Ләкин, карашында тотрыклылык булмаганлыктан, күп эшләре тәмамланмыйча, ярты юлда калды. Еш кына үз әмерен үзе бозар иде... Сиксән ике яшендә вафат булды, Уфа шәһәренең таш мәчете күршесендә җирләнде. Балалары булмады», диелә «Мөстәфадел-әхбар...» китабында Сәлимгәрәй мөфти турында.


Алда билгеләп үтелгәнчә, Тәфкилевләрнең иң тәүге зур җир биләмәләре Каргалы авылы тирәлегендә булып, төп утарлары да аның янәшәсендә урнаша. Ә ерак бабасы исемен йөртүче соңгы морза, Котлымөхәммәд Батыргәрәй улы Тәфкилев, патша чорындагы дүрт чакырылыш Дәүләт думасы депутаты, ул җир биләмәләренең ике мең дисәтинәдән артыграгын Мәхмүт бай Хөсәеневкә сата, дип язган идек алдарак. Бу морзаларның икенче зур җир биләмәләре дә шул ук Оренбург губернасының Бөгелмә өязендә була. 1848 елдан ул биләмәнең төп хуҗасы буларак Сәлимгәрәй Тәфкилев исәпләнә. Шул ук елда ул Бөгелмә өязе алпавытларының җитәкчесе итеп тә сайлана. Һәм үз утарында хәзергәчә үзенчәлекле архитектура истәлеге булып саналган затлы сарай төзетә. «Мөфти итеп билгеләнгәч, ул берничә мәртәбә Казанда була, Тифлис ягына да барып кайта», дип яза Ш.Мәрҗани. Ләкин Кавказ төбәге биләмәсенең үзәге булган, императорның шул тәбәктә яшәүче барлык милләт вәкилләре өстеннән җитәкчелек итүче вәкиле – наместнигы утырган Тифлис (бүгенге Тбилиси) каласына ни өчен барганлыгы әйтелми. Дөреслектә ул анда мөселманнарның сөнни мәзһәбенә керүчеләре өчен ачылган мәчеткә бәйле берәр төрле вакыйгада катнашырга дип барган булгандыр, мөгаен. Нәкъ Сәлимгәрәй мөфтилек иткән еллардан башлап анда сөнниләр мәчете имам хатибы буларак татар морзалары Терегуловлар династиясе вәкилләре торган. Сәлимгәрәй мөфти Тифлиска барган вакытта, 1870 елларда, ул җәмиг мәчет мулласы вазифасын Касыйм төбәгеннән чыккан Терегуловлар нәселе биләгән. Ә Тәфкилев белән Терегуловлар исә гомер-гомергә кода-кодача булып яшәгәннәр ич.

Татар энциклопедиясенең русча 5нче томында Сәлимгәрәй мөфтинең Уфа шәһәрендә авыру һәм мохтаҗларны карау өчен дип үз исеменнән мөселман приюты ачканлыгы, төрле урыннарда мәчет һәм мәктәп-мәдрәсәләр төзү һәм тоту өчен махсус вакыф-фондка акча калдырганлыгы да хәбәр ителә.

## 9

Оренбург төбәгенең яңа чор морза-дворяннары нәселеннән чыккан Шаһимәрдән Ибраһимов баштарак мәрхүм Сәлимгәрәй мөфти урынын биләргә лаеклы кешеләр исемлегенә кертелгән була. Әйе, күпчелек рус түрәләре тарафыннан да ул шул кәнәфине биләргә иң лаеклы шәхес саналган. Аңа чаклы ул байтак еллар дәвамында Төркестан төбәге генерал-губернаторының җирле халык белән аралашу буенча ярдәмчесе дә, якын-тирәдәге мөстәкыйль ханлыклар белән элемтә тотучысы да булган.

Ләкин аңа каршы русның югары дәрәҗәле дин әһелләре һәм карагруһчы зыялылары күтәрелүе мәгълүм. Миссионер, берара Казан университетының төрек-татар кафедрасы мөдире дә булып торган Н.И.Ильминскийның әлеге морза кандидатурасына каршы төшеп, Синодның өлкән прокуроры К.Победоносцевка язган хатлары сакланган. Ул



*Мөфти Мөхәммәдьяр Солтанов*

хатларның кайберләренең күчермәләре миндә дә бар. Хатларында ул Ш.Ибраһимов белән Казанда очрашкалаганлыгын бәян итә. Ул аны акыллы, югары белемле, русча бик иркен сөйләшә алучы «цивилизованный, энергичный» шәхес дип бәяли. Һәм Урта Азиянең, башка шәрекъ илләренең билгеле кешеләре белән якыннан аралашкан зат дип мактый да, нәкъ шул сыйфатлары безне куркытырга тиеш, дигән нәтиҗә чыгара. Уңай сыйфатлары белән ул мәрхүм Тәфкилев Сәлимгәрәй морзадан да күпкә өстен тора, дип яза. Шул өстенлеге белән ул безнең дин әһелләрен һәм чиновникларны мөшкел хәлдә калдырачак, ди («может обаять и ослепить наших господь и чинов высшего управления»). Киләчәк мөфти урынына безгә русча белеме чамалырак булган, түбән дәрәҗәле түрә алдында да калтырабрак калучы кеше кирәк. Мин ул урынга Солтановны кулайрак күрәм, дип яза Н.Ильминский 1885 елның 29 апрелендә җибәргән хатында. Һәм тиздән башкала түрәләре Шаһимәрдән Ибраһимовны исемлектән сызып ташлый. Бишенче мөфти итеп Минзәлә төбәгеннән чыккан морза, «башкорт-татар атлы казаклары гаскәрендә кантон башлыгы булган Мөхәммәдьяр Солтановны куярга кирәк», дип, император җәнапларына җиткерәләр. Шул рәвешле тиздән аны мөфтилеккә тәгаенләү турында фәрман бәян ителә. Шушы кәнәфине биләгәндә Мөхәммәдьяр Солтановның нәкъ Ильминский күрәзәлек иткәнчәрәк гамәл кылуы күпләргә мәгълүмдер ки. Ә Шаһимәрдән Ибраһимовны исә тиз арада Согуд Гарәбстанына, Җиддә шәһәренә илче вазифасын үтәргә дип озаталар.

Бик күп замандашлары кабул итмәгән бу мөфтинең дә Оренбург төбәгеннән чыкканлыгын билгеләп үтик. Гаскәри кантон башлыгы дәрәҗәсенә ирешкәнче аның башкорт-мишәр казаклары төркемендә күрше казакъ илен яулап алу сугышларында катнашканлыгы да искәртелә.

**10**

Габдессәлам Габдерәхим улы вафат булгач, өченче кеше рәвешендә мөфтилеккә тәгаенләнгән Габделвахид Сөләйман улы әл-Җәбәли әл-Әрбашчины искә алып үтик. Ул Оренбург төбәге кешесе түгел. Ш.Мәрҗани аны «мишәр таифәсеннән, Нижний өязе Әрбәшчи авылыннан чыккан», дип белдерә. Ягъни ул Сембер губернасында туган кеше. Мөфти кәнәфиенә утыртылганчы, ул Санкт-Петербургта сәүдә эшендә була. Үз эшләре арасында мулла вазифасын да башкара. Ул чорда әле башкалада мәчетләр булмый. Атасы авыл мулласы булганлыктан, Вахид намаз тәртибен дә, догаларны да яхшы үзләштергән була. «Россиянең вәкаләтле олы кешеләренә укымышлылыгын күрсәтеп, Габдессәлам вафатыннан соң мөфти булуга ирешә, 1256 (1840) елда Уфа шәһәренә килә, – дип хәбәр итә Шиһабетдин хәзрәт. – 1863 елда, 75 яшендә бу дөнья белән саубуллашкач, Уфадагы мөселман зиратында җирләнә», – ди. Димәк, ул чирек гасыр чамасы мөселман дине җәмгыяте идарәсе җитәкчесе булып торган. Ләкин дин ислам мәсьәләләренә кагылышлы хезмәтләрдә аның исеме сирәгрәк очрый.

***

Россия империясенең императорлары (патшалары) фәрманы белән билгеләнгән, шул ил мөселманнарының яшәеше – тормыш итеше өчен җаваплы булган алты мөфтине искә алдык. Бу вазифаны биләү еллары тәртибендә аларны кабат санап чыгыйк. Беренче мөфти, Россиядә иң әүвәл тәүге коръән китапларын бастырып таратучы Мөхәммәтҗан бине Хөсәен бине Мансур әл-Җәбәли әл-Борындыкый (1778-1824), Габдессәлам бине Габдеррәхим әл-Бөгелмәви (1825-1838), Габделвахид бине

Сөләйман әл-Җәбәли әл-Әрбашчи (1840-1863), Сәлимгәрәй бине Шаһингәрәй бине Йосыф Тәфкилев (1865-1885), Мөхәммәдьяр бине Мөхәммәтшәриф Солтанов (1886-1915), Мөхәммәдсафа бине Гатаулла Баязитов (1915-1917).

1917 елдан мөфтиләр төрле җыеннарда сайлап куела башлый. Иң беренче булып бу вазифаны үтәргә Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе мөдәррисе Галимҗан Баруди сайлана. Бу вакыйга шул елның май аенда Мәскәүдә узган Бөтенроссия мөселманнары корылтаенда була. 1921 елның декабрендә ул вафат булганнан соң, Үзәк Россия һәм Себер төбәгенең яңа дин башлыгы итеп күренекле галим һәм танылган мөхәррир Ризаэддин бине Фәхретдин бине Сәйфетдин сайлап куела. Бу вазифаны ул 1936 елга чаклы – вафат булганчы башкара.

## Төпләмеш

Каргалы авылы һәм анда гомер кичергән олуг шәхесләр мине балачактан кызыктырып килделәр. Мәктәптә укыган елларда Каргалыны күреп белмәсәм дә, безнең Бозаулык суы буе татар авыллары белән ныклы элемтәсе барлыгын ишетеп тә, укып та үсәргә туры килгән иде. Мин үскән Иске Актау (Иске Белогор), аның янәшәсендәге Яңавыл (Яңа Актау), Аюлы, Бәшир, Имангол, Кондызлы ише авыл картлары белән сүз чыкканда, әледән-әле шул сихри Каргалы мәдрәсәләре, Каргалы мәчетләре, Каргалы муллалары телгә алынырлар иде. Фәлән мулла Каргалыда укыган, икенчесе Каргалыдан килгән, имеш. Яңавылдан чыккан язучы һәм галим Габделбарый Баттал да атасы мәктәбендә башлангыч белем үзләштергәннең соңында укуын Каргалыда дәвам иттергән.

Авылыбыз зираты уртасындагы зур, биек «изге таш»ны да Каргалы авылы исеменә бәйләп сөйлиләр иде. Шул авылдан чыккан Рафыйк баба җиденче мәртәбә хаж сәфәреннән кайткан вакытта безнең Иртәк инеше буенда үлеп калган икән. Ул вакытта безнең авылда Каргалы кешесе Әхсән имам-хатиб булып торган. Шуларда кунып чыгарга дип килгәндә, бик тә эссе көндә авыл очына җиткәч үлеп калган бу изге хаҗи. Әле сугыштан соң да аның кабере өстенә куелган «Изге таш» янәшәсендә ятып сихәтләнеп, терелеп чыгар өчен дип, төрле тарафтан авыру яисә күңел тынычлыгын җуйган кешеләр дә килеп кунгалар иде. Шундыйлар арасында хәтта хәрби киемнәрен дә салмаган, култык таякларына таянып, көчкә атлап йөргән соңгы сугыш каһарманнары да очраштыргалады. Ул мөсафирларны зират янәшәсендәрәк яшәүче Җомабикә әби каршы алыр һәм озатып куяр иде. «Файдасы булдымы соң?» – дип сораучы карт-карчыкларга мөсафирлар еш кына: «Әлегә рухым савыкты. Алла боерган булса, тәнем дә савыгыр», диебрәк җавап бирәләр иде.

Авылга бер кайтуымда мин шул изге ташка ни-нәрсә дә булса язылганмы икән, дип кызыксынган идем. Авыл мулласы белән без ул ташта бернинди язу да тапмадык. Ә аның янәшәсендәге кабер ташыннан исә Каргалыдан чыккан Әхсән мулланың монда чирек гасыр имам-хатиб булып торуын, 1824 елда 69 яшендә вафат булганлыгын укып белдек. Ул монда муллалык иткән елларда, Самара белән Оренбургны «чуен юлы» тоташтырганчы (1879), башкала тарафына яисә хаҗга барырга чыккан һәр мөселман кешесе диярлек Бозаулык суы буена гәрәбәдәй тезелешкән татар авыллары аша йөри торган булган. Димәк, кайчандыр бу юлдан алда санап үтелгән барлык шәүкәтле мулла һәм мөфти хәзрәтләребез дә бер генә мәртәбә үтмәгәндер. Хәтта ки даһи шагыйрь Пушкинның да, Уральск тарафына юл тотканда, шушы тирәләрдәге биек акбур тауларына карап, язылачак повестенең үзәгендә торган авыл исемен «Белогорская крепость» дип атаган булуы бик ихтимал. Нәселе Каргалыга бәйле булган рус теле укытучысы Рашат абый да кайчандыр шундый фикер әйтеп, безне «Капитанская дочка» повестен кат-кат укырга ымсындырган иде.

Башлангыч сыйныфларда укыткан укытучым Хөснә апа да Каргалыны бик еш телгә алыр иде. Оренбургның аргы ягындагы Чебенке авылларының берсендә туган булса да, ул Каргалыны, аның кешеләрен дә бик сагынды, ахрысы. Берничә ел шунда укыган

да булса кирәк. Оренбург төбәгенең элеккеге барлык зыялысы да Каргалыдан чыккан дип, мисалга Айдаров морзалар гаиләсен китерер иде. Әнә бит, Кәраметдин Айдаров хәзер Сәмәрканд университеты профессоры, аның туганы Галим Айдаров Оренбург педагогия институтында укыта икән. Бозаулык буе татар авылларының соңгы ахуны Харис хәзрәт тә шул морзалар нәселеннән ди.

– Аның улы Әсгать Айдар – күренекле язучы. Сез аны яхшы белергә тиешсез. Кечкенә Әсгать сезнең кебек вакытта шушы Искеавыл урамнарыннан йөргән. Авыл читендә, Иртәк инеше буенда аларның җимеш бакчалары булуын барыгыз да беләсез... Киләсе дәрестән без аның «Ташбай» исемле әсәрен укый башларбыз, – дип сөйләр иде Хөснә апа дүртенче класс балаларына.

Шул ахунның XX гасыр башында Иске Актау авылы янәшәсендә сабантуйлары оештырганлыгын, аңа Каргалы, Оренбург, Бозаулык, Самара тарафларыннан күпсанлы кунаклар җыелганлыгын мин соңрак «Вакыт» газетасыннан укып белдем. Мондый вакыйгага багышланган хәбәрләр анда 1914 елгача даими рәвештә басыла килгән икән. Менә 1910 елның 29 май санындагы хәбәрдән бер өзек: «Бозаулык өязе Иске Белогор карьясы янында, Айдаров хәзрәт утарында зур бәйге булды. Мөселман милләтеннән күп кеше җыелган иде, көрәш кеби кызыклар белән Сабан туе ясалды. Берничә гәүдәт үгез суелып, халык хозурына аш бирелде...» Хәзер дә әле «хәзрәт бакчасы» исемен йөрткән ул урында кыргыйлашкан алмагач кәүсәләре саклана. Шул сәхрәдә узган Сабантуйларында, бәлкем, минем бабам да катнашкан, ахун хәзрәтләре догасы белән чын мөселманча суелган яшь үгез итен ашагандыр...

Алда әйтелгәнчә, Каргалы безнең төбәкнең Бозаулык, Иртәк, Иләк, Ток, Самар (фарсычасы, Сәмәр бугай) елгалары буе авыллары өчен үзенә күрә кечерәк бер Мәккә булган. Күрше-тирә авылларның муллалары башлыча шул Каргалы мәктәп-мәдрәсәләрендә укыган. Туасы шаулы гасыр алдыннан гына авыл мәчетен яңартуда тырышып катнашкан бабамның олы кызының кияве Хәбибулла да Каргалыда мәдрәсә тәмамлап кайткан була. Ләкин ул рәсми рәвештә мәхәллә имамы булып сайланырга өлгерми кала. Илдә зур үзгәрешләр башлана. 1919 елның җәендә шушы авылдан Урта Азия тарафына таба ургылган атаклы Татбригада сугышчылары аны да үзләре белән ияртеп алып китә. Яу-сугышлар беткәч тә, ул шунда кала, Миһербан апабызны да үзе янына алдыра. Илленче елларда аларда кунакта булганда, җизнә бабай туган авылы белән бердәй итеп Каргалыны да бик сагынып искә алган иде.

– Шунда үзләштергән белемемне дә һич онытканым юк. Казакъ, үзбәк авылларында укытканда да, көндез хәлфә, кичләрен мулдакә идем. Хәзер дә шулай, – дип мактанып та куйган иде Чимкәнт шәһәре янәшәсендәге зур үзбәк авылында гомер иткән Хәбибулла бабабыз.

Йә Ходам, Үзең ярлыка. Изге юлда йөреп, изге эшләр башкарган барлык имамнарыбыз, мөфтиләребез кылган изге гамәлләр мәңге онытылмасын. Бүгенге укымышлы дин әһелләребез белән бергә ара-тирә булса да узган гасыр мөфтиләренең изге эшләрен дә искә алгалыйк. Алар рухына изге догаларыбызны багышлыйк.

**Лирон ХӘМИДУЛЛИН,**
*Г.Исхакый исемендәге әдәби премия лауреаты*

Мәгъсум
Харисов

# УКЫТУЧЫ ИРТӘ ЧАЛАРА

## «Мин сугышта үлмим икән»...

*Атландым атның биленә,*
*Киттем Герман җиренә...*

Татар халык җыры

1942 елның март башында безнең 689нчы артполк фронтка китү өчен эшелоннарга төялде. Димәк, берничә көннән соң без дошман белән очрашачакбыз. Кайберәүләр фронтка җибәрүне тизләтергә сорасалар да, күпләр сугыш эченә барып керүне уенга санамадылар. Ватанны саклау һәркем өчен җитди һәм хәтәр бурыч. Без юлга кузгалдык, әмма кайсы юнәлешкә китүебезне белмибез. Командирлардан сорасак та, алар иңбашларын сикертеп кенә җавап бирәләр. Әллә белеп тә белмәмешкә салыналар идеме? Без Саранск, Тамбов, Воронеж шәһәрләрен үттек, димәк, көньяк-көнбатыш фронтка юл тотабыз булса кирәк. Төн. Тынлык. Караңгы. Тимер юл станциясе. Маскировка аша беркайда да ут чаткысы күренми. Бу станция әле дошман тарафыннан бомбага тотылмаган. Безне шушы станциядә бушатачаклар, имеш. Ләкин безгә монда тукталырга туры килмәде. Лисичанская станциясен үткәндә, сугыш афәтен күреп, гаҗәпкә калдык. Берничә тимер юл составы яндырылган. Үле хайван гәүдәләре аунап ята. Биналар җимерелгән. Күмергә әйләнгән баганалар тырпаеп тора. Күмер-көл өемнәре. Дошман авиациясе бу тирәләрне бомбага тотарга өлгергән, димәк, фронт та ерак түгел. Командирларыбыз һава һөҗүменнән ничек сакланырга икәнен кабат исебезгә төшерделәр. Без тагын юлда. Озак барырга туры килмәде, безне туктаттылар. Без бу юлы тимер юл вагоннарыннан чыктык һәм тимер юлдан ераклаша башладык. Кечкенә генә урманда тукталып, көнне шунда үткәрдек. Пушка-гаубицаларны нык маскировать итәргә туры килде. Немецның разведка самолётлары һәр җирне күзәтеп, капшап тора. Без әле билгеләнгән урыныбызга барып җитмәгәнбез икән. Язгы пычрак юлдан хәрәкәт итүе җәяүлеләр өчен дә, техника өчен дә бик авыр. Фараларны яктыртып булмый, машиналарны, тракторларны кирәгеннән артык гүләтергә дә ярамый. Дошманның күзе үткер, колагы сизгер. Таныш булмаган юлда, разведка мәгълүматларын көтеп, әледән-әле тукталышлар ясарга туры килә. Ниһаять, безгә бер кечерәк кенә авылга туктарга әмер булды. Димәк, без фронт сызыгына килеп җиткәнбез. Әлегә бу тирәләрдә тынлык хөкем сөрә. Ара-тирә безнең өстән дошман самолётлары очып үтә. Без әле сугыш дәһшәтен күрмәсәк тә, Кызыл Армиянең дошманга каты каршылык күрсәтүен, чигенгән вакытта да аның җанлы көчләрен һәм техникасын тар-мар итүләрен газеталардан укып һәм политинформацияләр аша беләбез. Кызыл Армиянең 1941 елның ноябрь һәм декабрь айларындагы һөҗүмнәре белән дошман Ростов-на Донудан куып чыгарыла һәм көнбатышка шактый чигендерелә. Менә без шул кызу участокка дошманның көчләрен тоткарларга җибәрелгәнбез дә. Дошман Ростов-на Донудан чигендерелгәч, Матвеев-Курган тимер юл станциясе аша һәм тимер юл буйлап яңадан Ростовка юл ачу өчен әледән-әле һөҗүм оештыра. Безнең бурыч

*Дәвамы. Башы 5, 6, 8 нче саннарда.*

фронт линиясендәге пехота дивизиясенә артиллерия белән ярдәм итүдән гыйбарәт. Ике мәртәбә фронт үткәнлектән, бу урындагы авыллар бик теткәләнгән. Саман өйләрнең мичләре һәм морҗалары гына тырпаеп тора. Хәтта җиләк-җимеш куаклары да киселеп, анда-санда гына алмагачлар, грушалар басып калган. Безнең 689нчы артполкның өченче дивизионы, Таганрог белән Сталино (Донецк) шәһәре арасындагы Матвеев-Курган тимер юл станциясен саклап, оборонада торучы пехотага ярдәмгә өстәмә көч итеп билгеләнде. Безнең өченче дивизион алгы сызыктан 6-7 чакрым тылда ике генә урамлы кечкенә бер авылга урнашты (исеме Пановка иде бугай, яки шуңа охшашрак). Авыл аша ике мәртәбә сугыш узганлыктан, 2-3 йорт кына төзек чамасында калып, калганнары хәрабә хәленә килгән.

Без, элемтәчеләр, бер ишелгән өйнең подвалына һәм идән астына урнаштык. Шул көнне карлы яңгыр яуды. Подвалга, идән астына су үтеп, тамчы тамып торды. Икенче көннәрне инде өстен төрле әйберләр белән япкалап, маскировка ясадык. Исән калган гаубица-пушкаларны алма, груша агачлары ышыгына урнаштырдык. Авылдан ерак түгел тирән ерынтыда котлованнар казып, гаубица-пушкаларны шунда урнаштырып, без фронтның алгы сызыгына телефон элемтәсе үткәрдек. РБМ аппараты белән эш итәргә өйрәнүне дәвам итәбез. Дивизион белән алгы сызыктагы КП (команда пункты) белән ике катлы элемтә урнаштырабыз. Ләкин РБМдан файдалану тыела, иң кирәк вакытларда гына аннан файдаланылачак, чөнки аны дошманның пеленгаторлары тотачак. Бу – бик куркыныч.

1942 ел март башының аяз суык төне, күктә йолдызлар җемелди. Җир өстен шактый катыра. Дүшәмбе көннең аяз иртәсе. Немецларның атакасы көтелә, чөнки немецлар якшәмбе көнне ял итәләр. Билгеле, оборонада торганда, урынчылык өчен булган сугышларда гына. Менә безне – радистларны – иртән, тревога белән күтәреп, алгы сызыкка алып киттеләр. РБМ станциясе ике өлештән тора. Приёмник үзе 16 кило, ә аны эшләтү өчен питание-батарея 17 килолы. Бер станциягә ике элемтәче. Станцияне аркага асып юлга чыктык. Көн бик матур. Кояшка каршы җир өстендә бозланып каткан үлән сабаклары ялтырый. Ара-тирә алгы сызыктан яралыларны арбаларга төяп кайтаралар. Поход кухнялары очрый. Күңелгә һич тә бу җирдә сугыш булыр дигән уй башка да килми, куркытмый да кебек. 3-4 чакрым үтүгә фронтның билгеләре көчәя. Казылган окопларны, траншеяларны, блиндажларны еш очратасың. Йөрәкне курку ала. Менә безнең алда аз гына түбәнлектә зур тимер юл станциясе җәелеп ята. Станция немецлар кулында. Без шул станциядән немецларны бәреп чыгарырга, тимер юлны алырга тиешбез. Озак барырга туры килмәде, алда атыш тавышлары ишетелеп, авыл өстендә снарядлар ярыла башлады. Безнең пехота «ур-р-ра» кычкырып алга ыргылды. Немецлар да безнекеләргә каршы ут ачты. Әле без, чын сугыш белән күзгә-күз килмәгәннәр, нишләргә дә белмичә, аяк өсли алга баруны дәвам итәбез. Менә әче сызгырып, миннән 2-3 метрга гына мина килеп төште. Килеп төште төшүен, әмма шартламады. Үзем дә белмәстән: «Мин бу сугышта үлмим икән!» – дип кычкырып җибәрүемне сизми дә калдым. Үрмәләп траншеяга барып төштем. Без рация белән КПдан дивизионга батареяларга хәбәр итәргә тиешбез. Рация белән хәбәрләшә башлагач, немецлар безне тиз тотып алдылар, безнең өскә снарядлар ява башлады. Рация белән элемтәгә керү безнең дивизионда шунда ук туктатылды. Без РБМ рациясе белән элемтәгә керүне башка кабатламадык, рацияләрне тиешле урынга тапшырып, телефон аппараты һәм үткәргеч катушкасы (кабель-үткәргеч) алдык. Билгеле, 16-17 килолы рация асып чабуга караганда телефон аппараты белән окопта утыруы күпкә уңайлырак. Ләкин... ләкин телефонист булуның үзенә күрә бик кыен яклары да бар. Батарея белән КП арасындагы кайсы урынга эләгәсең бит?! Кабель сузарга кирәк, ул кабель өчен син җаваплы. Башта кабельне маскировать итеп сузарга, юл аркылы үтсә, казып күмәргә, кырдан үткәргәндә җиргә салып үткәрергә кирәк – үлән өстендә күренмәсен, кеше аягына эләкмәсен, машина көпчәгенә чолганмасын, дошман күзенә күренмәсен. Аны әледән-әле нәрсәгәдер беркетеп, бәйләп калдырасың. Ә кайбер вакытларда кабельне үлгән кеше аягына яки кулына бәйләү-чолгау фактлары да булды. Кабельне бәйли-беркетә дә белергә кирәк, әгәр кинәт кенә чигенергә

туры килсә, кабельне тиз генә җыеп алырлык та булсын. Сугыш барышында иң куркынычы – өзелгән кабельне ялгап, элемтәне өзми тоту.

Дивизион үзенең урынын алмаштырганда без телефонистлар да гаубица-пушкаларны урнаштыру өчен котлован казыша идек. Май азакларыннан июнь урталарына кадәр оборонада торсак та, әледән-әле немец баш калкытты, көчле бәрелешләр булды. Мине элемтәнең икенче төренә – почта ташуга күчерделәр. Минем карамакка шофёры белән «ГАЗ»ик бирделәр. Мин көн дә фронт сызыгыннан, команда пунктыннан төрле донесениеләр, хатлар алып китеп штабка, шулай ук штабтан КПга төрле донесение, хат, газета-журналлар алып кайтырга тиешмен. Машина белән 25-30 чакрым гына үтәсе булса да, ай-һай, ул араларны үтүе озак һәм кыен. Дошман күзеннән яшеренергә кирәк, ә ул җирдән дә, һавадан да күзәтә. Шуның өчен сусыз тирән чокырлардан, иңкүлекләрдән, юлсыз җирләрдән, иген кырлары аша узарга кирәк. Менә бер эпизод. Июнь аеның матур бер көне. Без шофёр белән штабтан почта алып кайтабыз. Ярты юлны бик әйбәт үттек, юлны дәвам итеп, элек дивизион торган балкага якынлашабыз. Кинәт немец самолётлары безнең өстә бөтерелеп, күптән түгел генә дивизион торган урынга бомба коя башладылар. Нишләргә? Элекке блиндажга кереп качарга туры килде. Бомбёжкадан землянка-блиндаж дер селкенеп тора, шартлаулар ерак түгел. Ә менә берсе безнең блиндажның янәшәсенә үк килеп төште, ләкин, ни хикмәттер, шартламады, әмма блиндажның бер почмагын ачты. Шпалларның берничәсе блиндаж эченә дә төште. Безнең бу вакытта курыкканны укучы кеше шәт үзе дә чамалар. Бомбардировщиклар киткәч, машинабыз янына барсак, машинабызга да ул-бу булмаган – исән. Тиз генә дивизионга юл тоттык. Почтаны тапшырганда минем ярты почтам юклыгы беленде. Бу – бик куркыныч хәл. Өлкән лейтенант Болташенко югалган почтаны бер сәгать эчендә табып кайтырга, почта табылмаса, штабка хәбәр итәчәген белдерде, алай гына да түгел, военный трибунал белән янады. Ул, безнең белән барып, югалган почтаны эзләшергә 5 солдат та бирде. Безнең бомбага тотылган урын билгеле булганлыктан, дивизион элек торган балканы эзләп табуы читен түгел. Бу вакытта инде кояш төшлектән авышкан иде. Бардык һәм блиндажны таптык, ләкин почта анда калмаган булып чыкты. Блиндажга шуышып барган идек, шул юлда почтабызның бер өлеше төшеп калган булган. Исән калуыбызга шатланып, блиндаждан тиз генә чыгып киткәнбез дә почтаның бөтенлегенә игътибар да итмәгәнбез. Яныбызга төшкән бомбаның, сугышка керүемнең беренче минутында шартламаган мина кебек үк шартламавы кабат «мин сугышта үлмим икән» дигән ышанычны ныгытты.

Безнең почта дошман кулына эләкмәде, хәтта иртәгәсен начальнигыбыз Божанов шофёр белән миңа строй алдында рәхмәт тә белдерде.

Почта югалту – сугыш вакытында зур ЧП. Посттан солдат югалту да зур ЧП булып санала. Яз көне, әле көннәр салкын вакытта, посттан бер солдатыбыз югалды. Билгеле, ул солдатның тышкы кыяфәтенә, белеменә, профессиясенә карап һич тә аны үзе теләп немецлар ягына чыккандыр дип әйтеп булмый. Ул 3-4 класс белемле, Идел буенда туып-үскән бер колхозчы иде. Кыска буйлы, юантык булганга, «Толстый» дип эндәшәләр иде үзенә. Яңгырлы язның бер караңгы төнендә постта торганда әнә шул Миша-толстый юкка чыкты. Тревога күтәреп эзләсәк тә, Миша-толстый табылмады. Аның белән бергә постта торган 3 солдат Мишаның ничек югалуы турында берни дә белмиләр. Михаилның йокларга яратуын һәм гырылдап йоклавы аркасында, аны немецлар «тел» итеп урлап алып киткәннәр дигән нәтиҗә чыгарып, постта уяулыкны тагын да көчәйтү турында боерык булды. Постларны әледән-әле тикшерүләр ешайды.

Оборонада торганда немецлар еш кына һавадан безнең якка листовкалар ташлыйлар иде. Ул листовкаларны җыеп яндыра идек. Листовкаларда рус солдатларын үзләре ягына чыгарга, әгәр чыксалар, тормышларын сакларга, Германиядә тормышның яхшы булуы, шуңа күрә Сталинның һәм Молотовның малайлары ирекле рәвештә әсир төшүләре турында язылган була иде. Ләкин мин үз теләкләре белән дошман ягына чыккан бер генә совет солдатын да белмим. Кичләрен дә немецлар рупор аша совет солдатларын үзләре ягына чыгарга димлиләр, листовкаларын укыйлар, төрле ялган дәлилләр китереп ышандырырга тырышалар иде.

Безнең участокка Кара диңгез флоты морякларын китерделәр. Алар 1-2 көн ял

иттеләр. Кояш баегач, участоклар, аерым калкулыклар өчен атакага күтәреләләр иде. Кайбер вакытларда немецларны кысрыклап чигендерсәләр дә, шунда ук зур югалтулар белән үзләре дә чигенәләр. Диңгез пехотасына танклар да, артиллерия дә ярдәм итми, тик алар алгы сызыкка китү алдыннан эчкән спирт тәэсирендә генә «геройлананалар» иде, шуның шаукымы астында гына атакага ташлананалар. Мондый атакаларның кемгә һәм ни өчен кирәге булгандыр, ул вакытта һәм хәзер дә сәбәбен белмим, аңламыйм. Мондый атакалар вакытында үлгән солдатлар, үлә алмыйча интегүчеләр бик кызганыч. Оборонада торганда фронт линиясендә нейтраль зона барлыкка килә. Һәр ике як та, сукыр тычкан кебек, җир казып яшеренә. Шушы нейтраль зонада яраланып калган сугышчының хәле бигрәк тә кызганыч. Украинада июнь кояшы. Көндезләрен эсселек 25-30 градуска җитә. Хәрәкәтләнә алмый торган яралы солдат шушы шартларда берничә көн үлә алмый тилмереп ята. Яралы солдатны көндез тылга алып чыгу турында сүз булырга да мөмкин түгел. Аны коткарырга баручыга дошманның берничә винтовкасы, пулемёт көпшәсе төбәлгән. Төннәрен яралы янына бару шулай ук мөмкин түгел, чөнки бу зона дошманның парашютка эленгән прожекторлары белән бик нык яктыртыла. Яралыларның ярдәм сорап ялварулары окопка ишетелә, кыймылдап ятуларын күрәсең, нихәл итмәк кирәк, һич тә ярдәм итеп булмый. Бу хәлгә дучар булган солдат сусызлыктан, каны күп китүдән, гангренадан, җәрәхәте кортлаудан газап чигеп, озак үлә. Мондый үлемне иң җәфалы үлем дип саныйм мин.

1942 елның июнь ахырларында, 965 нче укчы полк белән безгә – 689 нчы артиллерия полкына – чигенергә приказ булды.

Кирза итегем тишелгәнлектән, аны ремонтка алып, 39 нчы размер урынына миңа 41ле ботинка бирделәр. Ул вакытта ботинканы обмотка белән кияләр иде. Беренчедән, бу ботинка миңа зур, икенчедән, аны чолгау белән кияргә кирәк, ә мин чолгау белән кия белмим. Шуның өчен бу ботинка мине күп җәфа чиктерде. Чигенергә хәбәр иртә белән булса да, без кич, караңгы төшкәч кенә, юлга кузгалдык, чөнки дошман һавадан күзәтә. Немецның разведка «рама» самолётлары («Фокке-Вольф-189») безнең өстән еш очалар. Ә без күченергә юлга чыгарга әзерләнәбез. Кайсы якка, кая чигенүне беркем дә белми. Төнлә белән чигенү башланды, дошман безне әлегә эзәрлекләми. Без чигенеп, Новошахтинскига якынлаштык, ләкин анда безгә кадәр немецларның танк колоннасы кергән булып чыкты. Берничә сәгать тукталыштан соң, Новочеркасск шәһәренә таба чигенә башладык, аны читләтеп үтәргә туры килде. Менә бу вакытларда инде безнең чигенүче гаскәрләрне немецлар һавадан бик каты бомбага тоттылар. Без монда да оборона кора алмыйча Ростов юнәлешенә чигенүне дәвам иттек. Полк Ростовка кадәр оешкан төстә чигенә алмады, дошман безнең сафларны какшатты. Төрле юллардан чигенергә туры килгәнлектән, штаб белән элемтә өзелде, кухня аерылды. Безнең элемтәчеләр батальоны да таркалды. Ростовка җиткәнче без, немецларга каршылык күрсәтә-күрсәтә, Азов диңгезе ярларына ук килеп чыктык. Безнең ара-тирә каршылык күрсәтү баштанаяк коралланган немец армиясен тоткарлый алмады. Безнең чигенүче армия бер зур гына хутор өчен бигрәк тә каты каршылык күрсәтте. Хутор урамнары өчен көрәш башланды. Немецның мотопехотасы шушы хуторда безне чак кына камап алмады. Зур югалтулар белән хутордан кичке якта чыгып киттек. Хуторның янәшәсендә үк кыр ышыклау урман полосасы булуы гына безне әсирлектән коткарып калды. Ростов шәһәре аша Дон елгасын кичәргә приказ булганлыктан, без Ростовка чигенәбез. Чигенү вакытында мин плащ-палаткамны югалттым. Диңгез якын булганлыктан, төннәрен бик куәтле чык төшә икән. Плащ-палаткасыз төн кичерүләре бик кыен. Нишләргә, кайдан юнәтергә?! Гомеремдә бер генә мәртәбә дә кеше әйберенә кул сузмаганлыктан, мин, «кирәк дип» кешенекен ала да алмыйм.

– Мә, якташ, игелеген күр, синекен кирәк кеше алган булса, без дә сиңа кирәккә генә алдык,– дип, районлашым Хәеретдинов Изахетдин (Буа районы Югары Лашчыбашы авылы) миңа плащ-палатка юнәтеп бирде. Менә шул якташымны взвод командиры үзе янына чакырып алды да арттан килүчеләргә безнең чигенү юлын күрсәтерсез дип, кыр юлы аермасына бастырып калдырды. Шуннан соң без күрешмәдек инде. Без өйдән чыгып киткәннән бирле бер отделениедә хезмәт иттек. Бер-беребезгә кыен

вакытларда ярдәм итештек, бер сынык икмәкне бергә бүлеп ашадык. Менә шундый иптәшемнән һәм якташымнан аерылдым мин ул көнне.

Без иртә белән Ростов шәһәренә якынлаштык. Батальон командиры «Ростовсельмаш» заводы коймасы янына туктатты да: «Безнең дивизион шушы завод ишегалдына оборонага туктарга тиеш, мин хәзер белешеп чыгам, беркая да таралмаска, көтәргә», – дип, приказ биреп, завод ишегалдына кереп китте. Ә без куаклыкка ышыкландык. Командирыбыз өлкән лейтенант Болташенконы (ул украинец, шахтада мастер булып эшләгән, диләр) көтәбез – юк, көтәбез – юк. Ял да иттек, тамак та ялгадык, көтәбез – юк та юк. Взвод командиры өлкән сержант Иванов белешер өчен завод ишегалдына кереп китте, озак та тормады, әйләнеп чыкты һәм: «Завод ишегалдында бернинди дә Кызыл Армия частьлары юк», – дип хәбәр итте. Без тагын берәр сәгать көтәргә дигән карарга килдек. Көттек – ул килмәде. Безне шәһәргә взвод командиры алып керде.

Ростов шәһәренең көнбатыш өлешендәге бер паркына якын мәктәп ишегалдына урнаштык. Безнең армия бу вакытта югарыдан килгән күрсәтмә нигезендә чигенде булса кирәк. Шунлыктан Ростов шәһәрендә чигенүче частьлар бик күп иде. Төш алдыннан якындагы поход кухнясыннан аш алып ашарга әмер булды. Без котелокларга аш алып ашарга гына утырган идек, дошман Ростовны һавадан бомбага тота башлады. Ишегалдына бомба төшеп ярылды. Солдатлар арасында үлүчеләр, яраланучылар булды, шул җөмләдән, безнең взвод командирыбыз да һәлак булды. Мин котелокны җиргә куеп, аны сул кул белән тоткан килеш, аш ашый идем. Бомба шартлагач та карниздан кирпечләр коелып төште. Бер ярчык минем котелокка килеп бәрелде, аны кулымнан йолкып алды. Карасам, котелок аумыйча гына берничә сантиметрга шуышкан, ә үзе нык кына ямьшәйгән. Гаҗәбе шул: ничек бомба ярчыгы миңа тимәгән дә, мин яраланмый калганмын да, ничек котелоктагы аш түгелмәгән?!. Күзгә күренмәгән хәвефле хәлләр сугыш кырында кешене минут саен сагалап тора, бу исә минем күзгә күренгән фаҗигале хәлдән өченче мәртәбә исән-имин калуым иде.

Ростовта берничә сәгать торсак та, безгә югарыдан бернинди дә приказ булмады. Штаб югалды. Командирсыз да калдык. Безнең элемтәчеләр белән идарә итүне өлкән сержант Васильев үз өстенә алып, аның командалыгында Дон кичүенә киттек. Шәһәр урамнары чигенүче армия частьлары белән тулган. Шәһәрдә тәртипсезлек. Кибетләрдән, складлардан халык нәрсә таба шуны өенә ташый. Кемдер илне фашизм тырнагыннан азат итү өчен канын койса, кемнәрдер, ыгы-зыгыдан файдаланып, байлык туплый, ә кемдер, шинелен салып атып, кунак каршыларга әзерләнә. Әйтерсең лә ул кешеләргә ил язмышы кагылмый. Гаҗәп – ләкин факт. Ростов шәһәренең тынычрак урамыннан Дон кичүенә барганда исерек сугышчыларны күреп хәйран калдык. Сораша торгач шул беленде: якын гына бер подвал-складта вино саклана икән. Мичкәләрне ачып, шуннан шәраб ташыйлар һәм эчәләр икән. Безнекеләр дә читләтеп үтәргә теләмәделәр. Дөрестән дә склад ачык, балга умарта корты сырган кебек, складны солдатлар камап алган. Котелок белән дә, чиләк белән дә вино ташыйлар яки эчәләр. Без дә флягаларга, котелокларга вино тутырдык. Хәмер үзенекен итә, эчеп алган егетләребез чигенергә бер дә ашыкмыйлар. Кояш баер алдыннан, ял итеп алу өчен бер ишегалдына кердек. Кайбер мәрхәмәтле шәһәр халкы чигенүче солдатларны ашата-эчертә, сыйлый. Бераз төшереп тә алгач, егетләребезнең кәефе күтәрелде, җырлап бии дә башладылар. Мин, бу хәлнең ахыры начар булачагын чамалап, үзем генә түгел, ә Божановка (Саранск шәһәреннән) да эчмәскә киңәш иттем. Ул мине аңлады. Кояш баегач, солдатларның кайберләре өйләр буйлап таралып, бер-береңне күзәтми башлагач, Божанов белән икәү, бу ишегалдыннан чыгып, гомуми чигенүче солдатларга кушылып, кичүгә киттек. Безнең элемтәчеләрнең күпчелеге украиннар. Аларның уй-фикерләрен белү читен иде. Үз-үзләрен тотулары да бик сәер. Башта безнең батальон командиры өлкән лейтенант үзе юкка чыкты, ягъни качты, дияргә була. Җирле халыкның күпчелеге совет солдатын, вареникилар пешереп, аларның тамакларын туйдырып, хәерле юл теләгәндә, тиздән бу җирләргә җиңү белән кайтырга чакырганда, сирәк булса да совет солдатларын сүгүчеләрне, сорагач та эчәргә су бирмәүчеләрне, хәтта: «Безнең яклаучыларыбыз, ашатучыларыбыз килә, сезгә кирәкләрегезне бирәләрме?!» – дип, немецларны түземсезлек белән көтүчеләрне һәм аларны мактаучыларны да очратырга туры килде.

Без Донга килеп чыкканда караңгы төшкән иде. Дон аша салынган тимер юл күпере шартлатылган, ул асылынып тора. Донны кичү өчен пантон күпер корылган. Бу күпердән танк, гаубица-пушкаларны чыгару мөмкин түгел. Шуның өчен аларны башка җирдән чыгару өчен юл эзлиләр, ләкин Дон аша башка юллар да немецлар кулында. Пантон күпердән үтә алмаган тягачларны, гаубица-пушкаларны Дон төбенә җибәрделәр. Безнең дивизион солдатлары орудиесез калды. Алар да үзләренең батареяләрен, взвод, роталарын югалтып, ирекле рәвештә йә башка төр гаскәрләргә кушылып чигенәләр. Ростов белән Батайск арасы 8-10 километр булып, сазлыклар аша дамбалы юл салынган булган. Анда да берничә күпер булган, ләкин алар да немецлар тарафыннан җимерелгән. Переправа аша үткән барлык төр гаскәр дә сазлыклар аша гына Батайскига чигенә ала. Дон елгасы Ростов турында атау белән икегә бүленгән. Донның яр буе һәм яр буе кварталлары чигенүче гаскәр белән тулган. Пантон күперне немецлар һавадан бомбага тота. Елга өстенә немецлар көчле прожекторлар эләләр. Күпергә керү өчен чират. Ниһаять, Божанов белән мин дә күпергә кердек. Донның беренче өлешен чыгу белән безне утрауда туктаттылар. Утрауда оборона тотып, немецларны Дон аша чыгармыйбыз, имеш. Бу – күрәләтә үлемгә бару дигән сүз. Винтовка, автомат ярдәмендә, вак калибрлы орудие белән ялангач утрауда немецларга каршылык күрсәтеп булмаячак. Караңгылыктан һәм башка гаскәрнең хәрәкәтеннән файдаланып, без Донның икенче өлешен дә кичеп чыктык. Бик арылган, йончылган. Хәл алырга дип яр буенда тукталдык. Йокымсырап та киткәнбез. Кемдер безне типкәләп диярлек йокыдан уятты. Яр буендагы барлык туктаган солдатларга чигенергә кушалар. Чигенү юлы фәкать сазлык аша гына.

Кояш чыкканчы ук сазлыкка кереп киттек. Сазлыкның күпчелек өлешен камыш каплаган. Камышлыктан чигенәбез, ә өстебездә умарта кортлары кебек немец истребительләре оча. Үлүчеләр, яралылар камыш арасында кала. Ай-һай ла, ул камышлы сазлык аша үтүләре! Су тирән урыннарда винтовканы һ.б. баш өстендә күтәреп муеннан суда барулары. Бер-беребезгә ярдәм итә-итә, без, ниһаять, Батайскига килеп чыктык. Юеш киемнәребезне салып сыктык та кояшка кибәргә элеп куйдык. Без тукталган хатада хуҗалар җырлашып аракы эчәләр. Бу күренешне без ничек тә аңламадык, бәяли алмадык. Әллә кайгыдан, әллә шатлыктан эчеп җырлыйлар. Без дә флягалардагы винолардан авыз итеп, тамак ялгап, киемнәрне кояшта киптерәбез. Бик арылган. Кояшка каршы кызуда изрәп йоклап та киткәнбез. Безне тагын төрткәләп уяттылар һәм шушы сәгатьләрдә шәһәргә немецлар керәчәген әйттеләр. Кипкән киемнәрне киеп, ашыгыч рәвештә юлга чыкканда өй бушап калган, эчеп-тамаша кылып утыручылар юк иде инде. Без Батайскидан чыкканда немец шәһәр әйләнәсен бомбага тотты. Бу – чигенүче совет армиясен күпләп юк итү һәм кайберләрен камалышта тоту максатыннан шулай эшләнде булса кирәк. Без бомбага тоту зонасыннан көчкә котылдык һәм кыр ышыклау урман полосасы буйлап алга хәрәкәт иттек. Көн кызу, эчәсе килә. Саз һәм юлдагы күлдәвекләр суын эчәргә мәҗбүр булдык. Менә инде без берничә тәүлек шулай чигенәбез, ә аякта 41ле ботинка. Ул аякны бик кырды, көчкә атлыйм. Көнбатыштан яшенле яңгыр килә. Без зур гына хуторга туктадык. Монда чигенүчеләр ялга, бәлкем, кич кунарга да тукталганнардыр. Атлы повозкалар, җигелмәгән повозкаларга бәйләп кенә куелган атлар да күп. Озак та үтмәде, давыллап, яшенле яңгыр ява башлады. Солдатлар төрлесе төрле урында яңгырдан ышыкландылар. Менә шушы вакытта башка бер уй килеп төште. «Шушы ыгы-зыгыда берәр буш атны чишеп алырга да, ат өстендә алга таба юл тотарга!» Һәм без Божанов белән шулай эшләдек тә. Караңгы төшү белән атларның иң тыгыз бәйләнгән җиренә барып, бераз әйләнәтирәне күзәттек. Ыгы-зыгы тынып та бетмәгән бер вакытта Божанов белән икебез дә берәр атны чишеп алып, җитәкләп күрше тыкрыкка кереп киттек.

Оешкан төстә чигенүчеләргә караганда, адашып, ягъни үз частьларыннан аерылып чигенүчеләр күбрәк тә булгандыр. Шунлыктан, аз гына урыныңны алмаштыру да башкаларга буталып китү өчен бик җиткән. Кыскасы, без икебез дә атлы булдык. Атка атланып, икенче хуторга киттек. Яшенле яңгыр артыннан бу төнне сибәләп кенә җылы яңгыр яуды. Без атларны тышаулап, печәнгә кушып, үзебез печән кибәненә куыш ясап, шунда кереп ял итәргә, аз гына черем итәргә булдык.

Безнең чигенү Ростов, Төньяк Кавказ тимер юлы буйлап Кущевская аша Тихорецкига таба дәвам итте. Тамак газабын, юл газабын укучы кеше үзе чамалар, күз алдына китерер, ул турыда язып тормыйм. 1942 елның җәендә Советлар Союзы өчен гадәттән тыш авыр хәл туа. Немец армиясе инициативаны үз кулына ала. Немецлар Донны үтеп, Сталинградка якынлаша. Кавказга үрмәли. Вакыты истә калмаган, июль аеның ничәседер? Чигенү бетте. Тихорецк шәһәре янында безне туктаттылар. Һәр чигенүчене, кемнең нинди частьта хезмәт итүенә карамастан, тезеп, полк, рота, взвод, отделениеләргә беркеттеләр. Мин укчы полкка эләктем, ләкин ул полкның ничәнче полк икәнен дә хәтерләмим.

Бер тәүлек ял иткәннән соң, безне автомашиналарга төяп, чигенгән юлыбыздан кире (50 км тирәсе) алгы фронтка алып киттеләр. Без Кавказга үрмәләүче немец армиясе юлына каршы бастык. Һәр авыл, һәр калкулык, һәр километр тимер юл өчен каты сугышлар башланды. Немец армиясе һаман алга үрмәли, безгә зур югалтулар белән чигенергә туры килә. Без авылларны калдыра барабыз, ә алар авылларга урнаша киләләр. Кыскасы, без немецларның алга баруын туктата алмасак та, аның хәрәкәтен тоткарладык һәм аларның байтак кына җанлы көчен юк иттек. Гәрәбә кебек бодай өемнәрен, дошманга калмасын дип, керосин сибеп яндырулар да, терлек көтүләрен юк итүләр дә булды. Янәшәңдә яраланып авып калган иптәшеңә ярдәм итә алмыйча, аны калдырып китүләр дә булды. Сугыш!.. Сугыш!..

## Чигенүче армиядә. Контузия

Бер адым да чигенмәскә! Немецларның Кавказ һәм Сталинград юнәлешендә хәрәкәтен туктату бурычы шулай катгый куелса да, чигенүче безнең армиягә немецларны туктату бик кыен иде. Чигенү вакытындагы нигезсез, әзерлексез сугышларда җанлы көч тә, техника да күп югалды. Авыр орудиеләр Дон аша үтә алмады. Чигенүче армиягә танклар белән дә, һавадан да ярдәм булмады.

1942 елның август урталарында Краснодар өлкәсенең Тихорецк белән Ростов арасында зур гына станица өчен бик каты бәрелеш булды. Немецларның мотопехотасы безне чолгап алырга тырышса да, зур югалтулар кичереп, без урылмаган иген басуы аша чыгып котылдык. Безнең көч торган саен азая, сафлар сирәгәя барды. Якшәмбегә каршы, кечкенә генә авылга туктап, гадәттәгечә оборонага урнаштык. Иртә белән авылда ара-тирә халык күренсә дә, соңга таба авыл хәрәкәтсез калды. Якшәмбе көннең тынычлыгыннан файдаланып, авылның төн ягына окоп-траншеяларга урнаштык. Һәм авылның көньягына икенче линия оборона хәстәрлеген дә күрдек. Ике яклап сөзәк иңкүлеккә утырган бер урамлы авыл уртасыннан кечкенә генә инеш ага. Авыл шактый яшел. Бакчага урнашкан позициябез немецларны ут белән каршыларга бик уңай. Безнеңчә, немецлар калкулык аша чыгып, үзәнлеккә урнашкан авылга төшәргә тиешләр – аларны прицелга аласы гына кала. Без немецларны авылга якын җибәреп, кинәт ут ачарга, аларны авылга кертмәскә, чигенергә мәҗбүр итәргә тиешбез. Авыл өстеннән немецларның разведка самолётлары очып үтте. Безнең көч аз. Уң һәм сул флангларда һәм үзәк өлештә берәр пулемёт булып, калган сугышчыларда винтовка, автомат һәм гранаталар. Менә шул кораллар белән без немецларга каршы торырга, аларның алга барышын тоткарларга тиешбез. Немецларны иртән үк көтсәк тә, алар сәгать 10-11ләрдә генә пәйда булдылар. Немец пехотасы башта аяк өсли кыр буйлап сибелеп төшсә, авылга якынлашкач, сугыш алымы буенча, җиргә ятып, иген кыры аша алга шуыша башлады. Алар бу кечкенә генә авылда безнең техника юклыгын яхшы беләләр. Зур көч юклыгына да ышаналар булса кирәк. Саклык йөзеннән алар, шуышып, һаман авылга, безнең позициягә таба якынлашалар. Немецның танклары да күренми, артиллерия тавышы да юк. Иген арасыннан үзләрен ачык күрмәсәк тә, аларның хәрәкәте сизелә. Сигнал булуга, без немецларга ут ачтык. Немецлар җиргә сеңделәр һәм безгә каршы ут та ачтылар. Бурыч: ничек тә немецларны бакчаларга, каралты-курага, йортларга якын җибәрмәскә! Озак көтәргә туры килмәде, авыл өстенә миномётлардан ут ачтылар. Без ике ут арасында калдык һәм икенче позициягә чигендек. Немецлар авылга керделәр, аларның мотопехотасы авылны урап ала башлады. Авылның

көньягына артиллерия снарядлары төшеп, безнең чигенү юлын бүлде. Без солы кыры аша, урман полосасы буйлап, чигенә башладык. Солы кырыннан шуышу хәтердә, ә калганын белмим. Соңыннан уйлавымча, шул солы кырында мин немец снаряды яки бомбасы шартлаудан контузия алганмын. Нindидер бушлыкта томан эчендә йөзәм. Күз алдымда нindидер алкалар оча, шәүләләр йөзә. Колак шаулый, тоташ бер гүләү. Хәлсезлек. Күз ачылмый. Ми кайный. Калтырану... Мин үземне белештерми күпме ятканмындыр, ә исемә килгәндә шундый бер авыр хәлдә идем. Салам өстендә ятам икән. Янымда кешеләр. Сөйләшәләр, ләкин һични аңламыйм. Соңга таба төшендем: мин авыру, ә минем янымда яралы солдатлар. Мин тирә-юньне таный башлагач, тагын шуны аңладым – без немецлар кулында, имеш. Ә берничә көннән чыннан да немецларда әсирлектә икәнлекне аңладым. Без бу авылның клуб идәнендә, белмим, күпме яткандырбыз, ул да билгесез. Җиңел яралы, контузия алган совет солдатларын җыйнау берничә көн дәвам иткән. Үзләренең монда эләгүләрен төрлесе төрлечә сөйли.

Берничә көн үткәч, йөри ала торган әсирләрне колоннага тезеп, яралы һәм безнең кебек хәлсезләрне автомашинага төяп, каядыр – көнбатышка алып киттеләр. Ростов шәһәрендә безне бер ишегалдына алып кереп, машинадан бушаттылар. Без килгәндә бу ишегалдында халык байтак иде, зур капкадан әледән-әле яңа әсирләр колоннасы кереп тора. Бирედә төрмә булган дип сөйләделәр. Безгә – яңа килүчеләргә рәт-рәт тезләнеп утырырга куштылар. Утырдык. Немец офицеры нәрсәдер сөйләнде, тылмач безгә аңлатты:

– Арагызда кем комиссар, кем еврей? Комиссарлар, еврейлар, алга чыгыгыз!

Ләкин беркем дә урыныннан кузгалмады. Озак та үтмәде, сафлар арасына кереп, немец офицерлары комиссарларны һәм еврейларны тышкы кыяфәтләренә карап эзли башладылар. Берничә кешене сафтан аерып алдылар һәм стена буена илтеп тезделәр. Немец офицеры сөйләде, тылмач русчага тәрҗемә итте. Эчтәлеге түбәндәгечәрәк хәтердә калган: имеш, Россиядә кысанлыкта яшәгән халыкларга Германия армиясе ирек бирә, Кызыл Армия сафында солдатларны немецларга каршы котыртучылар – комиссарлар, ә тылда дөнья бутаучылар – еврейлар, шуның өчен аларны кырып бетерергә, арабызда булган комиссар һәм еврейларны тотып бирергә. Анда стена буена тезелгәннәргә стенага карап басарга, кулларын югары күтәрергә боерык булды. Озак та үтмәде, винтовкалардан залплар яңгырады, стена буендагылар бөгелеп төштеләр. Ростовта булуның беренче сәгатендә үк немецларның менә шундый вәхшилеген күрдек. Монда без 4-5 көннәр торганбыздыр. Ашау бик тә начар. Көненә ике мәртәбә баланда бирделәр. Ул күгәргән икмәкне җылы суда изрәткән болганчык су. Күпчелек солдатның шул суны салдырырга котелогы гына да юк, шул җөмләдән минем дә. Төннәрен ачык һавада кунабыз. Хәлсезлек торган саен көчәя. Баш әйләнә, күз күрми башлый. Бу арада мин ике рус егете белән танышып алдым. Аларның икесенә бер плащ-палаткалары бар. Төннәрен үзләре яннарына мине дә сыендыралар, рәхмәт төшкерләре. Без фронтта булганда һәм оборонада торганда немецлар безнең өскә самолётлардан күпме листовка ташладылар! Ул листовкаларда Германия – җәннәт, Советлар Союзы тәмуг итеп сурәтләнгән була. Кичләрен көчле радио рупорлары аша, төче телләнеп, үзләре ягына чыгарга өндиләр. Аларның ничек эш итүләрен, вәхшилекләрен, канэчкеч булуларын газеталар аша укып белә идек. Политзанятиеләрдә безгә бу турыда бик ачык аңлаталар иде. Шушы кыска гына вакыт эчендә дә фашизмның нәрсәгә сәләтле икәнен үз күзебез белән күреп белдек. Картлар әйтмешли, дустыңа түгел, дошманыңа да Ходай язмасын немец колы булырга.

**Редакциядән:**

*Хөрмәтле укучыларыбыз! Мәгъсум Харисовның «Укытучы иртә чалара» дип аталган истәлекләренең журнал вариантын шуның белән төгәллибез. Авторның улы, басмага әзерләүче Ренат Хариска рәхмәтебезне җиткерәбез һәм истәлекләрнең тулысы белән китапта басылып чыгуын телибез.*

# Зәки Вәлиди Туган

## ХАТИРӘЛӘР

### Ибраһим Качкынбай

Ибраһим, Алакуянбаш авылының имамы Шәмсетдин Качкынбай углы, миннән ике яшькә олырак. Буе ике метрга якын Шәмсетдин белән янә үзе кебек озын буйлы агам Вәли мулла, башкорт атлы гаскәре полкында бергә хезмәт иткән вә югарыда исеме аталган Йосыф Майор Карамышевның боерыгында урыс гаскәренең Сыр-Дәрья буйларында, Кукандларга каршы яуларында бергә булганнар. Вәли мулла кебек, Шәмсетдин Качкынбай да гарәпчә, фарсыча һәм урысча яхшы белә вә һәр икесе дә Чыгытай әдәбиятына, аеруча Әхмәт Ясәви, Нәваи вә суфи Аллаһияр әсәрләренә чыннан да мөкиббән шәхесләр иде. Бөрҗән башкортлары арасында Сәет углы Габдулла исемле шәех белән бу Шәмсетдин Качкынбаев культуралары мөкәммәлләшкән инсаннар иде. Һәр икесе дә Сыр-Дәрья буйларында булып, күршеләребез Макар авылыннан Йосыф Майор Карамыш вә Сайран авылыннан Бәкбулат мулла кебек, Урта Азия культурасын Башкортстанга алып килүчеләр. Боларда гарәпчә, фарсыча язма әсәрләр дә бар иде. Шәмсетдин мулланың китаплары арасында «Миһр вә Мөштәри» исемле бер-берсен хөрмәт иткән ике егет турындагы ак шигырь белән язылган хикәясе бар иде. Мулла минем белән углы Ибраһимны бу «Миһр вә Мөштәри»гә охшата иде һәм безгә ул хикәяне сөйли торган иде. Бу әсәрнең рәсемнәр белән бизәлгән гүзәл бер нөсхәсен 1958 елда Вашингтонда «Freer Galleri of Art»та күрдем.

Шәмсетдин улы Ибраһим атамның мәдрәсәсендә укыта иде. Минем кебек, Ибраһим да гарәпчә, фарсыча белән бергә урысча да өйрәнде. Урыс телен, минем белән чагыштырганда, Ибраһим яхшырак белә иде. Гарәп, фарсы культурасы, безнеке белән чагыштырганда, гаять югары. Ибраһим гадәттән тыш ягымлы, назик күңелле, мәһабәт, бик зиһенле егет. Өстебездәге киемнәребез, «билбау» дип аталган озын ефәк кушакларыбыз, биек үкчәле итекләребез, ат дирбияләребез, өзәңгеләребез, коешкан каешларыбыз, түшлек, аркалыкларыбыз, аелларыбыз, ияр җәяләребез, камчыларыбыз, Дагыстаннан килгән тимерчеләр, көмешчеләр тарафыннан коеп эшләнгән ат җиһазларыбыз икебезнең дә бертөсле иде. Безгә боларны Ибраһимның анасы эшләтте. Чигешле-бизәкле кушакларны үз куллары белән тукып бирде. Ибраһим белән кыш айларында Үтәктән кайткан вакытларда, язын май, апрель, сентябрь айларында мин аларда яши идем, бу айларда без гел бергә була идек. Атасы вафат булгач, анасы «ялгыз калдым», дип, Ибраһимны өйләндерде. Шуңа күрә, укуын дәвам иттермичә, көр тормышлы гаиләсенең өй эшләрен карау мәҗбүрендә калды һәм ул моңа бик борчыла иде. Аларның атлары Шүлгән токымлы, яхшы нәселле атлар иде. Имеш, риваятьләргә күрә, бу токымның бияләре Шүлгән исемле авыл янындагы мәгарә күленнән чыккан айгырлардан буаз калганнар икән. Ибраһим иң җитез атлары арасыннан бер айгыр, бер бияне миңа бүләк итте. Бу бия белән айгыр безнең ат көтүенә килеп кушылгач, «нәселсез атларыбыз арасына затлы канлы атлар килеп кушылды», дип горурлана торган идек. Мәдрәсәне ташласа да, Ибраһим китап укуын ташламады. Аның иң яраткан шагыйрьләре урысчада – Лермонтов, фарсыдан – Аттар вә Аллаһияр, төркчәдән – Нәваи, «Мөхәммәдия» китаплары иде. Икебезнең арада бик тә самими язылган хатлар йөри башлады. Бу хатлар, Бохарада күрдегем ысулда, томар шәкелендә, озынча итеп төрелгән кечкенә торбачыклар иде. Күпвакыт бу хатлар халык шигырьләре вә яки борынгы әдәбияттан алынган әсәрләр белән баетылган була иде. Берсен әле дә булса хәтерлим. Кар яуганда, ике җылкыбыз авылга, араннарга кайтмады. Мин Ибраһимга

*Дәвамы. Башы 7, 8нче саннарда.*

хат яздым, адашкан җылкыларыбызны ике яклап эзләргә кирәк иде. Хатыма каршы ул җавап язды: «Баш өсте, башкарырбыз. Инсан дустын – солтан, үзен – аның колы, дустын – рух, үзен тик гәүдә дип белсен. Дус бүрек кияргә теләсә, башыңны бир, җаныңны теләсә, җаныңны фида кылырга әзер бул!» дип язылган иде хатта. Чыннан да, Ибраһим хезмәтчеләре белән бергә берничә көн эзли торгач, безнең авылдан 80 чакрым ераклыкта җылкыларыбызны табып, өебезгә хәтле китереп тапшырды.

Башкортларның җәйге тормышы ялкаулыктан гына торадыр кебек күренсә дә, мал асрау, урман эшләре, бал кортлары үрчетү, гаскәр хезмәтендә аларның ялкаулыгы тылсымлы кул белән сыпырып алгандай юкка чыга. Ибраһим шуларның бер мисалы иде. Җылкыларыбызны тапканчы, тау араларында ат чаптырып, 200 чакрым ара узганнар. Ибраһимның атасы аңа Нәваиның вә Госманлы әдәбиятыннан Язучы углының «Мөхәммәдия» әсәрен вә Кәмал Өмми шигырьләре тупламасының бик күп урыннарын фарсычадан – Аттар, Хафиз Дивани вә Тимернекеләр заманында бик могтәбәр булган «Нөзхәт әл-арвах» китабын ятлаткан. Мин бу соңгы аталган әсәр белән һич таныш түгел идем. Соңыннан 1913 елда Бохарага килгәч, бу әсәрне эзләп табып, берничә кат укып чыктым да Ибраһимны исемә төшердем. Байтак вакытлар узгач, бу әсәрнең кесәгә сыешлык кечкенә нөсхәләрен күрдем. Шәмсетдин мулланың фарсыча берничә кулъязма әсәре бар иде. Ләкин боларның нинди китаплар икәне һәм аларның язмышы турында миңа мәгълүм түгел, ул чакта бу язмалар белән кызыксынмый идем әле. Ибраһим белән мин кымыз мәҗлесләрендә чыгытайча шигъри әсәрләрдән мәгълүм бәетләр сөйли идек. Дустым Ибраһим «курай» дип аталган башкорт уен коралында хисапсыз күп көйләр уйный-уйный җырлый. Ул бик тә саф, нечкә тавышлы иде. Кайвакыт ул тау түбәсенә менеп курай уйный, җырлый. Җырлаган җырларында, Такыя-Сусак дип аталган тауларга бәрелеп, кайтаваз булып кире кайта. Ул кайтаваз тыңларга ярата, монда, Ярув, Карагач җәйләүләрендә чакта, Качкынбайлар ат сыртында чапканда җирдән камчы кармап алу уеннары уйныйлар иде. Камчыны ала алмаганнарны камчы белән яралар. Галишер Нәваи дә Сары-тула исемле төрек дусты белән яшьлегендә шундый ат бәйгеләренә катнашканлыгы турында яза:

*Мин Сарыг-тула илә берлектә юлга чыксам,*
*Тау, ялан, үзән вә йә чүл икәнен аермыйча,*
*Бөркәвеч ярыгыннан кулларым чыгарып,*
*Ул качса ки, мин кусам, мин качсам ки, ул да куса.*

Ибраһим шушы мәгънәдәге шигырьне һәр форсат чыккан саен укый иде. Кызу канлы яшь-җилкенчәк егетләрнең ат менгән кызлар белән куышу гадәте бар иде. Кыздан качып өлгермәгән егетне куып җиткән кыз камчылый, кызны артыннан куып җиткән егет аны үбәргә тиеш. Алдарак яшәгәннәр вакытында бу рөхсәт ителә иде. Ибраһимның туганы булган Оркыя исемле бер кыз шундыйлардан иде. Ибраһимның хатыны Аккилен бу вакыйгаларда тамашачы буларак катнаша иде. Безнең авылда, гаиләбездә сабый чагымда Мөхия, Гөлсем исемле апаларыбыз җайдаклыкта ирләрдән калышмый иде. Фәкать авылыбызга күчеп килгән татарлар мөселман культурасына артык капланып, бер җәмәгать булып урнашканнарына күрә, аларның йогынтысы аркасында, хатыннарыбызга да аларның культурасы йокты. Куып җиткән егетләр кызларны үпми башлады. Бөрҗәннәр дә урыны-урыны белән бу гадәтләрне алдылар. Җилдәй җитез атка атланган булса да, мин Оркыя артыннан куып җиттем. Ул иске дастаннарда язылган «Кара юрга» җырын гүя атланган атына багышлаган кебек: «Үз сыртымдагы бикәчне үптертмәм вә бикәчне кочтыртмам», дип җырлый иде. Бу «кызкуыш» ярышларында мин Оркыяны куып җиттем, беләгеннән тоттым, ләкин үпмәдем. Картлар кычкыра: без үбә идек, син дә кызны үп, дип кычкыралар. Соңыннан Оркыя мине куып җитте дә камчы белән яра башлады. Шулвакыт Аккилен: «Һыдыр ошол татарды, тиреһен һалдыр», дип кычкыра башлады. Чөнки без татарларга – башкорт, Бөрҗәннәр өчен татар була килдек. Качкынбайларның гаиләсендә кымызның иң шәбе эшләнә, Алакуян елгасының Агыйдел суына кушылган җирендә корылган, «Ызба» дип аталган кышлакларга күченгәч, әчебал эчәләр иде, һәм бик тә хәтәр биюләр була торган иде. Намазны да онытмыйлар, исерек-

сәрхуш булсалар да, намазны укыйлар. Рамазанда ураза тотмаган кеше булмас иде. Миңа халык дастаннарына, милли уеннарга, кызкуышларга мәхәббәт тәрбияләгән агам Вәли мулла белән Качкынбай булды. Ибраһимның ир-егет холыклы анасы да, Ибраһимның хатыны да, мулланың кызлары да укый-яза беләләр иде.

## Бүтән иптәшләрем

Яшьлегемдә иң якын дусларымнан авылыбыздагы җәгәнем (пләмәннигем) Нурмөхәммәд белән күрше Макар авылындагы бер имамның углы Газиз һәм урысча башлангыч мәктәп мөгаллиме Мифтахетдин углы Әмир Карамышев иде. Нурмөхәммәд укуын дәвам итмәде. Аның белән бергә урман эшләренә йөрибез, бергә сунарга барабыз, чаңгылар киеп, кыш көне бергә куян аулыйбыз. Бәгъзе әсәрләр язган Газиз исә Троицкидагы шәехның мәдрәсәсендә бер үк вакытта урыс мәктәбендә дә укый, бик зиһенле, шагыйрь бер егет иде. Соңыннан мәшһүр шагыйрь Мәҗит Гафури белән берлектә Троицки шәехенең мәдрәсәсендә белем алалар. Һәр икесе бергә казакъ арасына китеп, җәй көне мөгаллимлек кылалар һәм көзләрен икесе дә, авылларына кайтып, Газизләрдә кунак булалар. Газиз шагыйрьлек ягыннан, Мәҗит белән чагыштырганда, истигъдадлырак (талантлырак) булса да, басылган әсәрләре юк иде. Мәҗитнең бер-ике кечкенә шигырь мәҗмугасы чыкты. Мин аксак шагыйрь белән (ихтимал, 1907 елдыр) беренче тапкыр күрештем, соңыннан алар Газиз белән бергә берничә тапкыр безгә килделәр. Һәр икесе шигырьләрен укыды, атам белән анама ул әсәрләр бик ошады. Мәҗит басылган әсәрләрендә: «башкортлар Идел белән Дим елгасы буйларында үзбаш хөр җәмгыять булып яшәгәндә, чит-ятлар килде дә аларны әсир итте», мәгънәсендәге шигырьләрен шул вакытта укыды. Мәҗит миннән сигез-тугыз яшькә кече иде. Газиз биш яшькә олы булгандыр, дип уйлыйм. Әмир исә миннән бер-ике яшькә кече. Шуңа да карамастан, ул шигырьне яхшы аңлый, Мәҗит белән Газизнең шигырьләрен яттан сөйли. Әмир соңыннан урысча укырга керде вә хәрби мәктәптә укуын дәвам итте, ниһаять, 1917 елгы милли хәрәкәтләрдә аның белән бергә корган беренче хәрби бүлекләрдә Беренче атлы гаскәрнең командиры, соңыннан төмән (ун меңлек гаскәрнең) җитәкчесе булып китте.

Карамышевлар гаиләсе әһелләренең барысы бик укымышлы иде. Алар XVIII- XIX йөзьелда башкорт гаскәрендә субай, ватандашлык эшләре башында торучы «кантон» җитәкчеләре булып хезмәт итәләр иде. Минем олы агаларым югарыда Йосыф Майорның идарәсендә иде. Боларның барысы да күчмә тормышны ташлады, һәм авылда бары тик мәдәни эшләр генә кайный иде. Өйләрен акшарлыйлар, әтрафы бакчалы, бакчаларда җиләк-җимеш, аеруча, алма чәчәк ата. Йосыф Майорның Сыр-Дәрья елгасы буйларында утыручы авыллар турында вә казакъларның иҗтимагый тормышына кагылышлы урысча матбугатта язмалары да чыкты. Болардан гаиләбезгә дә, Качкынбайларга да иң якын Гомәр Хаҗи исемле бай, олы яшьтәге бер зат иде. Бу зат борынгыдан Башкортстан Мохтари булган заманнарда кантон рәисе иде. Төркияне, Хиҗазны барып күргән кеше. Троицкидагы Зәйнулла ишанның иң якын дусты иде. Бу Карамышевлардан Әхмәт исемле берәү, байтак еллар элек Алмания императоры гаиләсенә кымыз эчертер өчен, бияләре һәм хатыны белән бергә Алманиягә күчеп киткән. Шулай итеп, ул алманча сөйләшергә өйрәнеп кайтты. Ул безгә Алманиянең гүзәллекләре турында рәсемнәр күрсәтеп сөйли иде, ягъни Алман пропагандасына хезмәт итә иде. Фәкать безнең иң яраткан кешебез Карамышевның атасы, урысчага өйрәтүче Мифтах иде. Боларның күбесе соңыннан Башкортстан мохтарияте хәрәкәтендә хәрби вә идарә эшләрендә минем янымда вазифа алдылар. Башка якын иптәшләрем авылыбызның көньяктагы Сайран, Арлар авылларында Бәкбулат хәзрәт, Нури мөәзин белән Госман Хаҗи Ильяс углы гаиләләре иде. Боларның угыллары – атамның мәдрәсәсендә укып чыккан кешеләр. Болар 1917 елдан соңгы вакыйгаларда безнең хәрәкәтләребездә төрле вазифаларда булды.

## Атамның Җаекка сәяхәтләре

Август аеның ахырларында Ирәмәл дип аталган җирдәге көтүлектә печән чабу, чапкан печәнне киптерү һәм җыю өчен атам өмә оештыра торган иде. Өмәләрдә кабиләбезнең «Илчек-тимер» ыруына насыйп авылларның күбесе катнаша, бик күп мал чалына иде.

Бу – гаиләбезнең олы бер бәйрәме кебек иде. Бу эш беткәч, атам дуслары вә шәехләрне күрергә юлга чыга. Бу сәяхәт Троицк шәһәрендәге пири-шәех Зәйнулланы зиярәт итү белән тәмамлана. Юлда барганда, Карагай, Кыпчак, Бөрҗән ыруларына караган дусларының вә шәехләренең җәйләүләрендә аш мәҗлесләре уза. Бу мәҗлесләрдә алар гыйльми, дини, хәтта кайбер сәяси мәсьәләләр турында да сөйләшәләр. Кире кайтканда, атам үзләрен дастан каһарманы «Чура Батыр туруннары» дип санаган ырулар: Мәһди белән Әмин авылларының мөселман казакълары, төнгәвир, төнгатар, тамьян вә катай кабиләләренең юлы белән кайта, аларда да кунак була. Бу сәяхәт ай ярым вакыт дәвамында була. Һәр елда кабатланган бу сәяхәтләрнең өчесендә мин дә катнаштым, мин атларны, арбаларны карап торыр өчен атам белән бергә йөри идем. Һәр сәяхәт минем фикри хәятемдә яхшы тәэсир калдыра иде. 1904 елдагы сәяхәтебез – Рус-Япун сугышына, 1905 елдагы сәяхәтебез – Урыс түнтәрелеше көннәренә, өченчесе 1906 елда Урыс Думасы бәрелешләре вакытына туры килде. Мин тасаввуфны (хорафатларны, мистиканы) сөйми идем. Рыякяр (мәкерле, хөсетле) булган шәехләргә нәфрәтле идем, шуның белән бергә араларында Муллакай Габдулла хәзрәт, Колбакты Ѓабделханнан хәзрәт кеби, атамның табындашы булган Троицкидагы дусты Зәйнулла хәзрәт кеби самими инсаннарны, әхлак вә игелеге булганнарны бик хөрмәт итәм. Искә алынган бу өч сәяхәтемдә мин бик күп матур нәрсәләр күрдем һәм гүзәл нәрсәләргә өйрәндем. Җөмләдән, 1906 елда сәяхәткә чыккач, Зәйнулла ишан миңа күп илтифат итте. Бәләкәй булуыма карамастан, ул миңа төрле сөальләр биреп, җавапларымны дикъкать белән тыңлый һәм үгет-нәсихәт бирә. Беркөнне иртәнге чәй мәҗлесендә янә нindidер сорау бирде бу, мин белгәнемчә җаваплапдым. Аннан соң барысының каршысында: ал, углым, бәлки, берәр нәрсә сатып алырсың, дип кулыма ун тәңкә алтын акча тоттырды. Мин бу акчага «Хезмәт» дип аталган татар китабы кибетеннән Газзалиның динне (теологияне) тәнкыйть иткән бер әсәрен, Мисырда да, Истанбулда да басылган һәм Ислам җәмгыяте вә фәлсәфәсенә кагылышлы басмаларны, башка бәгъзе гарәпчәгә тәрҗемә ителгән урыс романнарын, французча өйрәнү өчен төрекчә «Мүкаләмә-и Франсевия» китабын вә бер урыс кибетеннән Толстойның 1891 елда мин туган елда булган котчыккыч ачлык турындагы «Ачлык еллары» исемле әсәрен сатып алдым.

Берничә көннән соң шәех миннән акчамны нәрсәгә тотканым турында сорады. Мин сатып алган китапларымны санап күрсәттем. Хуплады, «урысча беләсең икән, хәзер французча да өйрәнсәң, бик яхшы булыр», диде. Физика вә астрономия китапларын алганымны да бик ошатты. Толстойның ачлык еллары турында язган китабы хакында аңа сөйләдем, бик яхшы китап алгансың, диде. Мәгәр ки, шәех ун тәңкәне мине сынап карар өчен биргән булып чыкты. Берничә көн узгач, ул нинди китаплар укыганлыгым турында, аларның эчтәлеге турында сорады. Газзалиның «әл-муккыйз мин әл-далала», ягъни «ялгыш юлдан китүдән коткаручы» исемле әсәрен алганым турында әйткәч, шәех «син моны аңламассың», диде, «мин ул китапларны гарәпчәне ныклап өйрәнгәннән соң укырмын», дидем. Ул минең аркамнан сөйде һәм тагын акча бирде. Башка мәҗлесләрдә дә ул минем бу эшемне бик хуплый иде:

– Унбиш яшь кенә булуына карамастан, бу бала китап сайлый белә! – дигәч, мин бик нык горурлана идем. Аны барысы да бик хөрмәт итә иде, бу затның мактау сүзләре мине канатландыра, аның хуплаулары булмаса, бәлки, минем тормышым гыйльмияттән башка юнәлешкә киткән булыр иде. Казан шагыйре Тукай әйтмешли: азмы какканны вә сукканны күтәрдем мин ятим, азрак үстерде сыйпап тик маңлаемнан милләтем. Әгәр шәехнең бу хуплаулары булмаса, мин сәүдә белән мәшгуль булып, бер прикашшик кына булып калган булыр идем.

## Казакълар вә Себер (Төмән) татарлары белән аралашуыбыз

Бу сәяхәтләребез бары тик Көнчыгыш Башкортстан төбәкләренә генә түгел, казакълар арасындагы багланышларны да тәэмин итә иде. Бу элемтәләр 1917-1918 елларда башкорт Милли хәрәкәтен оештыру гамәлендә бик зур файда эшләде. Патша хөкүмәте Башкортстан белән Казакъстан арасында бер урыс өлкәсе корып, Җаек (Урал) елгасының көньягында миллионнарча гектар казакъ җирләрен басып алып, казакъ

төркләрен шул җирләрдән куып чыгарды. Әмма 1904 вә 1905 елларда казакълар, аеруча, кыпчак күчмәннәре Башкортстан чиге буйларында яшәп, хайванчылык белән шөгыльләнүләрен дәвам итә иде. Болар арасында атамның дуслары Найза белән Нурпәй Хаҗи исемле бик байларның ике гаиләсе бар иде, аларны зиярәт итеп, аларда берничә көн кунак булдык. Нурпәй Хаҗи атам белән яшьтәш. Соңыннан атам аның белән бергә хаҗга китте. Болар Троицкиның көньягында Еркарагай өлкәсенә якын тора. Бу кыпчаклар – XVIII гасыр гыйсъяннарында катнашкан һәм патша эзәрлекләвеннән качып килгән башкортларны сыендырган халык. Нурпәй хаҗи бик күп дастаннарны яттан белүче бөек шагыйрь иде. Мин ул дастаннарны аның үз авызыннан язып алдым. Советлар матбугатында бер казакъ шагыйренең Советларны мактап шигырьләр чыгарганы турында язалар иде. Ул шагыйрьнең исеме Нурфәез Байганин, һәм Советлар аның кайбер шигырьләрен бастырып та чыгарды. Соңыннан мин очраклы рәвештә генә белдем: бу Байганин безнең Нурпәй хаҗи, ләбаса. Бу зат үтә милләтче вә мөселман иде. «Кобланды» исемле мәгълүм бөек дастанның иң дөрес, иң тәфсилле риваятен ул гына белә иде. Бу сәяхәтләрдә атамның иске дусларыннан типтәрләр авылы Ахун Муса хаҗиның «төнгатар» башкортларыннан Гайсә Ахун исемле бер затның Тамьян ягындагы Чакмагыш авылында Габдуллатыйф хәзрәт дигән бер шәехнең угыллары илә якыннан таныштым. Болар белемле вә зыялы инсаннар иде. Алар 1917-1918 елларда милли хәрәкәтләрдә, хөкүмәттә мөһим вазифалар башкарды, Тамьяннан Мортазаның углы Муса бездә Икенче гаскәрнең төмәнбашы иде.

1907 елда атам агам Хәбиб Нәҗҗар белән бергә тимер юл буйлап Уфа, Чиләбе юлы илә Троицк шәехен зиярәт итәргә китте. Мин аларны Дәүләкән тимер юлы ыстансасына илтеп куйдым, ул вакытта миңа 15 яшь иде, беренче тапкыр тимер юлны күрдем. Караңгылыкта поездның утлары ерактан күренде, соңра яктылык зурая башлады, атлар курыкты. Локомотивның дәһшәтле гөрелтесен ишеткәч, атлар тыеп тора алмас дәрәҗәдә дулый башладылар. Арба диварга бәрелде. Фәкать өйләр артына чыккач кына, атларны мең бәла белән тыя алдык. Атам белән агам арбада иде, ләкин аларга һични булмады. Бу сәфәрендә атам, Троицкидан кайтканда, Себердә Мансил саласында яшәүче Нигъмәтулла хаҗи өенә төшкән һәм аннан мәшһүр Себер мохтариятчесе вә иске түрк Орхон язма һәйкәлләрен тапкан Ядринцевнең «Колония буларак – Себер» вә «Себердәге урыс булмаган милләтләрнең хәле» исемле ике сәяси әсәрен алып кайтты. Углының (ягъни, минем), атам сөйләве буенча, урысча белгәнемне ишеткәч, Нигъмәтулла хаҗи бу ике әсәрне бүләк иткән. Бу иң олы вә иң әһәмиятле бүләк иде. Һәр ике әсәрдәге мәкаләләрдән аңлаганымны атама вә агама бөртекләп тәрҗемә иттем. Бу документларда урыс булмаган милләтләрнең инкыйразга мәхкум булуы, аларның тигез хокуклы булырга һәм үзләренчә яшәргә тиешлеген яклап чыккан сүзләр бар. Һәр ике әсәр дә минем сәяси мәйданга килүемә нык тәэсир итте. Бу Мансил саласында атамнан алда агам Вәли мулла булып киткән икән. Шулай итеп, Көнбатыш Себер (Төмән) татарлары белән элемтәләр урнаштырылды.

## Атамның тасаввуфы (мистикасы), суфилыгы

Сәяхәтеннән кайтуга ук, атам: «Фазканга барабыз», диде. Фазкан дигәнебез Алакуянбаш авылында яшәүче Качкынбайларның берсе иде. «Фазкан», ихтимал, Фазулла яки Фазилханнан алынгандыр. Фазкан – суфи, типтерүче, юмарт вә егет бер адәм иде. Менә шушы Фазкан:

– Әхмәдша (ягъни, минем атам) шәехлек алса, мин аның иң беренче мөриде булыр идем, – дигән икән.

Бу ел шәех Зәйнулла атама шәехлек дәрәҗәсен бирде, атам язулы таныклык та алды. Ләкин атам шәехкә әйткән:

– Суфилык заманы узды инде, ишан (шәех) дәрәҗәсен алдым, әмма мөрид буларак, Фазканнан башка беркемне дә алмам, чөнки аңа сүз биргән идем, – диде. Фазкан аз гына малы булган авыл кешесе иде. Муллакай хәзрәтнең шәкерте. Фарсыча да, гарәпчә дә белә. Ул безнең авылдан 100 чакрым арада яши иде. Аның янына барып җиттек. Атама аттан төшәргә ярдәм итим, дип, янына килдем, өйдән тавыш, хәттаниндидер

гөрелте ишетелде, ләкин шәехне каршыларга беркем дә чыкмады. Ниһаять, берәү чыкты. Ул Фазканның үзе икән, ул исерек иде. Ул атамның өзәңгесен үпте. Атамны аттан төшерде дә өенә алып кереп китте. Өйнең эче әчебал исе белән тулган, ис чыдап булмас дәрәҗәдә иде. Атам «ах, дуңгыз, тагын эчкәнсең», диде. Чыннан да, монда ниндидер бер типтерү мәҗлесе булганга охшый. Фазкан сөйләп бирде:

– Син килгәнне күргәч, көрәгәләр (ягъни, бал мичкәләре) – сәке астына, кунакларым тәрәзәдән чыгып качты, – диде.

Бераздан соң икенде намазын укыдык. Фазкан җылый иде, озак җылады ул, аңа кушылып атам да җылый. Ясәвинең: «Суфи сурәтле булдың вә ләкин беркайчан да мөселман булмадың», шигырен икесе бергә укыдылар, тәэсирләнделәр. Югарыда бер тапкыр искә алынган, асылы Шәмс-и Тәбризи-Мәүланадан килгән бу акылдан яздырырлык шигырьләрнең мәгънәсе шул иде: бер сәрхуш сиңа сәлам бирер, кальбеңне урлаган бу адәмнең җаны сиңа ялчы булып хезмәт итә. Син юкны – бар вә барны юк итүчене беләсең, сәрхушның сәламын тыңла, бу шундый бер сәрхуштыр ки, һәр ике кулын капкыныңа каптырмыш. Син һәр иреннең тәмесең, һәр мәзһәпнең кыйбласысың, күктәге ай исә һәр кичтә өеңнең әтрафында сакта тора. Бу гыйшык бер карасаң, сиңа канат бирә: син очасың, бер карасаң, син көймәнең ләңкередер (якоредер) кузгалмыйсың; бер мизгел – ул синең таңыңдыр, бер мизгелдә исә синең кояшың баер. Ул, сине бер мәл тетрәндерер; бер мизгел ул шаркылдатып көлдерер, бер карасаң, сине исертер, бер карасаң, сине җансыз бәллүр итәр, ташка әверелдерер. Зарар юк, тән булмасам, бәллүр булырмы; гәүһәр булмасам, гәүһәрләрнең каны булырмын, әй күңел, яман шөһрәт яулаудан курыкма, яхшы дан казанырсың.

Боларның шулай суфилык тилелегендә дөньяны онытканнарына җаным сыкрады. Атамның тилеләрчә хәрәкәтләрен туктатыр-тыяр өчен:

– Атай, атларга су биримме? – дип кычкырдым.

– Бир! – диде, мине мактады: – Менә Әхмәтзәки безне айнытты, ул тилермәгән, тилерү аңа хас түгел, мин тасаввуфны вә шигырьләрен яратам, әмма суфичылыкны сөймим, җитте, әйдә, кайтыйк! – диде.

Атам шул ахшам Фазканны үзенә мөрит итеп кабул кылды һәм шәехлектән ваз кичте.

Икенче көнне Фазкан, атамның шәрәфенә яшь бия суйдырып, күрше авыл муллаларын вә халыкны чакырып, бик шәп бәйрәм ясады. Бу зияфәт (сый табыны) Качкынбай токымының нәселдән нәселгә күчеп килгән дуслык җепләрен мәңгеләштерү өчен әзерләнгән иде. Мин кичен Ибраһим Качкынбай өендә кундым. Вакытыбыз әчебал эчү рәвешендә узды, моны атам белә иде, ләкин безнең әчебал эчкәнебезне күрмәс өчен, безнең тарафка килмәде. Качкынбайлар кыпчак ыруы белән бик тыгыз мөнәсәбәтләрдә торалар иде, Ибраһим миңа, әүвәлдәгечә, бу юлы да казакъ шагыйре Сәедалинның шигырьләрен, «Кызҗебәк» дастанын укыды. Чөнки мәрхүм атасы Троицкида яшәгән казакъ мөхәррире Сәедалин гаиләсе белән якын дус иде, аның урыс шагыйре Пушкиннан тәрҗемә шигырьләрен Ибраһим яхшы белә иде. Ибраһим миңа бу сәфәр шундый хөрмәтләр күрсәтте ки, гомерем буе «Фазканның мөритлек бәйрәме»н һич онытмадым. Фазкан да:

– Әхмәт мулла шәех булды, берсен дә мөрит буларак кабул итмәде, фәкать мине генә алды, – дип мактанып йөрмәде. Ул да Муллагол кеби гаҗәеп бер инсан иде. Аның белән сөйләшеп утыруы бик тә рәхәт иде. Ул да бик күп шигырьләр һәм дастаннарны яттан белә. Вакыт-вакыт исерек булса да, ул беркайчан да намазын калдырмады, «савытындагы шәрабны түктергәне» өчен ялраткан Алласына, «син сәрхушмы, Алла», дип кычкырган Анадолу дәрвише сыман курку белмәс иде. Атам беркөнне башка бер авылдагы дустына кунакка китте. Мин Фазкан өендә бер атна чамасы калдым. Фазкан август эссесендә кипкән печән җыеп, арып, кичен өенә кайтты.

– Икенде намазын укырга онытмадыңмы? – дидем.

– Икенде ниемә кирәк! – дип салмасынмы. – Эш булганда, намаз кайгысымы? Алла көтәр, ләкин чабылган печән көтмәс, намазны соңрак кылырмын, печән туплауны азакка калдырып булмый, мин моны Аллаһтан яхшырак беләм, – диде.

Атам үзенең бердәнбер мөриде Фазканның мондый көферлекләрен белә иде.

Фазканның алгы тешләрен земләмир (урысның җир бүлүче хезмәткәрләре) белән орышта койганнар. Әмма ул тормышында мөселманнарга һәрчак игелек кылды.

– Алла аның ара-тирә сөйләгән көферлекләрен ярлыкар, иншалла. Ул – минем замандашларым арасында иң самими мөселмандыр, ул – Алланың иң сөекле колларының берседер, – диде атам.

Фазкан шушы вакыйгалардан соң исерткеч эчүен ташлады. Атам да:

– Минем шәехлегемнең бердәнбер файдасы Фазканны исереклектән тартып алу булды, – дип рәхәтләнеп көлә торган иде.

## Көзге айлардагы көнкүрешебез

Көзен мин, авылдагы умарталардан җыйган кебек, таулардагы «чолык» чокырларыннан да бал җыя торган идем. Бу эшне Кулгын авылындагы дустым Мәхмәт Кафи вә Бөрҗәндәге Ибраһим Качкынбай белән бергә башкара идек. Көз көннәренең берендә өйдә физика тәҗрибәләре узгара идем, Троицк сәяхәтләребездә физика әсбаплары сатып алган идем. Атам мәдрәсәсенең бер бүлмәсе шул әсбаплар өчен бирелгән иде, без аны «лаборатория», дип атый идек. Бу эштә миңа Макар авылында яшәүче Газиз агам ярдәм итә иде. Электр куллану һәм дә телеграф эшләре белән мәшгуль булдым. Өебез белән мәдрәсә арасында Морзе әлифбасы ярдәмендә сөйләшә идек. 1907 елда яз көнендә почта аша Уфадан яки Троицкидан күрә (глобус) кайтарттым. Моны бездән 35 чакрым арадагы Эстәрлетамак почтасына барып алырга кирәк иде. Атамнан рөхсәт сорамыйча гына, качып, ат менеп барып алдым. Мәдрәсәдә шәкертләргә галәм гыйлеменнән (астрономия) дәрес бирә башладым. Бу дәресләрне Әхмәт белән Сәет исемле ике уйдырма затның сөаль вә җаваплары шәкелендә яздым. Фламмарионнан, Хөсәен әл-Җиср исемле бер сүрияле галим әсәреннән файдаландым. Болар мәмләкәтебездә яңалык һәм шәкертләр өчен дә бик кызыклы иде. Бу – мин язган иң беренче гыйльми әсәр иде. Атам бу дәресләремне хупламый, чөнки алда сөйләгәнем кеби, Җирнең әйләнүенә ул ышанмый. Мин глобусның тагын да зуррагын ясадым. Караңгылыкта Кояш (лампа) әтрафында Җирнең әйләнешен шәкертләргә күрсәттем. Җир шарын (глобусны) ясаганда, җилем урынына камыр кулландым. Җир шарын җәйгелеккә мәдрәсәдәге бүлмәмдә калдырдым. Җир шарымны тычканнар, күселәр ашап бетергән, бөтен тырышлыгым юкка чыкты. Атам исә бик канәгать калды:

– Җирнең әйләнешенә хәтта тычканнар да ышанмыйлар! – диде дә шаркылдап көлә башлады. Физикага кагылышлы дәрес китапларымнан башка, Истанбулда басылган төрекчәләре дә бар иде. Аларны Троицкидан алган идем.

Бал кортлары тотуыбызны һәм умартачылыкны яратуымны элек тә сөйләгән идем инде. Бал кортларына кагылышлы китапларны, аеруча «Пчеловодство» исемле бер урысча мәҗмугадан укыганнарымны үз кортларыма да куллана идем. Көз килгәч, умарталарыбызны кышлык ызбаларыбызга үзем урнаштырам. Бу кортлар мине һич чакмыйлар иде, алар үз дусларын бик яхшы белә.

Көз мәшәкатьләреннән берсе – яхшы симертелгән җылкыларны Эстәрлетамакка алып барып сату вә өйдә кышлык ит әзерләү. Бәлки, көз көненең иң гүзәл, иң кызык эше кыш өчен хайван чалып, ит әзерләү булгандыр, мөгаен, «сугым», дип атала ул ит әзерләү. Аннан казы ясыйлар. Ул вакытта кара-каршы кунакка чакырыш, табын әзерләү – бәйрәм итәләр.

Авылда бөтенесе дә бал шәрабы (әчебал) ясый. Ислам тыймаган бу шәрабны кайбер башкорт имамнары да эчә торган иде. Безгә туган тиешле бер имам бар иде, Әһил мулла исемле иде ул. Халыктан «гошер сәдакасы», дип, әчебал ала, барысын да эчеп бетерә. Аңа оеган җәмәгать тә үзенә охшаган була, алар Әһил мулланы минем әтиемә караганда да нык яраталар иде. Имам әфәндебезнең бу гамәле Галишер Нәвоиның, казакъ шагыйре Абайның фикере һәм дөньяга карашларына да туры килә иде. Ул заманда да сугым көннәрендә бал шәрабе күп эчелә иде. Галишер әйтәдер ки:

– Кояш батып, шәфәкъ кызарганга чаклы, шәраб белән мәҗлесеңә балкыш бир, чөнки Алла кәримдер, иртәгә сине гафу итәр.

Мин көзләрен таулардагы «чолык» балларын үз кулым белән җыеп, балны сатып, бераз

акча туплыйм. Корт умарталарын ызбаларга урнаштырам, беренче кар яугач, иптәшләрем белән мылтык, ау бөркете алып, атка атланып, тау араларына, кыр тавыгы йә куян ауларга чыгабыз. Шушы ауны башкармыйча, мин мәдрәсәгә бармыйм. Малларыбыз кар катламы калынайганчы авылга, араннарга кайтмый. Алар тибенеп, кар катламын тояклары белән ачып, кар астында калган үләнне рәхәтләнеп ашыйлар. Без килә башласак, качалар. Бу кыргый-буйсынмас атларны тирәнәйгән кар каплаган урманнардан эзләп табар өчен, чаңгы киеп барабыз. Кар артык калынайса, алар урмандагы кибән янына җыела. Шул кибән янында аларны тотабыз. Качарга теләгән, чыгымчы атларны кыйныйбыз, игә китерәбез. Безнең башкортлар да сөекле хатыннарын шулай кыйный, игә китерә.

## 1908–1916 еллар
## БЕРЕНЧЕ ФӘННИ ГАМӘЛЛӘРЕМ

### Оренбургка, аннан Казанга йөрешем

18-26 яшьләрдәге тормышым бик кыен шартларда узды: укып белем алу, мөгаллимлек, фәнни эзләнүләр, ватаным Башкорт иле белән Казан, соңра Фирганә, аннан Петербург, Бохара арасындагы сәяхәтләрем, эзләнүләрем чагыштырмача киң бер мохиттә әкрен-әкрен ачыла барды. Бу мохиткә мин 1908 елның 29 июне көнне авылымнан аерылгач, әкрен-әкрен килеп кердем. Ул көнне мин, атам-анам күрше авылда кунакта чакта, өйдән җәяү чыгып киттем, өйдән бер тиен акча алмадым, сыртымда биштәр, биштәр эчендә бер бөтен ипи, бер дуга казы, бер йомарлам корот, бер чеметем бөртекле чәй иде, мин авылымнан шулай аерылдым. Атама язу калдырдым: укуымны дәвам итәчәкмен, өйләнмим, дидем. Һәм борынгы бер гарәпчә шигырьне дә өстәп куйдым:

– Вакытыннан әүвәл өйләнгән бәндә койрыгына себерке таккан тычканга охшар, һәм ул үз өненә керә алмас. Миңа ачуланмагыз, догада булуыгызны үтенеп сорыйм.

Качып китәчәгемне авылдашларымның берсенә дә әйтмәдем. Бик яраткан иптәшем һәм матур мәҗлесләрдә бергә булган, ат сакларга бергә йөргән, тарлауларда, җәйләүләрдә бергә аркага арка куеп йоклаган җәгәнем (пләмәннигем) Нурмөхәммәдкә генә китәсемне алдан сөйләгән идем. Ләкин кайчан китәчәгемне аңа да әйтмәдем. Күршебездә бик яхшы мишәр әзинең кызы Ләйлибәдәр яши, анамның бик сәләтле шәкерте, мин аңа үлеп гашыйк идем, без аның белән бергә фарсыча, төрекчә дин, әхлак китаплары укый идек. Китәргә дип ишегалдына чыксам, Ләйлибәдәр безнең коедан су алырга кереп килә иде. Җыламасын, дип, мин аңа да китәсемне әйтмәдем. Бу эшемнән хәбәрдар бары тик кардәшем Габдеррәүф кенә иде. Икебез дә бер атка атландык, такыр сукмактан киттек, гадәттә, без бу сукмактан йөрми идек, «Тугыз кыр» дип аталган тау сыртына мендек. Кардәшем мине моннан ун чакрым озата барачак һәм кире борылачак. Аттан төштек, икебез дә үксеп елый башладык. Чөнки бу минем маҗаралы, кыенлыклар тулы яңа тормышымның башы иде. Мин җәяү киттем. Габдеррәүф исә мин күздән югалганчыга чаклы карап җылап калды. Якын-тирәдәге авыл кешеләренә, һәрберсенә таныш булганыма күрә, юлымда очраган авылларга кермичә, әйләнеч юлдан барам. Сәйран авылына да кермәдем. Соңгы авылны узып барганда, Гомәр Кырау исемле бер башкорт каршыма очрады.

– Нимә һин болай йәяү йөрәйһең ул? – диде Гомәр.

Мин:

– Ат эзлим, – дидем.

Ул:

– Аттарыгыддың төбәге ошында түгел бит, – диде.

Мин дә:

– Кунакларыбызның атларын эзлим, – дидем.

Гомәр шиккә калды.

Аның белән саубуллашып, мин юлымда булдым. Ләкин бу кеше мине бу якларда күргәнен, һичшиксез, атама әйтәчәк, дип уйладым. Атамның мине эзли чыгуын мин теләми идем. Юлымны башка якка үзгәрттем.

Бүген христианнарның Троица дип аталган «Кече пасха» бәйрәме иде. Верхотор

атлы урыс авылы иде ул. Бу авылга мин көчкә-чакка килеп егылдым. Урыслар «без Троицы дом не строится», ди. Ягъни бу бәйрәм, урысларның диненә күрә, эш башлангычы алдыннан әйбәт бер көн иде. Аркамда биштәр булуына карамастан, урыс кызлары белән биедем. Элек тә мин урыслар җырлаганда ишеткән: «во саду ли, в огороде девушка гуляла», кебек җырларны җырлап күрсәттем. Кызлар да, мине кочаклап, «мой башкирёнок», дип үбәргә тотындылар. Эчемнән: мин ни гөнаһлар эшлим, әгәр болай барса, эшем харап, дип уйлыйм. Бер урыс егете аракы эчәргә кыстый башлады. Эчмим, дип чокырдагы аракыны җиргә түктем. Ул минем өскә аракы агызды. Мин җыладым. Чөнки кечкенә чагымнан бал гына эчә торган идем. Бал эчкәндә дә, берәр тамчы бал киемемә тамса – ул гөнаһ, чөнки хәмер Коръәнгә күрә, нәҗес санала. Марҗа кызлары биштәремне аркамнан салдырып яшерделәр. Мин боларның ниятләре яман икәнен аңладым. Атам-анамнан аеры бу кяферләр арасында ни кылам? Ниһаять, мине яшел печән өстендә йоклап ятучы исерек бер башкорт чабаны янына яткыздылар. Бу, сәрхуш булуына карамастан, вакыйганы карап яткан икән:

– Улардың телен беләһең, улар менән бииһең, ни өсен илайһың ул? Ят та юкла, – диде.

Биштәремне дә, китереп, баш очыма куйганнар. Иртәгесе көнне кояш чыкканчы, мин юлда идем инде.

## Мәләвездә дин хөррияте бәйрәме

Өч көннән Мәләвез дигән салага килеп җиттем. Мәләвезгә, мөселманнар бәйрәменә килгән бер башкорт мөгаллиме миңа әйтте:

– Гомәр Кырау атаңа сине күргәне турында сөйләгән, моны ишеткәч, атаң атына атланып, сине куа чыккан, Азай авылында Кадыйр исемле бер бай башкорт йортына төшкән, Кадыйр бай атаңа сине эзәрлекләмәскә һәм кире кайтарырга тырышмаска киңәш биргән. Атаң, аның киңәшен тотып, ниятеннән баш тарткан да, кире борылган, – диде.

Моны ишеткәч, миңа җиңел булып китте. Мәләвездә патша вакытында ирексезләп чукындырылган татарлар да яши икән. Болар күңелләрендә мөселман, ди. 1905 елда инкыйлаб биргән чагыштырмача иректән файдаланып, алар ачыктан-ачык мөселманлыкка кайтканнар да мәчет корганнар. Хәзер шушы мәчетнең ачылыш тантанасы икән. Бу бәйрәмгә күрше авыллардан имамнарны, татар-башкорт арасында абруй казанган шәхесләрне чакырганнар. Берничә куй, берничә үгез-сыерны корбанга чалганнар. Мине муллалар табынына утырттылар. Кымыз бик мул иде. Япуниядә Исламның киң җәелгәне турында «Галәм-и Ислам» гәзитендә басылган хәбәрләр турында сөйләшкәндә сүз чыкты:

– Япуннар, мөселманлыкның хак мәзһәбен кабул кылмасалар да, мөселман саналамы? – дип бәхәс купты. Мин мәзһәпләрдән өстен тагын да саф бер Исламият булганлыгын исбат итәргә алындым һәм Ислам голамәсеннән Ибн Таймия, ибн Кайюм, әл-Җазви исемле галимнәр язган бөек әсәрләрдән үрнәкләр китердем. Мөтәгассыйлар (фанатиклар) миңа ябырылды. Гәрчә, мәзһәп вә тарикатлар аерымлыгы Ислам өчен зарарлы, дип миңа каршы төшкәннәр дә, мине яклап сөйләгән муллалар да булды. Сүзләрем, минем фикерем Гилаҗ (Гыйлаҗетдин) Баязитов исемле бер татар сәүдәгәренең игътибарын җәлеп иткән. Ул мине өенә чакырды һәм ачык, һәм алдынгы карашлы имамнарны да дәшкән. Аңлашылды ки: Гыйлаҗ ага бу мәүзугъ тирәсендәге бәхәсләрдә гыйлем әһелләренең иркен вә әтрафлыча сөйләшүләрен теләп, бу мәҗлесне махсус корган булып чыкты. Бик кызыклы әңгәмәләр булды монда. Килгән муллалар белемемне арттырырга чит илләргә китеп баруым турында белделәр. Болар – Ислам дине мәйданында киң белем алу өчен, Мисырга барырга кирәк, дип киңәш иттеләр. Башкортстанның кечкенә бер почмагында Ибн Таймиянең фикерләре белән кызыксынган бер сәүдәгәрнең яшәве – ул вакыттагы татар-башкортлар арасында милли мәдәниятнең туктамыйча, алга үсешен исбатлый торган күренештер.

## Кунакбай гүзәле

Мәләвездән мин җәяү чыктым. Атамның эзәрлекләвеннән куркып, мин шосседан китмәдем, әйләнеч юллардан йөри башладым. Төннәрен ялан кырда йоклый идем. Шулай итеп, Кунакбай исемле бер кечкенә авылның кырындагы бер алачыкка керергә булдым. Шунда ашап-эчеп алырмын, дип уйлаган идем, монда бик фәкыйрь бер гаилә яши икән,

өйдә олылардан бер кеше дә юк иде, 12-14 яшьләрендәге бер кыз вә бер ир олан миңа су кайнатып бирде, ипи белән чәй эчтем. Кызның исеме Зөләйха иде. Оланнар гадәттән тыш матур иде. Бер теләнче үлгән икән, аның пычрак, ертык чапаныннан юрган ясамакчылар икән.  Йа Рабби, бу инсаннар никадәр фәкыйрь, болар ничек итеп тормыш алып бара, дидем. Мин аларның гүзәллегенә чиксез хәйран калдым. Мин аларга биштәремдә булган ипи, корыт белән казы бирдем. Нинди гүзәллек белән нинди фәкыйрьлек янәшәдә яши, ничек, ни өчен, дип сорыйм үземнән. Җәләлетдин Руми төрк тормышында күзәтелгән гарип имәнгечлекне (контраст, несоответствие) шулай тасвирлый: кәҗә тиресеннән ясалган чатыр никадәр кара вә фәкыйрь исә, аның эчендәге төрк гүзәле дә ай кебек балкыр.

Боларның бер кәҗәсе бар, шул кәҗәне савып, сөтен эчәләр. Башкортларның юмартлыгы хәттин ашкан, бу кардәшләрнең аталары, әгәр бер газиз дусты кунак булып килеп керсә, гаиләнең туендыручысы булган шул бердәнбер кәҗәсен чалып, кунак итәр иде. Белем алыр өчен юлга чыкмаган булсам, мин, шаять, шушы кызга өйләнгән булыр идем. Ир кардәше алачык тирәсендәге утлакта утлаган кәҗәнең утлагын икенче урынга күчереп куйган арада, бу кызны үпсәм, дип уйладым. Ләкин бу эшне кылудан курыктым. Зөләйха: «Елга бер тапкыр гына булса да безгә килерсеңме?» – дип, гашыйкларча сорады, мин аңа, ерак-ерак җирләргә укырга барам, дип аңлаттым.

Ул да:

– Шулайдыр, ерак юлга чыгасың, эшеңә ярар, – дип, кыз миңа берничә саплам ак җеп белән энә бирде. Ихтимал, бу бер йола булгандыр, ышану булгандыр.

Шосседан бер читтә Муса исемле татар авылында атамның дусты бай Нәби хаҗида кунак булдым.

– Әгәр дә атаң сине эзләп монда килеп чыга икән, мин сине аңа бирмичә, качырып калдырам, – диде Нәби хаҗи.

Ул да минем авыл кысаларында калуымны теләми иде, хәтта бу турыда ул атама да әйткән: улыңа белем алуда ярдәм итәргә кирәк, дигән. Икенче көнне моннан китәргә җыенганда, ул миңа, Каргалы авылына илтеп куяр өчен, арбага җигелгән ат бирде. Бераз юл хәере дә сонды. Бер киемлек комач та бирде:

– Моны Орынбурда тектерерсең, – диде.

Мин Кунакбай авылының читендәге алачыкта бер фәкыйрь гаилә яшәп ятканын әйттем, миңа аталган комач урынына минем исемнән үзләренә бүләк сыйфатында Кунакбай авылына, кырый өйгә ике юрган җибәрүен үтендем.

Хаҗидан аерылгач, арбага менеп утырдым. Юлда барганда, зиһенем Зөләйха һәм аның энесе турында гына  кайнаша иде. Ни булса да, форсаттан файдаланып, аны үпмәдем, дип үкенеп куйдым. Безнең авылда андый гадәт юк. Бу кызны үбәргә теләү фәкать мин укыган романнардан гына килә булыр.

Вакытлар узды. 1913 елда почта атлары белән Оренбургтан Эстәрлетамакка кайтып киләм, юл Кунакбай авылына якын уза иде. Шул елларда өйрәнгән Гётеның «Зөләйха» исемле кызга багышлап язган шигыре минем Зөләйхама аталган кебек хис иттем. Гётеның «Үбешү тәме белән гыйшкый вөҗдан газабыннан коткар, чөнки мин – кяфер. Син табына торган нәстәң калбеңдәге миңа булган мәхәббәтнең тылсымы булсын», сүзе, бәлки, «фетиш», ягъни ясалма алла, ырым, сихер, Зөләйханың миңа биргән ак җебе белән энәседер? Почта ыстансасында очраткан бер Кунакбай кешесеннән:

– Авылыгызның читендә торган алачыкта яшәгән Зөләйха исемле бер кыз белән аның энесен беләә идем, алар ни хәлдә? – дип сорадым.

Ул:

– Һәр икесе дә никахлы, – диде, – икесенең дә берәр баласы бар, берзаман аларның өендә кунак булган шәкерт аларга ике юрган җибәргән иде, ә син үзең кем соң?

Мин кызга гашыйк булганымны сөйләмәдем, бары тик:

– Алар бик фәкыйрь иде, Нәби хаҗи ярдәме белән аларга шул бүләкләрне юллаган идем, – дигәч, бу зат:

– Син дә фәкыйрь шәкертмесең?.. Без дә ул кызны «Бичара Зөләйха», дип йөртә идек, – диде.

*Төрекчәдән* **Рабит БАТУЛЛА** *тәрҗемә итте.*

*(Дәвамы киләсе саннарда)*

# ЗЫЯЛЫ РЕЖИССЁР ИҖАТЫ

## ПРАЗАТ ИСӘНБӘТНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ



Татар режиссура сәнгате мәйданында XX гасырның икенче яртысында ат уйнаткан олуг шәхесләр арасында актёр, режиссёр, педагог, инсценировкалар авторы, Татарстанның халык артисты (1981), ТАССРның һәм Россия Федерациясенең атказанган сәнгать эшлеклесе (1967, 1986) Празат Нәкый улы Исәнбәт (1927-2001) исеме иң беренчеләрдән булып аталырга хаклы. Дәрьядай киң эрудицияле булганы, энциклопедик белеме, профессиональ осталыгы өчен генә түгел, бәлки тумыштан килгән зыялылыгы, тәрбиясе, кабатланмас бай эчке дөньясы өчен дә. 1944-1949 елларда Мәскәү театр институтында (ГИТИС) актёрлык һәм 1951-1956 елларда режиссёрлык факультетларында белем ала ул. 1958 елдан гомеренең ахырына кадәр Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты һәм режиссёры булып эшли, милли театрыбыз үсешенә бәяләп бетергесез колачлы зур өлеш кертә.

Театрга багышланган биш дистәгә якын ел, житмештән артык куелган спектакль, уйналган рольләр, инсценировкалаштырылган, сәхнәгә күтәрелгән проза әсәрләре. Штрих кебек өзек-өзек булса да, гомер озынлыгын иңләгән театраль-педагогик эшчәнлек. Каян башлана соң бу бәрәкәтле зур иҗатның башы?

П.Исәнбәтнең режиссура сәнгате белән кызыксынуы А.В.Луначарский исемендәге Дәүләт театр институтының Татар студиясендә уку елларында уяна. Студия җитәкчеләре О.Н.Пыжова һәм Б.В.Бибиковлар, гәрчә үз шәкертләренең идея эчтәлеге һәм сәнгатьчә эшләнеше ягыннан бербөтен сәхнә әсәре тудыру омтылышын хупласалар да, режиссёр профессиясенә шәхес буларак өлгергәнлек, тормыш тәҗрибәсе кирәклеген искәртәләр. Бәлки шуңа күрәдер дә П.Исәнбәт, ГИТИСның режиссура бүлегенә шушы ук югары уку йортының актёрлык осталыгы буенча Татар театр студиясен тәмамлап, Казан Яшь тамашачылар театрында һәм Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында берничә ел эшләгәннән соң, шактый тәҗрибә туплап, 1952 елда гына укырга керә. Остазы Н.М.Горчаков кул астында режиссёр профессиясе серләренә өйрәнә. Ниһаять, бу юлы да студент еллары артта кала. 1957 елда ул диплом спектакле куяр өчен яңадан Г.Камал исемендәге театрга кайта.

Илленче елларның икенче яртысында, бөтен совет театр сәнгате кебек үк, татар театры да яңарыш чоры кичерә. Иҗатчыларның сәхнәдәге тормыш дөреслегенә карашлары үзгәрә, реализм рамкалары киңәя, үз эченә шартлылык төшенчәсен дә ала башлый. Шул ук елларда халкыбызга К.Тинчурин, М.Мутин, Г.Ибраһимов, Ф.Бурнаш, Ш.Усманов кебек танылган сәнгать эшлеклеләренең, герой-шагыйрь Муса Җәлилнең иҗади мираслары кире кайтарыла. Сәхнәгә Ш.Хөсәенов, А.Гыйләҗев, Х.Вахит кебек драматурглар күтәрелә. Яшь режиссёр алдына тәүге адымнардан ук шул социаль ситуацияне исәпкә алу, аны үз иҗатында актив чагылдыру бурычы килеп баса. Әтисе Н.Исәнбәтнең «Муса» трагедиясе буенча эшләнгән спектакль илдә барган шул яңарыш процессының сәхнәдәге җанлы гәүдәләнеше булып тора. Җәлил образын сәхнәбезгә

беренче буларак алып чыккан бу әсәр республика мәдәни тормышында зур вакыйга буларак кабул ителә. Бөек Октябрьнең 40 еллыгына багышланган әлеге беренче эше өчен яшь режиссёр махсус диплом белән бүләкләнә.

Әтисе Н.Исәнбәт исеме телгә алынгач, шул ук авторның икенче бер әсәре буенча куелган спектакльгә дә тукталып китик. Н.Исәнбәтнең истәлекләренә караганда, беренче татар артисткасы С.Гыйззәтуллина-Волжская шәрәфенә һәм татар театрының кырык еллыгына багышланган пьеса инде 1944 елда ук язылып беткән була. Шул ук елны уздырылган иң яхшы пьесалар конкурсында беренче вариантта «Сәхипҗамал Волжская» дип аталган әсәр икенче дәрәҗәдәге бүләккә лаек дип табыла. Әмма аның сәхнәгә юлы шактый озак һәм сикәлтәле булып чыга. Беренче тапкыр ул бары тик 1963 елда режиссёр П.Исәнбәт тарафыннан Г.Камал исемендәге театрда куела. Моның сәбәбе, автор әйтүенчә, тарихи шәхесләрнең һәм уйлап чыгарылган персонажларның катнаштырылып бирелүендә. Ул елларда мәдәният өлкәсендә эшләүче кайбер хезмәткәрләрне «вакыйгада катнашучылар тарихи билгеле исемнәргә генә кайтарып калдырылса, бу аларны сәнгатьчә гомумиләштерелгән образлар итеп күрүгә комачаулык итәчәк», дигән фикер дә борчыган.

Әмма татар хатын-кызының тиңсез каһарманлыгын сурәтләгән һәм халыкның милли үзаңын тәрбияләүгә юнәлдерелгән әсәрнең куелмавының төп сәбәбе бөтенләй башкада. 1944 елда ВКП(б) Үзәк Комитетының һәм хөкүмәтнең татар халкы тарихын, аның бөек шәхесләре эшчәнлеген, данлы үткән юлын сызып ташлау өчен чыгарылган «Татарстан партия оешмасында масса-сәяси һәм идеология эшенең торышы һәм аны яхшырту чаралары турында» дигән 9 август карары кабул ителә. Шуңа күрә Н.Исәнбәт тарафыннан татар милләтенең беренчеләрдән булып сәхнәгә чыккан батыр ул-кызларына тирән хөрмәт, кайнар мәхәббәт белән язылган һәм шундый ук хисләрне тамашачыларда тәрбияләячәк әсәр ул елларда берничек тә театр репертуарына кертелә алмаган. Бу бары тик «Хрущёв җепшеклеге» дип аталган һәм идеологик басым бераз кимегән алтмышынчы еллар башында гына мөмкин була.

Спектакльнең премьерасы 1963 елның 12 сентябрендә зур уңыш белән уза. Бу чынлап та күмәк иҗат тантанасы – режиссёр П.Исәнбәт, рәссам Ә.Тумашев, уенда катнашучыларның гаҗәеп берлеге, бөтенлеге нәтиҗәсе була. Сәхнәдә уен түгел, чын тормыш мизгелләре урын алган кебек тоела.

«Гөлҗамал» исә – режиссёрның шактый тәҗрибә туплаганнан соң куелган спектакле. Аңа кадәр Г.Ахунов һәм Ф.Мостафиннарның «Тынгысыз йөрәк» (1959), Илдар Юзеевның «Янар чәчәк» (1961), М.Кәримнең «Җырланмаган җыр» (1962), бераз соңрак Х.Вахитның «Карлыгач канат кага» (1964), А.Расихның «Ике буйдак» (1967) кебек әсәрләр сәхнәләштерелде. Аларда П.Исәнбәтнең заман проблемаларына җитди игътибары, көн геройларын сәхнәгә күтәрергә тырышуы сизелде. Бу спектакльләрне куйганнан соң, Празат Исәнбәт тамаша барышында үзенчәлекле психологик атмосфера тудырырга, характерларның эчке дөньясын тирәннән ачарга сәләтле лирик-драматик пландагы режиссёр буларак ачыла. Алга таба да аңа автор тәкъдим иткән материалга үтә сак караш, сәхнә бизәлешендә тормыш дөреслеге кануннарын саклау хас.

Әгәр П.Исәнбәтнең «Татар хатыны ниләр күрми» (Г.Ибраһимов әсәре буенча Х.Сәлимҗанов инсценировкасы, 1960), «Гөлҗамал» (Н.Исәнбәт, 1963), «Ата хакы, Тәңре хакы» (В.Лаврентьев, 1965) кебек спектакльләрендә тормыш-көнкүреш төгәллеге, яшәеш детальләре өстенлек алса, Бразилия драматургы Фигейредоның «Кол» («Эзоп», 1967) пьесасы белән аның иҗатына бөтенләй башка төрле сурәтләү чаралары, гомумиләштерү, яңа образлылык килеп керә. Шуңа күрә дә стиль ягыннан бу спектакль алдагыларыннан күпкә аерыла. Биредә тамашачыга тормыш дөреслеге кануннарыннан чыгып төзелгән интерьерлар түгел, бәлки, шартлы образлылык таләпләрен исәпкә алып эшләнгән, бөтен спектакль өчен уртак корылма тәкъдим ителә. Сәхнәнең бар тирәнлеге һәм киңлеге кулланыла. Бу спектакльдән соң П.Исәнбәт үз иҗатында традицион тормыш дөреслеге театры сурәтләү чараларын да, шартлы-метафорик театр образлылыгын да бердәй осталык белән куллана башлый. Алга таба режиссёр иҗатындагы традицион линияне «Гөлҗәннәтнең җәннәте» (Ю.Әминев, 1969), «Туй алдыннан», «Мәхәббәтең чын булса» (Х.Вахит, 1969, 1972), «Эңгер-

меңгер» (А.Гыйләҗев, 1971), «Тартюф» (Мольер, 1978), «Бәхетсез егет» (Г.Камал, 1986) кебек әсәрләр дәвам итсә, икенчесен «Акчарлаклар» (Ш.Камал, 1971), «Татар хатыны ниләр күрми « (1978), «Банкрот» (Г.Камал, 1978), «Ике фикер» (Г.Колахмәтов, 1981), «Һаваларда йолдыз» (М.Горький әсәрләре буенча П.Исәнбәт инсценировкасы, 1984) шикелле спектакльләр тулыландыра. Соңгы төркем сәхнә әсәрләрен куйган, режиссёрга драматургик материалга ирекле мөнәсәбәт, форма активлыгы, сценографиянең күпмәгънәлелеге, образларның тирәнлеге, психологик төгәллек хас.

Р.Батулланың «Кичер мине, әнкәй...» трагикомедиясе шулай ук режиссёр иҗатындагы традицион линиягә карый.

Ярты гасырлык режиссёрлык дәверендә П.Исәнбәт күп кенә милли классик драматургия үрнәкләрен өр-яңадан сәхнәгә күтәргән, кötелмәгәнчә шәрехләгән эзләнүчән шәхес икәнен кат-кат дәлилли. Г.Камалның «Банкрот» комедиясе режиссёрның бу пьесага төптән-тирәннән уйланган мөрәҗәгате иде. Заман режиссурасының соңгы казанышлары спектакльдә ничек чагылыш таба? Вакыт факторы әсәрнең жанрында, стилистикасында, структурасында нинди үзгәрешләр тудыра?

Г.Камал үзе «Банкрот»ны «пьеса» дип кенә тәкъдим итә. Аны, гадәттә, тормыш-көнкүреш комедиясе итеп уйныйлар иде. Режиссёр П.Исәнбәт, әнә шул традицион куелыштан китәргә тырышып, спектакльнең жанрын «водевильгә якын музыкаль комедия» рәвешендә хәл итә. (Спектакльнең программасында «музыкаль комедия» дип куелган.) Жанр атамасының беренче сүзе әсәр тукымасында музыканың мөһим урын тотуын сөйли. Бу чыннан да шулай. Музыкага режиссёр гаять күп яңа функцияләр йөкли. Ул спектакльнең темпо-ритмын билгели, аерым образларның лейтмотивы буларак килә, персонажларның эчке кичерешләрен, халәтләрен тамашачыга тулырак җиткерә, режиссёрның, артистларның аерым персонажларга мөнәсәбәтен ачыграк белдерә.

«Банкрот» спектаклендәге фантазия байлыгы, эзләнү һәм фикер төгәллеге Г.Колахметовның «Ике фикер» пьесасы буенча сәхнәгә куелган спектакльгә дә хас.

Пьеса инкыйлабкача да, Совет власте елларында да сәнгать әһелләренең игътибар үзәгендә тормый. Моны иң элек аның шартлы-аллегорик һәм тормыш чынбарлыгы алымнары нигезендә бик үк гадәти булмаган формада язылуы белән дә аңлатырга мөмкиндер. Чөнки һәрбер классик әсәрне сәхнәләштергәндә, режиссёр алдында котылгысыз рәвештә килеп баса торган актуальлек проблемасы өстенә пьесаның катлаулы стилистикасын ничек саклау мәсьәләсе дә туа.

Г.Колахметовның тууына 100 ел тулу уңае белән Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында чын ачыш дәрәҗәсендә яңгыраган «Ике фикер»не куйган режиссёр П.Исәнбәт әлеге проблемаларны ничек хәл иткән соң?

Актуаль яңгырашлы спектакль тудыру максатыннан, режиссёр әсәрдәге вакыйгаларны турыдан-туры хәзерге көнгә күчерә. Спектакль бүгенге көн тамашачысына бернинди файдасыз, уйсыз, теләксез, күңел ачып кына яшәүнең мәгънәсезлеге турында сөйли, битарафлыкка, үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртып яшәүчеләргә каршы чыга, хакыйкать өчен көрәшкә чакыра, тормышта үз урыныңны табарга, җәмгыятькә файдалы кеше булырга өнди.

Сценография ачышлары, мизансценаларны метафора буларак файдалану режиссёр П.Исәнбәт тарафыннан Г.Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» повесте буенча эшләнгән спектакльдә дә киң кулланыла.

Әсәр үзәгенә куелган мәңге искерми торган гомумкешелек проблемаларын хәтергә төшерергә кирәк. Театр коллективы повестьның рамкаларын киңәйтеп, үзәккә куелган хатын-кыз язмышы аша масштаблы полотно тудыруга ирешкән. Шул ук вакытта спектакль яхшылык һәм явызлык, кеше күңеленә төзәлмәс яра ясап, аны үлемгә илтеп җиткерергә сәләтле битарафлык, күңел тупаслыгы турында зур сөйләшү буларак та кабул ителә. Режиссёр П.Исәнбәт әсәрнең сәхнә варианты өчен шул проблемаларны нигез итеп алган һәм алар соң дәрәҗәдә актуаль булып яңгырый.

Режиссёрлык эшчәнлегенең уңышлы башланып китүенә карамастан, П.Исәнбәт халык арасында иң элек актёр буларак танылa. Артист хезмәте өчен «үлчәп теккәндәй»

буй-сын, мөлаем йөз, табигый, иркен пластика, төрле төсмерләргә бай тавыш, үзенә генә хас тыенкырак уен манерасы ул башкарган Әхмәт (М.Әмир, «Гөлшаян»), Да-Хай (Цао Юй, «Тайфун»), Синцов (М.Горький, «Дошманнар»), Васильков (А.Н.Островский, «Котырган акчалар») һ.б. рольләрнең уңышлы чыгуын тәэмин итә, аларны спектакльләрнең үзәк персонажлары рәтенә күтәрә. Икенче яктан, артист профессиясенең серләрен бөтен нечкәлекләренә кадәр белү, Казан художество училищесында кечкенәдән үк мавыккан рәсем сәнгате буенча алган махсус белем кебек үк, П.Исәнбәткә режиссёрлык хезмәтендә зур ярдәм итә, спектакльне тудыруда катнашкан башка барлык иҗатчыларны тирәннән аңларга, кирәк чагында аларга дөрес юнәлеш күрсәтергә, булышырга мөмкинлек бирә. Ярты гасырлык иҗат дәвере дәвамында, актёр буларак, Г.Камал исемендәге театр сәхнәсендә Празат Исәнбәт шактый күп образлар иҗат итә: Кодар (Г.Мөсрепов, «Кузы-Көрпәч һәм Баянсылу»), Дерамо (К.Гоцци, «Болан-патша»), Васильков (А.Островский, «Соңгы корбан»), Синцов (М.Горький, «Дошманнар») һ.б.

П.Исәнбәт актёрлар белән эшләгәндә үзе теләгәнен тыныч кына, сабыр гына аңлатырга тырыша. Бу эштә аңа табигый эчке культурасы һәм киң эрудициясе, күп белүе ярдәм итә. Белгәне белән бик теләп уртаклаша иде ул. П.Исәнбәт үткәргән репетицияләр еш кына сәнгать тарихы, теориясе дәресләренә охшап китә, режиссёрның чиктән тыш иҗат юмартлыгы сәбәпчедерме, артистлар аның белән эшләргә ярата иде. Сәхнә әсәре иҗат иткәндә, Празат Нәкыевичның үзе генә куллана торган методикасы булды. Һичкайчан теге яки бу артист шәхесенә ят төсмерләр, уен алымнары тәкъдим итмәде ул. Киресенчә, һәр очракта да аларның иҗади мөмкинлекләрен, сәләтен, тәҗрибәсен исәпкә алып эшләргә омтылды. Әйтик, яшь артист сәхнәдә ни эшләргә белми югалып калды ди. Режиссёр ситуацияне шул дәрәҗәдә кора ки, башка актёрлар ярдәмендә аның ул халәтен шундый «уйната», спектакльдә тәҗрибәсезлек кимчелек түгел, бәлки уңай як, табыш буларак кабул ителә башлый. П.Исәнбәт – артистларны үстерә торган режиссёр, һич икеләнмичә аны режиссёр-педагог дип атап була иде.

Педагогика турында сүз чыкса, Празат Нәкыевичның татар театрлары, үзешчән сәнгать өчен яшь кадрлар әзерләү өлкәсендәге эшчәнлеген дә искә алу урынлы булыр. В.И.Качалов исемендәге Зур драма театры каршында оештырылган студиядә, Театр училищесында, Казан дәүләт культура институтында кайчандыр ул тәрбияләгән шәкертләр хәзер танылган артистлар, халык театры режиссёрлары булып җитештеләр.


Татар театр сәнгатенең илле елга якын вакыт аралыгындагы үсеше П.Исәнбәт иҗаты белән аерылгысыз бәйләнгән. Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры режиссёры (баштагы ун елда артисты да) милли культурабызның алга барышында төпкә җигелеп тартучы, әйдәп баручы лидерларның берсе иде.

...Празат ага белән миңа берничә ел Казан дәүләт культура институтында актёрлык осталыгы һәм режиссура буенча дәресләр алып барырга туры килде. Дәресләр вакытын иң беренче пар итеп билгелиләр. Ул вакытта әле кафедрада беркем булмый. Икебез дә егерме-егерме биш минутка алданрак килгәнгә, безгә аның белән шактый озак гәпләшеп алырга мөмкинлек була иде. Шул сөйләшкән арада да мин аның күпне белүенә, дөнья әдәбияты, сәнгате, театры, мәдәнияте буенча киң мәгълүматына, үзара аралашу мөнәсәбәтенә соклана идем. Хәзер дә уйлап утырам, еш искә алам. Шул кыска гына вакыт аралыгында да күп нәрсәләр турында сөйләшенгән, никадәр баеткан икән мине Празат абый! Бу язмам – шул вакытлар истәлеге – Рухыңа дога булып барып ирешсен!

**Мөхәммәтгали АРСЛАНОВ**

# ТОРМЫШ ЧЫНБАРЛЫГЫ

## ЮНЫС САФИУЛЛИНГА 70 ЯШЬ


*«Йосыф һәм Зөләйха» спектакленнән бер күренеш. Йосыф – Руслан Хайсаров, Зөләйха – Алсу Галина-Гафарова.*

«Мине әсәрләремнән эзләгез», – дигән бер акыл иясе. Мин дә үз героемны аның «Алмазбулат», «Сукбай артистлар», «Әллә өйләнергә инде?», «Ләйсән ире Хәсән», «Йөзек һәм хәнҗәр», «Идегәй» әсәрләреннән эзлим. Аларда – конфликтларның корылышы, вакыйгаларның чишелеше, каһарманнарның бер-берсенә мөнәсәбәтләре, хис-кичерешләре... «Йөзек һәм хәнҗәр»дәге Фәрһад әнә нәрсә ди: «Гомерем буе тезләндерергә тырыштылар. Хәзер дә шулай. Ә минем тезләнәсем килми. Кеше булып кала алу – бәхет». Кайсы гына әдәби әсәрне алма – шигырь-поэмамы, хикәя-бәянмы, сәхнә әсәреме – аның артында автор үзе, уй-фикерләре, дөньяга карашы. Олпат язучыбыз Аяз ага Гыйләҗев: «Юныс яшьлегендә беркемгә дә яраша белмәгән әүлиядай егет иде. Тормышын авыр корды, кыен елларда, тәлинкә тотып, хакимият алдында тез чүкмәде, ихтыярны изә торган елларда күңеле һәм вөҗданы бөтен калды», – дип әйтә алган икән, димәк, драматург Юныс Сафиуллин әсәрләрендә үзе теләгән геройларны тудыра, аларны сәхнәдә гәүдәләндерә, теләгән фикерләрен алар аша укучыга ирештерә алган.

«Бер тапкыр театр һавасын сулагансың, сәхнә тузаны үпкәләреңә үткән икән – театрдан китә алмыйсың», – дип әйтүләре белән күпләр хаклыдыр да, мөгаен. Яшел Үзән районының Бакырчы авылында туган Юныс Сафиуллин сигезьеллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, Казан театр училищесында укыган чагында, Камал театры спектакльләрендә катнаша башлаган вакытларында ук аңлый моны. Театр дөньясыннан аны берничә елга армия тормышы гына аерып тора. Аннан Кучмә театрда актёр, Мәскәү дәүләт театр сәнгате институты каршындагы икееллык Югары режиссёрлар курсында укулар, янәдән Күчмә театр, Камал театрында актёр һәм әдәби бүлек мөдире...

Юныс Сафиуллинның үзенең беренче сәхнә әсәрләрендә – «Алмазбулат», «Ләйсән ире Хәсән», «Әллә өйләнергә инде»дә драматург булярак яшьләргә хас темаларны күтәрүе табигый, яшь кеше үз дөньясы белән яши, ул дөньяга яшьләр күзе белән карый. Тыныч тормыштагы татар халкының ярасы булган Чечня сугышы фаҗигасен актыртып язган «Йөзек һәм хәнҗәр»дәге герое Рәсим дә: «Без бит Ичкериягә бармыйча кала ала идек. Күп кеше бармады. Төрмәләргә утыртсалар да... Ә менә без бардык!» – ди үкенеп, анда күргәннәреннән ачынып. Әйе, Юныс Сафиуллин үзе әйткәндәй, төрле кеше төрле чакта төрлечә ачыла, драматургның осталыгы шунда да күренә.

Беренче (өйрәнчек дип әйтсәк тә, бәлки, урынлы булыр) әсәре языльп, шундук сәхнәгә куелып, шундук танылу алган драматург, мөгаен, юктыр да ул. Юныс Сафиуллин да күп яза, ләкин язганнарын сәхнәдә куйдыра алуга, драматург исемен алуга ул акрынлап, баскычлап кына ирешә. Берәү булса, бәлки, күңеле төшеп кул селкер дә театрдан китеп тә барыр иде. Миңа калса, аңа авыр вакытларында белемле булуы, милли рухлы җаны терәк булгандыр. Театр дөньясының аяусыз икәнлеген, сөеп тә, төеп тә торганлыгын да онытмый ул.



*Ю.Сафиуллинның «Идегәй» трагедиясеннән күренеш. Идегәй – Ринат Таҗетдин, Норадын – Рамил Төхфәтуллин. 1994 ел.*

Милли күтәрелеш чорында – 1994 елда «Идегәй» дастанының, Юныс Сафиуллин тарафыннан драма әсәре итеп язылып, Камал театрында куелуы, халыкка кайтарылуы, авторның үзе өчен дә, театр өчен дә зур вакыйга була. Ничәмә-ничә еллар яшеренеп киленгән Болгар ханлыгының җимерелү, Алтын Урданың таркалу сәбәпләре, Ил-Ватан төшенчәләре, хакимлек өчен көрәштә туган белән туган мөнәсәбәтләрен күрсәтә алу – Туктамыш ханча әйтсәк, дәвер кемнең дәвере, заман кемнең заманы икәнен ачыклап бирүдә, милли аңны уята алуда зур этәргеч бирә. Ташка бастырылып калынган сүз тарихи әһәмияткә ия булса – биектән яңгыраган сүз еракка ишетелү көченә ия. «Идегәй» спектакле дә ил буйлап сәяхәт итеп, сибелеп яшәгән, мөһаҗирлектә тилмергән татарларыбызда да берләшүгә өмет, ышаныч уята алды.

...«Ул кеше турында ни дә булса беләсегез килсә – аның башкалар турында ни әйткәнен белегез», – дигән икенче бер акыл иясе. Зурлыймы – хурлыймы, күтәрәме – түбәнәйтәме... Юныс Сафиуллин иҗатының тагын бер тармагы – аның иҗатташ дусларын күтәреп, зурлап язган язмалары – әдәби портретлары, парчалары. Журналыбызда сәнгать бүлеген дә җитәкләү сәбәпле, үзем дә еш мөрәҗәгать итәм аңа. Җанына якын ул кешеләр арасында Рәүф Игъламов, Наил Дунаев, Дания Нуруллина, Дамир Сираҗиевлар... Аларның чәчәкле һәм күз яшьле иҗат юллары, тормышлары, югалтулары, табышлары... «Ун кешегә җитәрлек итеп бирелгән таланты Дамир җанын мизгел дә тынычлыкта калдырмый иде кебек. Сәхнә имгәтеп ташлаган җаннарын кемнәрдер шәраб белән юганда, гайбәт сатып юанганда, ул юанычны (аеруча иҗатының тәүге елларында) тау-тау хезмәт арасыннан эзләп таба килде», – ди ул иҗатташ дусты Дамир Сираҗиев турында. Ярты сүздән бер-береңне аңлый, әсәреңне син көткәннән дә артыграк итеп сәхнәдә җанландыра ала торган үз режиссёрыңны табу – һәр драматургның хыялы. Дөрес, беренче әсәрләре – «Менә без дә үсеп җиттек»не куйган Әлмәт, «Әллә өйләнергә инде?»не куйган Республика Күчмә театрына да, атаклы Марсель Сәлимҗановка да рәхмәтле ул. Яңача эшләргә атлыгып торган, яңа идеяләр белән янган Дамир Сираҗиев белән дуслык, режиссёрның автор белән рухи уртаклыгы аны тагын да үсендереп, өметләндереп җибәрә. Нәтиҗәдә, балалар өчен кебек тоелган, әкият рәвешендәрәк язылган «Алмазбулат» һәммә кеше тарафыннан яратып кабул ителерлек, алай гына да түгел, милли рухлы әсәр булып сәхнәдә яктыртыла, Тукаебызның «Туган тел»е дә ул вакытта ук гимн булып сәхнәдән яңгырый. Бу әле 1981 ел! Ә инде 1986 елны куелган «Ләйсән ире Хәсән» спектакле берничә сезон буе сәхнәдән төшми уйнала. Тик менә Дамир Сираҗиев тәкъдиме белән язылган «Сукбай артистлар» дөнья күрми кала...

Милли кино сәнгатен үстерү, яңарту юлында да аның эзе бар – 2004 елда, Гаяз Исхакыйның «Зөләйха» әсәренә нигезләнеп, Юныс Сафиуллин сценарие буенча төшерелгән фильм – әнә шуның бер үрнәге.



*«Йосыф һәм Зөләйха» спектаклендә катнашучылар.*

«Кешеләрнең мин бары тик яхшы ягын гына күрәм, начарын алар үзләре дә күрсәтә», – дигән өченче бер акыл иясе. Әле унҗиде яшьлек чагында, театр училищесында укыганда, Юныс Сафиуллинны уйга сала торган бер вакыйга була. «Син, Юнус, икейөзле Янус! Бер йөзең саф күңел, олыларга хөрмәт күрсәтсә, икенче йөзеңдә кирелек, үҗәтлек, беркемгә дә баш бирмәү өстенлек итә», ди аңа курс җитәкчесе. Егет уйланып кала һәм, дәресләр тәмамлануга ук, Януснең кем икәнен ачыклау өчен китапханәгә йөгерә. (Өстәвенә рифмалашып та тора: Юныс – Янус, балачактан шигырь язган егет өчен бу да мөһим.) Борынгы Рим Алласы Янусны «эзләп таба ул», аның хакында язылганнарны, хәтта сурәтен дә, һәм ни гаҗәп, бер як йөзе яшь-яшь, икенче ягы карт кеше йөзе булган бу образ анда кире тәэсир калдырмый, киресенчә, театр символы булган икейөзле битлек-масканы күрә. Хәер, Такташның «ике мине» кемдә генә яшәми икән ул! Син бер төрле уйлыйсың, үзеңчә хыялланасың, ә тормыш синең алдыңда бөтенләй башка яссылыкта ачыла.

Ул Камал театрында озак еллар әдәби бүлек мөдире, бүгенге көндә исә әлеге бүлекнең мөхәррире булып эшли. Бер караганда, биредә Юныс Сафиуллин кебек белемле, тәҗрибәле, күпне күргән кешенең эшләве табигый дә, икенче яктан исә, ах, ничек үз иҗатыңа суга ул кеше язмалары белән эшләү! Моны үзләре гомер буе кулъязмалар белән эшләгән кешеләр генә белә.

Журналыбызда укучыларга тәкъдим ителүче «Йосыф һәм Зөләйха» әсәре дә бүгенге көндә М.Гафури исемендәге Башкорт Академия театрында зур уңыш белән бара.

Бөтен яшәеше, тормышы театр белән бәйле булган, милли сәнгатебезнең үсеше өчен һәрчак янып-көеп яшәгән, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, драматург Юныс Сафиуллин үзе турында менә нәрсәләр ди: «Яшь чагымда йөзем яшь, күңелем карт иде. Бүген исә йөзем карт, ә күңелем яшь-яшь». *(«Мирас», «Үзем турында», 1997, 2нче сан.)* Язучының йөзе – аның әсәрләре. Әсәрләрдә исә – тормыш чынбарлыгы. Яшәеш, чынбарлык үзгәрерме?

**Гөлзадә БӘЙРӘМОВА**

# ТУГРЫЛЫК



Рәшидә Җиһаншина 1917 елның 19 октябрендә Казан шәһәрендә туа. Татар академия театрына 1936 елны Татар театр техникумын тәмамлауга ук килә ул. Хәер, аңа кадәр, әле укыган чагында ук «Беренче чәчәкләр»дә Хәдичә роленә чакыралар аны. Аннан соң «Алар өчәү иде»дә – Сүнмәс ханым... Таҗи Гыйззәтнең «Мактаулы заман» әсәре театрда куелырга җыенганлыктан, әлеге әсәр алар группасының диплом спектакле итеп тә билгеләнелә. Камал III, Х.Уразиков, Х.Сәлимҗанов, Н.Таҗдарова, Г.Камскаялар белән берлектә зур уңыш белән барган спектакль булачак артистларга да уңыш китерә, Людмила роле Рәшидә Җиһаншинаны өметле артистка итеп таныта. Ветеринария фельдшеры Людмиладан башланган роль аңа сәхнәдә М.Горькийның «Дошманнар»ында чибәр, горур Клеопатраны, М.Әмирнең «Миңлекамал»ында эшлекле Миңлекамалны, Т.Миңнуллинның «Канкай углы Бәхтияр»ында данлыклы Әби патша – Екатерина IIне, «Әлдермештән Әлмәндәр»дә тыйнак, итагатьле Хәмдебануны, «Моңлы бер җыр»да Муса Җәлилнең анасы – сабыр, мәрхәмәтле ана Рәхимәне һәм башка бик күп төп рольләрне уйнау югарылыгына күтәрә, Татарстанның һәм Рәсәйнең халык артисткасы исеменә ирешә ул.

Бөек Ватан сугышы елларында театрны яшәтү, саклау да, авылларда йөреп, тылдагыларның күңелен юату да аларның бурычы була, алай гына да түгел, фронтта катнашып, сугышчыларга да концерт-спектакльләр куялар.

Театрларда төрле чаклар була – репертуар ярлылыгы тамашачыга кире тәэсир иткән чорлар да, оештыру сәләтенә ия булган яхшы җитәкчегә кытлык еллар да. Әнә шундый катлаулы бер чорда, инде театрның партоешма җитәкчесе буларак үзен җитәкче итеп күрсәткән Рәшидә Җиһаншина Камал театрына директор итеп билгеләнә. Театр тормышын бөтен тулылыгы, дан-дәрәҗәсе белән аңлаган ханым әлеге вазифада да үзен оста җитәкче итеп таныта ала һәм унбер ел хезмәт куя. Тарихка «юклык заманы» белән кереп калган еллар, билгеле, хатын-кыз җитәкче өчен генә түгел, ир-атлар өчен дә җиңел булмый. Ул директор эшенә алынуга, башка милләт кешеләре дә татар театрына йөрсенгә, синхрон тәрҗемә өчен урындыкларга колак телефоны куюны, ерактагы милләттәшләребезгә дә татар спектакльләрен күрсәтү, артистларны азрак ял иттереп алу максатын да күздә тотып, кояшлы, җиләк-җимешле Алматы, Ташкент шәһәрләренә гастрольләрне оештырып җибәрә. Ул вакытта башланган хезмәттәшлек бүгенге көндә дә мәдәниятара багланышлар булып дәвам итә. 1975 елда Рәшидә Җиһаншина директорлыктан китсә дә, Бөтенсоюз театр җәмгыятенең рәисе вазифасында егерме елга якын хезмәт куя, Татарстан Югары советы депутаты була, 1991 елда театрның өлкән артистларыннан торган «Инсанният» группасын оештыра, пьесалар да иҗат итә, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының үткәнен, аның күренекле артистларының иҗатларын киләчәк буыннарга тапшырып калдыру максатыннан, «Күңелем түреннән» дип исемләнгән истәлекләр китабы яза. Анда без халкыбызның талантлы артисткасы Рәшидә Җиһаншинаның үзе турында: «Мин 50 елдан артык гомеремне театрга багышладым, сәхнәдә 70 яшемне тутырдым, ләкин бервакытта да «уф, ардым, театрдан туйдым», димәдем», дигән сүзләрен укып, аңа театрның никадәрле якын, газиз булганын да тоябыз. Тормыш юлының беренче көннәрен театрдан башлаган талантлы артистка гомеренең соңгы көннәренә кадәр театр дөньясыннан аерылмый.

**Гөлзадә БӘЙРӘМОВА**

# БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫНЫҢ VI СЪЕЗДЫ РЕЗОЛЮЦИЯСЕ

*Казан шәһәре*
*2017 елның 3 августы*

2017 елның 2-3 август көннәрендә Казан шәһәрендә Бөтендөнья татар конгрессының VI съезды булып узды. Анда Татарстан Республикасыннан, Россия Федерациясенең 73 төбәгеннән һәм 41 чит илдән 800 делегат һәм 279 кунак катнашты.

Без, Бөтендөнья татар конгрессының VI съезды делегатлары, түбәндәгеләрне җиткерәбез:

– татар халкының бердәмлегенә, туган телебезне, мәдәниятебезне, гореф-гадәтләребезне саклап калуга һәм үстерүгә, барлык халыклар вәкилләре арасында татулыкны һәм дуслыкны ныгытуга омтылышыбызны белдерәбез;

– Россия Федерациясе җитәкчелегенең халыкара аренада илебез мәнфәгатьләрен яклау курсын, Дәүләт милли сәясәтенең стратегиясен гамәлгә ашыруны тәэмин итүгә, Россиядә яшәүче халыкларның телләрен, мәдәниятләрен, гореф-гадәтләрен саклап калуга һәм үстерүгә, гомумроссия гражданлык үзенчәлеген формалаштыруга юнәлдерелгән программа чараларын хуплыйбыз;

– Сәяси корал кулланып эш иткән Америка Кушма Штатларының Россиягә карата санкцияләр сәясәтен кискен тәнкыйтьлибез, бу Европа илләре белән хезмәттәшлектә тискәре чагылыш таба һәм ясалма рәвештә киеренкелек тудыра;

– Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хакимият органнарының биредә яшәүче халыклар яшәеше өчен уңайлы мохит булдыру һәм республикабыздан читтә яшәүче татарларның этномәдәни үсешенә ярдәм итү буенча эшчәнлеген аерым билгеләп үтәбез;

– хәзерге заманда кискен үзгәрешләр чорында татар халкының этномәдәни үсеш мәсьәләләрен хәл итүдә татар иҗтимагый оешмалары әһәмиятен һәм Бөтендөнья татар конгрессының 25 ел дәвамында татар халкын берләштерү буенча эшчәнлеген хуплыйбыз;

– Россия Тышкы эшләр министрлыгының һәм «Россотрудничество» оешмасының Россия мәдәниятенең һәм башка мәдәниятләрнең аерылгысыз өлеше булып торган татар мәдәниятен популярлаштыру буенча чараларны оештыру һәм уздыруда һәм чит илләрдә яшәүче татар халкын алга таба да берләштерүдә зур ярдәмен билгеләп үтәбез;

– «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү», «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау (2014-2019 елларга)», «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программаларын уңышлы гамәлгә ашыруны таныйбыз;

– дөньядагы барлык татарлар өчен җиде томлык «Борынгы заманнардан алып татар тарихы» дигән хезмәтнең һәм алып барылган гамәли эзләнүләрнең әһәмиятен билгеләп үтәбез;

– фәнни-мәгариф һәм дини-мәгърифәти мөселман үзәге буларак, ата-бабаларыбызның традицион рухи кыйммәтләренә нигезләнеп эшләячәк Болгар ислам академиясен булдыру һәм үстерүне мөһим проект дип саныйбыз;

– «ТНВ-планета» телевидение каналын, «Татар иле» һәм «Ана теле» ресурсларын, «Татар-информ» агентлыгының татар редакциясен үстерүне, Татарстан Республикасыннан читтә яшәүче татарларны татар телен һәм мәдәниятен өйрәтүгә булышлык итә торган «Татар әдәбияты үзәге» интернет-порталын булдыруны хуплыйбыз;

– Бөтендөнья татар конгрессы каршында оештырылган «Ак калфак» Бөтендөнья татар хатын-кызлары оешмасы, Бөтендөнья татар яшьләре форумы, Бөтендөнья татар эшмәкәрләренә ярдәм итү ассоциациясе, «Россиянең татар авыллары» Бөтенроссия иҗтимагый оешмасы, «Татарча көрәш» милли көрәш спорт федерациясе» Бөтенроссия иҗтимагый оешмасы, «Татар гаиләсе» Бөтенроссия иҗтимагый фонды, Бөтентатар төбәк тарихын өйрәнүчеләр җәмгыяте, укытучылар съездлары кебек берләшмәләр һәм халыкның иҗтимагый көчләрен берләштерә торган эшчәнлекнең башка формаларын таныйбыз;

– Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында үзара эшләр бүлешү һәм вәкаләтләр алмашу турында Шартнамәнең мөһим тарихи чорда Татарстанның һәм тулаем Россия Федерациясенең этномәдәни, социаль-икътисади һәм иҗтимагый-сәяси үсешендә уңай роль уйнавына ышануыбызны белдерәбез;

– үзен уңай яктан раслаган югары дәрәҗәдәге дәүләт хакимияте формасы буларак, Татарстан Республикасы Президенты вазифасын саклап калу турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мөрәҗәгатен яклыйбыз;

– татар иҗтимагый оешмаларының татар телен, мәдәниятен һәм халкыбызның гореф-гадәтләрен саклап калу һәм үстерү буенча тырышлыкларын берләштерүне кирәк дип саныйбыз;

– татар оешмаларының башка җәмәгать оешмалары, татарлар күпләп яшәгән илләрнең һәм төбәкләрнең дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары белән тынычлык һәм татулыкны, социаль-икътисади тотрыклылыкны саклап калу һәм барлык халыкларның этномәдәни үсеше өчен уңай шартлар тудыру хакына актив конструктив хезмәттәшлеккә омтылышларын белдерәбез.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнехановның чыгышын, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының хисап нотыгын һәм съездда катнашучыларның чыгышларын тыңлап, бүгенге көндә татар иҗтимагый хәрәкәте үсешенә анализ ясап, Бөтендөнья татар конгрессының VI съезды делегатлары түбәндәгеләр турында карар бирде:

1. Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының V һәм VI съездлары (2012-2017 еллар) арасындагы эшчәнлеген канәгатьләнерлек дип танырга.

2. Киң җәмәгатьчелек катнашында Татар телен һәм татар халкының рухи мирасын саклап калу һәм үстерү платформасын эшләргә һәм кабул итәргә.

3. Татар мөһаҗирлеге музее һәм Татар халкының портрет галереясе

проектларын хупларга, иҗтимагый берләшмәләргә экспонатлар базасын формалаштыру эшенә керешергә.

4. Россия Федерациясе Дәүләт Думасына Россия халыкларының мәдәни һәм тарихи мирасын чагылдырган бәйрәмнәр – татар халкының милли бәйрәме «Сабантуй»ны һәм рус халык бәйрәме «Каравон»ны Кешелекнең матди булмаган мәдәни мирасының репрезентатив исемлегенә кертү максаты белән, ЮНЕСКО Генераль конференциясе тарафыннан 2003 елның 17 октябрендә кабул ителгән Матди булмаган мәдәни мирасны саклау турында конвенцияне Россия тарафыннан ратификацияләү турында мөрәҗәгать белән чыгарга.

5. Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгына түбәндәге мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итәргә:

– милли мәктәпләрдә белем алучы укучыларга Бердәм дәүләт имтиханын туган телдә тапшыру хокукын бирү;

– гражданнарның туган телдә белем алу һәм туган телне өйрәнү хокукын җайга салучы, шул исәптән финанс ягыннан да, норматив-хокукый документ әзерләү зарурлыгы.

6. Россия Федерациясе субъектлары җитәкчеләренә татарларның һәм Россия Федерациясе төбәкләрендә күпләп яшәүче башка халыклар вәкилләренең үз туган телләрен өйрәнүгә конституциячел хокукларын канәгатьләндерү өчен кирәкле шартлар тудыру, шул исәптән тиешле чыгымнарны бюджеттан финанслауны тәэмин итү тәкъдиме белән мөрәҗәгать итәргә.

7. Татарстан Республикасы Хөкүмәтенә түбәндәге мөмкинлекләрне карау тәкъдиме белән мөрәҗәгать итәргә:

– Россия Федерациясенең татар авыллары тарихларын өйрәнүне, аны нәшер итүне «Татар халкының милли үзенчәлекләрен саклау (2014-2019 елларга)» программасына кертү;

– балалар өчен татар телендә белем бирә торган телевидение каналын булдыру.

8. Конгрессның яңадан сайланган җитәкче органына:

– җитешсезлекләрне бетерү һәм съездда катнашучылар тарафыннан әйтелгән тәкъдимнәрне гамәлгә ашыруга юнәлтелгән чаралар комплексын булдырырга;

– этномәдәни үсеш мәсьәләләре һәм татарлар күпләп яшәгән төбәкләрнең дәүләт һәм муниципаль хакимиятләре органнары белән хезмәттәшлекнең иң яхшы тәҗрибәләрен үз эченә алган методик кулланма эшләргә;

– Татарстан территориясендә урнашкан югары уку йортларына Россия төбәкләреннән һәм чит илләрдән ватандаш абитуриентлар кабул итүгә ярдәм итү системасын алга таба үстерергә;

– заманча мәгълүмат технологияләре кулланып, татар милли-мәдәни үзәкләре, мөһим тарихи вакыйгалар, татар халкының гореф-гадәтләре турында кыскача мәдәни белешмә әзерләүне оештырырга.

9. Төбәкләрдә эшләп килүче татар оешмаларына Бөтендөнья татар конгрессы белән берлектә төбәктә яшәүче татар халкының телен, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен саклап калу һәм үстерү буенча активлыкны арттырырга.

10. 2020 елда узачак Бөтенроссия халык санын алуда татарларның төгәл санын дөрес чагылдыру өчен, максатчан эшчәнлек алып барырга.

# ХАЛЫК БЕРДӘМЛЕГЕНДӘ – МИЛЛӘТНЕҢ КӨЧЕ!

## Татар халкына Бөтендөнья татар конгрессының VI корылтаеннан

## МӨРӘҖӘГАТЬ

*Казан шәһәре*
*2017 елның 3 августы*

Кадерле милләттәшләр!

Татар халкының тамырлары тирән. Без – бай мәдәнияткә һәм рухи мираска ия булган дәүләтле халык. Бөтен җиһанга таралган татар халкы һәркайда күрше кавемнәр белән дус, тату яшәргә һәм килешеп-барышып дөнья көтәргә омтыла. Бу – безнең төп үзенчәлек.

Гасырлар аша безгә килеп җиткән телебезне, мәдәниятебезне, гореф-гадәтләребезне саклаган һәм яңа буыннарга җиткергән хәлдә генә без үзебезне бердәм милләт итеп хис итәбез. Кыенлыклар кичереп, уңышларга ирешеп ныгыган татар рухы безне берләштерә һәм бербөтен булып заманча яшәргә булыша.

Татарстан Республикасының яңа дәүләтчелеген булдыру шартларында эш казанып, чирек гасыр дәвамында Бөтендөнья татар конгрессы олы юл үтте. Ул юлның әһәмияте һәм нәтиҗәсе бәһасез. Дөньяның төрле төбәкләрендә яшәүче татарлар, төп үзлекләрен югалтмыйча, үзара берләшә алды.

Көчле һәм уңышлы Россия Федерациясенең булуы татарлар мәнфәгатенә дә туры килә. Ул – безнең дә тарихи Ватаныбыз, күпмилләтле уртак гаиләдә татар халкының да иҗтиһат итәргә тулы хокукы бар. Татарстанның киләсе уңышлары бары тик көчле Россия белән бәйле, һәм шушы хәл татар халкының этник-мәдәни үсешенә нигез булып тора.

Татарстанның уңышлары һәм аерым милләттәшләребезнең төрле өлкәләрдәге казанышы барлык татар халкының дәрәҗәсен үстерә. Уртак уңышларыбызда хезмәт сөючән тырыш кардәшләребезнең генә түгел, безнең белән иңне иңгә куеп, Татарстанда яшәгән башка халыкларның да өлеше бар. Татарстан Республикасы – Россия Федерациясендә танылган лидерларның берсе, һәм ул лаеклы рәвештә халыкара мөнәсәбәтләрдә дә катнаша. Милләтебезнең кодрәтен һәм дөньяда тоткан урынын һәрберебезнең игелекле гамәле билгели.

Гомуми глобальләштерү һәм дөньяви мөнәсәбәтләрнең кискенләшүе татар халкы өчен дә олы сынау булып тора. Мондый шартларда борынгыдан килгән мирасыбызны саклау, арттыру, киләсе буыннарга тапшыру өстәмә кыенлыклар тудыра. Ләкин без телебезнең, мәдәниятебезнең, гореф-гадәтләребезнең, рухи мирасыбызның, тарихыбызның милләтебез яшәешендә нинди әһәмияткә ия булуын аңлыйбыз, шуңа да аларның югалмавы хакына заманча юллар эзләргә тиешбез. Безнең төп максатыбыз – татар милләтенең үзлеген, аңа гына хас йөзен саклау, һәм моның өчен һәрберебез җан-фәрман тырышырга бурычлы.

Кадерле милләттәшләр! Без ышанабыз – бердәм булып, бер максатта тупланып, кайда торсак та, үзара ярдәмләшеп, тарихи һәм рухи ватаныбыз Татарстан белән бер юнәлештә даими хәрәкәт итеп яшәсәк кенә, юлыбыздагы кыенлыкларны җиңәрбез, югары казанышларга ирешербез.

Халык бердәмлегендә – милләтнең көче!

# Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## ПРЕЗИДЕНТ ЮЛЛАМАСЫ

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов Салих Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында ТР Дәүләт Советының 31нче утырышында парламентка еллык юллама белән чыгыш ясады. Аны депутатлардан тыш министрлар, муниципаль район башлыклары, шәһәр мэрлары, предприятиеләр, оешмалар, компанияләр җитәкчеләре, галимнәр, әдәбият-сәнгать әһелләре, руханилар, массакүләм матбугат чаралары вәкилләре, телевидение, радио аша, онлайн режимда турыдан-туры Татарстан халкы тыңлады. Юлламада төп максат итеп республикабыз халкының тормыш дәрәҗәсен күтәрү куелды. Президент сыйфатлы белем бирү, шул исәптән Татарстан Республикасында дәүләт теле буларак татар телен укыту методикасын, укытучылар әзерләүне, аларның белем дәрәҗәсен бәяләүнең яңа объектив алымнарын куллануны кабат төзелә торган Милли педагогия институтында камилләштерү бурычын куйды. Юлламада ТР Милли китапханәсен, универсаль зур концерт залын төзү дә күздә тотыла.

## ИСЛАМ АКАДЕМИЯСЕ АЧЫЛДЫ

Болгар ислам академиясе ачу тантанасы булды. Бәйрәм Татарстан мөфтие Камил Сәмигуллинның Коръән аятьләрен укуы белән башланды. Тантанада ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, РФ Президентының Идел буе федераль округындагы тулы вәкаләтле вәкиле Михаил Бабич (ул РФ Президенты Владимир Путинның әлеге вакыйга уңаеннан котлау телеграммасын укыды) һ.б. чыгыш ясады.

## МӨСЕЛМАН КИНОФЕСТИВАЛЕ

Казанда «Пирамида» мәдәни-күңел ачу үзәгендә XIII Халыкара мөселман кинофестивале ачылды. Анда фестиваль кунакларын һәм тамашачыларны ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов сәламләде. Бәйрәмне рәсми рәвештә Россия Мөфтиләр шурасы рәисе, мөфти Равил Гайнетдин ачып җибәрде.

Быел бәйгедә 27 илдән 60 фильм катнашты. Фестивальдә күрсәтелгән фильмнарга Николай Досталь рәислегендәге 11 илдән килгән 20 кешелек жюри бәя бирде. Җиңүчеләрне 11 номинациядә ачыкладылар. Фестивальнең иң яхшы фильмы – Төркия һәм Венгрия кинематографистлары төшергән «Каландар салкыннары» (Режиссёры – Мостафа Кара). Үзебезнең фильмнардан Илшат Рәхимбайның «Күз алдына китер» фильмы Президентыбыз Рөстәм Миңнехановның «Сәнгатьтә гуманизм өчен» дип исемләнгән махсус бүләгенә лаек булды. Рөстәм Рәшитовның «Тапшырылмаган хатлар»ы Казан мэры Илсур Метшинның махсус бүләген алды.

Фестивальнең ябылу тантанасы М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында узды. Анда ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин катнашты һәм чыгыш ясады.

## ТАКТАШКА – ҺӘЙКӘЛ

Казанда, Һ.Такташ һәм М.Сәлимҗанов урамнары чатында күренекле шагыйрь Һади Такташка һәйкәл (авторлары – Асия Миңнуллина, Андрей Балашов) ачылды. Аны ачу тантанасына ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов килде һәм чыгыш ясады. Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов һәйкәл өчен республикабыз җитәкчеләренә рәхмәт сүзләрен җиткерде. Тантанада ТР Президенты Аппараты җитәкчесе Әсгат Сәфәров, Премьер-министр урынбасары Васил Шәйхразиев катнашты.

## К.ТИНЧУРИННЫҢ ТУУЫНА – 130 ЕЛ

Татар әдәбияты классигы, драматург, режиссёр Кәрим Тинчуринның тууына 130 ел тулу уңаеннан, ТР Фәннәр академиясендә Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе булып узды. Анда катнашучыларны ТР Фәннәр академиясе президенты урынбасары Дания Заһидуллина, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры Ким Миңнуллин, К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры директоры Фәнис Мөсәгыйтов, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рәмис Аймәт сәламләде. Конференциядә унлап доклад тыңланды. Татар дәүләт драма һәм комедия театры бинасында Кәрим Тинчуринга бюст (авторы – Рөстәм Габбасов) ачу тантанасы булды. Анда ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин чыгыш ясады. Тантанада ТР мәдәният министры Айрат Сибагатуллин катнашты. Олуг юбилей уңаеннан ТР Милли музеенда К.Тинчуринның тормыш юлына һәм иҗатына багышланган зур күргәзмә ачылды.

## КОНГРЕСС

Казакъстанның Төркестан каласында төрки журналлар баш мөхәррирләренең VIII конгрессы булды. Анда Татарстаннан «Казан утлары», «Безнең мирас», «Идел», «Мәйдан», «Сувар» журналларының баш мөхәррирләре Илфак Ибраһимов, Ләбиб Лерон, Радик Сабиров, Фидаил Мәҗитов, Константин Малышев катнашты. Алар республикабызда әдәби процессның барышы, үзләре җитәкләгән редакцияләрнең эшчәнлеге турында чыгыш ясады. Әлеге чараның Төркестан каласында узуы аның халыкара «ТЮРКСОЙ» оешмасы тарафыннан 2017 елда төрки мәдәниятләр башкаласы итеп билгеләнүенә дә, бөтен төрки халыкларның күренекле галиме, шагыйрь, дин әһеле Хуҗа Әхмәт Ясәвинең Ватаны булуына да бәйле. Конгресста катнашучылар Чимкент өлкәсе хакиме, Хуҗа Әхмәт Ясәви исемендәге университет галимнәре һәм студентлары белән очраштылар, Хуҗа Әхмәт Ясәви мавзолеенда, шәһәрнең тарихи урыннарында булдылар. Татарстанлылар өчен әлеге конгресс Кентау каласында милләттәшләребез хозурында булу, конгресста Татарстанның халык шагыйре Зиннур Мансуровның «ТЮРКСОЙ» һәм Евразия Язучылар берлеге тарафыннан 2018 төрки әдәбиятлар елы кешесе итеп игълан ителүе белән дә истә калачак.

## АХУН ЧИШМӘСЕ

Татарстанның халык язучысы Гариф Ахуновның туган ягы – Арча районында, кайчандыр Өчиле авылы булган урында әдип хөрмәтенә чишмә ачылды. Мондагы барлык эшләрне «Таттелеком» компаниясе башкарды. Чишмә ачу тантанасына Казаннан Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, берлек әгъзалары Фоат Галимуллин, Зиннур Мансуров, Ләбиб Лерон, Рөстәм Зәкуан, Рифат Җамал, Сания Әхмәтҗанова, Эльмира Шәрифуллина, Вакыйф Нуриев, Наилә Ахунова (Гариф Ахуновның кызы) кайттылар. Алар Казанбаш мәктәбендә яшь иҗатчыларга район хакимиятенең Г.Ахун премияләрен бирү тантанасында да катнашты һәм чыгыш ясады.

## ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ КӨННӘРЕ

Мөслимдә татар әдәбияты көннәре кысаларында, район мәдәният йортында шушы төбәктә туып үскән күренекле шагыйрьләр Зөлфәтнең һәм Наис Гамбәрнең тууына 70 ел тулу уңаеннан искә алу кичәсе үткәрелде. Чарага Казаннан язучылар, сәнгать әһелләре, шагыйрьләрнең туганнары кайтты.

## ОЧРАШУ

Актаныштa Татарстаннан – Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, Башкортстаннан – Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рәшит Зәйнуллин җитәкчелегендә яшь шагыйрьләр делегацияләре очрашты. Алар Әнәктә – ТРның беренче Президенты Минтимер Шәймиевнең, Актаныштa «Туган якны өйрәнү» музейларын карады. Районның Мәдәният сараенда шигърият кичәсе үткәрелде. Анда Татарстаннан – Лилия Гыйбадуллина, Рифат Сәлах, Фәнил Гыйләҗев, Фидаил Мәҗитов, Гөлназ Газизова, Рүзәл Әхмәдиев, Гүзәл Закирова, Гөлүсә Шиһапова, Алсу Сәлахова, Башкортстаннан башкорт шагыйрьләре Айбулат Сәсәнбаев, Гөлнара Хәлфетдинова, Олеся Әхмәтрәхимова, Таңчулпан Рәсүл, Артур Габдуллин, нәфис сүз остасы Артур Төхвәтуллин, курайчы Айдар Байтимеров, татар шагыйре Руслан Сөләйманов, рус шагыйрәсе Кристина Андриянова (Книга), казакъ шагыйре Ильяс Сагынбеков һ.б. катнашты.

## МУЗЕЙ АЧЫЛДЫ

Актаныш районы Качкын төп белем бирү мәктәбендә язучы, галим Фарсель Зыятдинов музее ачылды. Аны ачу тантанасында район башкарма комитетының бүлек җитәкчесе Рөстәм Ильясов, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының мәгариф идарәсе башлыгы Гөлназ Исмәгыйлева, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Расих Сабирҗанов, язучының каләмдәшләре Газинур Морат, Фәйрүзә Мөслимова, Рәдиф Сәгъди, Айгөл Әхмәтгалиева, «Агросила» ЯАҖнең генераль директоры Фәнис Газетдинов һ.б. катнашты.

## А.АЛИШ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЫ

Шагыйрь **Ленар Шәех** «Алдамыйм!» (Татарстан китап нәшрияты, 2014 ел) ТР Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Язучылар берлегенең Абдулла Алиш премиясенә лаек булды. Бу бүләк аңа каһарман шагыйрьнең туган ягында, Спас районы Көек авылы мәдәният йортында, Казаннан бер төркем язучылар катнашында узган бәйрәмдә тапшырылды.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Эзтабар язучы, шагыйрь **Шаһинур Мостафин** «Мамадыш шәһәренең шәрәфле гражданины» исеменә лаек булды.

2017 елның 17 сентябрендә 76нчы яшендә язучы-драматург, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе, М.Җәлил исемендәге республика премиясе лауреаты **Ризван Мирхәбибулла улы Хәмидуллин (Ризван Хәмид)** вафат булды.

2017 елның 24 сентябрендә 78нче яшендә галим, җәмәгать эшлеклесе, публицист, ТР Фәннәр академиясе әгъза-корреспонденты, ТРның Дәүләт премиясе лауреаты **Азат Шәймулла улы Зыятдинов** вафат булды.

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: рассказы Р.ЗАЙДУЛЛЫ, стихи И.ГИЛЯЗОВА, Ф.ЗАМАЛЕТДИНОВОЙ, З.ДАРЗАМАНА, Г.ИБУШЕВА.*
*«Круглый стол» с участием Д.ИСХАКОВА, Ф.ХУЗИНА, И.ЗАГИДУЛЛИНА, Дж.МУХАМЕТШИНА, Р.ХАННАНОВА, К.КАРИМОВА, В.ИМАМОВА. Подготовил И.ИБРАГИМОВ.*
*«Драматургия»: Ю.САФИУЛЛИН. «Юсуф и Зулейха». Мюзикл.*
*«Лучший рассказ»: Р.КАРИМОВА. «Майра».*
*«100-я страница»: Н.НАДЖМИ. «Татарский язык».*
*«Из литературы родственных народов»: стихи К.КУЛИЕВА, с предисловием Р.КУРБАНА.*
*Интервью И.ИБРАГИМОВА с доктором искусствоведения Мухаметгали АРСЛАНОВЫМ.*
*«История»: Л.ХАМИДУЛЛИН. «Родина первых муфтиев».*
*«Воспоминания»: М.ХАРИСОВ. «Учитель стареет рано» (продолжение).*
*«Литературное наследие»: З.ВАЛИДИ. «Воспоминания» (продолжение).*
*«Искусство»: М.АРСЛАНОВ. «Творчество талантливого режиссёра»;*
*статья Г.БАЙРАМОВОЙ, посвящённая 70-летию Ю.САФИУЛЛИНА;*
*Статья Г.БАЙРАМОВОЙ, посвящённая 100-летию со дня рождения Р.ЗИГАНШИНОЙ.*
*Резолюция VI съезда Всемирного конгресса татар.*
*В единстве народа — сила нации! Обращение VI съезда Всемирного конгресса татар к татарскому народу.*
*Из фотоархива журнала.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: «Сююмбике». Картина Ильяса Файзуллина;*
*Мамадыш. Набережная Вятки.*

# IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: stories by R.ZAYDULLA, poems by I.GILYAZOV, F.ZAMALETDINOVA, Z.DARZAMAN, G.IBUSHEV.*
*«Round table» with the participation of D.ISHAKHOV, F.HUZIN, I.ZAGIDULLIN, Dz.MUKHAMETSHIN, R.KHANNANOV, K.KARIMOV, V.IMAMOV. Produced by I.IBRAGIMOV.*
*«Drama»: Yu.SAFIULLIN. «Yusuf and Zuleikha». Musical.*
*«The best story»: R.KARIMOVA. «Mayra».*
*«100th page»: N.NADZHMI. «Tatar language».*
*«From the literature of kindred peoples»: poems by K.KULIEV, with the foreword by R.KURBAN.*
*Interview of I.IBRAGIMOV with Doctor of arts Mukhametgali ARSLANOV.*
*«History»: L.KHAMIDULLIN. «Homeland of the first Muftis».*
*«Memoirs»: M.KHARISOV. «The teacher grows old early» (continued).*
*«Literary heritage»: Z.VALIDI. «Memoirs» (continued).*
*«Art»: M.ARSLANOV. «Creativity of a talented director».*
*Article by G.BAYRAMOVA, dedicated to the 70th anniversary of Yu.SAFIULLIN.*
*Article by G.BAYRAMOVA, dedicated to the 100th anniversary of R.ZIGANSHINA.*
*Resolution of the VI Convention of the World Congress of Tatars.*
*In the unity of the people is the strength of the nation! The appeal of the VI Convention of the World Congress of Tatars to the Tatar people.*
*From the photo archive of the magazine.*
*Diary of social and cultural life.*
*On our covers: «Syuyumbike». Painting by Ilyas Fayzullin;*
*Mamadysh. The Embankment of the Vyatka*

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Сөембикә». *Ильяс Фәйзуллин картинасы.*

*Тышлыкның икенче, өченче битләрендә: Ләбиб Лерон һәм Фидаил Мәҗитов фотолары.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* Мамадыш. Нократ буе.